Җамалетдинов Р.Р.
Нурмөхәммәтова Р.С.

# ТЕЛ ТЕОРИЯСЕ

**КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ**
**Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты**
**Г. Тукай исемендәге милли мәдәният**
**һәм мәгариф югары мәктәбе**
**Гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы**

**Р.Р. ҖАМАЛЕТДИНОВ**
**Р.С. НУРМӨХӘММӘТОВА**

# ТЕЛ ТЕОРИЯСЕ

**Уку-укыту ярдәмлеге**

**КАЗАН**
**2020**

**УДК 81(075.8)**
**ББК 81я73**
**Ж26**

*Казан (Идел буе) федераль университетының*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты*
*Укыту-методик советы*
*(16 март, 2020 ел, 6 нчы номерлы беркетмә)*

*Гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы утырышы*
*(04 март, 2020 ел, 10 нчы номерлы беркетмә)*
*карары белән басыла*

**Рецензент:**
филология фәннәре докторы, профессор **М.З. Зәкиев** (КФУ);
филология фәннәре докторы, профессор **И.С. Насипов** (БДПУ)

**Җамалетдинов Р.Р.**
**Ж26** **Тел теориясе:** уку-укыту ярдәмлеге / Р.Р. Җамалетдинов, Р.С. Нурмөхәммәтова. – Казан: Казан университеты нәшрияты, 2020. – 264 б.

Әлеге уку-укыту ярдәмлегендә «Тел теориясе» фәне буенча лекцияләр курсы өчен теоретик материаллар туплап бирелде. Хезмәтнең максаты – студентларның лингвистик циклдагы фәннәрдән алган белемнәрен гомумиләштерү. Уку-укыту ярдәмлегенә югары уку йортларында укытылган башка тел белеме фәннәрендә каралмаган тел белеме тарихы, тел белемендәге фәнни юнәлешләр һәм мәктәпләр, лингвистик тикшеренү методлары турында мәгълүматлар кертелде.

Уку-укыту ярдәмлеге югары уку йортларының педагогик белем, филология юнәлешләрендә көндезге бүлектә белем алучы IV–V курс студентларына дәресләргә мөстәкыйль әзерләнү өчен ярдәмлек буларак тәкъдим ителә. Хезмәттәге мәгълүматлар тел белеме фәннәрен укытучыларга да файдалы булыр.

**УДК 81(075.8)**
**ББК 81я73**

**© Җамалетдинов Р.Р., Нурмөхәммәтова Р.С., 2020**
**© Казан университеты нәшрияты, 2020**

## Сүз башы

Тел белеменең аерым бер бүлеге буларак “Тел теориясе” (теоретик, яки гомуми тел белеме) кешеләр төрле телләрнең барлыгын, текстны филологик күзлектән тикшерү зарурлыгын, телләрне өйрәнү һәм өйрәтүнең катлаулыгын таныган вакыттан, фәлсәфәчеләр, тел белгечләре һәм мантыйкчылар фикер йөрткән, бәхәсләшкән проблемаларны һәм идеяләрне мирас итеп алып, XIX гасырда аерылып чыга.

Хәзерге көндә тел белеме тарихы тирәнтен эшкәртелгән. Аерым бер телнең тарихын, төзелешен, яшәешен яхшырак аңлау өчен, кеше телләренең барлыкка килү, үсү, төзелү һәм яшәвендәге гомуми законнарын аңларга кирәк, чөнки һәр тел – кешелекнең тел күренешендә бер өлеш кенә. Шунлыктан аерым бер телне (татар, рус, инглиз, испан, япон, кытай һ.б.) өйрәнү теоретик проблемаларны төшенү белән тулыландырыла.

Теоретик тел белеме (уку планнарында бу фән “Тел теориясе” яки “Гомуми тел белеме” дип йөртелә) – тел белеменең телләрнең килеп чыгышы, үсеше, төзелеше һәм яшәешендәге төп закончалыкларны фәлсәфә, нейрофизиология, психология, социология, логика, антропология, этнография, культурология кебек чиктәш фәннәрдә каралучы проблемалар белән тыгыз бәйләнештә өйрәнә торган бүлеге. Ул тел белеменең хосусый бүлекләрендә кулланылучы лингвистик тикшеренү методларын һәм алымнарын эшкәртә, шулай ук лингвистик тикшерү нәтиҗәләрен гамәлдә куллану юлларын ачыклый, гомумиләштерә.

Хәзерге көндә тел белеменең теоретик казанышларын гамәли куллану өлкәләре түбәндәгеләр: туган телләрне һәм чит телләрне тел белгечләре тасвирламаларына таянып өйрәтү; халык тарихын һәм аның мәдәниятен тел фактларына (сүзләрнең этимологиясенә һәм фразеологизмнарга, сүзлек үсешенең лингвомәдәни анализына) нигезләнеп тикшерү; борынгы текстлар һәм язмаларга расшифровка ясау; телдән сөйләм һәм язуга карап тел шәхесен лингвистик идентификацияләү; текстларның авторларын билгеләү һәм мәгънәләрен шәрехләү; тәэсирле реклама текстлары язу; машина тәрҗемәсе;

автоматлаштырылган системалар (роботлар) өчен сөйләмне синтезлау һәм анализлау системаларын эшкәртү; сөйләм кимчелекләре белән интегүче кешеләрне реабилитацияләү; текстларга лингвистик экспертиза ясау һ.б.

Теоретик белемнәр аерым телләрне гамәли яктан өйрәнү нәтиҗәләреннән барлыкка килә. Үз чиратында алар аерым телләрне өйрәнү принципларын һәм алымнарын камилләштерүгә йогынты ясыйлар. Телләрне һәм тел төркемнәрен өйрәнү тел теориясе даими бәйләнештә тора: тел белгечләре телләрдә ачыклаган яңалыклар шунда ук тел теориясенә үтеп керә; һәр яңа теоретик казаныш аерым телләрне өйрәнү практикасын баета, билгеләмәләрдә чагылыш таба, телләрне өйрәнү һәм өйрәтүгә үзгәрешләр кертә.

Әлеге ярдәмлектә туплап бирелгән материал югары уку йортларында бакалаврлар әзерләү максатларына һәм бурычларына туры китереп сайланды, аларда әлеге фәннең интегратив характеры һәм башка фәннәр белән бәйләнеше исәпкә алынды.

Укыту-методик ярдәмлек В.А. Звегинцев, Ф.М. Березин, Н.А. Кондрашов, Т.А. Амирова, Б.А. Ольховиков, Ю.В. Рождественский, Н.В. Боронникова, Ю.А. Левицкий, З.Д. Попова, И.А. Стернин, А.Т. Хроленко, В.Д. Бондалетов, А.А. Горбачевский, Ю.С. Степанов кебек танылган, тел белеменең классикларына әверелгән галимнәрнең хезмәтләренә таянып эшләнде, күп мәгълүмат Интернетта ачык кулланылышта булган тел белгечләренең хезмәтләреннән (Ю.С. Степанов, Л.П. Иванова, Д.Ә. Сәлимова, В.И. Драчева, О.К. Жармакин, Н.А. Козельская, В.Ю. Меликян һ.б.) алынды. Татар тел белеме өлкәсендә нәтиҗәле хезмәт иткән Ә.М. Ахунҗанов, И.Б. Бәширова, М.З. Зәкиев, Ф.С. Сафиуллина, Х.Х. Сәлимов кебек күренекле галимнәрнең эзләнүләре һәм фикерләре дә әлеге китапта урын алды.

Ярдәмлекнең төп эчтәлеге аерым темаларга караган лекцияләр өчен шактый киң күләмдәге теоретик мәгълүматлар бирүне күздә тота һәм студентларга гамәли дәресләргә мөстәкыйль әзерләнү өчен тәкъдим ителә.

*Төзүче-авторлар*

КЕРЕШ

**Лингвистик фән буларак “Тел теориясе”**

Кешеләр бик борынгыдан телнең асылы, төзелеше, кеше теленең хайваннар тавышыннан аермасы, кеше сөйләменең җәмгыятьтә кешеләр куллана торган башка аралашу чараларыннан өстенлекләре турында уйланганнар. Шул рәвешле лингвистика (тел белеме) – тел законнары турында фәнни белемнәр өлкәсе формалаша башлаган. Тел белеме үсеше, фактлар һәм белемнәр туплану белән бергә, телне тикшерү-өйрәнү методлары да камилләшкән. Галимнәргә ярдәмгә статистика, чагыштырмалылык теориясе, тамгалар теориясе һ.б. ярдәмгә килгән.

Европа фәне тарихында тел турында фикерләр шулкадәр төрле һәм каршылыклы ки, аларны логик үсештәге тарихи эзлеклелектә тәртипкә салу мөмкин түгел диярлек. Бу, беренчедән, башка гуманитар фән тармаклары белән чагыштырганда, тел белемендә телнең үзен өйрәнү, тасвирлау бары тел ярдәмендә генә була алуга бәйле. Икенчедән, бу тел белеменең иң борынгы фәннәрнең берсе булу белән дә катлаулана. Ә аның чишмә башын Борынгы Грециядә генә түгел, Борынгы Һиндстанда да, Якын Көнчыгышта да табарга мөмкин.

XX гасыр ахырында күпсанлы бәхәсләр һәм фикер алышулар нәтиҗәсендә тел турында чагыштырмача бердәм күзаллау барлыкка килә: 1) гомумән тел, тамгалар системасының аерым классы буларак тел; 2) аерым, ягъни этник, идиоэтник тел – чынбарлыкта яши торган тамгалар системасы; ул билгеле бер социумда, күпмедер вакыт эчендә һәм ниндидер пространство чикләрендә кулланыла.

Беренче мәгънәсендәге тел – гомумән тел турында, бөтен телләрнең уртак сыйфатлары хакында абстракт күзаллау. Аерым телләр – тел сыйфатларының күпсанлы чагылышы. Тел табигый рәвештә барлыкка килгән һәм закончалыклы рәвештә үсә торган иҗтимагый сыйфатлы тамгалар системасы. Ул аерым индивидка түгел, билгеле бер социумга хезмәт итә. Моның белән бергә, әлеге тамгалар системасына функцияләре һәм кулланыла торган аваз (яңгыраш) материалына бәйле берникадәр чикләүләр дә

салынган. Болар XX гасырда “лингвистик борылышлар” рәте тууга сәбәп була һәм фәндә телнең үзгәрүчән образын барлыкка китерә. **Тел**: 1) табигый тел, кешеләр аралашуында иң мөһим чара; тел фикерләү белән тыгыз бәйләнештә, мәгълүмат саклауда һәм тапшыруда иҗтимагый чара, кешенең үз-үзен тотышы белән идарә итү коралларының берсе; сөйләмдә гамәлгә ашырыла һәм яши; 2) теләсә нинди тамга системасы, мәсәлән, математика теле, кино теле; 3) шул ук стиль.

Телнең күп функцияле булуын күздә тотып, түбәндәге нәтиҗәгә килергә мөмкин: беренчедән, тел ярдәмендә дөньяны танып беләләр; икенчедән, анда шәхеснең үзаңы чагылыш таба; өченчедән, мәгълүмат саклана һәм тапшырыла; дүртенчедән, ул кешенең үз-үзен тотышы белән идарә итә. Әлеге функцияләр телне төрле яктан карарга мөмкинлек бирә, алар гуманитар фәннәрдә төрле юнәлешләр барлыкка китерә. Бу исә фәнни танып белү объекты төзелешенең катлаулылыгы һәм каршылыклы булуы белән бәйле.

Телне төрле яссылыкларда, аспектларда һәм формаларда тикшерүче күпсанлы фәнни концепцияләр корпусы кысаларында аны интегратив өйрәнү мөһим, нәкъ менә ул телне төрле яклап характерлаучы лингвистик, логик һәм фәлсәфи концепцияләрне категориаль һәм методологик синтезлау ысулларын табарга ярдәм итәчәк.

## “Тел теориясе” курсының максатлары һәм бурычлары

“Тел теориясе” – студентларны тел белеме буенча әзерләүне тәмамлый торган курс. Ул студентларның тел белеменә кереш, диалектология, тел тарихы, хәзерге татар яки рус тел белеме, стилистика, сөйләм әдәбе кебек фәннәрдән алган белемнәренә таяна. Әлеге фән эчтәлеге, төзелеше, оештыру принциплары ягыннан “Тел белеменә кереш” курсы белән тыгыз бәйләнгән, хәтта аңа охшаган дияргә дә була. Әмма “Тел белеменә кереш”тә тел фәннәре системасы турында тулаем күзаллау формалаштырылса, “Тел теориясе” кешелек феномены булган телне, аның аерым проблемаларын җентекләп өйрәнүне күздә тота. “Тел теориясе” тел фәлсәфәсеннән гыйбарәт, чөнки анда

тел һәм аралашу, тел һәм фикерләү, тел һәм сөйләм, тел һәм тарих нисбәтләре һ.б. тирәнтен карала.

Тел теориясенең *объекты* – телнең бөтен күләме, функцияләре, төзелеше, яшәеше һәм тарихи үсеше. Гомуми тел белеме алдында торган өч бурычны билгеләргә мөмкин: 1) дөньядагы төрле телләрдә очрый торган типик сыйфатларны ачыклау; 2) семантикада һәм синтаксиста телнең оешуындагы универсаль закончалыкларны билгеләү; 3) күп телләрнең үзенчәлекләрен һәм охшашлыкларын аңлату өчен кулланырдай теория эшкәртү.

Хәзерге тел белемен эчке һәм тышкы лингвистикага бүлү кабул ителгән. Эчке лингвистика телнең системалы-структур оешуын өйрәнүне үз бурычы итеп билгели; ә тышкы лингвистика исә телнең социаль, иҗтимагый проблемаларын өйрәнү белән шөгыльләнә.

Гомуми тел белеме карый торган проблемалар бик киң, болар: 1) телнең асылы һәм табигате; 2) төзелеше һәм эчке бәйләнешләре; 3) тарихи үсеше; 4) функцияләре; 5) тамгалары; 6) төп лингвистик тәгълиматлар тарихы; 7) тел универсалияләре; 8) телне өйрәнү методлары.

Болардан чыгып, тел теориясе фәненең *максаты* түбәндәгечә күзаллана: уку фәне һәм чынбарлык күренеше, фәнни белемнәр объекты һәм предметы буларак телне теоретик аңлау; студентларның гомумлингвистик әзерлеген тирәнәйтү һәм тел теориясенең мөһим проблемалары, лингвистика фәне тарихы һәм лингвистик анализ методлары буенча белемнәр туплау. Әлеге максат телнең эчке төзелешен, яшәү һәм үсеш-үзгәреш принципларын, билгеле бер телдә универсальлек һәм идиоэтниклык нисбәтен аңлауны; шулай ук телнең телдән тыш чынбарлыкка, җәмгыятьтә һәм индивидның аңына мөнәсәбәте турында күзаллауны; фәлсәфи, фәнни һәм милли-мәдәни тел сурәтләре нисбәтен төшенүне үз эченә ала. Бу максатка ирешү студентларны лингвистик фикерләргә өйрәтү һәм аларның лингвистик күзаллавын киңәйтүдән башка мөмкин түгел.

"Тел теориясе" фәне кысаларында хәзерге тел белеме проблемалары гомумтеоретик, методологик һәм гамәли дәрәҗәләрдә карала. Фән буларак ул студентларның тулаем

лингвистик әзерлегенә нәтиҗә ясап кына калмый, тел феномены турында бүгенге көнгә кадәр формалашкан гомуми күзаллауны төшенергә; телнең тамгалар системасы буларак асылын, эчке төзелешен, аның индивид, этнос һәм җәмгыять, фикерләү, мәдәният белән бәйләнешен аңларга; телнең үсеш закончалыклары һәм телне өйрәнү методлары, төп лингвистик юнәлешләр һәм мәктәпләр турында белемнәр тупларга ярдәм итә.

Алда билгеләнгән максатларга ирешү өчен, түбәндәге *бурычлар*ны хәл итү мөһим:

1. Студентларның башка лингвистик фәннәрне өйрәнгәндә формалашкан тел турындагы белемнәрен гомумиләштерү.

2. Тел белеменең башка гуманитар һәм табигать фәннәре белән бәйләнешләрен нигезләү.

3. Студентларны тел турында белемнәрнең хәзерге структурасы белән таныштыру һәм, фән буларак тел белеменең ролен, урынын һәм комплексды характерын билгеләү.

4. Тел белеменең хәзерге методологик проблемалары турында төшенчә бирү.

5. Тел белемендә һәм логикада төрле фәнни юнәлешләр һәм агымнар, төп лингвистик традицияләр турында фикерләр формалаштыру.

6. Кеше эшчәнлегенең фикерләү, танып белү, аралашу кебек төрләре белән тел арасындагы бәйләнешне аңлату.

7. Хәзерге лингвистик тикшеренүләрнең проблемалары, идея һәм юнәлешләре белән таныштыру.

8. Лингистик методлар һәм алымнар турында мәгълүмат белән таныштыру.

9. Студентларның югары уку йортындагы лингвистик тикшеренүләр кысаларында алып барылган мөстәкыйль фәнни эшләре өчен кирәкле теоретик белемнәр нигезен булдыру.

Лингвистик фәннәр циклында йомгаклау курсы буларак, “Тел теориясе” курсы дәвамчанлык принцибына нигезләнә, уку материалын өйрәнү процессында студентларның башка лингвистик фәннәрне үзләштергәндә формалашкан төшенчәле-терминологик аппарат өлкәсендәге лингвистик компетенциясенә, аларның тел фактларын һәм күренешләрен аңлау һәм анализлау күнекмәләренә таяна.

**Тел белеменең төп сораулары**

Башка фәннәр кебек үк, тел белеме дә бер төркем сорауларга җавап табуны максат итеп куя. Бу сораулар үзара тыгыз бәйләнгән һәм алар хосусый тел белеме өчен дә, гомуми тел белеме өчен дә бердәй әһәмиятле. Шулай да кайбер сорауларга бары тик гомуми тел белемендә генә ачыклык керүен билгеләп үтәргә кирәк. Күзаллау яхшырак булсын өчен, аларны төркемләп карау уңышлы.

I. "***Нәрсә?***" проблемасын ача торган төркем. Монда түбәндәге сораулар керә:

- Тел белеменең турыдан-туры объекты *нәрсә*?
- Тел белеме һәм башка фәннәр кызыксына торган уртак өлкәне *нәрсә* тәшкил итә?
- Тел белеменең берәмлеге *нәрсә*?
- *Нәрсә* ул инвариант һәм вариант?
- Тел белемендә кулланыла торган методлар һәм алымнар дигәндә *нәрсә* күздә тотыла?
- Тел белеме тарихындагы фәнни мәктәпләр (юнәлешләр) *нәрсә* аңлата?

II. "***Ничек?***" проблемасы төркеме:

- Тел, гомумән, *ничек* төзелгән?
- Аерым тел берәмлекләре *ничек* төзелгән?
- Тел берәмлекләре үзара *ничек* бәйләнгән?
- Тел халык, җәмгыять тарихы белән *ничек* бәйләнгән? Ул кемгә хезмәт итә?
- Тел *фикерләү* белән ничек бәйләнгән?
- Аерым тел берәмлекләре телдә *ничек*, нинди ешлыкта кулланыла?
- Тел белеме башка фәннәр белән *ничек* бәйләнгән?

III. "***Кайчан?***" проблемалы төркеме:

- Кешеләрнең сөйләме (теле) *кайчан* аңлаешлы була башлаган?
- Теге яки бу тел (диалект) *кайчан* барлыкка килгән?
- Телнең аерым берәмлекләре *кайчан* формалашкан?
- Тел белеме тарихындагы аерым мәктәпләр (юнәлешләр) *кайчан* барлыкка килгән?

IV. “***Нинди шартлар?***” проблемалары төркеменең кайбер сораулары:

- Аралашу актының уңышлы булуы нинди шартларга бәйле?
- Аралашу процессы *нинди шартлар*да бара?
- Тел берәмлекләрен сайлау-куллану *нинди шартлар*га бәйле?
- Җирле диалектлар барлыкка килү һәм яшәү өчен *нинди шартлар* аеруча уңайлы санала?
- Тел белемендәге натуралистик юнәлеш барлыкка килүгә *нинди шартлар* сәбәп булган?

V. “***Ник / нигә?***” проблемалары төркеме:

- Бу тел күренеше *ник* барлыкка килгән?
- Теге яки бу тел күренеше *нигә* кулланылыштан чыккан?
- Әлеге тел күренеше телдә *ник* сакланган?
- Телнең төрле яклары *нигә* төрле тизлектә үзгәрә?
- Чагыштырма-тарихи тел белем *нигә* XIX гасырда гына барлыкка килә?
- Фәнни тикшеренүләрдә *нигә* кайвакыт хаталар күзәтелә?

Әлеге сорауларга җавап эзләү процессында тел турындагы фәннең төп үзенчәлекләрен ачыклау максаты куела.

**Тел универсалияләре**

*Универсалияләр* – дөньядагы бөтен телләргә (абсолют универсалияләр) яки телләрнең күпчелегенә (статик универсалияләр, фреквенталияләр) хас булган тел күренешләре. Гомуми тел белеме тел универсалияләрен билгели һәм формалаштыра. Тел универсалияләрен хәзерге лингвистикада (Россиядә, АКШда) XX гасырның 60 нчы елларында гына тикшерә башладылар. Универсалияләр теориясе эшкәртелә башлауны еш кына Джозеф Гринберг (1915-2001) исеме белән бәйлиләр, әмма телләрдә универсалияләр булу турындагы фикерләр антик заманнарда ук барлыкка килә.

Универсалияләр, бер яктан караганда, күпсанлы телләрне тикшереп анализлау нәтиҗәсендә табыла. Мисал өчен, Дж.Гринберг 30 телне өйрәнеп, 45 универсалияне ачыклый. Икенче яктан, билгеле бер телне тирәнтен анализлау нәтиҗәсендә дә универсалияләр табылырга мөмкин.

Универсалияләр кеше телләренең бердәмлегенә ишарә итә. Аларны төркемләү критерийлары бик күп. Мәсәлән, *телләрне колачлау дәрәҗәсе ягыннан* караганда абсолют һәм статик универсалияләрне аералар. Бер-берсенә ерак торган телләр дә гомуми сыйфатларга һәм билгеләргә ия. Алар арасында телләрнең барысында да тартыклар һәм сузыклар, сүзләр, грамматик формалар, җөмләләр, ялгызлык исемнәр, алмашлыклар һ.б. булуны күрсәтергә мөмкин. Болар – абсолют универсалияләр. Телнең әйтмә һәм язма формаларын, стилистик аерымлану нормаларын статик универсалияләргә мисал итеп китерергә була. Болар бер төркем телләргә генә хас күренешләр.

*Тел материалы ничек тасвирлану*га карап, фонетик, морфологик, синтаксик, семантик универсалияләрне билгелиләр. Мисал өчен,

- фонетик универсалияләр: тартык һәм сузык авазлар, телнең вертикаль хәрәкәте буенча сузыкларның өч күтәрелештә ясалуы;
- морфологик универсалияләр: сүз төркемнәре, грамматик җенес категориясе, сан категориясе;
- синтаксик универсалияләр: барлык телләрдә дә җөмләдә ия һәм хәбәр табыла;
- семантик универсалияләр: һәрбер телдә метафоралар, абстракт күренешләрне сурәтләү өчен кулланылучы физик тоемлауны белдерә торган сүзләр бар; кайбер сүзләр мәгънәләрен киңәйтергә, ә икенчеләре тарайтырга омтыла һ.б.

### Тел belеменең башка фәннәр белән бәйләнеше

Кешелеккә мәгълүм булган барлык фәннәрне ике зур төркемгә бүлеп йөртәләр: иҗтимагый фәннәр һәм табигать фәннәре[1].

*Табигать фәннәре* табигать күренешләренең яшәү һәм үсү закончалыкларын өйрәнә. Аларга география, астрономия, зоология, ботаника, физика, математика һ.б. фәннәр керә. Иҗтимагый фәннәргә җәмгыять турындагы фәннәр, ягъни фәлсәфә, әдәбият, тарих, археография, этнография, психология, логика һ.б. фәннәр карый. Тел – иҗтимагый күренеш, димәк тел

[1] Фәннәрне физика-математика, техник, табигать һәм гуманитар фәннәр дигән төркемнәргә бүлү дә бар.

турындагы фән дә ижтимагый фәннәр рәтенә керә. Ижтимагый фән буларак тел белеменең тарих, икътисади география, психология, педагогика һ.б. фәннәр белән тыгыз бәйләнештә торуы аңлашыла. Гомумән алганда, тел белеме ике төркем фәннәр белән дә бәйләнешкә керә, тик аның әлеге фәннәргә мөнәсәбәте төрлечә. Мәсәлән, тел белеменең антропология белән бәйләнеше сөйләм барлыкка килү мәсьәләләре белән генә чикләнә, ә логика (мантыйк), психология, әдәбият белеме белән бәйләнешләр тирәнрәк. Тел белеменең башка фәннәр белән тыгыз мөнәсәбәттә торуы аның үзенчәлекле мөстәкыйль фән булуына шик тудырмый. Тел белеме фәне телне төрле яклап өйрәнә, ә башка фәннәр исә аны аерым бер яктан гына тикшерә.

Тел белеме һәм әдәбият белеме чигендә *поэтика* – сәнгатьле сөйләм нормалары, язучыларның сәнгать стильләре үзенчәлекләре, язучылар куллана торган сурәтләү чаралары җыелмасы турында өйрәтмә тора. *Стилистика* һәм *әдәби тел тарихы* фәннәре исә бу ике фәннең үзара мөнәсәбәтен тагын да ачыграк чагылдыра.

Тел белеме кешелек җәмгыятенең үсешен өйрәнә торган ***тарих*** фәне белән бәйләнгән булу гаҗәп түгел, чөнки тел тарихы халык тарихының бер өлешеннән гыйбарәт. Телнең сүзлек составы җәмгыять тарихы белән аеруча бәйләнгән. Тел белеме һәм тарих бәйләнеше ике яклы: тарихи мәгълүматлар телдәге конкрет-тарихи үзгәрешләрне ачыкларга ярдәм итсә; тел белеме мәгълүматлары халыкның килеп чыгышын, төрле этапларда мәдәният һәм җәмгыять үсешен, халыклар арасындагы багланышларны өйрәнгәндә төп чыганакларның берсен тәшкил итә.

Аерым алганда, тел белеме *археология* (тарихны матди чыганаклар – хезмәт кораллары, төрле кораллар, бизәнү әйберләре, тормыш кирәк-яраклары һ.б. буенча өйрәнә торган фән) һәм *этнография* (халыкларның көнкүреше һәм мәдәнияте турындагы фән) кебек тарихка бәйле фәннәр белән дә мөнәсәбәттә тора. Тел белеменең этнография белән бәйләнеше диалекталь сүзләрне өйрәнгәндә, телләр һәм халыкларны төркемләгәндә, халык аңының телдә чагылышын тикшергәндә ачык сизелә.

*Археография* фәне борынгы кульязмаларны туплау белән шөгыльләнә, тел ягыннан эшкәртеп бастырып чыгара һәм тарих өчен материал бирә. Галимнәр әлеге язмалар ярдәмендә халыкның тормышын, рухи дөньясын, башка халыклар белән мөнәсәбәтен һәм тел үзенчәлекләрен өйрәнәләр.

*Эпиграфика* фәне кабер ташларындагы язмаларны туплый, өйрәнә. Ул тел белеме һәм тарих өчен кыйммәтле чыганак.

Кешенең сөйләм эшчәнлеге факты буларак тел бер үк вакытта *психология*нең һәм тел белеменең предметы да. Психология фәне күп кенә тел проблемаларын чишүгә үзеннән зур өлеш кертә. Ул сөйләмне барлыкка китерү һәм тоемлау белән бәйле психик процессларны, ягъни телнең психофизиологик механизм белән бәйләнешен өйрәнә. Сөйләү процессы яисә сөйләмне кабул итү һәм аңлау да психологиядән башка аңлатыла алмый. Психология шулай ук баш миенең функцияләре, реаль чынбарлыкның чагылышы кебек психик күренешләрне дә (сизү һәм тоемлау, уй-фикер, тойгы һәм теләкләр, ихтыяҗ һәм кызыксынулар, омтылыш һәм сәләтләр) күзәтә.

Сөйләм максатыннан чыгып формалаштырылган җөмләләрнең һәр төрен (хикәя, сорау, боеру җөмләләр) психологик дәлил итеп алырга мөмкин, чөнки аларда уй-фикерләр, кичерешләр, тойгылар, теләкләр, ягъни кешенең тулы психологик дөньясы тасвирлана. Сүзләрнең күпмәгънәлелеге, шулай ук күчерелмә мәгънәләре (метафора, метонимия, синекдоха) ассоциациянең психологик ягы белән бәйле.

*Психолингвистика* телне кешенең сөйләмен көйли торган динамик, хәрәкәтчән система буларак кабул итә. Аның максаты – сөйләм процессларын һәм механизмнарын (сөйләмне барлыкка китерү, кабул итү) тел системасы белән чагыштырып өйрәнү. Бу фәннең игътибары тел берәмлекләренә (авазлар, сүзләр, җөмләләр һ.б.) түгел, кешегә, аның психологик үзенчәлекләренә, сөйләмне барлыкка китерүгә һәм кабул итүгә, шулай ук телне өйрәнүгә һәм куллануга юнәлдерелгән. Ул индивидның сөйләм эшчәнлеге һәм психофизиологик сөйләм модельләрен булдыру, аларны эксперименталь тикшерү белән шөгыльләнә.

Психолингвистика өйрәнү предметы буенча тел белеменә, ә методлары буенча – психологиягә якын тора.

Психолингвистикада табигый һәм иҗтимагый карашлар янәшә кулланыла. Ул нейролингвистика, когнитив психология, когнитология, информатика, ясалма интеллект теориясе һәм практикасы, социаль психология, социолингвистика, прагмалингвистика, дискурс анализы, шулай ук соңгы елларда барлыкка килгән чиктәш характердагы этнопсихолингвистика, социопсихолингвистика, текст психолингвистикасы һ.б. белән дә тыгыз бәйләнештә тора. Хәзер когнитив психологиядә психолингвистика өйрәнә торган мәсьәләләргә аеруча зур урын бирелә. Бу уңайдан кайбер галимнәр алга таба психолингвистка мәсьәләләрен тулысы белән когнитив психология үзенә алырга мөмкин дигән шик тә белдерәләр.

Натуралистик (биологик) тел белеме яссылыгында психология, лингвистика һәм нейрология (нейрофизиологиянең бер бүлеге буларак) чикләрендә тагын ***нейролингвистика*** дип исемләнгән фән дә яшәп килә. Бу фән сөйләм кимчелекләре һәм баш мие тышчасының функциональ үзәкләре арасындагы корреляцияне өйрәнә. Нейролингвистика нәтиҗәләре сөйләмне барлыкка китерү һәм аңлау механизмнарына төшенүдә мөһим урын алып тора. Әлеге фәндә афазияләргә аеруча зур игътибар бирелә. Афазия – баш миенең сөйләм зоналары җәрәхәтләнү белән бәйле сөйләм кимчелекләре. Афазияләрнең төрләре: а) динамик афазия (семантик дәрәҗәдәге кимчелекләр, ягъни сөйләмнең мәгънә схемасын төзүдәге кыенлыклар белән бәйле очрак); ә) синтаксик афазия, аграмматизм (синтаксик дәрәҗәдәге кимчелекләр, ягъни сөйләмнең грамматик яктан проблемалы булуы); б) эфферент мотор афазия (мотор дәрәҗәсендәге кимчелекләр, ягъни сөйләмнең мотор кинетик төзелешендәге кыенлыклар). Булуы ихтимал барлык сөйләм кимчелекләрен – афазияләрне өйрәнү лингвистларга нормаль сөйләмне аңлау өчен генә түгел, бәлки тел төзелешен һәм аның яшәешен өйрәнү өчен дә күп мәгълүмат бирә.

Тел белеме *педагогика* белән дә бәйләнгән, телне укыту методикасы кебек хосусый дидактик фән гамәли тел белеменең бер бүлеге буларак карала. Телгә өйрәтү методикасында тел белеме, психология һәм педагогика нигезләре дә бар. Хәзерге

методика туган телгә өйрәтү методикасын гына түгел, ә чит телгә өйрәтү методикасын да үз эченә ала.

XX гасыр башында тел белеме белән чиктәш тагын бер фән – *лингвосемиотика* барлыкка килә. *Семиотика* (грекча “тамгалар турында өйрәтмә”) барлык тамгаларны, аларның гомуми үзенчәлекләрен өйрәнә: телеграф коды, флаглы сигнализация, юл тамгалары (знаклар), хәрби тамгалар, жест телләре һ.б. Табигый тел иң төп һәм аеруча катлаулы классик тамгалар системасы булганлыктан, семиотика телне дә башка тамга системалары белән бергә өйрәнә.

Тел белеменең *фәлсәфә* белән бәйләнеше дә борынгыдан килә. Борынгы Грециядә тел белеме фәлсәфә фәне төпкелләрендә туа, ул антик галимнәрнең космос, табигать һәм кешене бербөтен итеп кабул итүләреннән килеп чыга. Табигать, җәмгыять, кеше һәм аң үсешенең аеруча гомуми законнары турындагы фән буларак фәлсәфә, телне феномен итеп тикшерү өчен, тел белемен гомуми методологик принциплар белән коралландыра. Телнең асылын фәлсәфи аңлау тел белеме өчен мөһим һәм файдалы. Шул ук вакытта, фәлсәфәдә дә телнең фикерләү һәм танып белү коралы булу мәсьәләсе әһәмияткә ия.

Башка фәннәр белән чагыштырганда тел белеме фәлсәфә белән ныграк табигый бәйләнештә тора. Фәлсәфә тел белеменең үсеше өчен уңай шартлар булдыра; ул тел белемендәге төп проблемаларның (телнең асылы, роле, үсеше, килеп чыгышы, телнең формасы һәм эчтәлеге) чишелеш юлларын күрсәтә.

Фәлсәфә – дөньяга караш ул. Фәлсәфә кешенең дөньяда тоткан урынын, кеше аңының нәрсә икәнлеген билгели, материянең, табигатьнең, чынбарлыкның һәм аңның нинди тәртиптә булуы хакында фикер йөртә. Соңгысы тагын да әһәмиятле, чөнки аның ни рәвешле чишелеше төрле нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Кешенең фикерләве тел ярдәмендә тормышка ашырылганга күрә, фәлсәфә, һичшиксез, уйлау процессының телдә ничек чагылуын, ягъни кешенең әйләнә тирәсендәге чынбарлыкны танып белү мәсьәләсен урап уза алмый.

Тел шулай ук *логика* (мантыйк) фәненең дә өйрәнү предметы. Билгеле булганча, логика – фикерләү берәмлекләрен (төшенчә, фикерләү, нәтиҗә) аңлату формаларын өйрәнә. Логика тел

ярдәмендә фикерләү законнарын ачу белән шөгыльләнә. Аны фикернең формасы, төзелеше җәлеп итә. Телче исә, тел законнарын өйрәнә һәм фикерләү законнары аны бары тик телнең төзелешенә мөрәҗәгать иткәндә генә кызыксындыра.

Тел һәм фикерләү категорияләре арасындагы бәйләнеш катлаулы. Тел фактлары күпкырлы, Җир шарындагы телләрнең саны берничә мең, шул ук вакытта фикерләү законнары бөтен кеше өчен дә бер. Логикның һәм телченең уртак максаты – телнең күпкырлылыгын бер уртак фикерләү законына буйсындыру; сүзнең мәгънәсе һәм төшенчә, җөмлә эчтәлеге һәм фикерләү арасындагы уртаклык һәм аермаларны билгеләү.

Тел белеменең *дин* белән бик борынгы һәм тыгыз мөнәсәбәтләренә тукталып үтми мөмкин түгел. Беренче лингвистик метафизик идеяләр дини тәгълиматларга барып тоташа, нәкъ менә алар күп кенә халыкларда тел белеменең барлыкка килүенә этәргеч була. Сүзнең илаһилык идеясе һәм аның чиксез кодрәте (моннан Изге текстларның төрле телләрдәге вариацияләреннән курку килеп чыккан) Борынгы Һиндстанда һәм Борынгы Көнчыгышта тел белеменең үсешенә китерә. Дин тарихында тел мәсьәләләре элек-электән гаять мөһим санала.

Тел, иҗтимагый күренеш булудан тыш, кешенең физиологик төзелеше, баш мие, нерв системасы, сөйләм аппараты белән дә бәйле. Фикер, ә аның белән беррәттән тел дә, кешенең баш миенең эшчәнлеге нәтиҗәсе. Шуңа күрә тел белеме фәне кеше организмын өйрәнә торган фәннәр, аерым алганда *физиология* белән тыгыз элемтәдә тора. Бу бәйләнешләр дә борынгыдан килә. Борынгы һиндлар ук инде авазларны физиологик нигезләрдә тасвирлаганнар. Физиология һәм нейрофизиология сөйләм аппаратының төзелешен, анда сөйләм авазларының ясалышын, ишетү органнары ярдәмендә сөйләм агымын кабул итүне, телнең рефлексы физиологик нигезен өйрәнәләр.

XIX гасырның урталарында, Ч.Дарвинның эволюция теориясе тәэсире белән, лингвистика һәм *биология* фәннәренең тыгыз берләшмәсе оеша, телгә табигый күренеш буларак карау – тел белемендә натуралистик юнәлеш барлыкка килә. Аңа нигез салучы – немец тел белгече А.Шлейхер (1821-1868). XX гасырда

генетик код һәм табигый телнең төзелеш охшашлыгы табылу нәтиҗәсендә, нейролингвистика, биология белән тыгыз берләшеп, үз чикләрен киңәйтә бара.

Тел белеменең *география* белән бәйләнешләре дә шактый нык. Еш кына географик шартлар лингвистик факторларга алхәбәр булып тора: таулы Кавказ яки Памирдагы үзенчәлекләр аз санлы кешеләр сөйләшә торган телләрнең яшәешен билгели; ачык, киң территорияләр, кагыйдә буларак, диалектларның читләшүенә китерә, ә чикләнгән территорияләр, киресенчә, аларны якынайта; диңгезләр һәм океаннар борын-борыннан тел багланышларына киртә булып торганнар һ.б. Лингвистика һәм географиянең үзара бәйләнештә торуы XIX йөз ахырында *лингвогеография* дип аталган гибрид фән туугa сәбәп була. Бу фән телләрнең һәм диалектларның, шулай ук аерым тел күренешләренең территориаль таралышын өйрәнү белән шөгыльләнә. Лексикологиянең бер бүлеге булган топонимика да (төрле географик атамаларны – тау, диңгез, океан, елга, күл, торак пунктлар, урынчалыклар һ.б. исемнәрен өйрәнә) лингвогеографик характерга ия. Мондый атамаларны өйрәнү еш кына кабиләләр таралышы, халыкларның күченүе, төрле чорларда кешеләрнең яшәү рәвеше турында ышанычлы тарихи мәгълүмат бирә.

Тел – физик күренеш буларак кабул ителергә мөмкин булган авазлардан тора. Акустика фәне күзлегеннән чыгып караганда, кеше сөйләменең авазы да табигатьтәге башка авазлар ия булган сыйфатларны йөртә. Бу исә үз чиратында телнең *физика* белән бәйләнешен күрсәтә. Тел белеменең физика, бигрәк тә аның бер бүлеге булган *акустика* белән бәйләнешен борынгы грекларда ук очратырга була, алар сөйләм авазларын яңгыраш ягыннан өйрәнгәннәр. Акустика белән бәйләнеш бүгенге фәндә дә актуаль булып кала һәм бу хәл яңа лингвистик фән – сөйләм авазларын өйрәнүдә приборлар куллана торган *эксперименталь фонетика*ның тууына сәбәп була.

Билгеле булганча, соңгы елларда тел белеменә математикада кулланыла торган төрле методлар керә башлады. Бу исә телнең исәпләүгә һәм дедуктив-математик эшкәртүгә буйсынган сыйфатларын ачыклауда ярдәм итә. XX гасырның 50 нче

елларында математика һәм лингвистика чикләрендә *математик лингвистика* барлыкка килә, ул табигый телләрне тасвирлау өчен формаль аппаратлар эшкәртә. Математик лингвистика телне өйрәнгәндә төрле математик бүлекләрне – статистика, ихтималлык теориясе, күплекләр теориясе, алгебра, математик логиканы файдалана. Математик методларны куллану төрле тел фактларын сан ягыннан өйрәнергә, аларны төркемләргә, ешлык сүзлекләре төзергә, тел берәмлекләренең формаль ярашуын өйрәнергә, сөйләм барлыкка килү һәм аны кабул итү процессларының модельләрен төзергә, математик идеяләрне телне система буларак аңлауда кулланырга, язма текстның кайбер үзенчәлекләрен (авторлык, язылу вакыты һ.б.) ачыкларга ярдәм итә.

Тел белеменә мөнәсәбәттә торган математик дисциплиналар арасында *информатика* да бар, ул телне мәгълүмат саклау, эшкәртү һәм тапшыру чараларының берсе буларак өйрәнә. Лингвистика белән берлектә, информатика мәгълүмати-эзләү системалары һәм автоматлаштырылган идарә системалары эшчәнлеген оештыруны тәэмин итә.

Хәзерге лингвистика *кибернетика* белән дә тыгыз бәйләнгән. Кибернетика – идарә һәм идарә процессларында мәгълүматның урыны турындагы фән. Кибернетика телне кешенең тормыш эшчәнлегенең барлык өлкәләрендә диярлек идарә итү процессларында катнаша торган табигый һәм көчле, үзен-үзе көйли торган мәгълүмат системасы буларак аңларга тырыша. Тел белеменең кибернетика белән багланышлары *инженерия лингвистикасы*н барлыкка китерә, ул телне компьютерларга, текстларны машина белән эшкәртү мөмкинлекләренә һәм кеше тавышларын синтезлауга һ.б. проблемаларга мөнәсәбәттә өйрәнү белән шөгыльләнә.

Шулай итеп, хәзерге тел белеме барлык фәнни өлкәләр белән киң бәйләнешләрдә торган күп тармаклы һәм күп аспектлы фән булып күз алдына килә.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Тел турында бердәм күзаллау кайчан барлыкка килә?
2. Телнең бүгенге фәндәге образын сурәтләгез.
3. “Тел теориясе” курсының максат-бурычлары нидән гыйбарәт?

4. “Тел теориясе” нинди проблемаларга ачыклык кертә?

5. “Тел белеменә кереш” һәм “Тел теориясе” фәннәренең охшаш һәм аермалы билгеләрен әйтегез.

6. Тел белемендә нинди сораулар карала?

7. Тел универсалияләре дип нинди күренешкә әйтәләр?

8. Тел белеме нинди фәннәр белән бәйләнештә тора?

9. Тел белеменең иҗтимагый фәннәр белән бәйләнеше турында сөйләгез.

10. Тел белеменең табигать фәннәре белән бәйләнешен конкрет мисаллар белән исбатлагыз.

## ТЕЛ БЕЛЕМЕНЕҢ КЫСКАЧА ТАРИХЫ

Бүгенге көн тел белеме – тел турындагы фәннең озын тарихи үсеш нәтиҗәсе. Әлеге фән мифлар заманында, трансцендент (“теге дөнья”, кеше аңлап бетерә алмый торган; кеше мөмкинлекләреннән читкә чыга торган) белемнәр хөкем сөргән вакытта барлыкка килә. Ул озак еллар буе филология, фәлсәфә, тарих һәм башка гуманитар фәннәр белән янәшә үсеш ала.

Тел белеме тарихына күз салсак, ул бик үзенчәлекле, авыр юл узган: бер лингвистик юнәлеш башка юнәлешләр белән алмашына, төрле концепцияләр көрәшендә яңа лингвистик фикерләр, телне өйрәнү методлары барлыкка килә, бик күп башка фәннәр белән тыгыз мөнәсәбәтләр урнаша.

Тел турындагы фәннең үсешенә тәэсир иткән күп кенә факторларны билгеләргә мөмкин: планетаның төрле төбәкләрендә төрлечә булган цивилизация дәрәҗәсе, җәмгыятьнең төрле гамәли ихтыяҗлары, әлеге фәннең үсеш логикасы һәм башка фәннәр рәтендә тоткан урыны, теге яки бу фәлсәфи фикерләрнең, фәнни принципларның өстенлек итүе, милли тел традицияләренең тәэсире, аерым галимнәрнең тел турындагы фәнгә карата мөнәсәбәте, керткән өлеше һ.б.

Тел белеменә карата тарихи караш иң мөһим фәнни теорияләрне һәм мәктәпләрне системага салуны һәм каталогын төзүне, фән үсешендәге тарихи этапларны, лингвистиканың алга таба үсеше өчен кирәк булган казанышларга бәя бирүне үз эченә ала. Инде билгеле булган казанышларны бәяләргә булыша торган яңа теорияләр барлыкка килгәндә, фәндә яңа адымнар ясалганда фәнни теорияләрне системалаштыру аеруча мөһим. Барлык фәннәрнең тарихын системага салу үз эченә фәнни теорияне яки фәнни теорияләр җыелмасын туплаган “фәнни традиция”, “мәктәп”, “юнәлеш” кебек терминнар белән эш итүне күздә тота. Мәсәлән, язма телнең гомуми кагыйдәләре барлыкка килү нәтиҗәсендә, галимнәр тел белеме тарихында өч мөһим лингвистик (грамматик) традицияне – кытай, һинд һәм грек-латин традицияләрен аерып чыгара. Тел белемендәге этап, мәктәп, юнәлеш төшенчәләре, фәннең башка этапларыннан, мәктәп һәм юнәлешләреннән аерылып торган, үз вакыты өчен

яңа дип табылган концепцияләрнең мөһимлеген ачыклаган, тел белеменең алга таба үсешен күзаллаган актуаль белемнәрне, фикерләрне күз алдында тота. Моның белән беррәттән, “фәнни мәктәп” төшенчәсе фән белән шөгыльләнүче бер төркем галимнәрне түгел, ә бәлки теге яки бу тел теориясе үзенчәлеген нигезләүчеләрнең бер гомуми фикер, фәнни модельләштерү методы нигезендә берләшүләрен аңлата. Мәсәлән, чагыштырма-тарихи тел белеме телне генетик кардәшлек дип санаса һәм аның килеп чыгышын аңлату белән шөгыльләнсә, логик мәктәп вәкилләре исә, телнең фикерләү өлкәсенә караганлыгын исбатларга тырышып, телдә гомумилекне табу белән һәм, телне милли тел формасы белән бәйләп, шәхсилекне эзләү белән шөгыльләнә; психологик юнәлеш вәкилләре төп игътибарларын тел һәм фикерләү арасындагы мөнәсәбәтне, тел фактларының семантик ягын җентекләп өйрәнү мәсьәләләренә юнәлтә.

Тел белеме үсешендә, тарих белән бәйле рәвештә, берничә этап бүлеп чыгарыла. Ләкин ул этапларны билгеләүдә телчеләр уртак фикердә түгел. Бу каршылыклар, нигездә, тел белеме тарихының максаты һәм өйрәнү предметы, чорларга бүлү принципларының төрлелеге, шулай ук, төрле этапта тел белеменең эчке логикасы һәм эчтәлегенең төрлечә аңлатылуы белән бәйле.

Тел белеменең тарихын чорларга бүлүнең бер төре тел теориясе типларына нигезләнә. Бу типлар исә төрле эмпирик материал һәм гамәли кулланылыш нигезендә аерыла. Яңа тип тел теорияләренең пәйда булуы тел белеме үсешендә яңа этаплар барлыкка килү белән бәйле. Бу уңайдан тел белеме тарихында түбәндәгеләргә игътибар ителә:

1) исемләү теориясе (антик чорда фәлсәфи систематика кысаларында барлыкка килгән исемләү кагыйдәләрен билгели торган теория). Әлеге теория тел турындагы специфик белемнәрне күз алдында тотмый, шуңа күрә галимнәр исемләү теориясен тел белеме корпусына кертмиләр, ләкин фәннең камилләшүен аңлау өчен мөһим дип саныйлар;

2) грамматиканың антик традицияләре (Көнбатыш, Көнчыгыш антик һәм урта гасыр грамматиклары тарафыннан тәкъдим ителгән грамматик теорияләрнең барлыкка килүе);

3) универсаль грамматика (фәнни тел белеме барлыкка килүнең беренче этабы, тел системалары гомумилеген өйрәнү һәм яңа заман тел белеме барлыкка килү);

4) өч юнәлешне үз эченә алган чагыштырма тел белеме: а) телнең генетик гомумилекләрен өйрәнү белән шөгыльләнә торган чагыштырма-тарихи тел белеме; б) телләрнең мәдәни-тарихи ягына игътибар итмичә, бары структур типлары белән генә кызыксына торган чагыштырма-типологик тел белеме; в) лингвистика эчендә тел фәлсәфәсен барлыкка китергән һәм гомуми тел белеме теориясе өчен башлангыч булып торган теоретик тел белеме;

5) системалы тел белеме (тел фәлсәфәсе бүлегендә психолингвистика һәм социолингвистика концепцияләренең барлыкка килүе);

6) структур лингвистика (телнең эчке төзелешен өйрәнү, башка тамга (знак) системалары белән мөнәсәбәт урнаштыру; лингвистик методлар һәм методикалар теориясе формалашу, лингвистик модельләштерү өчен нигез барлыкка килү).

Күренгәнчә, әлеге бүленештә төгәл хронологик чикләр билгеләнмәгән, бу исә үз чиратында, элементлар системасына билгесезлек өсти һәм төрлечә аңлау-аңлатуга урын калдыра.

Фәнни тел белеменең башлангыч ноктасы итеп 1660 елны, ягъни беренче универсаль грамматика дөнья күргән елны атыйлар. Кайбер галимнәр исә, аның соңрак, якынча XIX гасыр башында барлыкка килүен әйтәләр. Алар фикеренчә, нәкъ менә шушы чорда һинд-европа телләрен өйрәнүдә махсус принциплар формалаша һәм чагыштырма-тарихи метод кулланыла башлый. Бу фикер нигезендә, чорларга бүлүдә борынгы чор филологиясеннән башлап, XVIII гасырны үз эченә алган этап аерым күрсәтелергә тиеш була.

Ләкин әлеге чордагы тел белеме өлкәсендәге үзенчәлекләрне җентекләп караганнан соң, бу этапны үз эчендә тагын берничә өлешкә бүлү кирәклеге ачыклана. Чөнки бу чорда тел белемендә төрле юнәлешләр, фәнни мәктәпләр барлыкка килә. Моннан тыш, тел белеме тарихын этапларга бүлүнең әлеге төре, гәрчә дөреслеккә бик үк туры килеп бетмәсә дә, тел белеменең бу тарихи чоры лингвистик кыйммәткә ия түгел һәм тел турындагы

фәннең башлангыч, төп тарихыннан алдагы чор дип табыла. Шул ук вакытта, тел белеме өлкәсендә әле бүген дә актуальлеген югалтмаган проблемалар күтәрелә, лингвистика фәненең терминологиясе тулылана һ.б. Тел теориясе фән һәм, гомумән, цивилизация үсеше белән үрелеп бара, җәмгыятьтәге гамәли ихтыяҗларның үзенчәлекләре белән билгеләнә.

Чорларга бүленеш хронология һәм эчтәлекне исәпкә алу принциплары нигезендә дә башкарыла. Әлеге классификациянең аеруча киң таралган бер төре буенча, тел турындагы фәннең үсешендә түбәндәге этаплар бүлеп чыгарыла:

- борынгы классик филология (V гасырга хәтле булган чорны үз эченә ала);
- урта гасырлар һәм Яңарыш чоры тел белеме (VI-XVI гасырлар);
- XVII-XVIII гасыр тел белеме;
- XIX гасыр тел белеме;
- XX гасыр тел белеме.

Болардан тыш, XX йөз ахыры – XXI гасыр башы тел белеме дә аерым каралырга тиеш.

Әлеге этапларның һәрберсе, төрле үзенчәлекләренә бәйле рәвештә, чорларга, агымнарга, фәнни мәктәп һәм юнәлешләргә бүленә. Мондый гомуми хронологик бүленеш тел белеме фәненең өзлексез үсештә булуы турында сөйли. Тел белеменең санап үтелгән һәрбер этабы үзенә генә хас фәнни мәктәпләрнең, агымнарның, юнәлешләрнең булуын күз алдында тота, фән үсешендәге чираттагы этапларның нигезе булып тора, яңа фикерләрнең барлыкка килүенә һәм камилләшүенә китерә, уңыш-казанышларга бәя бирә һәм лингвистиканың алга атлавын тәэмин итә.

## Борынгы классик филология

Тел белеменең беренче адымнары ук кешеләрнең бер-берсе белән аралашу зарурлыгы нәтиҗәсендә ясалган. Мәгълүм булганча, Борынгы Һиндстанда зур хөрмәткә ия һәм борынгы һиндләр өчен үзенә бертөрле остаз ролен үтәгән изге дини җырлар – Ведалар булган. Бу дини җырларның темалары – дөнья һәм кешенең андагы роле. Ведаларның теле үрнәк

саналган һәм аларны бозарга ярамаган. Ләкин һиндләрнең сөйләм теле бертуктаусыз үзгәреп торган. Бу үзгәрешләр, һичшиксез, Ведаларның теленә дә тәэсир иткән, чөнки алар телдән-телгә күчеп йөргән. Тора-бара Ведалардагы кайбер сүзләрнең мәгънәсе халыкка аңлашылмый башлаган һәм аларның аңлатмасын эшләү ихтыяҗы туган. Борынгы һинд телендәге әлеге процесслар тел белеменең килеп чыгуына башлангыч булган да инде.

Моңа охшаш процесслар Борынгы Грециядә дә барган. Биредә исә җирле халык “Илиада” һәм “Одиссея”нең телен саклап калу һәм аңлату белән мәшгуль булган.

Язу барлыкка килү дә тел белеменең үсешенә берникадәр ярдәм иткән. Халык әсәрләре буыннан-буынга күчкән һәм укучыларны хәрефләрнең язылышын гына түгел, ә бәлки укылыш нечкәлекләрен дә өйрәнергә мәҗбүр иткән.

Ничек кенә булмасын, тел белеме аерым бер акыллы кешенең фикерләве нәтиҗәсендә түгел, ә гади кешенең көндәлек ихтыяҗларын канәгатьләндерү нәтиҗәсендә килеп чыккан.

*Борынгы Һиндстан*да тел турындагы беренче фәнни фикерләүләр б.э.к. IV гасырның икенче яртыларында барлыкка килә. Дөрес, хәзерге көн фән күзлегеннән чыгып карасак, бу фикерләүләр тулы һәм төгәл булмаган.

Ә инде тел белемендә б.э.к. IV һәм III гасырның икенче яртысында булган фикерләүләр чагыштырмача югары булган. Соңрак, XIX гасырда, әлеге фикерләүләр, хезмәтләр, белемнәр Европа галимнәренә чагыштырма-тарихи тел белемен үстерүдә ярдәм иткән.

Борынгы Һиндстан галимнәре арасында б.э.к. IV-III гасырлар тирәсендә яшәгән Панини зур игътибарга лаек. Галимнең хезмәтләре төгәллекләре белән хәзерге галимнәрне дә таң калдыра. Панининың һәм аның шәкертләренең хезмәтләре XIX гасыр филологларына кардәш телләрне чагыштырма аспектта тикшерүләрендә ярдәм итә, борынгы һинд әдәби теле санскритның морфологик һәм фонетик төзелешен күзалларга булыша.

Борынгы Һиндстанда тел өйрәнү, күп очракта, гамәли юнәлештә барган. Борынгы һинд грамматикаларының уңай һәм тискәре яклары нәкъ менә шушы юнәлеш белән бәйле дә инде.

Бу грамматикаларда билгеле бер морфологик яисә фонетик төзелеш җентекләп каралган, ләкин шул ук вакытта укучыга бернинди дә гомумтеоретик чишелеш бирелмәгән.

*Борынгы Греция*дә исә тел белеменең үсешендә бераз башка кыйммәтләргә басым ясалган. Иң элек бу фәнне фәлсәфәчеләр үз кулларына алган. Нәкъ менә грек фәлсәфәчеләренең хезмәтләрендә тел һәм сүзнең табигате турында, сүзнең предметка һәм фикерләүгә мөнәсәбәте хакында карашлар урын ала. Мәсәлән, борынгы грек фәлсәфәчеләрен мондый сораулар борчыган: һәр әйбер үзенең исемен табигате белән бәйле рәвештә аламы икән (“табигатенә күрә” – füsei), яисә предметның исеме кеше тарафыннан ирекле, нигезсез рәвештә, гадәтләргә таянып биреләме (tesei)? Бу турыда бәхәсләр уртак нәтиҗәгә китермәгән. Ләкин шундый темаларга бәйле теоретик бәхәсләр нәтиҗәсендә борынгы грекларның грамматика өлкәсендәге күзаллаулары формалаша. Мисал өчен, данлыклы Платон үзенең “Кратил” дигән хезмәтендә Грециядә беренче тапкыр сүз төркемнәрен барларга тырышып карый – фигыль (rema) һәм исемне (onoma) аера. Бөек грек фәлсәфәчесе Аристотельнең (б.э.к. 384-322 еллар) “Поэтика” һәм “Риторика” дип аталган хезмәтләрендә сүз төркемнәренең тагын да тулы исемлеген күрергә була. Ләкин Платонны да, Аристотельне дә сүз төркемнәре тел берәмлекләре буларак кызыксындырмый, алар өчен бу – бары тик фәлсәфи эзләнүләр нәтиҗәсе.

Алга таба грамматик карашлар бераз үзгәрә, ләкин озак вакыт төгәл һәм ачык кабул ителми. Мәсәлән, Хрисипп һәм Диоген хезмәтләрендә сүз төркемнәренең биш төре турында әйтелә: исем, уртаклык исем (нарицание), фигыль, теркәгеч, кисәкчә (член). Исем “бердәнбер сыйфатны” күрсәтә (Диоген, Сократ). Уртаклык исем исә уртак сыйфатны белдерә (кеше, ат). Фигыль – хәбәрлекне белдерә (язам, сөйлим). Теркәгечнең килеше юк, ул сүз төркемнәрен үзара бәйли. Кисәкчә (член) – сөйләмнең исемнәрне затка һәм санга бүлә торган кисәге.

Ничек кенә булмасын, Греция тарихының эллинизм чорында (б.э.к. IV-I гасырлар) грамматика фәне, фәлсәфә фәненнән аерылып чыгып, аерым бер тармак барлыкка китерә. Тел аерым бер өйрәнү объекты буларак кабул ителә башлый.

Берничә гасырга (б.э.к. III г. – б.э. V г.) Грециянең фәнни үзәгенә әйләнгән Птолемейлар илендә – Александриядә грамматика тулысынча фәлсәфә фәненең басымы астыннан чыга. Александрия чорының грек филологлары чагыштырмача дөрес төзелгән грамматика булдыралар. Аристарх, мәсәлән, сигез сүз төркемен аерып чыгара. Дионосий Фракийоний исә аерым сүз төркемнәрен тасвирлый. Аполлоний Дисколның синтаксис турындагы хезмәте мәгълүм. Тел белеменең башка тармаклары, шул исәптән, фонетика, ул чор галимнәрендә кызыксыну уятмый.

Шунысы әһәмиятле, борынгы грек фәнендә этимологик эзләнүләр омтылышлар ясала һәм грамматикада “аналогия”, “аномалия” кебек төшенчәләр барлыкка килә.

Борынгы грекларның грамматика өлкәсендәге эзләнүләрен римлылар дәвам иттерә. Алар үз телләре турында күп гасырлар буе җыелып килгән мәгълүматларны греклар тарафыннан төзелгән грамматик схемаларга салалар. Шулай итеп, римлыларның берничә грамматик хезмәте дөнья күрә. Алар арасында Элий Донатның грамматикасы (б.э. IV гасыры) һәм Присцианның Аполлоний Дискол тарафыннан язылган хезмәте ярдәмендә латин телен өйрәнүгә багышланган грамматикасы бар. Рим грамматикалары озак вакытлар дәвамында үрнәк булып тора һәм Көнбатыш Европада урта гасырлар грамматика фәне формалашуга һәм аның үсешенә зур йогынты ясый.

**Урта гасырлар тел белеме**

***Урта гасырлар Европа тел белеме.*** V гасырда Көнбатыш Рим империясенең таркалуы Европа территориясендә христиан диненең киң кулланылышка керүенә сәбәпче була. Дөньякүләм диннәр – бары тик ышанулар гына түгел. Диннәр чынбарлыкны тикшергән фәлсәфәне, җәмгыять һәм дәүләтне өйрәнү белән шөгыльләнгән сәяси фәннәрне, хокук, әхлак, эстетик карашлар системасын да үз эченә ала. Әлеге санап үтелгән юнәлешләр нигезендә исә архитектура, сынлы сәнгать, рәсем сәнгате, әдәбият үсеш ала.

Антик дәүләтләрнең таркалуы, дәүләтләрнең яңа сәяси, икътисади, дини, этик карашлар ярдәмендә күзаллавы

мәдәнияттә генә түгел, хәтта телдә дә эзен калдыра. Бу чорда ике тел өлкәсе бүленеп чыга: тел белемендә һәм иҗтимагый-тел практикасында “дөрес” дип табылган каноник һәм классик телләр (болар барысы да борынгы цивилизация телләре) сферасы һәм “варвар”, “вульгар” телләр сферасы (язусыз яки яңа язулы телләр), болар исә “дөрес түгел” дип табылган телләр.

Каноник текстлар җәмгыятьнең идеологик нигезе була һәм алга таба бөтен белемнең һәм белем эчтәлегенең нигезенә әйләнә.

Кулланышта булган телләрне күзәтүдән һәм анализлаудан баш тарткан, латин грамматикасының абруена басым ясаган урта гасырлар фәне грамматик күренешләргә каршы логик карашны беренче планга чыгара. Грамматиканы өйрәнү логикага буйсына, аның кагыйдәләренә таяна. Аристотельнең фәнни логик-грамматик карашлары да таныла. Әлеге карашлар киләчәктә француз рационалистик фәлсәфәсе тарафыннан хупланган тел белеменең аерым бер тармагы барлыкка килүендә зур роль уйный. Бу тармакның исеме – фәлсәфи (гомуми) грамматика. Аның төп эчтәлеге: конкрет бер телнең сүзләре һәр кеше өчен дә уртак булган төшенчәләрне аңлату асылы һәм алар бу төшенчәләргә буйсына. Ә җөмләләр – һәр кеше өчен дә бер булган фикерләүләрнең нигезе. Бу фикер буенча тел – гомуми логик схеманың бер төре.

Тел белеме өлкәсендә бу чорда телгә карата схоластик карашлар хөкем сөрә, латин телен өйрәнү фән һәм мәгарифтә бердәнбер дөрес юл дип санала. Ул гамәли максат белән – белем алу өчен генә өйрәнелә. Донат һәм Присциан тарафыннан төзелгән латин теле грамматикаларын өйрәнү белемнең югары ноктасы дип санала. Латин грамматикасының кагыйдәләре һәм төшенчәләре гомуми дип билгеләнә һәм башка телләрнең грамматикаларына да күчә. Латин грамматикасы үзе исә акыллылыкның, дөрес сөйләшү һәм язуның үрнәгенә әйләнә.

Донат һәм Присциан грамматикалары укыту өчен кулланыла торган төп дәрес китабы була. Бу китаплар иҗтимагый-тел практикасында каноник латин текстларын аңлау һәм кабатлау өчен кулланыла. Моннан тыш, каноник текстларны җиңелрәк аңлау өчен, әлеге грамматикаларга кушымта буларак глоссарийләр, яки сүзлекләр төзелә. Присциан грамматикасы яңа

тел нормаларын чагылдырган комментарийлар белән тулылана. Тел теориясендә грамматик традиция логистик традициягә урын бирә башлый.

Урта гасырлар тел белемендә логистик юнәлешнең, ягъни логистик грамматиканың барлыкка килүе XI-XII гасырларга карый. Нәкъ менә шушы чорда Европа кешеләре Аристотель хезмәтләре белән таныша, логик фикерләү эшчәнлегенең күп кенә мәсьәләләрен өйрәнә. Бу уңайдан XIII-XV гасырларда эшләнгән Раймонд Луллий (1235-1315) һәм Петр Гелийский хезмәтләре аеруча кыйммәтле. Луллий латин теле нигезендә логик модельләштерү механизмын адекват рәвештә чагылдырган универсаль фәлсәфи тел системасын эшләү кирәклеген әйтә. Гомуми яки универсаль грамматика концепциясе буларак кабул ителгән фәлсәфи грамматика хакындагы фикерләр Гелийский тарафыннан да тәкъдим ителә. Һәр ике галим дә, латин телендәге күренешләргә таянып, барлык телләрнең фактларын да үз эченә алырлык тел схемасы булдырырга омтыла.

Пор-Рояль монастыре аббатлары К.Лансло һәм К.Арно тарафыннан 1660 елда язылган һәм халыкка танылган "Универсаль һәм рациональ грамматика" тел белеме тарихында аеруча зур урын алып тора. Бу хезмәтне фән тарихында Пор-Рояль грамматикасы дип тә йөртәләр. Хәзерге вакытта әлеге грамматика урта гасырлар хезмәте буларак кына каралмый, ул грамматикада теоретик фикерләр уянуын дәлилли торган факт та.

Шулай итеп, урта гасыр Европа тел белеме антик грек-рим тел теориясенә (беренче чиратта, ике телнең – латин һәм грек телләренең грамматик кануннарына) нигезләнә. Шунысын ассызыклап үтәргә кирәк, Европада урта гасырлар лингвистикасында яңалыклар бик аз күзәтелә. Догмачылык һәм схоластика аның мөмкинлекләрен чикли. Борынгы Һиндстан, Греция, гарәп (көнчыгыш) галимнәренең уй-фикерләре урта гасыр догмалары тәэсирендә кыенлыкларга очрый. Борынгы грек һәм латин телләре классик формаларында ярым онытылган хәлгә килә, кулланылышта булган телләр бөтенләй диярлек өйрәнелми, табигый нигезгә таяна торган теоретик эзләнүләр

Инҗил (Библия) белән бәйле буталчык схоластик фикерләүләр белән алмашына.

Һичшиксез, урта гасырлар фән өчен бөтенләй үк файдасыз булмый. Кайбер халыкларның язма телләре һәм әдәбияты үсеш ала. Шулай ук, тел фактлары белән танышу дәвам итә. Сүзләрне тупларга һәм аңлатырга омтылып карыйлар, төрле максатлар өчен һәм күптөрле аңлатмалы сүзлекләр, элифбалар төзелә. Каноник текстларны өйрәнү кысаларында лексикологик һәм этимологик тикшеренүләр бара. Мәсәлән, герменевтика һәм экзегетика фәннәре барлыкка килә. Герменевтика иске яки авыр аңлашыла торган текстларның эчтәлеген аңлата. Монда текстны аңлау телне грамматик тикшерү, вакыт узу белән аңлашылмый башлаган текстларны өйрәнү нәтиҗәсендә ирешелә. Экзегетика исә каноник текстларның килеп чыгу тарихы һәм чынбарлыгы, язылу шартлары белән кызыксына. Һәр ике фән дә текстология, палеография, эпиграфика һәм тел турындагы башка фәннәр өчен нигез булып санала.

***Урта гасырлар гарәп тел белеме.*** Гарәп тел белеме Борынгы Һинд һәм антик тел белемнәре белән турыдан-туры бәйләнештә барлыкка килә, үсә. Гарәп тел белеменең иң югары үсеш ноктасы булып Гарәп Хәлифәлеге чоры (VII-XIII гасырлар) санала. Хәлифәлек күпмилләтле булган, биредәге дәүләт дине – ислам, гарәп теле исә эш, фән һәм дин теле булып саналган. Хәлифәлектә тел өйрәнүгә карата кызыксыну, Һиндстандагы кебек үк, гамәли ихтыяҗлар нигезендә уяна. Болар Коръәнне саклап калу һәм аерым өлешләрен халыкка аңлату, классик гарәп теленең нормаларын булдыру һәм аны диалектларның тәэсиреннән саклау белән бәйле.

Гарәп лингвистик традициясе бердәм гарәп теле турындагы фәннән башлана. Аны өйрәнүне башлап җибәрүче – басралы телче әл-Хәлил ибн Әхмәт (718-791). Ул метрик рәвештә шигырь язу теориясен башлаган, гарәп сүзләренең морфологик төзелешен тасвирлаган шәхес. Әлеге галим “Айна китабы” дип исемләнгән гарәп сүзлеген төзи. Бу сүзлектә сүзләр, тамырдагы тартык авазларның артикуляцион билгеләренә карап, түбәндәге тәртиптә урын алган: бугаз тартыклары, тел тартыклары, теш

һәм ирен тартыклары. Әл-Хәлил ибн Әхмәтнең укучысы, шулай ук басралы галим, грамматик Сибавейхи (VIII г.) исеме шулай ук тел тарихында аерым урын били. Ул “Әл-Китаб” (“Китап”) хезмәтенең авторы. Бу хезмәт шулкадәр тулы һәм төгәл булган, аннан соңгы буын телчеләре Сибавейхи фикерләрен аңлату белән генә шөгыльләнгән.

“Китап”та тел анализының иң мөһим аспектлары аерыла: исем һәм фигыльнең төрләнеше, сүз ясалышы һәм фонетик үзгәрешләр, авазларның артикуляциясе һәм позицион вариантлары һ.б.

Гарәпләр үз вакытлары өчен фонетиканы бик төгәл итеп тасвирлаганнар. Алар авазларны һәм хәрефләрне аера белгәннәр, авазларны тасвирлаганда артикуляцион һәм акустик сыйфатларына да зур игътибар бирелгән. Гарәпләр, Аристотель белән бер фикердә булып, сүзләрне өч лексик-грамматик өлешкә бүлгәннәр: исем, фигыль һәм ярдәмче сүз төркемнәре. Сүз ясалышы өлкәсендә исә, гарәп телчеләре семит телләренә хас булган тамырдагы өч сузыкка дөрес бәя биргәннәр, аффиксация һәм эчке флексияне билгеләгәннәр. Гарәп галимнәренең әлеге фикерләре киләчәктә XVIII-XIX гасыр Европа тел белеменә зур йогынты ясый.

VIII-IX гасырларда тел белеме өлкәсендәге шактый гына мәсьәләләр буенча галимнәр арасында (аеруча ике грамматик мәктәп – Басра һәм Куфа арасында) бәхәсләр дә чыккан. Алар турында Ибн әл-Әнбәри үзенең 121 мәсьәләне яктырткан трактатында язып чыга.

X гасыр башына гарәп тел белемендә төгәл грамматик терминология һәм аңлау-аңлату аппараты формалаша, грамматиканың төп өлешләре системага салына. Лексикография аерым өйрәнү тармагы буларак аерылып чыга. Гарәп лексикографлары күләме буенча зур гына сүзлекләр төзи. Мәсәлән, бу чорда Сагана (1181-1252) тарафыннан тупланган һәм 20 томнан гыйбарәт булган “Дулкыннар ташкыны” (XIII г.) сүзлеге төзелгән. Әл-Фирузабади (1329-1414) тарафыннан XIV гасырда төзелгән 60 томлык “Камус” (“Океан”) дип исемләнгән сүзлек иң популяр хезмәт санала.

Гарәпләрдә телнең барлыкка килүе турында өч төрле караш яшәве билгеле: беренчесе буенча, ул Аллаһ тарафыннан Адәмгә тапшырылган; икенче караш буенча, телнең кулланылышка керүе пәйгамбәрләр белән бәйле; өченчесе нигезендә, телнең кайбер өлешләре генә Аллаһ тарафыннан Адәмгә тапшырылган, алга таба исә ул кешеләр тарафыннан камилләштерелгән.

Гарәп тел белеме тарихында тюрколог Мәхмүд әл-Кашгари (XI г.) аерым урын алып тора. Ул "Диван лөгать әт-түрк" (ягъни, "Төрки телләр җыентыгы") дип аталган күптомлык хезмәт иҗат итә. Бу хезмәтне төрки телләр энциклопедиясе дип йөртәләр, чөнки биредә төрки телләрнең грамматикасы, лексикасы яктыртыла, диалектлардагы аваз охшашлыклары, морфемалар тасвирлана. Европа тел белеме өчен әлеге хезмәт бары тик XX гасыр башларында гына ачыла.

Классик гарәп тел белеме, борынгы һинд һәм антик тел белемнәре кебек үк, гомуми тел белеме фәненең үсешендә зур роль уйнаган.

**Яңарыш чоры тел белеме**

Яңарыш чоры (Италиядә – XIV-XVI гг., Европаның башка дәүләтләрендә – XV-XVI гг.) гуманизмның яңадан алгы планга чыгуы, антик мәдәният нигезләренә игътибар арту, сәнгать, әдәбият, фәннең алга китүе белән бәйле. Бу чорда акыл һәм мәдәният белән бәйле өч юнәлеш үсеш ала: ренессанс, реформация һәм мәгариф. Ренессанс урта гасыр идеологиясе белән араны өзү һәм антик мәдәниятне яңадан ачуны, дини мәдәниятне дөньяви мәдәният белән алмаштыруны аңлата. Реформация Европа илләрендә милли көчләрнең үсүенә ярдәм итә. Мәгариф исә теологияне рационализм фәлсәфәсе һәм фән белән алмаштыра, алар белән Европа халкының бөтен рухи тормышын бәйли.

Тел белемендә исә антик һәм урта гасырларның лингвистик мираслары яңадан карала. Европаның антик дөнья мәдәнияте белән танышуы бары тик күп санлы грек текстларының басылуы һәм аңлатылуы белән бәйле. Антик әдәбият мирасларын бастыруда һәм комментарияләүдә француз гуманистлары Юлий Скалигер (1484-1558) һәм аның улы Иосиф Скалигер (1540-

1609), Роберт Стефанус (1503-1559) һәм аның улы Генрих Стефанус (1528-1598) керткән өлеш гаять зур. Ю.Скалигер өч берлек турындагы законны дәлилли, соңрак әлеге закон классицизмның норматив эстетикасы нигезен тәшкил итә (И.Скалигер “Латин теленең нигезләре турында” дигән китап бастыра, ә Г.Стефанусның “Латин теленең хәзинәсе” дип исемләнгән хезмәте дөнья күрә. Грек теленең тасвирламасы Г.Стефанус исеме белән бәйле, ул “Грек теле хәзинәсе” дигән китап авторы).

Европа илләрендә реформациянең үсеш алуы Тәүратның төрле телләргә тәрҗемә ителүен таләп итә башлый. Шул сәбәпле галимнәр семит телләре (борынгы яһүд теле (Иске тәүрат теле), гарәп теле һ.б.) белән кызыксына башлый. Бу исә, үз чиратында, семит филологиясенең барлыкка килүенә китерә. Изге текстларның төрле телләргә тәрҗемә ителүе Европа филологиясе барлыкка килүгә китерә. Чөнки яңа әдәби телләрнең нигезе турында сораулар туа, аларның грамматик һәм лексик төзелеш үзенчәлекләре ачыклана, диалект һәм әдәби формалары чагыштырыла.

Бөек итальян шагыйре Данте Алигъери (1265-1321), беренчеләрдән булып, халык теле һәм әдәби тел турындагы проблеманы күтәрә. “Халык сөйләме турында” дип аталган трактатында ул яңа милли әдәби телне яклап чыга, милли итальян теленең латинга караганда уңайрак булуын ассызыклый. Аның фикеренчә, итальян теле – “табигый”, ә латин теле – “ясалма” тел. Бу фикерләрен ул “Искиткеч комедия” дип аталган хезмәтендә чагылдыра. Шунысы үзенчәлекле, әлеге хезмәт традиция буенча латин телендә түгел, ә бәлки милли итальян телендә языла.

Китап басу эшендәге техник казанышлар да тел үсешендә гаять зур роль уйный. Басма текстларның барлыкка килүе уку-укыту процессының стандартлашуына, белемнең үсеш алуына, тел коммуникациясенең тизлеге артуга ярдәм итә. Милләт һәм милли дәүләтләр барлыкка килү сәбәпле, җәмгыять “дөрес булмаган” телләрне техника шартларына туры килердәй итеп үзгәртүгә зур көч куя. Яңа тел төзелеше “сөйләм һәм язу бердәмлеге” принцибы буенча тормышка ашырыла.

Кайбер славян дәүләтләрендә китап басу эшенең үсеш алуына белорус мәгърифәтчесе һәм гуманисты Франциск Скоринаның (1490-1541) эшчәнлеге зур этәргеч бирә. Шулай ук ул Тәүратны туган теленә тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнгән.

XIII-XIV гасырларда төрле дәүләтләрдә милли әдәби телләрнең формалашу процессы башланып китә, бу исә, үз чиратында, аларның тиешенчә тасвирлануын таләп итә.

XV-XVI гасырларда венгер, немец, нидерланд, француз, инглиз, кайбер славян телләренең грамматикалары дөнья күрә. Мәсәлән, 1562 елда П.Раме (Рамус) (1515-1572) тарафыннан әзерләнгән француз теле грамматикасы басыла. Француз Петр Статориус-Стойенский 1568 елда латин телендә язылган беренче поляк теле грамматикасын бастыра. 1574 елда исә Мәскәүдәге беренче китап бастыручы Иван Федоровның Львов шәһәрендә “Букварь” дип исемләнгән хезмәте дөнья күрә. Әлеге “Букварь”да иҗекләп уку кагыйдәләре, төрләнеш формалары, шулай ук уку өчен текстлар бирелә. 1596 елда Лаврентий Зизанийның грамматикасы басыла. 1619 елда грамматик традицияләргә зур йогынты ясаган Мелетий Смотрицкий (1577-1633) тарафыннан язылган “Грамматики славенския правилное синтагма” хезмәте дөнья күрә.

1596 елда Россиядә Лаврентий Зизаний тарафыннан төзелгән беренче басма сүзлек дөнья күрә. Ул авторның “Славян грамматикасы”на кушымта буларак эшләнә. Бу сүзлеккә славян текстларыннан алынган һәм рус, украин, белорус телләренә тәрҗемә ителгән 1061 сүз керә.

Яңарыш чоры шулай ук күп кенә географик ачышлар белән дә тарихка кереп калган. Бу ачышлар нигезендә европалылар әлегә кадәр билгесез булган яңа халыклар һәм телләр белән таныша, алар турында мәгълүмат җыя һәм тасвирлый; япон һәм фарсы телләре грамматикалары дөнья күрә, шулай ук индеецлар телләре – кечуа, гуарани, ацтек өйрәнелә. Бу чорга билгеле булган барлык телләрне дә үз эченә алган хезмәтләрнең барлыкка килүе XVI гасырга карый. Әлеге юнәлештә К. Геснер “Митридат” (1555) һәм И. Мегизер “Кырык телгә үрнәк” (1592) хезмәтләре белән таныла. Европаның күпсанлы башка телләр һәм мәдәниятләр белән танышуы, дөньяның күптөрлелеген

аңлау һәм кабул итү, рационализм фәлсәфәсенең барлыкка килүе, бөтендөнья теле турындагы фикерләрнең тууы төрле телләр өчен бер нигез – универсальлекне эзләүгә китерә.

Шулай итеп, урта гасырлар һәм Яңарыш чоры тел белемендә борынгы классик филология фикерләрен камилләштерү дәвам итә. Бу чорда милли телләрнең үзенчәлекләрен туплаган хезмәтләр барлыкка килә. Моның белән беррәттән, дөнья телләре турындагы мәгълүмат байый һәм тел белеменең алга таба үсеше өчен кирәк булган тел материалын туплау прцессы дәвам итә. Әлеге процесслар XVII-XVIII гасырларда тел турындагы фәндә зур үзгәрешләргә китерә.

**XVII-XVIII гасыр тел белеме**

XVII-XVIII гасырлар – Европада милли дәүләтләр барлыкка килү, икътисад һәм рухи эшчәнлектә зур алга китү чоры. Бу чорда фәндә дә, аеруча тел белемендә, үсеш күзәтелә. Яңа шартларда, милли үзаң үсү нәтиҗәсендә, теге яки бу милләт өчен уртак телнең кирәклеге тагын да ачык күренә. Нәкъ әлеге чорда милли телләр дәүләт, хокук, фән, әдәбият һәм мәдәният сфераларына кертелә, латин теле исә кысрыклана башлый. Болар белән беррәттән, бу гасырларда милләтара фәнни-мәдәни аралашуның дә мөһимлеге ассызыклана. Европада яшәүче халыкларның телләрен өйрәнүгә кызыксыну уяна, аларның латин грамматикасы схемаларыннан һәм кагыйдәләреннән арындырылган фәнни тасвирламалары дөнья күрә.

1627 елда украин тел белгече Памва Берынданың “Лексикон словенороссийский и имен толкование” дип исемләнгән хезмәте дөнья күрә. Әлеге хезмәттә барлыгы 6982 сүз була.

1704 елда Федор Поликарповның “Лексикон треязычный” хезмәте басыла. Биредә сүзләр борынгы славян, грек һәм латин телләрендә бирелә.

1789-1794 елларда 4 томлык “Словарь Академии Российской” басыла. Бу хезмәттә 43 меңнән артык рус һәм чиркәү-славян сүзләренең мәгънәсе аңлатыла.

Европаның башка телләре дә үзенең сүзлекләрен булдыра. Мәсәлән, 1612 елда – итальян, 1694 елда француз сүзлекләре дөнья күрә һ.б.

Берьюлы берничә телнең сүзлек составын үз эченә алган хезмәтләр дә барлыкка килә. Шулар арасында рус сәяхәтчесе, табигать фәннәре белгече П.С. Палласның 1786-1791 елларда дөнья күргән дүрт томлык сүзлеге игътибарга лаек. Бу сүзлектә дөньяның 276 телендәге кайбер сүзләрнең мәгънәсе бирелгән. Шундый ук тип сүзлекләргә испан галиме Лоренцо Эрвас-и-Пандура (1800-1804) һәм немец И.Х. Аделунг тарафыннан төзелгән (1806-1807) сүзлекләрне кертергә була. Испан галименең сүзлегендә 300 гә якын, ә немец галименең хезмәтендә 500 ләп телнең сүзләре хакында мәгълүмат тупланган. Һичшиксез, гамәли кулланылыш өчен әлеге сүзлекләр бик үк уңай булмаган. Ләкин фән тарихында моңарчы Европа халкына таныш булмаган күп санлы телләрнең тасвирламасын туплау һәм өйрәнү факты буларак әлеге хезмәтләр югары бәяләнә.

XVII гасырда тел фәлсәфәсендә өч төрле концепция барлыкка килә, әлеге концепцияләрдә инглиз эмпиризмы (Бэкон һәм Локк эшчәнлеге нигезендә), француз рационализмы (Декарт хезмәтләре һәм картезиан фәлсәфәсе – “картезиан” төшенчәсе Декарт фамилиясенең латинча язылышы нигезендә барлыкка килә – Cartesius) һәм Г.В. Лейбницның фәнни-фәлсәфи концепциясе ята.

Тел проблемасы белән бәйле төп фикерләрен Фрэнсис Бэкон (1561-1626) үзенең “Фәннең абруе һәм аны камилләштерү чаралары” һәм “Яңа Органон” дип аталган фәнни хезмәтләрендә чагылдыра. Фәлсәфи грамматика концепциясе нигезендә Бэкон эмпирик танып белү принцибын куллана, чөнки, аның фикеренчә, тикшеренүләр ярдәмендә телнең барлык якларын да карап чыгарга кирәк була. Грамматиканы ул хәреф (эмпирик) һәм фәлсәфи грамматикаларга бүлеп карый. Хәреф грамматикасы телне гамәли өйрәнүдә кулланыла, ә фәлсәфи грамматика сүзләр, предметлар һәм уй-фикерләр арасындагы мөнәсәбәтне өйрәнә. Ф. Бэкон сүзләрне уй-фикерләр һәм төшенчәләр белән мөнәсәбәткә кергән предметларның абстракт билгеләре буларак кабул иткән. Дөньядагы барлык телләрнең чагыштырма грамматикасын булдыру турындагы фикер Бэконга карый, биредә телләрнең уңай һәм тискәре сыйфатлары урын

алырга тиеш булган. Әлеге фикернең максаты – теге яки бу телнең тискәре сыйфатларыннан арындырылган, кешелек дөньясының барлык уй-фикерләрен дә аңлатырдай бер уртак универсаль тел барлыкка китерү.

Тагын бер инглиз фәлсәфәчесе – Джон Локк (1632-1704) исә үзенең "Кеше аңы турындагы тикшерү" дип исемләнгән хезмәтендә сүзләрнең мәгънәсенә зур игътибар бирә һәм әлеге проблеманы телләрнең нигезе белән бәйли. Дж.Локк фикеренчә, кешеләрнең белеме тышкы (тоемлау) һәм эчке (рефлексия) тәҗрибәгә бәйле. Тоемлау ярдәмендә фикерне кабул итеп тә, кешегә җиткереп тә булмый, шуңа күрә фикерне кабул итүче органнар аңлардай тамгалар (знаклар) рәвешендә җиткерергә кирәк. Шундый тамгалар (знаклар) рәтенә Дж.Локк сүзләрне дә кертә. Сүзләр, аның фикеренчә, физик табигатькә ия аерым авазлардан тора. Шул рәвешчә, алар ишетеп тою органнары ярдәмендә кабул ителәләр. Аныңча, сүз – фикернең хисләр ярдәмендә кабул ителә торган билгесе, ә сүзнең мәгънәсе – төшенчәләрне һәм күзаллауларны алмаштырып тору мөмкинлеге.

Рационализм фәлсәфәсе белән фәлсәфи (ясалма) тел барлыкка китерү турындагы фикерләр һәм проектлар тыгыз рәвештә бәйләнгән. Француз фәлсәфәчесе Рене Декарт (1596-1650) рациональ ясалма тел барлыкка китерергә тәкъдим итә. Әлеге телдә барлык сүзләр дә саннар кебек үк төз рәт рәвешендә урнашырга тиеш була. Мондый телдә төшенчәләрнең катлаулы системасы элементар берәмлекләрнең азсанлылыгы белән хәл ителә. Әлеге телнең формасы бик гади булырга тиеш: сүз төзүнең бер генә ысулы була; бозып сөйләү гадәте нәтиҗәсендә килеп чыккан тулы һәм ялгыш формалар бөтенләй булмый; яңа сүз барлыкка китерү яки сүзне үзгәртү процесслары сүзнең тамырына алдан яки арттан кушымчалар ялгау белән чикләнә.

Ясалма тел барлыкка китерү белән бәйле фикерләр шулай ук немец галиме Готфрид Вильгельм Лейбницның (1646-1716) фәнни-фәлсәфи концепциясендә дә чагыла. Ул универсаль логик фикерләү чарасын барлыкка китерергә, фикерләүнең нигезен аңлатырдай гомуми фәнни метод булдырырга тырыша. Г.В. Лейбниц формаль логиканы тәнкыйтьли. Аның фикеренчә, формаль логика фикерләү нигезләрен ачыкламый, ә бары тик

дәлилләү чарасы гына булып тора. Универсаль логик символикага нигезләнгән һәм барлык фикерләү предметлары белән мөнәсәбәткә кергән яңа логика – “фәнни ачышлар сәнгате” булырга тиеш. Әлеге символика табигый телне логик яктан анализлау нәтиҗәсендә барлыкка китерелергә мөмкин. Универсаль символик тел (фәлсәфи тел) турындагы фикерләрен Г.В. Лейбниц иң элек үзенең “Комбинаторика сәнгате турында” дип исемләнгән диссертациясендә чагылдыра.

Ул ясалма тел булдыру өчен комбинатор ысул тәкъдим итә. Әлеге ысул барлык катлаулы төшенчәләрнең гади комбинацияләре булуга нигезләнә. Катлаулы төшенчәләрне гадиләргә әйләндергәндә комбинаторика кагыйдәләренә нигезләнү шарт: беренче рәт терминнары – гади төшенчәләр, икенче рәттәгеләр – гади төшенчәләр пары, өченче рәттәгеләр – өч беренче рәт термины яки ике беренче рәт термины һәм бер икенче рәт термины комбинациясе һ.б. Шулай итеп, барлык катлаулы төшенчәләр мәгънә “атомнарыннан” барлыкка килә, ә фикерләүләр санап чыгарулар белән алмашына. Фикерләү процессы алгебраик үзгәрешләр белән белдерелергә мөмкин. Г.В. Лейбниц язма һәм әйтмә сөйләм өчен формальләштерелгән тел проектын тәкъдим итә, анда хәрефләр һәм авазлар саннар ярдәмендә белдерелә.

Шуны әйтергә кирәк, соңгы 300 ел эчендә 600 гә якын ясалма тел проекты тәкъдим ителгән. Арада иң уңышлысы дип 1887 елда Варшавадагы врач Людвиг Заменгоф тарафыннан уйлап чыгарылган эсперанто теле санала.

Г.В. Лейбниц тарафыннан тәкъдим ителгән универсаль тамгалар (знаклар) системасы өч максатны күз алдында тоткан: 1) халыкара ярдәмче тел вазифасын үтәү; 2) барлык булган яки булырга мөмкин белемне белдерү өчен гади тамгалар (знаклар) системасын үз эченә алу; 3) формаль кагыйдәләр ярдәмендә билгеле булган хакыйкатьтән яңасын булдыру коралы хезмәтен үтәү. Бу фикерләр символика фәненең үсүенә этәргеч була, хәзерге көндә математик логика һәм кибернетика өчен файдалы.

Фәлсәфи универсаль тел булдыру өлкәсендәге эзләнүләр хәзерге көн фәне өчен уңай нәтиҗәләр бирә. Алар теге яки бу төшенчәләр системасын төркемләү принципларын билгеләргә

ярдәм итә, ә бу исә үз чиратында хәзерге көн мәгълүмати системалар теориясенә уңай йогынты ясый. Ясалма тел системаларын булдырырга тырышу нәтиҗәсендә фикерләү модельләре санап чыгыла. Үз чиратында бу казаныш хәзерге көн лингвистик компьютер теориясенең үсешенә этәргеч бирә.

***Гомуми рациональ грамматика.*** XVII гасырда рационализм фәлсәфәсе барлыкка килү белән теге яки бу телнең грамматик күренешләрен логик категорияләрнең бер төре буларак кабул итү очраклары ешая. Грамматикада рационалистик караш гомуми (рациональ) грамматика килеп чыгуга сәбәпче була. Мондый грамматиканы, беренчеләрдән булып, 1660 елда Париж янындагы Пор-Рояль монастыреның галим-монахлары Антуан Арно (1612-1694) һәм Клод Лансло (1616-1695) төзи. Язылу һәм бастырылу урыны буенча аны "Пор-Рояль грамматикасы" дип йөртәләр, ә инде бу грамматиканың чын исеме – "Гади тел белән аңлатылган сөйләм сәнгатенең нигезләрен үз эченә алган гомуми рациональ грамматика; барлык телләрнең бөтен уртаклыкларының һәм аермалыкларының логик аңлатмасы, шулай ук француз теле буенча күпсанлы яңа өстәмәләр". Ләкин лингвистикада аның кыскартылган исемнәре кулланыла: "Гомуми теоретик-тәнкыйди грамматика", "Универсаль һәм рациональ грамматика", "Гомуми рациональ грамматика", "Пор-Рояль грамматикасы".

Хәзерге көн кайбер галимнәр фикеренчә, "Пор-Рояль грамматикасы" белән тел белемендә бөтенләй яңа сәхифә ачыла, чөнки шушы хезмәттән башлап, телне фәнни өйрәнү үсеш ала. Бу чорда табигый телнең төзелешен һәм функцияләрен аңлатырга тырышалар, дөнья телләренең уртак якларын эзлиләр. Моның белән бергә, рациональ грамматика гомуми тел белеменә фән буларак формалашырга да ярдәм итә, телне өйрәнүдә яңа юнәлешләргә юл ача.

"Гомуми рациональ грамматика" грек, латин, борынгы яһүд, француз телләре материаллары нигезендә төзелә. Шулай ук, күпмедер күләмдә итальян, испан, инглиз һәм немец телләре материаллары да анализлана. Ләкин бу чагыштырма грамматика түгел, бу – логик-типологик грамматика. Мондый

грамматиканың максаты – барлык телләр өчен дә уртак булган күренешләрне билгеләү һәм очраган төп аермалыкларны аңлату. Авторлар фикеренчә, югарыда санап узылган телләрне тикшерү башка телләргә дә туры килердәй нәтиҗәләрне ясау өчен җитәрлек булган. Авторларның максаты теге яки бу тел белән бәйле кагыйдәләрне аңлаешлы итеп язу гына түгел, ә бәлки телләрне өйрәнү процессын җиңеләйтү дә. Бу максатка ирешү өчен, язма һәм сөйләм телләре арасындагы семиотик бүленешне узарга кирәк була, бу исә, үз чиратында, бик тиз рәвештә яңа сүзләрнең эчтәлеген аңлау һәм өйрәнүгә ярдәм итә.

Грамматиканың төп максатлары түбәндәгеләр була: 1) сүзләрнең табигатен, төзелешен һәм билгеләрен, алар (сүзләр) арасындагы мөнәсәбәтне, аларның мәгънәләрен өйрәнү; 2) гомуми универсаль тел принципларын билгеләү; 3) телнең төзелеше һәм функцияләренең нигезен тәшкил иткән күренешләрне аңлату; 4) тел категорияләре, күренешләре һәм фикерләү категорияләре арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыклау. Әлеге максатларга ирешүгә тикшерү структурасы да буйсынган. Грамматика фонетика һәм грамматика бүлекләреннән гыйбарәт, һәр бүлек үз эчендә өлешләргә бүленә. Фонетика бүлеге алты өлештән тора. Биредә латин, грек, борынгы яһүд һәм вульгар телләрнең авазлары һәм хәрефләре, шулай ук басым һәм иҗекләргә бүленеш җентекләп карала. Икенче бүлек 24 өлештән тора: беренче 23 өлеш – морфологиягә, ә соңгы 24 нче өлеш синтаксиска карый.

“Гомуми универсаль грамматика” авторлары фикеренчә, телнең дөньядагы төп вазифасы – кешенең баш миендә барган барлык процессларны, хисләрен сүзләр ярдәмендә аңлату. Авторлар сүзне аерым авазлар рәте буларак билгели, соңрак бу аваз рәтләреннән кешеләр тамгалар (знаклар) төзи һәм шулар ярдәмендә фикерләрен аңлата. Сүз, тамга (знак) буларак, ике төрле структурага ия: авазлар тамганың (знакның) – тышкы ягын, ә сүзнең мәгънәләре эчке ягын хасил итә. Сүзләр арасындагы төп аерма шунда: сүзләрнең бер төре – фикернең предметын, ә башкалары фикернең барышын белдерә. Беренче төр сүзләргә субстантивлар, артикльләр, алмашлыклар, сыйфат фигыльләр, бәйлекләр һәм рәвешләр карый, икенчесенә исә

фигыльләр, теркәгечләр һәм ымлыклар керә. Грамматиканың авторлары әлеге сүзләрне анализлыйлар, аларның сөйләм барлыкка китерүдәге ролен һәм урынын билгелиләр.

Шулай итеп, кешелек өчен бер булган логика законнарына таянып, рациональ грамматиканың авторлары барлык телләр өчен дә уртак булган грамматиканың фундаменталь нигезләрен билгеләмәкче булалар. Анда төрле телләр универсаль логик-тел системасының бер төре буларак билгеләнә. Универсаль грамматикада басым ясалган карашлар үзгәрми һәм барлык телләргә карата да кулланыла ала. Нәкъ менә шушы сыйфатлары универсаль грамматиканы конкрет бер тел грамматикасыннан аерып тора да инде.

“Гомуми рациональ грамматика” озак вакыт буена тел теориясен һәм телләрне өйрәнүдә бердәнбер чыганак була, аның кагыйдәләре тел белеменең аксиомаларына әйләнә. Әлеге грамматика Европада 50 ел дәвамында алыштыргысыз роль уйный. XVIII гасырга кадәр язылган барлык хезмәтләрдә дә аның тәэсире чагыла. Төшенчәләрнең универсаль (лексик һәм грамматик) инвариантларын билгеләп, универсаль грамматика төрле телләрнең грамматик формалары һәм сүзләренә ачыклык кертә, моның нәтиҗәсендә исә чагыштырма тел белемен өйрәнүгә юл ачыла. Хәзерге көн тел белеменең лингвистик универсализм һәм тел типологиясе өлкәләрендә универсаль грамматика фикерләре чагылыш таба. Тел универсализмы һәм тел универсалияләре төшенчәләре хәзерге көн тел белемендә дә төп төшенчәләрне тәшкил итә.

***Тел белемендә тарихи һәм чагыштырма карашларның барлыкка килүе.*** XVII-XVIII гасырларда дөньяда яңа ачылган телләрне өйрәнү буенча да эш алып барыла. Географик ачышлар әлегә кадәр билгесез булган телләрне (Африка, Азия, Америка, Австралия телләрен) кулланылышка кертә башлый. Сәяхәтчеләр һәм миссионерлар дөньяның төрле урыннарын тикшереп, теге яки бу халыклар өчен сүзлекләр һәм глоссарийлар төзи башлыйлар, әлеге халыклар телләренең грамматикаларын булдыралар. XVI гасырда ук инде католик миссионерлар тарафыннан мексикан һәм ацтек телләренең грамматикалары

һәм сүзлекләре төзелә. Шул ук гасырда төрек, фарсы, әрмән грамматикалары булдырыла, япон һәм корея телләре турында мәгълүматлар дөнья күрә. XVI гасырда европалылар санскрит турындагы беренче мәгълүматларга тап булалар. XVII гасырда исә Төньяк Америка индеецлары, Һиндстанның дравид телләре, индонезия, кытай һәм манчьжур, Үзәк Африка негрларының телләре өйрәнелә башлый.

Күп кенә илләрдә, мәсәлән, Россия, Франция, Испаниядә күптелле сүзлекләр төзү буенча эш алып барыла. Россиядә 1787 һәм 1789 елларда чыгышы буенча немец сәяхәтчесе, табигать фәннәре белгече булган П.С. Паллас тарафыннан ике томлык “Барлык телләр һәм шивәләрнең чагыштырма сүзлекләре” дип аталган сүзлек дөнья күрә. Әлеге хезмәттә Азия һәм Европадагы 200 телгә караган 185 кә якын сүз урын алган. Әйтергә кирәк, сүзләр исемлеге һәм материалны туплау аңлатмасы Екатерина II булышлыгы белән эшләнгән. 1790-1791 елларда Петербургта чыккан дүрт томлык әлеге хезмәт исә “Барлык тел һәм шивәләрнең әлифба буенча теркәлгән сүзлеге” дип исемләнә һәм инде 276 тел һәм диалектны үз эченә ала. Болар арасына Африкадагы 30 һәм Америкадагы 23 тел керә. 1794 елда Италиядә испан монахы Лоренцо Эрвас-и-Пандура 21 томлык “Галәм идеясе” дип аталган сүзлеген халыкка тәкъдир итә.

XVIII-XIX гасырларда тел белеменә тиз үсеш ала барган табигый фәннәрдән һәм фәлсәфи өйрәнүләрдән яңа фикерләр керә башлый. Әлеге чор фәнендә тарихилык принцибына зур урын бирелә. Тел белемендә исә бу принцип телләрне тарихи нигездә чагыштыру һәм килеп чыгышлары буенча төркемләүдә чагылыш таба. Чагыштырма-тарихи тел белеменең килеп чыгышы, аның формалашуы романтизм фикерләре белән тыгыз мөнәсәбәттә була, бу, беренче чиратта, баба телгә ия булган баба халыкны, аның нигезләрен һәм яшәү формаларын өйрәнүгә нигезләнгән немец романтизмына барып тоташа. Романтизм тәэсире астында барлык мәдәни кыйммәтләрне дә тарихи күзлектән тикшерә башлыйлар. Монда туган тел һәм халык авыз иҗаты да читтә калмый. Романтизм чорында тарихта, әдәбиятта, тел белемендә, беренче чиратта, И. Гердер, В. фон Гумбольдт, Я. Гримм кебек галимнәр тарафыннан халыкчанлык,

милләтчәнлек, рухилык, универсаль һәм гомумкешелек рухы кебек темалар аерым өйрәнелә.

Телләрнең генетик кардәшлеге белән XVI гасырда ук кызыксына башлыйлар. 1538 елда француз гуманисты Г. Постеллусның “Телләрнең кардәшлеге хакында” дигән хезмәте дөнья күрә. Бу телләрне классификацияләүдә беренче адым була. 1599 елда голландияле лингвист И. Скалигер “Европалыларның телләре турында уйлану” дип аталган трактатында Европа телләрен классификацияләргә тырышып карый. Телләрне ул 11 төп төркемгә аера, алар арасында 4 зур тармак (латин, грек, тевтон (немец), славян тармаклары) һәм 7 кече ана телләрне (албан, татар, венгер, фин, ирланд, кимр (бритт), баск телләре) аера. Скалигер фикеренчә, әлеге унбер тел – кардәш булмаган телләр. Литвалы галим М. Литуанус үзенең хезмәтендә литва һәм латин телләрендә охшаш булган 100 гә якын сүзне атап уза. Хорват тел белгече Ю. Крижанич славян теленең беренче классификациясен тәкъдим итә.

Г.В. Лейбниц шулай ук телләрнең кардәшлегенә зур игътибар бирә. Аның фикеренчә, киләчәктә барлык дөнья телләренең дә грамматикалары һәм сүзлекләре төзеләчәк, ә бу исә үз чиратында телләрнең кардәшлек мәсьәләсен һәм классификация проблемасын чишәргә булышачак. Үзенең кайбер хезмәтләрендә ул барлык дөнья телләрен чагыштыру максатын алга сөрә, баба тел һәм тел гаиләләре турындагы сорауларны куя. Дөньядагы барлык телләрне ул ике төп төркемгә бүлә: арамей (семит) һәм яфетит. Яфетит телләрен Г.В. Лейбниц ике төркемчәгә аера: скиф телләре (фин, төрки, монгол, славян телләре) һәм кельт (европа) телләре.

Россиядә XVIII гасыр урталарында бөек М.В. Ломоносов тарафыннан язылган “Россия грамматикасы” (1757) дөнья күрә. Киләчәктә бу хезмәт рус теленең тасвирлама методы формалашуга сәбәпче була.

М.В. Ломоносов (1711-1765) үзенең кайбер хезмәтләрендә славян телләренең кардәшлегенә басым ясый һәм гомумславян телләренә рус, поляк, болгар, серб, чех, словак, венд (лужид) телләрен кертә. Шулай ук ул кардәшлекнең төрле дәрәҗәдә булганлыгын ассызыклый. Мәсәлән, аның фикеренчә, рус һәм

болгар телләренең кардәшлеге, поляк теле белән чагыштырганда, якынрак дип санала. М.Ломоносов, славян һәм башка һинд-европа телләре (балтыйк, герман, грек, латин телләре) арасындагы кардәшлекне дә билгели. Аныңча, славян телләре аеруча балтыйк телләре белән якын.

Славян телләрен системалы рәвештә чагыштырма юл белән тикшерүгә чех тел белгече Иосиф Добровский (1753-1829) нигез сала. Шулай ук аны славян филологиясенә нигез салучы буларак та билгелиләр.

Санскрит белән танышу галимнәр өчен телләрне чагыштырма-тарихи юл белән өйрәнүдә мөһим бер этәргеч була. “Браминнарның изге телләре” турындагы беренче мәгълүматны Европага итальян сәүдәгәре Филиппо Сассети җиткерә. Һиндстаннан язылган хатларының берсендә ул итальян сүзләре белән охшаш булган кайбер санскрит сүзләрен язып җибәрә. Санскрит һәм европа телләре лексикасындагы һәм грамматикасындагы кайбер охшашлыклар галимнәрдә төрле хисләр, фикерләр уята.

Санскритның таралуында Бенгалиядә судья вазифасын үтәгән юрист, көнчыгышны өйрәнү белгече Вильям Джонсның (1746-1794) роле зур. 1784 елда ул Һиндстан халыклары телләрен һәм мәдәниятен өйрәнү өчен “Азият җәмгыяте”н барлыкка китерә. Җәмгыятьне ачкан вакытта Джонс һинд-европа телләренең чагыштырма грамматикасының төп үзенчәлекләре турында сүз алып бара: “Санскрит теле, үзенең борынгылыгына карамастан, үзенчәлекле төзелешкә ия. Ул грек теленнән мөкәммәл, латин теленнән баерак һәм икесеннән дә нәзберегрәк. Шул ук вакытта, санскритның латин һәм грек телләре белән охшашлыклары шулкадәр күп ки, аның килеп чыгышы да болай гына түгел. Бу кардәшлек гаҗәептер, шуңа күрә әлеге телләр белән шөгыльләнгән һәрбер галим бер үк фикергә килә: бу телләр бер нигездән барлыкка килгәннәр һәм бүгенге көндә ул тел юкка да чыккан булырга мөмкин. Кайбер фикерләр буенча, гот һәм кельт телләре дә, башка диалектлар белән катнаш булуларына карамастан, әлеге нигезләргә барып тоташа. Шунысы үзенчәлекле: борынгы фарсы теле дә тамырлары белән нәкъ менә санскрит, латин, грек, гот һәм кельт телләренә барып

тоташа”. Джонс үз фикерләрен аваз охшашлыклары, грамматик анализ яки лексик тикшеренүләр ярдәмендә дәлилләмәгән. Бераз соңрак әлеге эшне башка тел белгечләре ахырына җиткерә.

1808 елда Фридрих Шлегель (1772-1829) үзенең “Һиндлыларның телләре һәм зирәклеге хакында” дип аталган китабын бастыра. Бу китапта ул сүзлек составы һәм грамматик төзелешләре буенча санскрит, латин, грек, фарсы һәм герман телләренең кардәшлеген сурәтли. Романтизм вәкиле буларак, Шлегель санскритны барлык һинд-европа телләренең нигезе дип саный. Аның хезмәтләрендә беренче тапкыр “чагыштырма грамматика” дигән төшенчә кулланыла.

Шулай итеп, чагыштырма-тарихи тел белеме барлыкка килүенең төп шартлары – Европа галимнәренең санскрит белән танышуы, төрле милли мәдәниятләрнең борынгы истәлекләре белән кызыксына башлавы, аларда табигать һәм җәмгыять күренешләренә карата тарихи-эволюцион караш формалашу.

**XIX гасыр тел белеме**

***Чагыштырма-тарихи тел белеме.*** XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башы тел белемендә телләрне өйрәнүдә яңа метод кирәклеге ачык рәвештә сизелә. Бу мәсьәлә немец галимнәре Франц Бопп һәм Якоб Гримм, данияле галим Расмус Раск һәм рус тел белгече А.Х. Востоков кебек күренекле галимнәр тарафыннан чишелеш таба. Аларның хезмәтләрендә төрле телләрнең, беренче чиратта һинд-европа телләренең төзелеше чагыштырма-тарихи аспектта тикшерелә.

Лингвистикада чагыштырма-тарихи юнәлештәге тикшерүләрне башлап җибәрүче Франц Бопп (1791-1867) була. Ул Майнц шәһәрендә дөньяга килә. Гимназиядә укыган чорда ук санскрит, фарсы, гарәп, борынгы яһүд телләрен үзләштерә. 1812-1816 елларда Париж шәһәрендә санскрит истәлекләрен өйрәнә, башка борынгы көнчыгыш телләре белән кызыксына. Ул Берлин университетында эшли (1821 елдан Бопп – көнчыгыш әдәбияты һәм гомуми тел белеме профессоры, ә инде 1829 елдан академик дәрәҗәсенә лаек була).

Үзенең хезмәтләрендә Ф.Бопп ике төп максат куя: 1) һинд-европа телләрен җентекләп тикшерү һәм аларның кардәшлеген дәлилләү; 2) флексияләрнең барлыкка килү серләрен ачыклау.

1816 елда Ф.Боппның "Санскритта төрләнү системасы һәм аның грек, латин, фарсы һәм герман телләре белән чагыштырмасы" дип исемләнгән беренче хезмәте дөнья күрә. Анда Ф.Бопп биш һинд-европа теленең фигыль флексияләрен ачыклый һәм чагыштыра, аларның охшашлыгын телләрнең бер нигездән килеп чыгулары белән аңлата.

Ф.Боппның төп хезмәте – өч томлык "Санскрит, зенд (борынгы иран теле), әрмән, грек, латин, литва, борынгы славян, гот, немец телләренең чагыштырма грамматикасы". Аның беренче томы 1833-1852 елларда дөнья күрә. Ф.Боппның чагыштырма грамматикасы, гомумән, чагыштырма морфология дип кабул ителергә мөмкин, чөнки төп тикшерү материалы – тамырлар ("тамыр теориясе") һәм флексияләр (күпмедер күләмдә фонетик күренешләр дә карала, ләкин ул сүзләрнең морфологик төзелешен тикшерү белән генә бәйле; синтаксис тикшерелми диярлек). Аның "тамыр теориясе" буенча телләр өч төргә бүленә:

- тамырсыз телләр, ягъни, кушыла алган тамырларга ия булмаган ("организмсыз"), грамматикасыз дип табылган телләр, мәсәлән, кытай теле;

- кушылуга сәләтле, бер иҗектән торган тамырлы телләр. Әлеге юл белән һинд-европа телләре үзләренең "организмына", грамматикасына ия була;

- ике иҗекле, фигыль тамырлы телләр. Биредә тамырны тәшкил иткән өч тартык аваз була, мәсәлән, семит телләре.

Ф.Бопп фикеренчә, фигыль формалары сүзнең төп мәгънәсен бирә, алмашлык тамырлар флексия барлыкка китерү нигезе була һәм фигыльнең субъект белдерә торган кушымчасы ролен үти.

Ф.Боппның чагыштырма-тарихи тел белемен үстерүдәге төп юнәлеше – һинд-европа телләренең грамматик структурасында гомуми генетик элементларны системалаштыру, әлеге материалга нигезләнеп, һинд-европа гаиләсенең булуын дәлилләүгә багышланган гомуми теория формалаштыру. Ф.Боппның һинд-

европа телләренең флексияләре белән кызыксынуы чагыштырма-тарихи тел белеме өчен мөһим роль уйный.

Ф.Бопп белән бер чорда, ләкин аңа бәйсез рәвештә, Дания галиме Расмус Христиан Раск (1787-1832) та һинд-европа телләрен чагыштырма-тарихи юл белән өйрәнүне башлап җибәрә. Раск Копенгаген университетын тәмамлый. 1816-1823 елларда, көнчыгыш һинд-европа телләрен өйрәнү өчен, ул Һиндстанга юл тота; Петербург, Мәскәү, Кавказ һәм Персиядә дә була. 1823 елдан Раск – Копенгаген университетының профессоры. Ул 25 телдә җиңел сөйләшә алган; испан, итальян, швед һәм башка телләрнең грамматикалары авторы. 1811 елда Раск үзенең беренче хезмәтен бастыра, ул “Исланд яки борынгы төньяк теле буенча кулланма” дип исемләнә. 1818 елда Раск “Борынгы төньяк телен өйрәнү яки исланд теленең барлыкка килүе” дип аталган төп хезмәтен чыгара. Ләкин Раскның бу хезмәте озак еллар буе халыкка таныла алмый, чөнки дат телен күп кеше аңламый. Әлеге хезмәтендә автор түбәндәге фикергә килә: исланд яки борынгы төньяк теле фракия теленнән барлыкка килгән; ә фракия теле, үз чиратында, көньяк-көнчыгыш Европаның юкка чыккан баба теле буларак кабул ителә. Раск фикеренчә, исланд теленнән грек һәм латин телләре барлыкка килгән. Ул исланд телен гренланд, кельт, баск, фин телләре белән чагыштыра һәм алар арасында кардәшлек булмавын дәлилли. Исланд теленең кардәшлеген ул славян, герман, балтыйк телләре белән бәйли һәм аларны һинд-европа телләре гаиләсенең аерым бер тармагы буларак кабул итә. Телләрне чагыштырганда, Раск грамматиканы һәм лексиканы төгәл рәвештә аерырга тәкъдим итә. Ул грамматик охшашлыкларның һәм борынгы лексик катламның мөһимлеген ассызыклый. Раск фикеренчә, телләрнең кардәшлеген яки бер нигездән килеп чыгуын дәлилли торган төп әйбер – ул грамматик охшашлыклар, чөнки үзара мөнәсәбәткә кергән очракта телләр бик сирәк кенә бер-берсенең төрләнеш (склонение һәм спряжение) формаларын кабул итәләр. Ф.Бопптан аермалы буларак, Раск үзенең хезмәтләрендә чагыштырыла торган телләрнең беренче формаларын китереп чыгаруны максат итеп куймый.

Якоб Гримм (1785-1863) чагыштырма-тарихи метод ярдәмендә телләрнең герман төркемен өйрәнә. Гримм Ганау шәһәрендә дөньяга килә, Марбург университетының юридик факультетында белем ала. Ләкин аны филология юнәлеше кызыксындыра. Ул 1830 елдан Геттинген университетында немец теле кафедрасында эшли башлый, 1840 елда исә Берлин университетының профессоры дигән дәрәҗәгә лаек була. Я.Гриммның эшчәнлеге энесе В.Гримм (1786-1859, әкиятче) белән тыгыз бәйләнгән. Я.Гримм, әкиятләр белән кызыксына, урта гасыр немец әдәбиятын өйрәнү белән дә шөгыльләнә.

Тел белеме тарихына Я.Гримм дүрт томлык “Немец грамматикасы” (1819-1837) дип аталган хезмәте белән кергән. Гомумән, бу – немец теле материалын беренче язма истәлекләрдән башлап анализлауга багышланган беренче тарихи грамматика. Хезмәтнең беренче томы – фонетикага, икенчесе – морфологиягә, өченчесе – сүз ясалышына, дүртенчесе исә синтаксиска багышланган. Я.Гримм, Ф.Бопп һәм Р.Расктан аермалы буларак, әдәби тел белән берррәттән, диалектларга да игътибар бирә.

Я.Гримм конкрет телләрнең һәм, гомумән, кеше теленең яшәешен үзгәрү, камилләшү буларак кабул итә. Һинд-европа телләренең тарихы, аның фикеренчә, әлеге телләр тарихында ике процессның алмашынуын күрсәтә: беренчесе – сүз өлешләренең кушылуыннан флексия барлыкка килү, ә икенчесе – флексия таркалу белән бәйле. Әлеге фикергә таянып, Я.Гримм кеше теленең камилләшүендәге өч баскыч турында яза. Беренче баскыч – тамыр һәм сүзләрнең барлыкка килүе, үсүе һәм камилләшүе. Бу чорда теге яки бу грамматик мөнәсәбәтләр гади сүзләр ярдәмендә белдерелә. Икенче баскыч камилләшкән флексиянең “чәчәк атуы” белән аңлатыла. Әлеге баскычта торган телләргә мисал буларак санскрит, зенд, борынгы грек телләрен атап уза. Бу чорда телләр тәмамланган формага ия, алар шигырь язуга җайлашкан, моңа борынгы һинд һәм борынгы грек шигърияте дәлил булып тора. Тел үсешенең өченче баскычы – фикер ачыклыгына омтылу, бу исә флексиядән баш тартырга мәҗбүр итә. Тел үсешенең әлеге чоры Һиндстанның бүгенге көн телләренә, фарсы, яңа грек, роман һәм күпмедер

дәрәҗәдә герман телләренә кагыла. Бу телләрдә “флексиянең эчке көче һәм сыгылмалылыгы” инде югалган.

Я.Гриммның чагыштырма-тарихи тел белемендә басым ясаган төп юнәлеше – аваз күчешләрен билгеләү: герман телләрендәге тартыкларның аларны башка һинд-европа телләреннән аерып торган беренче күчеше һәм, югары немец диалектын түбән немец диалектыннан, шулай ук немец телен башка телләрдән аерып торган икенче күчеш. Әлеге тикшеренүләр һәм нәтиҗәләр Гримм тарафыннан Раскка бәйсез рәвештә башкарыла. Шунлыктан, бу закончалыкны еш кына Раск-Гримм закончалыгы дип тә йөртәләр.

А.Х. Востоков (псевд.; чын фамилиясе Остенек, 1781-1864) – чагыштырма-тарихи методны славян телләре материалында кулланган беренче галим. Ул эстон шәһәре Аренсбургта дөньяга килә. Яшь чагыннан ук Востоков халык җырларын, мәкальләрен туплау белән шөгыльләнә, рус шивәләрен өйрәнә. Петербургта Кадет корпусында белем ала, соңрак Сәнгать Академиясендә укый. Император ачык китапханәсендә кулъязмалар саклаучысының ярдәмчесе булып эшләгәндә борынгы рус истәлекләре белән танышырга мөмкинлек туа. 1826 елдан Россия Академиясе әгъзасы була, 1841 елда исә Петербург Фәннәр Академиясенең академигы булып сайлана. Востоковның төп хезмәтләре: “Славян теле хакында төшенү” (1820), “Рус грамматикасы” (1831), “Румянцев музеенда саклана торган рус һәм славян кулъязмаларын тасвирлау” (1842), “Чиркәү-славян теле сүзлеге” (1858-1861) һ.б. А.Х. Востоков фикеренчә, телләрне үзара чагыштырганда һәм кардәшлек дәрәҗәсен билгеләгәндә, сүзләрне “беренче класс”, яки “беренчелек итүче”, һәм “икенче класс”, яки “ярдәмче” буларак бүлгәләргә кирәк. Беренче класска кешене атаган, аның гәүдә өлешләрен, туганлыкны белдергән сүзләр (исем һәм сыйфатлар), табигатьнең төп объектларын (күк йөзе, җир, су) һәм үзенчәлекләрен белдергән сүзләр, сан һәм алмашлыклар, бәйлек һәм теркәгечләр, кайбер фигыльләр һәм ымлыклар керә. Әлеге сүзләр телдәге борынгы катламга карый, алар башка телдән күчмәгән, ә инде бу төр сүзләрнең төрле телдәге охшашлыклары исә телләрнең кардәшлеген дәлилли. “Ярдәмче” сүзләргә

Востоков эш коралларының исемнәрен, сәнгать һәм хезмәт төрләрен кертә. Аның фикеренчә, әлеге сүзләрне халыклар бер-берсеннән алырга мөмкин, шуңа күрә бу өлкәләрдәге охшашлыклар тел кардәшлегенә дәлил түгел.

Шулай итеп, чагыштырма-тарихи тел белеменең үсеше белән телне өйрәнүдә чагыштырма-тарихи метод да үсеш ала. Аның төп үзенчәлекләре:

1) флексияләрнең охшашлыкларын (аеруча, фигыльләрнең зат кушымчаларына кагыла), сүзне үзгәртә торган күрсәткечләрне билгеләү;

2) лексиканың конкрет (борынгы) катламнарының гомумилеген ачыклау;

3) закончалыклы аваз тәңгәллекләрен (күчешләрен) билгеләү.

Чагыштырма-тарихи тел белеменең XIX гасырда алга таба үсеше түбәндәге бөек компаративистлар исеме белән бәйле: А.Ф. Потт (1802-1887), Г.Курциус (1820-1885), А.Шлейхер (1821-1868), И.Шмидт (1843-1901), Ф.Диц (1794-1876), Ф.И. Буслаев (1818-1897) һ.б. Әлеге галимнәр тарафыннан тикшерү алымнары камилләштерелә, компаративистиканың фәнни даирәсе киңәйтелә. Компаративистиканың иң төп казанышларының берсе – дөньядагы телләрнең генеалогик классификациясе. Бүгенге көн чагыштырма-тарихи тел белеме һәм аның соңгы табышлары яңа тел материалларын ачыклау һәм тикшерү методларының, карашларның киңәюе белән билгеләнә.

***Гомуми тел белеменең килеп чыгышы.*** XIX гасырда, чагыштырма-тарихи юнәлештәге тикшеренүләр белән беррәттән, И.Гердер, А.Шлегель, В. фон Гумбольдт, А.Шлейхер кебек исемнәргә бәйле рәвештә, тел фәлсәфәсенең дә үсеше күзәтелә. Әлеге галимнәр телнең эволюцион үсеш принципларын ассызыклыйлар, тел һәм фикерләү арасындагы мөнәсәбәтләрне, телнең табигатен билгеләргә тырышалар, телнең гомуми теориясен булдыру кебек эшләрне башкаралар.

Бу юнәлештә аеруча нәтиҗәле эшләгән галимнәр арасында Вильгельм фон Гумбольдт (1767-1835) аерым урын алып тора. Ул дворян гаиләсендә дөньяга килә. 1878 елда Франкфурт-на-Одере шәһәрендәге университетка укырга керә, биредә

юриспруденцияне өйрәнә, бер ел узуга, Геттинген университетына күчә. Университетта уку дәверендә ул тирән белем туплый. Бу исә аның бөтен яклап та дөньяга карашын билгели. В.Гумбольдт сәясәт һәм дипломатия, тел белеме һәм әдәбият теориясе, фәлсәфә һәм дәүләт хокукы кебек өлкәләрдә эшчәнлек алып бара. Ф.Шиллер һәм И.Гете В.Гумбольдтның иң якын дуслары була. 1801 елдан 1819 елга кадәр В.Гумбольдт хөкүмәттә эшли. 1808-1810 елларда ул дин мәсьәләләре буенча һәм халык мәгарифе министры вазифасын башкара, немец фәненең яңа үзәген – Берлин университетын ачуга зур өлеш кертә, урта һәм югары уку йортларын үзгәртеп коруларда катнаша. В.Гумбольдтның тел белеме өлкәсендәге беренче хезмәтләре баск телен өйрәнү белән бәйле була, соңрак исә ул Европа телләренең килеп чыгышы һәм кардәшлеге мәсьәләләрен өйрәнә. В.Гумбольдтның абыйсы – танылган табигать фәннәре белгече һәм географ Александр аңа Америка индеецлары белән бәйле материал тапшыра, бу исә В.Гумбольдтның телгә карата болай да югары булган кызыксынуын арттырып җибәрә. В.Гумбольдт үзенең лингвистик эзләнүләрен Европа телләре, баск, санскрит, кытай, Америка индеецлары телләре, борынгы мисыр, япон һ.б. телләр белән бәйли. Бу исә аңа дөньяның лингвистик сурәтен күзалларга булыша һәм гомумтеоретик төзелеш барлыкка китерү өчен нигез була.

В.Гумбольдтның “Кеше теленең структур төрлелеге”, “Ява утравындагы кави теле турында” һәм “Кеше теле төзелешендәге аермалыклар һәм аның рухи үсешендә телнең үтәгән роле” дип аталган хезмәтләре аеруча әһәмияткә ия. Аларда галим чагыштырмача тулы рәвештә үзенең тел онтологиясе теориясен чагылдыра. Монда ул И.Кант, Ф.Шиллер, Ф.Шеллинг, Г.Гегель кебек галимнәрнең фикерләренә таяна. В.Гумбольдт концепциясенең төп асылы – рух, рухи башлангыч һәм аның чагылыш формасы буларак тел. Төрле халыкларның мәдәни үзенчәлеген, телләрнең күплеген билгеләү өчен, ул Шеллинг һәм Гегельнең бөтендөнья тарихы концепцияләренә таяна. В.Гумбольдт мондый фикергә килә: тел белеме телне рухи эшчәнлек буларак кабул итү дәрәҗәсенә күтәрелми торып, бер проблеманы да чишә алмаячак.

В.Гумбольдт фикеренчә, халыкның рухи үзенчәлеге һәм аның тел төзелеше бер-берсе белән шулкадәр тыгыз бәйләнгән ки, хәтта икесенең берсе булса, икенчесен инде беренчесеннән китереп чыгарырга мөмкин. Бу турыда ул болай ди: "Тел – халык рухының тышкы халәте; халыкның теле – аның рухы, ә халыкның рухы – аның теле; шулкадәр тигез башка бер парны күзаллау кыен". Аныңча, "тел – рухның өзлексез эшчәнлеге" һәм аны "үле продукт буларак түгел, ә бәлки төзү процессы буларак" кабул итәргә кирәк.

Телне эшчәнлек буларак кабул итү тел теориясендә яңа адым була. В.Гумбольдт кешенең формалашуында, җәмгыятьнең үсешендә телнең мөһимлеген ассызыклый. Аның фикеренчә, кешенең фикерләүче иҗтимагый зат буларак камилләшүендә тел беренче рольне үтәгән.

В.Гумбольдт тел һәм фикерләү арасындагы мөнәсәбәткә басым ясый: "Тел – фикер барлыкка китерүче орган. Уйлау процессы рухи, эчке һәм эзсез узучан күренеш. Ул аваз һәм сөйләм ярдәмендә матдиләшә, аны тоеп була башлый. Шуңа күрә тел һәм фикерләү процессы бербөтен өзлексез бердәмлек хасил итә. Фикерләү мәҗбүри рәвештә һәрвакыт аваз белән бәйле. Шулай булмаса ул төшенчәгә әйләнә алмый. Тел һәм фикерләү бербөтен берлекне хасил итә: фикерләү процессы телдән башка башкарыла алмый, тел исә фикерләүне чагылдыра".

Генетик планда исә тел һәм фикерләү икесе дә бер үк вакытта барлыкка килә, аларның чыганаклары һәм башлангыч формалары безнең өчен сер булып кала. Моның белән беррәттән, рухның беренчел булу теориясенә таянып, В.Гумбольдт, төшенчә, формалашмаган хәлдә булса да, аны формалаштырган һәм теркәгән сүздән алда килә, дип уйлый.

Тел һәм фикерләүнең бербөтенлегенә таянып, В.Гумбольдт үзенең хезмәтләрендә телнең формасы хакындагы фикерләрен дә чагылдыра. Бу аның лингвистик теориясендә төп юнәлешкә әйләнә. "Тел – форма, һәм бары тик форма гына", – дип ассызыклый В.Гумбольдт. Ләкин "форма" – үзгәрүчән төшенчә. Биредә эчке һәм тышкы формалар аерыла. Тышкы форма – тел оешканлыгының тышкы, матди аспекты, эчке форма исә – психик, менталь субстанциянең формаль оешканлыгы. Тышкы

форма – аваз формалары, морфологик структура, мәгънә, ә эчке структура – төшенчәне аваз белән, фикерне тел белән бәйләү чарасы. Халыкның яки аерым бер кешенең рухы иң элек эчке формада объективлаша, соңыннан инде конкрет бер телнең тышкы формасы ярдәмендә чагылдырыла.

Төрле телләрнең тышкы аерымлыклары аваз формаларының төрле булуында чагыла, бу күренеш һәрбер телнең индивидуаль формасын билгели. Тавыш авазлары модификациянең күптөрлелеген үз эченә ала, ләкин артикуляцияләнгән аваз гына, ягъни, тел системасында урын алган һәм ул системада конкрет бер функциягә ия булган аваз гына мәгънәгә ия.

В. фон Гумбольдт, шулай ук, телнең тамга (знак) системасына нигез сала. Ул телне бер үк вакытта чынбарлыкның чагылышы һәм тамга (знак) буларак та кабул итә. Тел – предметлар түгел, ә бары тик шул предметларның мәгънәсе генә, – ди В.Гумбольдт. Сүз – аерым мәгънәнең билгесе, сүздә һәрвакыт ике әйбер урын ала – аваз һәм мәгънә. Гомумән алганда, тел абстракт рәвештә килеп чыккан продукт түгел, ул кешенең эчке дөньясы белән бәйле һәм телләр әлеге эчке дөньядан килеп чыга.

В.Гумбольдт, кешеләр бер төрдәге телдә сөйләшә, ләкин шул ук вакытта һәрбер кешенең аерым үз теле бар дип ассызыклый, шуның белән телне һәм сөйләмне фәнни тикшеренүләр объекты буларак бер-берсеннән аера. Тел кешегә үзен кешелекнең бер өлеше буларак хис итәргә булыша. Моның белән беррәттән, нәкъ менә кеше телендә сүзләр тәмамланган халәткә ия була, сүзләр ярдәмендә кешеләр гамәли эшчәнлекләре өчен кирәк булган аңлатманы таба.

Үз хезмәтләрендә В.Гумбольдт абыйлы-энеле Шлегельләрнең типологик классификацияләрен үзгәртә, камилләштерә һәм киңәйтә, яңа дип саналган инкорпорацияләнгән телләр төрен өсти. Телләрнең төзелешен карап чыгып, В.Гумбольдт телләрне “камил” һәм “камил булмаган” төрләргә аера. Ул дөнья телләрен дүрт төргә бүлә: флектив, аморф, агглютинацияле һәм инкорпорацияләнгән телләр. Башкалары белән чагыштырганда, “камил” дип табылган телләр рәтенә ул флектив телләрне кертә, чөнки биредә сүз төзелешендә эчке һәм тышкы синтез тулырак

чагылыш таба. Әлеге төргә, беренче чиратта, һинд-европа телләре керә. “Камил булмаган” телләр рәтенә исә В.Гумбольдт аморф (кытай теле), агглютинацияле (төрки телләр, фин телләре) һәм инкорпорацияләнгән (палеоазиат телләр, индеецларның телләре) телләрне кертә. Шуңа карамастан, барлык телләр дә халык рухын чагылдырырдай сыгылмалылыкка ия.

Телнең каршылыклы үзенчәлекләрен В.Гумбольдт антиномияләр нигезендә, ягъни, һәр икесе дә дәлилләнерлек ике күренеш арасындагы каршылык кебек формалаштырырга теләгән. Телнең төп антиномияләренә В.Гумбольдт түбәндәгеләрне кертә.

*Эшчәнлек һәм эшчәнлек нәтиҗәсе буларак – тел антиномиясе.* В.Гумбольдт фикеренчә, телне бар күләмендә яңадан укып чыгып һәм әз-әзләп үзләштереп була торган әзер материал итеп кабул итәргә ярамый: аны һәрвакыт һәм конкрет законнар нигезендә үзгәрә торган күренеш буларак аңларга кирәк. Тел – даими һәм үзгәрүчән. Икенче яктан, һәр яңа буын алдагы буыннан тел аша халык рухы эшчәнлегенең нәтиҗәсен әзер рәвештәге нәтиҗә буларак кабул итә.

*Тел һәм фикерләү антиномиясе.* В.Гумбольдт тел һәм фикерләүнең өзлексез бербөтен икәнлеген төрле яклап ассызыкларга тырыша: тел – фикер барлыкка китерүче орган; телдән башка төшенчәләрнең барлыкка килүе мөмкин түгел; сүз – төшенчәнең индивидуаль йөзе; сүз – аваз һәм төшенчә бердәмлеге һ.б. Моның белән бергәттән, кешенең рухы, төшенчә белән кушылганнан соң, һәрвакыт телдән азат ителергә тырыша, чөнки сүзләр рухның, фикернең эчке дөньясын кысаларга кертә.

*Телдә субъективлык һәм объективлык антиномиясе.* В.Гумбольдт фикеренчә, тел, өйрәнелә торган объектка карата – субъектив, ә кешегә карата – объектив. Тел мөстәкыйль яши, ул аерым кешеләргә бәйле түгел, ләкин ул кешеләрнең кулланулы нәтиҗәсендә генә яши ала. Тел – минеке, – ди В.Гумбольдт, – чөнки мин үз эшчәнлегем белән аны барлыкка китерәм. Ләкин мин аны бары шушы рәвешле барлыкка китерәм, ә нинди дер башка формада түгел, чөнки миңа кадәрге буыннар да шулай сөйләшкән, димәк тел үзе мине кысалар эченә кертә. Бер яктан карасак, кеше телне традиция нигезендә барлыкка китерә, ә

икенче яктан, үз сөйләмендә һәрвакыт телне яңадан яңгырарга мәҗбүр итә. Әлеге антиномия – субъективлыкны объективлыкка һәм, киресенчә, объективлыкны субъективлыкка әйләндерүдә мөһим корал.

*Тотрыклылык һәм телдәге хәрәкәт антиномиясе.* Әлеге каршылык телне эшчәнлек һәм эшчәнлек нәтиҗәсе буларак кабул итү белән бәйле. Тел һәрвакыт үзгәреп тора, шул ук вакытта ул гаҗәеп тотрыклы. Һәр кеше телгә үзенең үзгәртмәләрен кертә, шул ук вакытта кеше телне алдагы буыннардан кабул иткән формада куллана. Телнең кабул ителгән элементлары үле масса тәшкил итә, ләкин, шул ук вакытта, үзләрендә иксез-чиксез үзгәрешләр өчен нигез йөртә, чөнки һәрбер кеше аерым фикерли һәм һәрбер буын да телне үзгәртә, аңа тәэсир итә.

*Телдә индивидуальлек һәм коллективлык антиномиясе.* В.Гумбольдт фикеренчә, тел һәрвакыт бөтен халыкка, милләткә карый, шул ук вакытта, аерым бер кешенең эшчәнлек нәтиҗәсе, чөнки тел аерым бер кешенең авызында гына яши. Тел аерым бер кешенең дөньяга карашын чагылдыра, шул ук вакытта кеше халыкка бәйле. Эшчәнлек буларак тел һәрвакыт коллективны тәшкил иткән сөйләүчене һәм тыңлаучыны күздә тота.

*Тел һәм сөйләм антиномиясе.* Тел – билгеле бер система, билгеле бер фактларның күплеге һәм ул сөйләм эшчәнлегенең аерым актлары нәтиҗәсендә тормышка ашырыла. Сөйләм өчен тел аерым бер көйләү схемалары гына урнаштыра, индивидуаль күренешне исә сөйләүче кулына тапшыра. Тел системасы һәрвакыт сөйләмдә, сөйләм эшчәнлегенең аерым актлары буларак гамәлгә ашырыла.

*Аңлау һәм аңламау антиномиясе.* Сөйләм һәм аңлау, В.Гумбольдт фикеренчә, тел эшчәнлегенең төрле формалары. Сүзләр бары тик индивид сөйләмендә генә үзенең соңгы формасын ала. Сөйләүче дә, тыңлаучы да предметны төрле яклап кабул итәргә һәм бер үк сүзгә төрле, индивидуаль мәгънә салырга мөмкин. Шуңа күрә, сөйләшүчеләр арасындагы аңлашу, бер үк вакытта, аңлашмау да булырга мөмкин.

Шулай итеп, В.Гумбольдтның лингвистик концепциясе, аның карашлары тел белемендә яңа этап буларак кабул ителә. Ул

чордагы теге яки бу телгә һәм мәдәнияткә караган барлык эмпирик материал белән оста эш итә белгән В.Гумбольдт тел белемендә, беренчеләрдән булып, төзек һәм бербөтен лингвистик система төзүгә ирешә. Әлеге система телнең эчке төзелешен, халыкның акыл һәм рухи яшәеше белән бәйләнешен, аның мәдәниятен чагылдыра, киләчәк буын галимнәренә кеше эшчәнлегенең тел белән бәйле, интеллектуаль-рухи, мәдәни-тарихи механизмнарын өйрәнүгә ярдәм итә.

В.Гумбольдт – аерым бер тармак буларак теоретик һәм гомуми тел белеменә нигез салучы галим, аның күп кенә фикерләре хәзерге көндә дә дөнья тел белемендә аерым урын алып тора. Галимнең рух һәм фикерләү эшчәнлеге буларак тел турындагы фикерләре тел белемендәге психологик юнәлешнең үсеш алуына сәбәпче була. В.Гумбольдт концепциясендә төп рольне алып торган халык рухы турындагы төшенчә (милли тел – аның чагылыш формасы) хәзерге көн этнолингвистикасында һәм яңагумбольдтчылыкның башка формаларында да урын ала. В.Гумбольдтның телнең системалылыгы һәм тамгалылыгы хакындагы фикерләре А.Шлейхер, И.А. Бодуэн де Куртенэ, Ф. де Соссюр концепцияләре формалашуга; индивидның иҗади эшчәнлеге буларак тел турындагы фикерләре исә, А.А. Потебня, К.Фосслер, Б.Кроче кебек тел белемендәге эстетик юнәлешнең вәкилләре эшчәнлегенә дә, һичшиксез, йогынты ясаган.

Б.А. Ольховиков фикеренчә, В. фон Гумбольдт кебек галимнәрнең фәнни фикерләре үз чорларына түгел, ә бәлки алдагы буын фәненә карый.

### XX гасыр тел белеме

XX гасыр тел белемендә структуралистик карашлар агымында, кешенең табигый теле үзенчәлекләрен аңлату максаты белән, башка фәннәргә (аеруча психологиягә) мөрәҗәгать итүдән баш тартырга тырышып карыйлар. Шулай ук телне аналоглары булмаган, табигате буенча кабатланмас (sui generis) үзенчәлекле күренеш, үз законнары буенча яши һәм камилләшә торган семиотик система буларак таныган фикерләр дә үсеш ала.

XX гасырның 60 нчы елларына кадәр тел белеменең нигезендә структурачылык тора. Гомумән, структурачылык карашының төп таләпләре түбәндәгеләр:

1) телдән һәм системадан тыш факторларга, галимнең интуициясенә мөрәҗәгать итү куркынычын юкка чыгарган логика, математика, физика фәннәренең методларына тиңдәш булган төгәл лингвистик эзләнүләр методын куллану;

2) телнең бербөтен булуын һәм аның һәрбер элементының характеристикасын, телнең физик яки башка сыйфатларын санаудан түгел, ә бәлки телнең, шул ук тел системасының башка элементлары белән бәйләнешендә кабул итү;

3) телне – инвариант берәмлекләрнең һәм сөйләмнең үзендә йомык тамгалар (знаклар) системасы итеп, сөйләмне – телнең хәрәкәт итү мәйданы буларак һәм тел берәмлекләренең куллану мөмкинлекләрен аларның күп вариантлылыкларында кабул итү;

4) телнең күләм һәм кулланылыш планнарының гомуми, ә кайбер җыелма берәмлекләренең төгәл бүленеше;

5) телнең ике планлы һәм бер планлы берәмлекләре булу;

6) телнең күп дәрәҗәле, иерархик катлаулы система буларак тасвирлануы; анда тамга (знак) берәмлекләре дәрәҗәсе һәм тамга (знак) булмаган берәмлекләр дәрәҗәсенең булуы;

7) тамга (знак) берәмлекләренең тасвирламасы барышында, тамга (знак) булмаган, ягъни берьяклы берәмлекләрнең (мәсәлән, фонологик берәмлекләр) тасвирламасы вакытында кулланылган методларның үсеш алуы;

8) тел берәмлекләренең бер дәрәҗәдәге парадигматик һәм синтагматик мөнәсәбәтләрен аеру;

9) диахроник (төрле вакыт кисәкләрен үзара чагыштыру) аспектка түгел, ә бәлки синхроник (телгә хәзерге конкрет тарихи чорындагы хәләтендә бәяләмә бирү) аспектка өстенлек бирү.

Шушы һәм башка таләпләрне лингвистик структурачылыкның классик мәктәпләре һәм юнәлешләре дип саналган Прага, Копенгаген, Лондон лингвистик мәктәпләре, АКШдагы дескриптив лингвистика мәктәбе куя. Ә бу таләпләр, үз чиратында, Швейцария (Женева мәктәбе) һәм Франция мәктәпләренең структурачылык вәкилләре тарафыннан кабул ителә. Бу һәм аларга охшаш булган таләпләрнең эшләнешендә,

шулай ук, илебезнең (Мәскәү, Ленинград / Санкт-Петербург лингвистик мәктәпләре) тел белеме вәкилләре дә катнаша.

Структур тел белеме телнең авазларын өйрәнүдә аеруча киң кулланылыш ала. Иске классик фонетикага фонология каршы куела. Сүзләргә һәм морфемаларга карата аваз берәмлекләренең аеру функцияләре ассызыклану һәм, аваз берәмлекләренең матди аспектларына түгел, ә бәлки бу берәмлекләрнең аваз системасы эчендә каршы куелуына игътибар ясау фонология өчен иң төп моментлар була. Фонология фонема системасының иң кыска аваз элементы буларак модельләшүендә уңай нәтиҗәгә ирешә. Бу өлкәдә төгәл фәнни анализ методлары (оппозицияләр методы, дистрибутив метод) барлыкка килә. Алга таба исә бу методлар структур морфология һәм структур лексикология (семантика) төзүдә кулланыла.

Фонология үсешендә безнең ил галимнәренең өлеше дә гаять зур. Мәсәлән, Ленинград / Санкт-Петербург фонологик мәктәбе вәкиле Лев Владимирович Щерба һәм аның дәвамчылары – Маргарита Ивановна Матусевич, Лев Рафаилович Зиндер, Лия Васильевна Бондарко, Людмила Алексеевна Вербицкая, Мирра Вениаминовна Гордина, Вадим Борисович Касевич һ.б., шулай ук Мәскәү фонологик мәктәбе вәкилләре Рубен Иванович Аванесов, Петр Саввич Кузнецов, Александр Александрович Реформатский, Михаил Викторович Панов, Виктор Алексеевич Виноградов һ.б.

Фонологиягә (структур фонетика) һәм структур морфологиягә караган хезмәтләрдән соң, структур синтаксис буенча да хезмәтләр дөнья күрә. Дескриптивистлар кисәкчекләр буенча анализлау методын (immediate constituents analysis) уйлап чыгара. Бу методка бәйле рәвештә җөмлә һәр адым саен тагын да кечкенә кисәкчекләргә бүленә торган иерархик структура буларак бәяләнә. Люсьен Теньер тәкъдим иткән теория буенча, җөмлә иерархик структура буларак төзелә һәм структураның иң югары ноктасы булып фигыль санала. Безнең ил һәм чех галимнәре исә башка бер теория тәкъдим итәләр. Бу очракта җөмлә – модальлек һәм вакыт күрсәткечләре буенча аерылган парадигматик җыелма.

Телне тасвирлаганда мәгънәгә игътибар бирмәү лингвистиканың үсешенә комачаулаганы билгеле булгач, тора-бара структуралистлар телнең мәгънәсен формаль методлар белән тасвирлауга күчәләр. Мондый адым нәтиҗәсендә семантик кыр теориясе һәм сүз мәгънәсен компонентлы анализ теориясе белән өйрәнүне тәкъдим иткән структур семантика, яки структур лексикология барлыкка килә. Структурачылык нигезендә текст лингвистикасы һәм дискурс анализының беренче вариантлары барлыкка килә.

XX гасырның 60 нчы елларында структурачылык фикерләрендә телнең статистик тасвирламасыннан динамик тасвирламага күчү ниятләре сизелә башлый. Н.Хомскийның “барлыкка китерү грамматикасы” кебек телнең төп берәмлеге җөмлә булуга басым ясаган һәм синтаксик эзләнүләрне башлап җибәрүдә зур роль уйнаган теоретик модельләр берсе артыннан берсе дөнья күрә.

**XX гасыр ахыры тел белеме**

XX гасырның 60-70 нче елларында тел белеме редукционизм принцибыннан һәм аның белән бәйле нәтиҗәләрдән баш тарта. Мондый борылыш лингвистик фикернең түбәндәге маршрут буенча юнәлеше белән бәйле: фонетика (фонология) > морфология > синтаксис (үзенең формаль аспектында) > семантика (сүзнең структур семантикасы һәм аеруча җөмлә семантикасы). Нәтиҗәдә семантиканың прагматик һәм когнитив нигезләре формалаша.

Хәзер инде мәгънә объектка әйләнә һәм лингвистиканың беренче һәм төп бурычларыннан санала. Мәгънәнең табигатен һәм үзенчәлекле якларын аңларга тырышу тел белеменең структурачылык этабындагы казанышларын яңадан карауга китерә һәм ашыгыч рәвештә сүзнең һәм җөмләнең мәгънәсен түбәндәге шартларда гына тулысынча аңларга мөмкин дигән фикер туа:

- чыгыш яки текст кысаларында сүзлек контекстының шартлары күздә тотылган очрак;
- конкрет бер чыгыш барышында формалашкан прагматик ситуация игътибарга алынган очракта, ягъни, чыгышның

авторы, аудитория, авторның максатлары, аудиториянең бу чыгыштан нәрсә көтүе, чыгышның кайчан һәм кайда, нинди шартларда баруы;

- чыгышның эчтәлегенә, аның ничек формалашуына, чыгыш ясаучының (һәм тыңлаучының) нинди аң һәм хәтер ресурсларын куллануына, нәтиҗәдә тел һәм кешенең танып белү дөньясы, когнитив эшчәнлеге арасындагы бәйләнешенә, телнең, кеше һәм конкрет тел берләшмәсенең дөньяны күзаллауларына, ничек тәэсир итү фактына игътибар ителгән очрак.

Элек лингвистика телне үз эчендә йомык (имманент) берәмлекләр системасы буларак өйрәнгән булса, хәзер инде ул үзләштерү, аңлау һәм сөйләм барлыкка килү процессларында телнең ничек эшләвен, аның фикерләү һәм аң белән мөнәсәбәтен, телнең иҗтимагый һәм мәдәни контекстларга карата кешеләр арасында бертуктаусыз үзгәреп торган аралашу шартларына ничек тәэсир итүен тикшерә.

Структурачылыкта регресс башлануы күтелә. Соңгы берничә дистә ел эчендә лингвистик структурачылык дәверенең күп кенә каноннары яңадан карала. Бераз "либеральләшкән" лингвистика инде искергән дип саналган редукционизм принцибыннан чыккан кайбер кагыйдәләргә басым ясаудан туктый:

а) мәгънә лингвистика объектлары исемлегенә керми, ә семантика лингвистика кысаларыннан чыгарылырга тиеш дигән тезислар инде галимнәр арасында яклау тапмый;

б) мәгънәне "мәгънә берәмлекләренең эчке структурасы нигезендә аңлатырга мөмкин" дигән кагыйдә дә искергән дип санала. Сөйләү һәм сөйләгәнне аңлау өчен бары тик тел белү дә җитә. Җөмлә исә контексттан тыш та аңлашыла ала;

в) сөйләм һәм фикерләү арасындагы мөнәсәбәт телченең игътибарын җәлеп итмәскә тиеш дигән фикерләр дә инде кабул ителми башлый;

г) тел системасының бертөрлелеге (инвариантлылыгы), тышкы факторлардан, кулланылган ситуацияләрдән бәйсезлеге кире кагыла;

д) фонетика лингвистикадан чыгарылырга һәм фонологиядән аерылырга тиеш дигән фикер тарихта кала;

е) синхроник һәм диахроник карашлар әле дә аерыла, ләкин синхрония инде статика, тынычлык халәте белән чагыштырылмый;

ж) тышкы һәм эчке лингвистикага бүленү күздә тотыла, ләкин бу, телне бар яклап өйрәнү максатыннан караганда, лингвистик тикшеренүләрдән читкә чыгарылырга тиеш дигән сүз түгел;

з) үз вакытында Л.В. Щерба басым ясаган тикшерүченең тоемлау хисенә – интуициягә хокуклары кайтарыла;

и) тел/тел системасы (Соссюр буенча la langue, Хомский буенча – competence, ягъни, “компетентлык, сәләт”) һәм сөйләм (Соссюр буенча – la parole, Хомский буенча – performance, ягъни, “башкару”) аерылырга мөмкин. Ләкин алар аерым, мөстәкыйль объектлар буларак түгел, ә бәлки бер объектның (ягъни, киң мәгънәсендә телнең) бер-берсен тулыландыра торган ике аспекты буларак билгеләнә.

Сөйләм процесслары телчеләр тарафыннан шулай ук зур игътибарга лаек була. Инде 1931 елда ук Л.В. Щерба тел феноменын, беренче чиратта, сөйләм эшчәнлеге буларак кабул итә. Лингвистикада кайбер функциональ караш вәкилләре беренчелекне тел системасына түгел, ә бәлки сөйләм эшчәнлегенә бирергә омтылалар.

XX гасырның соңгы берничә дистә елында этнолингвистика яки лингвистик антропология, социолингвистика, психолингвистика, нейролингвистика, текст лингвистикасы (өйрәнү даирәсе һәм методы буенча киңрәк булган текст теориясе), сөйләм актлары теориясе, дискурс анализы (дискурс теориясе), конверсацион анализ (сөйләм анализы), прагмалингвистика (югарыда саналып үткән фәннәрнең күпчелек идеяләрен үз эченә алган) һ.б. юнәлешләр үсеш ала. Когнитив лингвистика, математик лингвистика, гамәли лингвистиканың кайбер юнәлешләре (аеруча инженер һәм компьютер лингвистикалары) югары дәрәҗәләргә ирешәләр.

Тел белемен телнең төрле якларын өйрәнә торган фән системасы буларак кабул иткәндә, системаның үзәген формалаштырган фәннәрне (фонетика, фонология, синтаксис, лексикология, семантика) һәм системадан бераз еракта торган

фәннәрне (этнолингвистика, социолингвистика, психолингвистика, нейролингвистика, текст лингвистикасы, прагматика, сөйләм актлары теориясе һ.б.) аерырга була.

**XXI гасыр тел белеме**

XX гасыр тел белеме XXI гасырга күп кенә мирас калдыра: традицион грамматика, чагыштырма-тарихи тел белеме, логик, психологик, социологик, неограмматик юнәлешләр, структурачылык һәм телнең тамга теориясе, типологик тел белеме һәм тел универсалияләре – бу бүгенге көн тел белемендәге актуаль проблемаларның тулы булмаган исемлеге. Бүгенге көн тел белеменең төп тенденцияләренең берсе – әлеге проблемаларны, лингвистик тикшеренүләрнең яңа принципларын, методларын кулланып, киң һәм тирән рәвештә теоретик һәм гамәли өйрәнү. Бу исә хәтта бер үк юнәлешләрнең дә үз эчендә тагы да вагракларга бүленүенә китерә. Бүгенге көн тел белеме, гомумән, күз алдына үткән чор казанышларына һәм традицияләренә таянган күп аспектлы плюралистик лингвистика булып килеп баса.

Бүгенге дөнья тел белемендә беренчелекне Европа (ә хәзер инде Европа-Америка) традицияләре тота. Бу традицияләрнең нигезендә антик (грек-рим) традицияләр һәм Европа тел белеменең урта гасырлар, Яңарыш чоры, мәгърифәтчелек чоры казанышлары урын ала. Моның белән беррәттән, гарәп һәм һинд традицияләре дә игътибарсыз калмый. Европада тел типологиясе һәм лингвистик универсалияләр өлкәләрендә уздырылган яңача тикшеренүләр, шулай ук төрле төзелештәге (аеруча “экзотик”) телләр белән танышу нәтиҗәсендә тел структурасы турындагы мәгълүматлар яңа дәрәҗәгә күтәрелә.

Хәзерге көндә түбәндәге юнәлешләрдә уңышлы гына тикшеренүләр алып барыла:

- *традицион юнәлеш*. Антик тамырларга, урта гасыр грамматик теорияләренә, XVII-XVIII гасыр универсаль грамматикаларына нигезләнгән, бер үк вакытта яңа юнәлешләрнең эшчәнлеген дә үзенә туплап бара;

- *генетик юнәлеш.* XIX гасырда чагыштырма-тарихи карашлар белән беррәттән килеп чыга һәм бүгенге көндә типологик, ареаль, логик-математик методлар ярдәмендә тулылана;

- *структур юнәлеш.* XX гасыр башында пәйда була. Үзенең килеп чыгышы белән И.А. Бодуэн де Куртенэ, Ф.Ф. Фортунатов, Ф. де Соссюр эшчәнлеге, шулай ук Прага, Копенгаген, АКШтагы Йель, Анн-Арбор (Леонард Блумфилд, Эдвард Сепир, Зеллиг Харрис), Лондон (Дж.Фёрс), француз (Андре Мартине) һәм безнең ил структурачылары белән бәйле;

- *генератив юнәлеш.* Америка галиме Н.Хомский эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килә һәм нигезендә математик лингвистиканың формализмнары ята;

- *функциональ юнәлеш.* Күпчелек теория һәм концепцияләрдә урын ала. Дөньяны танып белүдә һәм тел коммуникациясендә кеше факторының төп роль уйнавын таный.

Хәзереге вакытта, элеккечә үк, сөйләм теленә (аеруча спонтан сөйләм теленә) беренчелек бирелә. Шулай ук язма текстларны аңлау проблемалары да киң өйрәнелә.

Фонетиканың һәм фонологиянең якынаюы сизелә. Фонологик берәмлекләрнең үзара мөнәсәбәте нәтиҗәсендә барлыкка килгән үзенчәлекләр белән беррәттән, аларның матди (субстанциаль) үзенчәлекләре дә күздә тотыла.

Телне өйрәнүдә, беренчелекне синхроник карашларга бирү белән бергә, телне аның тарихы (диахрония) нигезендә өйрәнү дә мөһим санала.

Тасвири һәм аңлату методлары белән бергә нормализаторлык методының да мөһимлеге шик астына куелмый. Ул хәзер уку грамматикалары, сүзлекләр, орфографик, орфоэпик белешмәләр төзүчеләр тарафыннан башкарыла.

Яңа чор тел белеме телнең эчке структурасына һәм яшәү-камилләшүенә тышкы ареалның (кеше, этнос, социум) тәэсире белән дә кызыксына.

Дөнья лингвистикасының төп максаты – тел сәясәте һәм телнең планлаштырылуы. Бу юнәлештә XX йөзнең 20-30 нчы елларында безнең ил тел белгечләре актив шөгыльләнгән.

Тел турындагы фәннең бу чордагы үсеше тагын бер тенденция – лингвистиканың башка фәннәр белән мөнәсәбәткә

керүен дә ассызыклый. Тел белеме үсешенең беренче этапларында ук аның фәлсәфә, логика, психология, тарих һәм кайбер башка фәннәр белән мөнәсәбәте формалаша. Бүгенге көн тел белеме исә үзенең мөнәсәбәтләрен әлеге фәннәр белән генә киңәйтеп калмый, ә кайбер башка гуманитар, табигый фәннәр, физик-математик дисциплиналар – социология, этнография, география, молекуляр биология, биофизика һәм биохимия, нейрофизиология, кибернетика, математика, мәгълүмати системалар теориясе, теоретик физика һ.б. фәннәр белән дә үзара мөнәсәбәтләргә керә. Әлеге тенденция төрле фәннәр чигендә яңа лингвистик дисциплиналар – социолингвистика, этнолингвистика, лингвогеография, нейролингвистика, математик лингвистика, инженер лингвистикасы, лингвосемиотика һ.б. барлыкка килүгә сәбәп була. Фәнни тикшерүләрнең мондый үзенчәлеге тагын бер тенденциягә – фәнни тикшерүләрне интеграцияләү һәм аларның нәтиҗәләрен фәннең гомуми теориясе кысаларында кабул итүгә китерә.

Тел белемендә төрле мәктәп һәм юнәлешләрнең гомуми тел белеме теориясе кысаларында берләшүе инде XX гасырның 60 нчы елларында ук күзәтелә. Интеграциянең зарурилыгы турында 1962 елда Кембриджда (АКШ) Лингвистларның IX халыкара конгрессында ук әйтелә. Конкрет тикшеренүләрдә исә әлеге тенденция лингвистик универсалияләргә карата туган кызыксыну (Е.Курилович, А.Мартине, Р.Якобсон), дөньядагы күп санлы телләр нигезендә уртак үзенчәлекле сыйфатлар ята, дигән фикер белән бәйле рәвештә чагылыш таба. Телнең гомуми теориясендә, дөнья телләренең күпсанлы аермалыклары булуына карамастан, алар бер үрнәк нигезендә барлыкка килгән дигән идеяләр беренче урынга чыга. Әлеге үрнәкне, телнең бердәм эчке структурасын эзләү бүгенге көн фундаменталь фәненең төп тенденциясе – дөнья барлыкка килүнең бердәм нигезен эзләп табу һәм аның нигезендә фәннең гомуми теориясен булдыру белән бәйле.

Яңа чор тел белеме эмпирик (дөнья телләренең аерым берсен өйрәнү) һәм лингвофәлсәфи, теоретик (кеше теленең үзенчәлекләрен аңлату) проблемаларны берьюлы чишәргә тырыша. Күпчелек яңа саналган фәнни идеяләрнең,

теорияләрнең, модельләрнең бүгенге көндә 10-15, кайбер очракларда 20 ел эчендә искерүенә дә карамастан, тел белеме бик тиз камилләшә. Ләкин шуңа да карамастан, тел белеменең соңгы казанышларын, төрле методларның үзара продуктив эшчәнлеген чагылдырган, яңа,ербөтен, интеграль характердагы телнең булмавын кабул итәргә кирәк. Мондый тел моделе XXI гасырда уйлап чыгарылыр.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Тел белеме үсешенең төп этапларын санагыз.
2. Борынгы классик филология чорының нинди үзенчәлекләрен әйтә аласыз?
3. Панини грамматикасы турында нәрсәләр беләсез? Тел белемендә аның әһәмияте нәрсәдә?
4. Борынгы грек фәлсәфәчеләренең тел белеме үсешенә керткән өлеше турында сөйләгез.
5. Урта гасырларда Европада тел белеменең торышына күзәтү ясагыз, төп грамматикаларны санагыз.
6. Пор-Рояль грамматикасы турында сөйләгез.
7. Урта гасырлар гарәп тел белеме үсешенә күзәтү ясагыз.
8. Мәхмүд Кашгариның мәшһүр хезмәте турында сөйләгез.
9. Яңарыш чоры тел белеме үсешенә нинди йогынты ясый?
10. Урта гасырларның соңгы этабында Европада нинди галимнәрнең хезмәтләре мәгълүм була?
11. Урта гасырларда дөнья күргән рус теле белән бәйле нинди хезмәтләрне беләсез?
12. XVII-XVIII гасырларда тел белеме үсешенә китергән тарихи сәбәпләрне тасвирлагыз.
13. Тел белеме тарихында үзенчәлекле күренешләрнең берсе булган ясалма телләр, аларның уйлап табылуы турынданиләр беләсез?
14. Тел белеме тарихында чагыштырма-тарихи юнәлеш барлыкка килүнең алшартларын атагыз.
15. Чагыштырма-тарихи тел белеменә өлеш керткән галимнәр һәм аларның хезмәтләре турында сөйләгез.
16. XVIII-XIX гасырларда Европада һәм Россиядә тел белеме торышына күзәтү ясагыз.
17. Гомуми тел белемендә В. фон Гумбольдт хезмәтләренең әһәмияте турында сөйләгез, аның карашларына фикерегезне белдерегез.
18. XX гасырда тел белеменең үсешенә күзәтү ясагыз.
19. XX гасыр ахыры тел белемендә нинди яңалыклар була?
20. XXI гасыр тел белемендә нинди юнәлешләрдә тикшеренүләр алып барыла?

# ТЕЛ БЕЛЕМЕНДӘ ТӨП МӘКТӘПЛӘР ҺӘМ ЮНӘЛЕШЛӘР

## Тел белемендә натурализм

Тел белемендә натурализмның килеп чыгуы XIX гасырга карый һәм Европада табигать фәннәренең үсеш алуы белән бәйле. Ләкин телгә карата натуралистик караштa язылган фикерләр инде В. фон Гумбольдт, Ф.Бопп кебек галимнәрнең хезмәтләрендә үк чагылыш таба, әлеге галимнәр "организм" төшенчәсен телгә карата да кулланалар. Ләкин натуралистик юнәлеш вәкилләрендә генә әлеге термин ачык табигый төсен ала. Натуралистик концепция теге яки бу дәрәҗәдә немец галимнәре М.Рапп (1803-1883) ("Тел физиологиясе", "Табигый фән буларак чагыштырма грамматика" һ.б.), М.Мюллер (1823-1900) ("Тел турындагы фән буенча лекция"), америка галиме В.Уитни (1827-1894) ("Телнең яшәеше һәм үсеше") һ.б. лингвистларның хезмәтләрендә чагылыш таба. Тел фәлсәфәсе буларак натурализм югары дәрәҗәдә төгәл рәвештә немец тел белгече Август Шлейхерның (1821-1868) хезмәтләрендә урын ала. Һинд-европачылыкның аерым бер фән буларак формалашуы гына түгел, ә тел тикшеренүләрендә табигый фән методының кулланылуы да аның исеме белән бәйле.

А.Шлейхер, тел белеме белән беррәттән, фәлсәфә һәм ботаника кебек фәннәрне дә өйрәнгән, бу исә аның карашларына да йогынты ясаган. 1846 елдан ул Бонна университеты доценты, 1850 елдан Прагада укыта, 1857 елдан башлап Иена университетында эшли башлый. 1858 елда А.Шлейхер Россия Фәннәр Академиясенең чит ил әгъза-мөхбире итеп сайлана. Ул күпкырлы лингвист була, герман, славян, балтыйк телләрен чагыштырма-тарихи һәм типологик аспектларда өйрәнә. 1852 елда аның "Чиркәү-славян теле морфологиясе" дип аталган, ә 1856 елда "Литва грамматикасы" дип исемләнгән хезмәте дөнья күрә. 1861-1862 елларда А.Шлейхерның төп хезмәте саналган "Һинд-герман телләренең чагыштырма грамматикасының компендие" дөнья күрә. Биредә соңгы ярты гасыр эчендәге һинд-европа телләрен чагыштырма юл белән өйрәнүгә нәтиҗә ясала. Гомуми тел белемендә исә А.Шлейхер, беренче чиратта, натуралистик юнәлеш юлбашчысы буларак танyла.

А.Шлейхерның натуралистик фәлсәфәсе чагыштырмача тулы рәвештә аның “Дарвин теориясе һәм тел турындагы фән” (1863) һәм “Кешенең табигый тарихында телнең тоткан урыны” (1865) дип аталган хезмәтләрендә чагылыш таба.

А.Шлейхер телне табигый организм буларак кабул итә. “Телләр – аваз материясеннән барлыкка килгән табигать организмнары, аларның табигать организмы үзенчәлекләре бары тик ыру, төр, төрчәләргә бүленүдә генә чагылмый, моннан тыш, аларның үсүе конкрет законнар нигезендә тормышка ашырыла”. Телләр кешеләрнең эшчәнлегенә бәйсез рәвештә табигый юл белән барлыкка киләләр. Кеше үзенең организмын үзгәртә алмаган кебек үк, нәрсәне дә булса үзгәртү теләге телгә тәэсир итә алмый, шуңа күрә тел законнары, табигать законнары кебек үк, объектив характерга ия. А.Шлейхер фикеренчә, Ч.Дарвин тарафыннан тәкъдим ителгән хайван һәм үсемлек төрләренә кагылышлы законнарны тел организмнарына карата да кулланырга мөмкин. Шушы гомуми закончалыклар телне табигатьнең башка күренешләренә охшашландыралар, телләрне табигый организмнар рәтенә кертәләр.

Телгә карата мондый караш А.Шлейхерны тел белеме белән филологияне бер-берсеннән аерып карарга мәҗбүр итә. Телне табигый күренеш буларак караган тел белеме кешелекнең табигый тарихының бер өлешен тәшкил итә. А.Шлейхер фикеренчә, тел белгече табигать фәннәре галиме ролен үти, ягъни ботаник үсемлекләргә ни караштә булса, телче дә телгә карата шундый ук якын мөнәсәбәттә: ботаник өчен үсемлекнең эстетик һәм гамәли яклары мөһим түгел, ул бары тик үсемлекләрнең төзелеш закончалыкларын һәм үсешен тикшерергә тиеш. Филология исә тарих белән эш итә. Филологиянең өйрәнү объекты – кеше тарафыннан барлыкка китерелгән әдәби текстлар һәм язма истәлекләр, бу яктан, мәсәлән, язулары булмаган америка индеецлары филологиягә ия була алмыйлар. Ә менә тел белеме өчен язусыз халыкларның телләре һәм диалектлары зур кызыксыну уята. А.Шлейхер фикеренчә, текстларның филологик анализы һәм комментарийлары тикшеренү субъективизмы тәэсиренә эләгә. Моның белән бергә, филология һәм тел белеме үзара тоташкан

нокталар да юк түгел. Мисал өчен, синтаксиста объектив закончалыклар хөкем сөрә, ләкин субъектив сәбәпләр дә үз ролен уйнарга мөмкин. Мисалга кеше ниятен китерергә була.

Ч.Дарвинның төрләр барлыкка килү һәм үзгәрү хакындагы теориясе А.Шлейхерга зур тәэсир ясый. А.Шлейхер Дарвин тарафыннан билгеләнгән төрләрнең үзгәрүчәнлек законнарын телгә күчерә. Аның фикеренчә, тел өлкәсендәге бүленешләр, табигый организмнардагы бүленешләр белән бер үк. “Безгә мәгълүм булган тел кабиләләреннән без шәҗәрә төзи алабыз, нәкъ менә шушы юл белән Ч.Дарвин да үсемлек һәм хайван төрләрен төркемнәргә бүлгән”, – дип яза Шлейхер. Аның фикеренчә, телдә бер род төрләре тел исемен йөртә, ә төрчекләр – диалектлар, төрчәләр исә – җирле шивәләр, аерым затлар – индивидуаль сөйләм дип атала”. Моның белән беррәттән, телләрнең барлыкка килүен һәм үзгәрешен, элекеге формалардан яңа формаларның барлыкка килүен, үсемлекләр һәм хайваннарга караганда, телдә билгеләү җиңелрәк. Моңа язма истәлекләр сәбәп булып тора. Кайбер истәлекләргә нигезләнеп, телләрнең яки тел гаиләләренең ике мең еллык тарихын өйрәнеп була.

Ч.Дарвин законнарына нигезләнеп, А.Шлейхер телнең килеп чыгуы һәм үсеше белән бәйле гомуми законнарны билгеләргә омтыла. Аның фикеренчә, органик дөнья бер күзәнәкле организмнардан килеп чыккан кебек үк, телләр дә гади формалардан барлыкка килгән. Ул тел формаларында фигыль дә, исем дә, спряжение һәм склонение белән төрләнешләр дә булмаган. А.Шлейхер, барлык телләр өчен дә формага карата бердәй барлыкка килү юлын билгели: дөньяның барлык телләре дә гади тамырдан барлыкка килгән һәм төрле табигать шартларында яшәүче халыкларда аваз материалы һәм мәгънә ягыннан аерылып торганнар. Эволюция процессы дәвамында телләр гади структуралардан югары үсеш ноктасына кадәр камилләшү юлын узганнар. Телләрнең табигый организмнар белән тыгыз бәйләнешен күздә тотып, А.Шлейхер түбәндәге фикерен белдерә: “Телнең гомере башка тере организмнар гомереннән – үсемлекләр һәм хайваннар гомереннән әллә ни аерылып тормый, башка тере организмнар кебек үк, ул гади структуралардан катлаулы формаларга таба үсеш юлын күздә

тота һәм картаю процессын үза, телләр югары үсеш ноктасыннан ерагаялар һәм таркалу процессы башлана". А.Шлейхер телләр классификациясендә В.Гумбольдтның телләрне дүрт төргә бүлгән теориясеннән баш тарта һәм Шлегельның телләрне өч класска аерган теориясенә игътибарын юнәлтә: ул да изоляцияләнгән, агглютинацияле һәм флектив телләрне карый. Изоляцияләнгән, яки бер составлы телләр, үсешнең беренче баскычы булып санала, алардан телләрнең агглютинатив төрләре барлыкка килә, бу төрдән исә телнең югары төре – флектив төр башлангыч ала. Әлеге тел үсешенең баскычларына Шлейхер табигатьтә дә аналоглар таба: мәсәлән, кристалллар, үсемлекләр һәм хайваннар Җир шарының үсешендә төрле чорларга карый.

А.Шлейхер Дарвинның төрләрнең яшәү өчен көрәше хакындагы теориясен телгә карата куллана. Үсемлек һәм хайваннар дөньясында иң көчле төрләр генә яшәүгә сәләтле булган кебек, Шлейхер фикеренчә, телләр көрәшендә дә тел үсешенең югары баскычында торган, ягъни флектив телләр җиңүче булып чыга. Аның фикеренчә, хәзерге көндә яшәү өчен көрәштә аеруча һинд-герман кабиләсе телләре казанышларга ия, аларның җирдәге таралыш мәйданы артканнан арта, ә башка телләр исә алар тарафыннан кысрыклана бара.

А.Шлейхерның тел эволюция теориясенә Гегельның фәлсәфи системасы тәэсир итә. Гегель буенча, бөтен барлыкның формалашу һәм камилләшү сәбәбе – рух, рух эшчәнлеге. Рух табигатьтә икән, димәк, табигать камилләшәчәк. Рух үзенә кайта икән, табигать камилләшүдән туктый, теге яки бу формаларның таркалуы һәм юкка чыгуы башлана. Шушы ук күренешләрне Шлейхер телдә дә күзәтә. Кешенең иң борынгы, беренче яшәү этабында рух авазга бәйле була һәм аның барлык формаларында тел төзү процессы башлана. Рух үзенә әйләнеп кайтканнан соң, ул яңа телләрне барлыкка китерми; моннан алдагы чорда иҗади фикерләр белән тулы табигать хәзер инде бары тик яңадан кабатлауга гына кайтып кала. Әлеге чорда телдәге авазлар "ашала", төрле ассимиляцияләр, аваз кимчелекләре барлыкка килә, форма байлыклары юкка чыга, гадиләшү процессы башланып китә. Телне иҗади рух ташлап киткәннән соң, биредә

физик законнар хөкем сөрә башлый, тел бары тик барлыкка китерелә (әйтелә, сөйләшелә), искерә башлый.

Шулай итеп, телнең тере организм белән чагыштырылуы тел белемендәге натуралистик карашларның казанышы булып саналырга мөмкин. Бу исә телгә карата систематик карашларның киңәюенә китерә, тел үзенең структураларына һәм камилләшү законнарына ия булган объект буларак кабул ителә башлый. Шлейхер берничә фәнни фикерен киң җәмәгатьчелеккә җиткерә: тел типологиясенең проблемалары, баба тел проблемасы һәм һинд-европа теленең шәҗәрәсе белән бәйле проблемалар, телләрнең генетик һәм географик үзгәрүчәнлеге мәсьәләләре – әлеге фикерләр алдагы буын телчеләре тарафыннан камилләштерелә. Телгә карата биологик караш исә хәзерге көн тел белемендә дә генетик код һәм табигый телнең структур изоморфизмнары табигатен тикшерүдә чагылыш таба.

**Психологик юнәлеш**

Телнең натуралистик һәм психологик концепцияләре берникадәр вакыт янәшә кулланылалар, телнең гомуми теориясен чагыштырма-тарихи тикшеренүләр белән бәйлиләр. Күп кенә лингвистик хезмәтләр инде В. фон Гумбольдт чорында ук психологик карашка ия булалар, психологизм шулай ук XIX гасырның икенче яртысындагы тел белеме өчен дә характерлы күренеш. Психологизмның тел белемендә барлыкка килүе һәм үсеше XIX гасырның уртасына-ахырына туры килә. Ул Германиядә – Гейман Штейнталь (1823-1899), Мориц Лацарус (1824-1903), Вильгельм Вундт (1832-1920), Россиядә – А.А. Потебня (1835-1891) кебек галимнәр эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнгән.

Тел белемендә психологик юнәлеш кысаларында ике агым формалаша: *иҗтимагый* (коллектив, этник) *психологизм* һәм *индивидуаль психологизм*. Беренче агым вәкилләре телне халык психологиясенең үзенчәлекле күренеше буларак карарга тәкъдим итәләр. Биредә психологик социум – халык, коллектив, милләт социумы үзәк ролен башкара. Икенче агым вәкилләре исә телне индивидуаль психиканың эшчәнлек механизмы буларак кабул итәләр. Индивидуаль психологизмның үзәгендә

аерым бер кеше һәм аның психикасы тора. Лингвистик психологизмның үсешенә немец фәлсәфәчесе, психологы һәм педагогы И.Гербартның (1776-1841) эшчәнлеге зур йогынты ясый. И.Гербарт фикерләү процессын күз алдына китерү ассоциациясе буларак кабул итә. Охшашлыклар һәм контраст буенча күз алдына китерү мөнәсәбәтләре ассоциацияләр ролен уйный. Тел белеме фәнендә психологизм аерым бер юнәлеш буларак, беренче чиратта, Г.Штейнталь һәм М.Лацарусның халык психологиясе концепциясенә бәйле барлыкка килә.

Халык психологиясе, фәнни белемнәрнең аерым бер юнәлеше буларак, XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башларында барлыкка килә һәм тел белеме белән бәйле булган барлык фәннәр ярдәмендә үсеш ала. Халык психологиясенең төп идеясе халык рухы концепциясе белән тыгыз бәйләнештә тора. Лингвистик традициядә ул В. фон Гумбольдт фәлсәфәсенә нигезләнә. Штейнталь һәм Лацарус фикере буенча, халык рухы – кешелек җәмгыятенең эшчәнлек нәтиҗәсе, ә рухи эшчәнлек – чын яшәеш һәм кешенең максаты. Халык рухы рух эшчәнлегенең һәм, гомумән, кешенең нинди дә булса эшчәнлегенең чыганагы булып тора, ул гомуми эшчәнлекне белдерә. Халык психологиясе – халык рухы турындагы фән, ул төрле халыкларның рухи табигатен тәшкил иткән үзенчәлекле яшәү образларын һәм рухларының эшчәнлек формасын өйрәнергә тиеш. Милли мәдәният тарихы халык рухын өйрәнү өчен зур материал чыганагы булып тора, анда аеруча мөһим булган компонент – тел. Соңрак гореф-гадәтләр, мифология һәм дин өйрәнелә. Барлык саналып үткән компонентлар – халык рухының эшчәнлек нәтиҗәләре. Халык рухы – күпсанлы индивидлардан бербөтен халык төзегән күренеш, ул бербөтен халыкны тәшкил итүче индивидларның бертөрле фикер йөртүләре өчен кирәк булган нигез. Ләкин халык рухы бары тик кешедә була, кешедән башка яши алмый, бу яктан, халык рухында индивид рухында барлыкка килгән процесслар урын ала. Моның белән бәйле рәвештә, рух турындагы фән буларак, гомуми психология үзенең составында ике төп бүлеккә ия: халык психологиясе һәм индивидуаль психология. Индивидуаль психология – ул индивид рухы турындагы фән, ә халык

психологиясе – халыкның рухын өйрәнә торган фән. Беренче юнәлеш икенчесе өчен үзенә бер нигез булып тора. Кешенең барлык интеллектуаль эшчәнлеге тел белән бәйле булганга, психология, беренче чиратта, тел турындагы фән.

Халык психологиясенә нигез салучылар өчен, тел – беренче чиратта, бербөтен халык рухының үзаңы, дөньяга карашы һәм логикасы, шулай ук, индивидуаль рухның чагылышы. Телне аның барлык күпсанлы формаларын да күздә тотып өйрәнү халык рухының нигезләрен аңларга ярдәм итә, һәрбер тел – гомуми "тел" төшенчәсенең индивидуаль рәвештә тормышка ашырылуы. Бу очракта, халык рухын чагылдыра торган объект буларак, телләрне кардәшлек һәм төзелеш камиллеге буенча классификацияләргә була. Әлеге классификация төрле телләрдә һәм индивидуаль формаларда телнең гомуми нигезен чагылдырырга тиеш.

Халык психологиясенең бу принциплары Г.Штейнтальның тел белеме буенча язылган хезмәтләрендә урын ала: "Грамматика, логика һәм психология, аларның принциплары һәм үзара мөнәсәбәтләре" (1855), "Психология һәм тел белеменә кереш" (1851), "Тел идеясенең үсеше буларак телләрне классификацияләү" (1850), "В.Гумбольдтның тел белеме буенча язылган хезмәтләре һәм Гегель фәлсәфәсе" (1848) һ.б.

Г.Штейнталь тел белемен психологик фәннәр рәтенә кертә, чөнки сөйләм – рухи эшчәнлек һәм тел – психологик күзәтүләр объекты. "Тел белеменең өйрәнү объекты – тел, яки гомумән кеше теле, ягъни эчке психик, рухи хәрәкәтләрнең, халәт һәм мөнәсәбәтләрнең артикуляцияләнгән авазлар ярдәмендә белдерелүе" – дип яза ул. Тел материалы "күзаллаулардан тора, хәтта гади авазлар да, артикуляцияләр дә рухи башлангыч белән бәйле; алар бары тик психологик яктан гына өйрәнелергә мөмкин". "Тел" төшенчәсендә Г.Штейнталь тел күренеше буларак сөйләмне (сөйләшүне) күрә, психик һәм физиологик аспектларга басым ясап, сөйләшүгә сәләтне аерып чыгара; тел материалын сөйләм ярдәмендә барлыкка килгән элементлар итеп, һәм теге яки бу телне теге яки бу конкрет халыкның тел материалы буларак кабул итә.

Г.Штейнталь фикеренчә, теге яки бу индивидта сөйләм һәм фикерләүнең барлыкка килүе һәм камилләшүе кешелек җәмгыятендә телнең килеп чыгуына һәм камилләшүенә китергән сәбәпләргә бәйле. Г.Штейнталь бер халыкның барлык индивидлары да тәнендә һәм күңелендә шул халык табигатенең үзенчәлекле йогынтысын тоя дигән фикердә була. Физик охшашлыклар кан кардәшлек, табигатьнең бертөрле тәэсире, охшаш көнкүрешләр белән аңлатыла. Рухи охшашлыклар исә бергә тормыш итүгә бәйле. “Иң элек бары тик үзара мөнәсәбәттә торып фикер йөрткәннәр, ягъни, һәрбер кеше үзенең фикерен кабиләдәге башка кеше фикере белән бәйле рәвештә җиткергән, килеп чыккан яңа фикер һәр ике кешегә дә караган, моны баланың бер үк вакытта әтисенеке дә, әнисенеке дә булуы белән чагыштырырга мөмкин”, – дип ассызыклый Г.Штейнталь. Охшаш физик төзелеш һәм бертөрле хис-тойгылар охшаш омтылыш һәм теләкләр тудыра. Бу исә, үз чиратында, охшаш фикер һәм тел барлыкка килүнең сәбәбе булып тора. Тел – халык эшчәнлегенең нәтиҗәсе, ул бер үк вакытта аерым бер индивидка бәйле психофизиологик система вазифасын да башкара.

Г.Штейнталь тел белеме һәм логика арасындагы чикләрне катгый рәвештә билгели. Аның фикеренчә, тел һәм логика категорияләре – капма-каршы ике күренеш, аларның, “түгәрәк” һәм “кызыл” төшенчәләре кебек, охшашлыклары да бик аз. Штейналь предметлы һәм тел фикерләвен аера. Предметлы фикерләүнең нигезе – предметлар үзләре түгел, бәлки әлеге предметлар чагылдырган сыйфатларының бертөрле фикри күплек буларак кабул ителүе. Тел фикерләвенең нигезе исә – әлеге күзаллаулар хакындагы күзаллаулар, ягъни телнең эчке формасы дип исемләнгән икеләтә субъектив күренеш. Телнең тышкы формасы исә – аваз.

Г.Штейнтальның телне җәмгыять барлыкка китерүче индивидлар күплегенең вакыт һәм пространствода урын алган тел эшчәнлеге буларак кабул итүе тел белеме өчен уңай нәтиҗәләргә китерә.

М.Лацарус һәм Г.Штейнталь белән беррәттән, XX гасыр чигендә яшәгән һәм иҗат иткән этник психология мәктәбе вәкиле Вильгельм Макс Вундтның (1832-1920) хезмәтләре дә

зур хөрмәткә ия була. Гомумән, В.Вундт – телне тирәнтен өйрәнүче, аның нигезенә, яшәү һәм камилләшүенә, аның кеше эшчәнлегенең башка өлкәләре белән мөнәсәбәтенә игътибар бирүче беренче белгеч-психолог; ул телне коллективның эшчәнлек нәтиҗәсе буларак, миф һәм гореф-гадәтләр белән бер рәттә өйрәнә. Чөнки нәкъ менә миф һәм гореф-гадәтләр борынгы күзаллауларны һәм, шул ук вакытта, мәдәният, хокук һәм сәнгатьнең башлангыч чорын үз эченә ала. Әлеге синкретик рухи сәнгатьне В.Вундт психология нигезендә өйрәнә. Аның фикеренчә, психология ул әле төп фәлсәфи фән дә, чөнки һәртөрле фәнни белем, эмпирик нигез рәвешендә, психик процессларга таяна. Ул берничә тапкыр тел фактларының аны психология өчен файдалы булу ягыннан гына кызыксындыруын әйтә. “Халык психологиясенең максатлары һәм юллары” (1888) дип исемләнгән хезмәтендә В.Вундт психология һәм тел белеме арасындагы проблемаларга мөнәсәбәтен белдерә. “Халыклар психологиясе. Тел, миф һәм гореф-гадәтләрнең үсеш закончалыкларын өйрәнү” (беренче ике томы телгә багышланган күптомлы хезмәт; 1900), “Тел тарихы һәм тел психологиясе” (1901), “Халыклар психологиясенең элементлары” (1912) һ.б. хезмәтләрендә В.Вундт телнең гомуми һәм хосусый проблемаларын психологик яктан аңлата.

В.Вундт, халык психологиясен төгәл рәвештә билгеләргә омтыла, шул ук вакытта, андагы индивидуаль характердагы күренешләрдән баш тарта. Аның фикеренчә, игътибарны гомуми әһәмияткә ия психологик закончалыкларга юнәлтергә кирәк. Психология объекты буларак В.Вундт *тел*, *миф* һәм *гореф-гадәтләрне* аерып карый. Аныңча, болар психологиянең өч төп проблемасын тәшкил итә. Тел, миф һәм гореф-гадәтләр гомуми камилләшү законнарына буйсыналар һәм камилләшү процессының рухи нәтиҗәсе ролен үтиләр, биредә шулай ук психологик законнар да чагылыш таба. Телдә, мифларда һәм гореф-гадәтләрдә индивидуаль аңны тәшкил иткән элементлар югары үсеш ноктасында кабатлана, ләкин индивидуумнарның үзара рухи мөнәсәбәтләре аларга яңа шартлар өсти. Телдәге, мифлар һәм гореф-гадәтләрдәге гомуми закончалыкларның характеры аерым кешенең яшәешендә һәм халыкның гомер

итүендә чагылган тарихи үсеш характеры белән янәшә тора. Тел, миф һәм гореф-гадәтләр психик процессларның өч төренә, индивидуаль психологиянең өч проблемасына (күз алдына китерү, хисләр һәм омтылыш) тиңдәш дип табыла. “Тел халык рухында яшәгән күзаллауларның гомуми формаларын һәм аларның үзара бәйләнеш законнарын үз эченә ала, – дип яза В.Вундт. – Мифлар әлеге күзаллауларның башлангыч формасын тәшкил итә, гореф-гадәтләр бу күзаллаулардан барлыкка килгән омтылышның гомуми юнәлешләрен күрсәтә”. Тел – фән белән шигъриятнең башлангычы һәм этәргече, мифлар – диннеке, ә гореф-гадәтләр исә хокук һәм әхлак принципларына карый.

В.Вундт телне рух һәм тән эшчәнлеге итеп кабул итә, ягъни, телнең нигезендә кешенең психофизиологик эшчәнлеге ята, моның белән беррәттән, ул телне авазлар ярдәмендә фикер, хис чагылышы буларак характерлый. Ул тел эшчәнлегенең психофизиологик нигезләрен – баш миендә сөйләм үзәкләренең локализациясен, сүз барлыкка килүнең психофизиологик шартларын, “сүз күзаллауларының психологиясен” җентекләп карый. В.Вундт буенча, сүз барлыкка китерү механизмы түбәндәге элементларны ала: аваз (сөйләм) теле өчен – авазларның акустик күзалланышы һәм артикуляциянең мотор рәвешендә күзалланышы; язма тел өчен – хәрефләрнең оптик күзалланышы һәм язучы кулның хәрәкәте; сөйләмнең эмоциональ төсе өчен – сүзнең мәгънәсен күзаллау һәм хис тоннарының сүз белән кушылуы.

В.Вундт фикеренчә, телләрнең берничә төргә (тамыр, агглютинатив, флектив) бүленүе халыкларның психологик үсеш баскычларына бәйле, бу исә параллель рәвештә аерым бер кешенең аң үсеше процессына тәңгәл килә. Баланың аңы дөньяны тулысынча кабул итү белән характерлана. Флексия ярдәмендә кушылмаган аерым сүзләр күплеге формасындагы балалар сөйләме тамыр телләргә туры килә. Моннан соңгы үсеш чорында, кеше аң, күз алдына китерү процессын берничә үзенчәлеккә бүлүгә һәм аларны бер ноктада туплауга сәләтле була. Психологик үсешнең әлеге баскычы агглютинатив тел формаларына тәңгәл килә. Ниһаять, аң, охшаш сыйфатларны бер төшенчәгә туплау үзенчәлегенә ия булган очракта телләрнең

үсешендә яңа баскыч – флектив телләр барлыкка килә. Тел – халыкның үзенчәлекле рәвештә үсеш алган психофизик күренешләренең бер төре.

В.Вундт тел барлыкка килүнең һәм камилләшүенең психофизиологик теориясендә моторикага, мимик-жестикуляцион һәм пантомимик хәрәкәтләргә зур игътибар бирә. Аның фикеренчә, “тел – хәрәкәтләр нәтиҗәсендә хисләрнең, күзаллауларның, төшенчәләрнең чагылышы”, шуңа күрә, ул хәрәкәтләр теленә аерым басым ясый. Аның теориясе буенча, телләрнең үсеш чорында әлеге хәрәкәтләр теле беренче баскычта урнашкан һәм авазлы телдән алда килә. Психологик юнәлешнең башка вәкилләре белән чагыштырганда, В.Вундтның бер аермалыгы була: ул да булса, тел һәм фикерләү арасындагы мөнәсәбәтләргә дөрес бәя бирү. Ул Штейнтальның ассоциатив психологиясен волюнтаристик психология белән алмаштыра һәм тел фактларының аңлатылу нигезе буларак ассоциацияне түгел, ә бәлки апперцепцияне (кеше психикасының төп сыйфатын белдерә торган процесс, бу вакытта аң элементлары ачык һәм төгәл була) кабул итә. Бу җөмлә нигезе проблемаларында аеруча ачык күренә. Ассоциатив психология өчен җөмлә – берничә күзаллауның яки сүзнең кушылуы. В.Вундт исә җөмләнең психологик нигезе буларак күзаллауларның бербөтен булып җыелуын түгел, ә киресенчә, аларның таркалуын кабул итә. Галим фикеренчә, җөмләдә бербөтен катлаулы күзаллауның бер-берсе белән логик мөнәсәбәттә торган төрле өлешләргә бүленүе чагылыш таба. Җөмлә һәм сүз арасындагы аермалык исә шунда ки, җөмлә – күзаллауның тулы чагылышы, ә сүз – чагылышның бары тик бер өлеше генә.

В.Вундт фикеренчә, бербөтен катлаулы күзаллауның таркалуы һәрвакыт бинар була. Мәсәлән, җөмләдәге беренче күзаллау субъектка һәм аның сыйфатларына, икенче күзаллау – хәрәкәт процессына һәм хәрәкәтнең объектына бәйле. Әлеге бүленешләр нигезендә бер-берсе белән логик мөнәсәбәткә кергән күзаллаулар төркеме барлыкка килә. Күзаллауларның логик бүленеше – апперцепция акты. Күзаллауларның логик зарурлык һәм логик чираттан башка барлыкка килүе исә күзаллауларның ассоциациясе дип атала. Беренче процесс,

аналитик һәм фәнни фикерләү өчен характерлы булган ябык төзелмәләр барлыкка китерә, икенче процесс исә – чынбарлыкны поэтик, синтетик юл белән чагылдыра торган структураларның мәйданга чыгуларына сәбәп булып тора.

В.Вундтның идеяләре ул чор галимнәренә зур йогынты ясый һәм XX гасырда да яңагумбольдтчыларда һәм антропологик лингвистика вәкилләрендә үсеш ала.

**А.А. Потебняның лингвистик концепцияләре**

Александр Афанасьевич Потебня Полтава губернасында украин дворяны гаиләсендә дөньяга килә. 1850-1856 елларда А.А. Потебня Харьков университетының башта юридик факультетында, соңрак тарих-филология факультетында белем ала. Аның мөгаллимлек һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлекләре нәкъ менә Харьков университеты белән бәйле дә инде (1860 елда ул магистрлык диссертациясен яклый, 1863 елда приват-доцент дәрәҗәсенә ирешә, 1874 елда “Рус грамматикасыннан өзекләр” дип аталган темага язылган докторлык диссертациясен яклый, 1875 елда исә рус теле һәм әдәбияты тарихы кафедрасының профессоры дигән дәрәҗәгә лаек була). А.А. Потебняның фәнни кызыксыну даирәсе гаять киң була: тел фәлсәфәсе, гомуми тел белеме проблемалары, грамматик теория, семантика, диалектология, славян телләренең чагыштырма-тарихи грамматикасы, шигърият, фольклор, этнография. А.А. Потебня – дөнья тел белеменең үсешенә зур көч салган тел белгече. Аның гомумлингвистик карашлары “Фикер һәм тел” (1862), “Рус грамматикасыннан өзекләр” (I, II т. – 1874, III – 1899, IV - 1941) кебек хезмәтләрендә чагылыш таба. А.А. Потебняның лингвистик теориясенең фәлсәфи нигезен И.Кант, И.Фихте, Ф.Шеллинг, Г.Гегель кебек галимнәрнең эшчәнлеге, шулай ук, В. фон Гумбольдтның тел фәлсәфәсе тәшкил итә.

А.А. Потебняның фәнни эшчәнлегендә ике чорны аерырга мөмкин. Беренче чор (1860-1865) В.Гумбольдтның идеяләрен тәнкыйди яктан аңлау, И.Гербартның психологик теориясе, М.Лацарус һәм Г.Штейнтальның этник психологиясе нигезләрендә телнең фәлсәфи-психологик теориясен барлыкка китерү белән бәйле. Фәнни эшчәнлегенең әлеге чорында ул тел

белемендә бары тик психолог һәм фәлсәфәче буларак эш итә. Икенче чорда (1865-1891) исә А.А. Потебня рус теленең диалектология, грамматика һәм фонетикасы һәм кайбер башка славян телләренә нигезләнеп эш итә.

А.А. Потебняның тел фәлсәфәсенә В.Гумбольдтның өйрәтмәләре аеруча нык тәэсир ясый. Бу өйрәтмәләргә карата уңай мөнәсәбәт аның тел күренешләрен анализлаганда психик карашларга игътибар бирүендә чагыла. Ләкин, В.Гумбольдтның күп кенә фикерләрен А.А. Потебня башка юнәлештә аңлата. В.Гумбольдттан аермалы буларак, ул рухны телгә бәйле булган акыл эшчәнлеге итеп аңлый. Төшенчәләр сүз ярдәмендә генә бирелгәнгә, рух телдән башка барлыкка килә алмый, чөнки “ул үзе дә тел ярдәмендә туа һәм тел рухта вакыт буенча беренче вакыйга булып тора”.

А.А. Потебня В.Гумбольдтның эшчәнлек буларак тел турындагы идеяләрен лингвистик психологизм күзлегеннән чыгып аңлата. Телнең нигезе, аның фикеренчә, тел формаларының чиксез камилләшүенә, телнең бертуктаусыз яңаруына һәм үсешенә юнәлдерелгән. А.А. Потебня телне бертуктаусыз сүз иҗаты буларак кабул итә, сөйләм проблемасына, аның яшәештә уйнаган роленә, сөйләмдә тел берәмлекләренең функциясенә зур игътибар бирә. Тел берәмлекләренең, аеруча сүзнең яшәеше сөйләмдә генә тормышка ашырыла. Изоляцияләнгән сүз үлгән дип санала, чөнки инде ул үзенең сыйфатларына ия түгел. Моның белән беррәттән, сөйләмдә сүз һәрвакыт фикернең бер генә актына тәңгәл килә, ягъни, әйтелгән яки аңланган вакытта бары тик бер генә мәгънәгә ия. Сүзне башка төрле кулланган очракта, аның мәгънәсендә үзгәрешләр барлыкка килә, ягъни төрле фикер-сөйләм актлары яңгырашлары ягыннан бер, ләкин мәгънәләре ягыннан төрле булган сүзләр хасил була. Сөйләмнең индивидуаль акты биредә рухи иҗатның индивидуаль-кабатланмас акты буларак кабул ителә. Шуңа күрә, А.А. Потебня тарафыннан телне эшчәнлек буларак кабул итү сөйләм характеристикасы һәм сәнгать иҗаты проблемалары белән дә тыгыз мөнәсәбәттә тора. Шушы сәбәпләр аркасында А.А. Потебня В.Гумбольдтның тагын бер идеясен – аңлау һәм

аңламау антиномиясен камилләштерә. Индивидуаль психология теориясендә әлеге идея эчтәлек субъективлыгы һәм сөйләүче, тыңлаучының фикер төрлелеге белән тыгыз бәйләнештә тора.

А.А. Потебня аңламауны бары тик сөйләүчедән чыккан фикердән читкә тайпылу белән генә түгел, ә бәлки тыңлаучының иҗади эшчәнлеге, ягъни, "үзенчә аңлау" күренеше белән дә бәйли. Тыңлаучы бу очракта үзенә ниндидер бер яңалык ача, чөнки аның тормыш тәҗрибәсе башка. Аралашу вакытында сөйләшүче ике як та бер үк хис-тойгы чылбырына мөрәҗәгать итә, шуңа күрә һәр ике сөйләшүчедә дә туры килгән, ләкин бер үк булмаган төшенчәләр үзәккә чыга, чөнки кешеләрнең индивидуаль тәҗрибәсе һәм хатирәләре төрле. Шушы күренеш фикерне башка кешегә җиткергәндәге аңлашылмаучылыкны тудыра да инде, чөнки "сөйләү – үз фикереңне башка кешегә тапшыру түгел, ә башка кешенең фикерләрен уяту гына".

А.А. Потебня тел һәм фикерләү мөнәсәбәтенә зур игътибар бирә. Аның өчен телнең килеп чыгу проблемасы – телдән алда торган рухи яшәү күренешләренең проблемалары, аның барлыкка килү һәм камилләшү законнары, аның рухи эшчәнлеккә тәэсире, ягъни, психологик проблема. Галим фикеренчә, тел белән фикернең өйрәнү даирәләре берничек тә туры килми, чөнки кешелек тарихында фикер һәрвакытта да тел белән бәйле булмаган. "Кешелек үсешенең урта дәрәҗәсендә фикер сүз белән бәйле булырга мөмкин", ләкин башта ул, күрәсең, сүз дәрәҗәсенә кадәр үсеп җитмидер, "ә кешелек үсешенең югары дәрәҗәсендә исә фикер сүздән баш тарта". А.А. Потебня ассызыклаганча, фикер һәм тел арасындагы туры килмәүләр, мәсәлән, музыкант, шахматчы, рәссам иҗатында очрарга мөмкин, ә математикада исә төшенчәләр бөтенләй сүз ярдәмендә түгел, ә шартлы билгеләр ярдәмендә белдерелә. "Шуның белән беррәттән, – дип ассызыклый ул, – тел – аерым бер кеше фикеренең мөһим шарты", "кеше беренче булып нәкъ менә сүздә үзенең фикерен аңлый", кеше төшенчәләренең системасында сүз генә һәр әйбернең үз урынын билгели.

А.А. Потебня интерпретациясендә, фикерләү эшчәнлеге берничә этапны үз эченә ала: мин нәрсәне күрәм (предмет) > кабул ителгән предметның характерлы сыйфаты (эчке форма) >

предметның хисси образы (кабул итү күплеге) > күз алдына китерү (кабул итүләрне чагыштыру) > апперцепция (фикернең беренче акты) > төшенү (фикерләүнең төп формасы) > аңлау (төшенүләр күплеге).

Фикерләү һәм тел арасындагы мөнәсәбәтләрнең камилләшүе түбәндәгечә бара: ул сүзгә кадәрге фикерләүдән образлар ярдәмендә образлы фикерләү аркылы, сүз белән ассоциацияләнгән, сүзләр ярдәмендә төшенчәләр белән фикерләүгә кадәр юл үтә. Әлеге процесста мөһим роль сүзгә бәйле, сүз ярдәмендә предметның образы предмет хакындагы төшенчәгә әверелә. Фикернең эчтәлеге – образ яки төшенчә. Фикернең үсешен, образның төшенчәгә әверелүен сүз көйли. Фикер сүз ярдәмендә идеальләшкән, хис-тойгылардан азат ителгән саен, сүз акрынлап үзенең образлылыгыннан аерыла.

А.А. Потебняның лингвистик теориясендә сүз турындагы өйрәтмәләр төп урынны алып тора. Аның фикеренчә, тел тарихының төп максаты – сүзнең, шәхеснең табигатькә карата мөнәсәбәтен белдерү, системалар рәтен барлыкка китерүдә катнашын билгеләү. Кешенең ярсыткычларга реакция күрсәткән рефлектор тойгылары (ачлык хисе, курку, авырту кебек предметларга бәйле хисләр) сүз барлыкка килүнең нигезендә ята. Кабул ителгән күзаллаулар сүзнең мәгънәсен мотивлаштыралар, предметның образын түгел, ә бәлки образның образын бирәләр. Әлеге образны А.А. Потебня эчке форма дип атый. Сүзнең эчке формасы аныңча ике баскычлы табигатькә ия. Беренчедән, эчке форма – предмет образының үзәге, аның башка сыйфатлардан өстен булган, үзенең нигезе буларак предметның исемен алган сыйфатларының берсе. Мәсәлән, рус телендәге *подснежник* сүзенең эчке формасы – бу үсемлекнең исемендә теркәлгән сыйфатларыннан берсе, ягъни, яз башында, әле кар эреп беткәнче кар астыннан чыгу. Биредә эчке форма исә – күзаллау үзеге сүзнең иң якын мәгънәсе дә, ягъни, бер сыйфатны үз эченә алган этимологик, халыкчан, барлык кешеләр өчен дә уртак мәгънә. Икенче очракта сүзнең эчке формасында беренчел образны югалту (күзаллауның таркалуы) мәйданга чыга. Мәсәлән, рус телендәге *окно* сүзе рама белән пыяланы аңлата, шул ук вакытта, рус телендәге *око* сүзе белән булган

охшашлыгын күздә тотып фикер йөрткәндә, ул я нәрсәдер аша карауны, яки нәрсәдер аша яктылыкның узуын аңлата. Сүзнең тарихи үсеш процессында аның беренчел эчтәлеге онытыла, авазы тагы да актуаль мәгънә йөртә башлый. Сүзнең эчке формасы субъектив мәгънәне алмаштырган билге яки символга әйләнә. Мәсәлән, бала, лампаның түгәрәк калпагын *карбыз* буларак билгеләгән очракта, беренче сүзнең мәгънәсеннән яңа сүзгә бары тик бер сыйфат – шарсыман булу күчә. Әлеге сыйфат – сүзнең мәгънә билгесе, ул беренчел образ күрсәткече түгел, бәлки аваз күрсәткече, ягъни, билгенең билгесе, башкача әйткәндә, бер-берсе белән чагыштырылган ике катлаулы фикерләү берәмлегенең үзара чагыштырылу нигезе.

Шунысы игътибарга лаек: А.А. Потебня эчке формага төгәл генә аңлатма бирми. Ул берничә ел дәвамында эчке формага хас төрле билгеләрне тасвирлый, шуның соңгысына таянып фикер йөрткәндә, эчке форма – күзаллау һәм сүзнең этимологик формасы, шулай ук иң кечкенә мәгънә, ләкин әлеге мәгънәдән башка сүз – сүз була алмый. Күзаллаулы сүзнең күзаллаусыз сүзгә әверелүе сүзнең мәгънә ягыннан киңәюен аңлата, бу исә поэтик сүзнең прозаик сүзгә әйләнү сәбәбе дә булып тора.

А.А. Потебня телне үзара тыгыз бәйләнештә булган һәм үзара мөнәсәбәткә кергән элементлар системасы буларак кабул итә. Әлеге системадагы теге яки бу күренеш башка күренешләр белән элемтәдә тора, моның белән исә тел системасы төшенчәсенең формалашуы башлана. Тел системасы – төрле вакыт катламнарының күплеге. Телдә элек мөнәсәбәттә булган күренешләр вакыт узу белән яңа күренешләрнең нигезенә әйләнә, кайчак ул күренешләр, башка шартлар һәм нигезләр булу нәтиҗәсендә, үзгәртелеп корылырга да мөмкин. Тел исә һәрвакытта да тышта калган төрле характердагы катламнар белән күзгә ташланырга омтыла.

А.А. Потебня фикерләү категорияләре буларак грамматик категорияләрнең барлыкка килү һәм үзгәрү процессларына зур игътибар бирә. “Рус грамматикасыннан өзекләр” дип аталган дүрт томлык хезмәтендә ул тел һәм фикерләү эволюциясенең төп юнәлешләрен өйрәнә. Хезмәтнең беренче һәм икенче томнарында җөмлә кисәкләре һәм аларның тарихи

үзгәрешләренә игътибар бирелә, өченче томда исә исем һәм сыйфатның борынгы сыйфат фигыльдән барлыкка килүе турында языла, дүртенче томда фигыль һәм башка сүз төркемнәре турында сүз алып барыла.

А.А. Потебня хезмәтләрендә җөмләгә зур игътибар бирелә, чөнки ул җөмлә һәм фикер үзара төзелешен бәйли. Шул сәбәпле ул төрле тип җөмләләрнең эволюциясен билгеләргә тырыша. Җөмлә үсешендә галим ике чорны – борынгы һәм бүгенге көнне аерып чыга. Җөмләнең борынгы тибы исем белән бәйле булган, ә бүгенге көн тибы фигыль элементының беренче урында торуы белән характерлана. Әлеге ике тип фикер үсешенең ике этабына тәңгәл килә. Беренче этап предметларны, сыйфатларына игътибар бирмичә, конкрет рәвештә кабул итү белән характерлана. Бу исемле тел төзелешендә чагылыш таба. Икенче этапта исә, кешенең абстракт фикер йөртүгә бәйле сәләте ачыклана, кеше фикер һәм сөйләм бердәмлегеннән күзалланган предметны аның предметы, сыйфатлары һәм хәрәкәтләре ягыннан аерып карый башлый. Бу исә җөмләдә фигыльнең роле артуга китерә. Җөмләнең үсеше һәм үзгәреше грамматик категорияләрнең үсеше һәм үзгәреше белән тыгыз бәйләнгән, бу беренче очракта сүз төркемнәренә кагыла. А.А. Потебня фикеренчә, нәкъ менә җөмләдә формалар кушылмасы гына түгел, ә бәлки сүз төркемнәре үзләре дә үзгәрә.

А.А. Потебня буенча, беренче сүзләр ролен ымлыклар, яки нигезләрендә хис-тойгы образлары яткан сүзләр үтәгән. Әлеге сүзләр исем дә, сыйфат та, фигыль дә булмаган; охшашлыклары ягыннан алар, беренче чиратта, фигыльгә түгел, ә исемгә тартканнар. Галим аларны беренчел образдагы сыйфат фигыльләр дип атый, алардан исем, субстанциянең грамматик категориясе килеп чыккан. Алга таба исә исемдәге предметлык билгесе арткы планга китә, беренче рольгә сыйфатлык билгесе чыга, бу исә яңа грамматик категория – сыйфатның барлыкка килүенә китерә. Моннан соң субстанция категориясе (исем) процесс, хәрәкәт, көч, энергия категориясе тарафыннан кысрыклана һәм фигыль барлыкка килә. А.А. Потебня фикеренчә, фигыль исемне кайда алмаштыра ала, аны шул

җирдә кысрыклый башлый. Хәзерге чорга якынайган саен, җөмләдә фигыльнең роле арткannan арта бара.

А.А. Потебня грамматик форманы семантик-синтаксик төшенчә буларак кабул итә, тел сөйләмендә башка сүзләр һәм формалар белән бәйле рәвештә ачыкланырлык форма юк, дип ассызыклый. Аныңча, грамматик форманы аваз белән чагыштырырга ярамый, чөнки грамматик форма – иң элек мәгънә, ә кайбер очракларда күп кенә грамматик формалар аваз ягыннан билгеләнми. Грамматик формалар сүзнең формаль элементлары белән һәм аның синтаксик бәйләнешләре ярдәмендә белдерелергә мөмкин. Потебня грамматикасында "грамматик форма", "грамматик категория" һәм "сүз төркеме" төшенчәләренең үзара мөнәсәбәтләрен өйрәнә. Грамматик категорияләрне һәм сүз төркемнәрен ул рубрикалар буларак кабул итә, әлеге рубрикалар ярдәмендә безнең күзаллауларыбыз фикернең төрле актлары буларак классификацияләнә. Грамматик категорияләр лексик категорияләр, сүзнең предмет мәгънәсе белән дә тыгыз бәйләнгән, чөнки теге яки бу сүзнең предмет һәм формаль мәгънәләре икесе дә фикернең бер акты буларак эш итәләр. Грамматик һәм лексик мәгънәләрнең кушылуы телдә төгәл система булдыра торган грамматик форма ярдәмендә башкарыла.

А.А. Потебня лингвистик тикшеренүләрендә грамматик категорияләр семантикасына, телнең поэтик образлылыгына игътибарын юнәлтә. Аның фикеренчә, тел һәм телдәге һәрбер аерым сүз стихиясе буенча гына түгел, ә бәлки кушылу ысуллары буенча да сәнгатькә тәңгәл. Эчке форма теориясе белән бәйле рәвештә, А.А. Потебня тел символизмын аның шигърилеге буларак кабул итә, ә эчке форманың "сулуын", юкка чыгуын – прозачылык буларак карый. А.А. Потебняның сәнгать сүзе теориясе аның "сәнгать – рәссамның теле" дигән фикеренә нигезләнеп алга бара. Аныңча, сүз ярдәмендә кешегә үзеңнең фикереңне җиткереп булмый, ә бары тик кешедә аның фикерен генә уятып була, ул фикерне шулай ук сәнгать эшчәнлегендә дә тапшыру мөмкин түгел. Шул рәвешле, сәнгать эчтәлеге рәссамда түгел, ә бәлки ул сәнгатьне кабул итүчеләрдә уяна.

Шулай итеп, А.А. Потебняның гомумлингвистик концепциясе лингвистик психологизмның фикер белән телнең уртак үсеше турындагы нигез идеяләренә таяна. Фикернең тууы аның тел белән якын мөнәсәбәттә булуын дәлилли. Фикер тел эшчәнлеге белән башланып китә һәм үзенең категорияләрендә – күзаллауларда, образларда, төшенчәләрдә тел категорияләре һәм формалары барлыкка килү белән бер үк вакытта мәйданга чыга. А.А. Потебня, телнең төп чынбарлыгы тел булуын ассызыклап, телне халыкның шигъри иҗаты, гореф-гадәтләре белән мөнәсәбәттә өйрәнә, шуның белән беррәттән, рус диалектологиясе һәм этнографиясенә зур ачышлар китерә. Галим телнең грамматик формалары, грамматик төзелеше үзгәрешен фикерләү формаларының үзгәреше белән бәйли һәм төгәл грамматик теория барлыкка китерә.

Психологик юнәлеш, ассоциатив психологиянең төшенчәләренә һәм терминнарына таянып, телне тарихи һәм динамик күренеш буларак кабул итә, тел һәм фикерләү арасындагы тыгыз мөнәсәбәтләрне ассызыклый. Психологик юнәлеш вәкилләре тере телнең сөйләм актларын өйрәнүгә зур игътибар бирәләр, алар фикеренчә, бу телнең нигезен һәм килеп чыгышын билгеләргә, шулай ук аның эчке төзелешен һәм тел формаларының камилләшүен күзалларга ярдәм итә. Алар тел берәмлекләренең формалашуына зур басым ясыйлар, аны психологик законнар – ассоциация, ассимиляция, апперцепция нигезендә аңлатырга тырышалар. Лингвистик психологизм тел белеменең фән буларак формалашуына йогынты ясый, кайбер концепцияләренең (телне психологик яктан анализлауга нигезләнгән – младограмматизм, этнолингвистика, А.Мартиның универсаль грамматика теориясе) камилләшүенә китерә. XX гасырның 50 нче елларында барлыкка килгән психолингвистика психологик юнәлешнең яңа этабы буларак кабул ителә.

**Тел белемендә логик юнәлеш**

Инде Аристотель логикасында ук логик һәм грамматик категорияләр арасындагы мөнәсәбәтләр проблемасы күтәрелә. Пор-Рояль грамматикасы исә логик-грамматик категорияләрнең универсальлеген ассызыклый. Рациональ грамматикадан

аермалы буларак, XIX гасырның беренче яртысындагы тел белемендә логик юнәлеш тел формасының милли үзенчәлегенә, логика һәм тарихилыкның бердәмлегенә күбрәк игътибар бирә.

Тел белемендәге логик юнәлешнең аермалы сыйфаты – телне логик проблема буларак кабул итү: семантика – логик категорияләр һәм операцияләр белән, ә тел формалары – логик формалар һәм фикерләүләр белән чагыштырыла. Лингвистик логизм күзлегеннән чыгып фикер йөрткәндә, семантик рәвештә сүз – төшенчә, җөмлә – төшенү, ә катлаулы җөмлә – нәтиҗә чыгару буларак кабул ителә. XIX гасыр башы һәм уртасы логик-грамматик юнәлеш вәкилләре телнең төп берәмлеге буларак – җөмләне, ә категория буларак сүз төркемен билгелиләр. Грамматиканың төп максаты логик категорияләргә тәңгәл килгән тел формаларын эзләп табу була. Мәсәлән, К.Ф. Беккер фикеренчә, логикада 12 элемент һәм 81 бәйләныш бар. Шулай ук синтаксис категорияләре интерпретациясендә дә логик карашның телгә карата мөнәсәбәте югары була. И.И. Давыдов "синтаксис я төшенчәләрнең логик мөнәсәбәтен һәм аларның чагылышын, яки фикерләрнең логик мөнәсәбәтен һәм чагылышын өйрәнә," ди. Сүз классларын билгеләгәндә, беренче чиратта, аларның теге яки бу синтаксик функцияләрне башкаруларына ишарә ясала. Мәсәлән, исемнәр "ия сүзләре" буларак билгеләнә, хәбәр функцияләрен башкаручы сүзләр дә аерым төркемгә кертелә.

К.Ф. Беккер (1775-1849) "Тел организмы" (1827) дип аталган хезмәтендә логика законнарын немец теле материалына карата куллана. Ул телне органик каршылыклар буларак кабул итә, аныңча, әлеге каршылыклар бер-берсен юкка чыгармый, бәлки тулыландыра һәм организмның бербөтен буларак камилләшүе өчен бер-берсенә катгый рәвештә кирәк дип табыла. Ф.И. Буслаев фикеренчә, К.Ф. Беккерның сүз төркемнәрен һәм җөмлә кисәкләрен логик-семантик принцип буенча бүлгән схемасы "сүз төркемнәрен һәм җөмлә кисәкләрен дөрес билгеләгән" һәм күп кенә телләрнең грамматикаларында озак вакыт буена алдынгы роль уйнаган. Әлеге схемада җөмләләр һәм аларның компонентлары логик фикер йөртү һәм аның өлешләре белән тәңгәл килә.

Рус тел белемендә логик юнәлешнең төп вәкиле – Федор Иванович Буслаев (1818-1897). Ул ярлы өяз стряпчие (суд эшләрен алып бару тәртибен күзәтүче чиновник) гаиләсендә дөньяга килә. 1838 елда Мәскәү университетын тәмамлый, 1847 елдан әлеге университетта рус теленнән лекцияләр укуга керешә. Ф.И. Буслаев, Россиядә беренчеләрдән булып, һинд-европа телләренең чагыштырма грамматикасын һәм рус теленең тарихи грамматикасын укыта башлый. Аның лингвистик карашлары аның “Ватан телен укыту турында” (1844), “Рус теленең тарихи грамматикасы” (1858) дип исемләнгән төп хезмәтләрендә чагылыш таба.

Ф.И. Буслаев телне өзлексез иҗади процесс буларак кабул итә. Аның фикеренчә, бүгенге көн сөйләме – “меңьеллык тарихи хәрәкәт һәм күпсанлы үзгәрешләр нәтиҗәсе”. Шуңа күрә аны бары тик генетик юл белән генә билгеләргә була, бу исә тарихи тикшеренүләрнең зарурлыгына китерә. Ф.И. Буслаев тел күренешләренең чагыштырма һәм тарихи карашларын логик башлангычлар белән бәйли. Аныңча, тарихилык принцибы логика һәм грамматика арасындагы чикләрне төгәл билгели, тел һәм фикерләү арасындагы элемтәне ассызыклый. Романтиклар белән беррәттән, тел үсешендә ике чорны – иң борынгы һәм иң соңгы чорларны аерып, Ф.И. Буслаев иң борынгы чорны сурәтләү күзаллавы буларак характерлый. Әлеге чорда фикернең чагылышы хисләрнең һәм сөйләм теленең үзенчәлекләренә аеруча тәңгәл килә, ди ул. Иң соңгы чорда тел иҗаты инде тәмамлана һәм тел үлеп баручы организм ролен үти башлый. Әлеге чорда тере хисләрне һәм сөйләм барышында кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне белдергән сүзләр гомуми абстракт төшенчәләр мәгънәсенә ия була. Тарихи үсеш нәтиҗәсендә тел логикасы барлыкка килә, яңа чорда телнең борынгы чорындагы поэтик формасы урынын формаль логика ала. Тарихилык принцибы һәм романтик-фәлсәфи караш нигезендә, Ф.И. Буслаев “Рус теленең тарихи грамматикасы” дип исемләнгән хезмәтендә грамматик формаларның, рус теле категория һәм конструкцияләренең тарихи экскурс һәм комментарийлар белән параллель алып барылган аңлатмасын бирә. Әлеге аңлатмалар күпсанлы борынгы рус язулары, халык

шивәләре, халык авыз иҗаты һәм XVIII-XIX гасырларга караган әдәби ядкәрләргә нигезләнгән. Телдә халыкның бөтен тормышы чагыла – нәкъ менә шушы фикер Ф.И. Буслаев хезмәтләренең нигезе булып санала.

Романтик-фәлсәфи элементның бөтен мөһимлеген күздә тотып эш итүенә карамастан, Ф.И. Буслаев хезмәтләрендә лингвистик логизм беренче урында тора. Аның фикеренчә, грамматика логик башлангычка таянырга тиеш, чөнки бүгенге көн телләренең синтаксисында "алдынгы рольләрне этимологик форма түгел, ә логик законнарның абстракт мәгънәсе үти". Ф.И. Буслаев буенча, барлык сүзләр – гомуми күзаллауларның яки төшенчәләрнең исеме. Телнең төп функциясе – фикерне сүзләр ярдәмендә чагылдыру. Сүзләр ярдәмендә чагылган төшенү – ул җөмлә. Сүз төркемнәре исә фикернең төрле формалары буларак кабул ителә.

Ф.И. Буслаевның грамматик теориясе үзәгендә җөмлә тора. Аның өйрәтмәләре нигезендә, логик карашка таянып фикер йөрткәндә, җөмләдә бары тик ике кисәк – ия һәм хәбәр булырга мөмкин. Хәбәрне иягә кушу төшенүне барлыкка китерә. Хәбәрдә төшенүнең барлык көчләре дә тупланган, аннан башка төшенү була алмый, шуңа күрә телдә бары тик хәбәрдән торган җөмләләр бар, ә менә составында ия генә булган җөмләләр юк. Исем җөмләләр булу фактын галим кире кага. Ярдәмче җөмлә кисәкләре җөмләнең баш кисәкләрен ачыклый һәм тулыландыра. Ф.И. Буслаев фикеренчә, иярчен җөмләнең төп сыйфаты – баш җөмләдәге хәбәрдән кала башка бер кисәк белән тәңгәлләшә алу.

Элекеге грамматик традицияләрдән аермалы буларак, Ф.И. Буслаев морфология һәм синтаксисны аера, сүз төркемнәрен өйрәнүдә морфологик (сүз ясалышы һәм сүз төрләнеше) һәм синтаксик үзенчәлекләрне (сүз төркемнәренең мәгънәсе һәм кулланылышы) аерып чыгара. Галим тәкъдим иткән ярдәмче җөмләләр һәм җөмләнең иярчен кисәкләр классификациясе мәктәп практикасында рус телен өйрәтүдә йөз елдан артык кулланыла.

Ф.И. Буслаев фикеренчә, синтаксик теория телнең бербөтенлеген, аның системалылыгын күздә тотып төзелергә тиеш. Телнең барлык төзелеше – аерым бер аваздан башлап,

җөмләгә һәм җөмләләр күплегенә кадәр – бер-берсен тулыландырган һәм бербөтенне барлыкка китергән аерым кисәкләрнең үзара мөнәсәбәтен күз алдында тота, дип ассызыклый ул. Аның өчен тел системасы – төрле вакытка караган күренешләрнең күплеге; телнең тарихы аның хәзерге халәте белән тыгыз бәйләнгән, чөнки ул бүгенге көндә аңсыз рәвештә кулланыла торган күренешләрне яңарта һәм аңлата.

Тел белемендә логик юнәлешнең алга таба үсеше В.А. Богородицкий, А.А. Шахматов, И.И. Мещанинов һәм башка тел белгечләренең хезмәтләрендә чагыла. XX гасырда тел белеме һәм кайбер уртак фәннәрнең, мәсәлән, логика һәм математиканың үсеше нигезендә, лингвистик логизмның концепциясе үзгәрә. Бүгенге көн логик юнәлештә семасиологиягә карата кызыксыну арта, логик концепцияләрнең психологик сүз, җөмлә, сөйләм эшчәнлеге теориясе белән якынаюы алгы планга чыга, телнең логик-математик модельләшүе үсеш ала.

**Тел белемендә яшь грамматикачылык (младограмматизм)**

Яшь грамматикачылар мәктәбенең барлыкка килүе XIX гасырның ахырына карый. Яңа юнәлеш вәкилләре өлкән буынның телгә булган карашларын тәнкыйть утына тоталар, үзләренең дәртле эшчәнлекләре аркасында “яшь грамматикачылар” дигән шаян исемгә “лаек” булалар. Алга таба исә бу исем аерым бер юнәлешнең исеменә әйләнә. Яшь грамматикачылык Август Лескин (1840-1916), Карл Бругман (1849-1919), Герман Остгоф (1847-1909), Герман Пауль (1846-1921), Бертольд Дельбрюк (1842-1922) кебек галимнәргә бәйле рәвештә үсә. Алар Лейпциг университеты белән бәйле булалар, шуңа күрә яшь грамматикачыларны тел белемендә Лейпциг мәктәбе дип тә атыйлар. Әлеге юнәлешкә алга таба башка ил вәкилләре – француз тел белгече Мишель Бреаль (1832-1915), данияле тикшерүчеләр Карл Вернер (1846-1896) һәм Вильгельм Томсен (1842-1927), итальян галиме Грациадо Асколи (1829-1907), америкалы тел белгече Вильям Уитни (1827-1894), И.А. Бодуэн де Куртенэ һәм Ф.Ф. Фортунатов җитәкчелегендәге Казан һәм Мәскәү мәктәпләре лингвистлары да кушыла. Шулай

итеп, яшь грамматикачылык яңа методологияне һәм чагыштырма-тарихи тикшерү практикасына карата уңай караштa булган һәркемне үз эченә ала.

К.Бругманның һәм Г.Остгофның “Морфологик тикшеренүләр” (1878) дип аталган басманың беренче томына караган керештәге сүзләре яшь грамматикачыларның манифесты булып кулланыла башлый. Яшь грамматикачылык принциплары Б.Дельбрюкның “Һинд-европа телләрен өйрәнүгә кереш” (1880) дип аталган хезмәтендә, К.Бругман һәм Б.Дельбрюкның алты томлык “Һинд-герман телләренең чагыштырма грамматикасы нигезләре” (1886-1900) хезмәтендә, А.Лескинның “Борынгы болгар (чиркәү-славян) теленең грамматикасы” (1909) дип аталган хезмәтендә чагыла. Г.Паульның “Тел тарихының принциплары” (1880) дип аталган хезмәтендә яшь грамматикачыларның принципларын аеруча ачык һәм аңлаешлы рәвештә табарга мөмкин, әлеге китапны шулай ук яшь грамматикачылык энциклопедиясе дип тә атыйлар.

Телнең табигатенә, тел белеменең өйрәнү объектларына, фәнни өйрәнү методикаларына карашлары ягыннан, яшь грамматикачылык чагыштырма-тарихи психологик тел белемен чагылдыра. Яшь грамматикачыларның лингвистик концепциясендә үзенчәлекле сыйфат – фәлсәфәне урап узу теләге. “Тел белеме фәлсәфи чордан тарихи чорга аяк басты”, – дип ассызыклый Дельбрюк. Тарихилык – Паульның тел концепиясендә төп принципларның берсе. Аның фикеренчә, телнең тарихи үсеше хакындагы материалдан башка тел турында уйланып, уңай нәтиҗәләргә килеп булмый; галим фактларны гади констатацияләүдән читкә китеп, күренешләр арасындагы мөнәсәбәтләрне аңларга тырыша икән, димәк, ул тарих өлкәсендә эш итә башлый; тел белеме фәне мәдәни-тарихи фәннәр рәтенә керә, мәдәниятнең мөһим үзенчәлеге – психик башлангыч, димәк, тарихилык принцибы тел нигезләрен психологик яктан аңлауны күздә тота. Шуңа күрә, хәтта гади фактларның гади констатациясе турында сүз барганда да тел белеме тулысынча психологик булырга тиеш.

Пауль фикеренчә, психик оешулар индивидның күңелендә барлыкка килә, чынлыкта бары тик индивидуаль психология

генә бар, ягъни этнопсихология дигән күренеш бөтенләй юк. Шуңа күрә аның концепциясендә бары тик индивидуаль тел генә чынбарлык буларак кабул ителә. Һәрбер индивидның – үз теле, һәрбер телнең – үз тарихы бар. Алда әйтелгәннәргә таянып, Пауль мондый фикергә килә: дөньяда ничә индивид булса, шулкадәр тел дә бар. Шушы ук идея Бругман һәм Остгоф тарафыннан та ассызыклана: “Тел кешедән өстен булган яки кешедән аерым яши торган күренеш түгел; ул бары тик индивидуумда гына яши ала, шулай итеп телдәге үзгәрешләр бары тик ул телдә сөйләшүче индивидларның эшчәнлеге нәтиҗәсе булырга мөмкин”. Шулай итеп, Паульча, тарихилык һәм психологизм телне өйрәнүдә тагын бер принципны – индивидуализмны билгели.

Яшь грамматикачылык концепциясендә телне индивидуаль психофизик (психофизиологик) эшчәнлек буларак кабул итү төп рольне уйный. Тел белемендәге яшь грамматикачылыкка кадәрге чорларның төп тискәре ягы тел белеменең бары тик тел белән генә шөгыльләнеп, кешегә бөтенләй игътибар бирелмәвендә табыла, ә тел кешедән аерым рәвештә яши алмый. “Һичшиксез, яшь грамматикачылыкка кадәр булган тел белеме үзенең өйрәнү объекты саналган һинд-европа телләрен, кеше теле гомумән ничек яшәвен һәм үсеш алуын, сөйләмгә нинди фактларның йогынты ясавын, әлеге фактларның үзара мөнәсәбәте тел материалының алга таба үсүенә ничек тәэсир итүен күздә тотмыйча гына тикшерә. Тел аеруча теләк белән өйрәнелгән, ә ул телдә сөйләшүче кеше арткы планда калган”, – дип ассызыклыйлар Остгоф һәм Бругман үзләренең хезмәтендә. Сөйләшүче индивид – яшь грамматикачыларның башлангыч пункты һәм өйрәнү объекты. Кеше сөйләменең механизмында алар ике якны – физик һәм психик өлешләрне аерып чыгара, шул ук вакытта сөйләмнең физик ягына карата зурлап игътибар итүгә каршы булып, сөйләмнең психик фактларына да тиешле игътибарны таләп итәләр. Аерым бер кешенең сөйләме генә реаль дип табылса да, индивидуаль сөйләм гомумхалык сөйләменең чагылышы дип санала. Ул исә тел ярдәмендә аралашуга мөмкин бирә. Әлеге аралашу кешеләрнең психик тормышларының гомумилегенә таяна, сөйләүче һәм

тыңлаучының тел авазлары һәр ике кешедә дә бер үк күзаллау комплексын тудыра. Моның белән беррәттән, телнең үзгәрү законнары һәм сәбәпләре кешелек җәмгыятенең үсешенә түгел, ә аерым бер кешенең психикасына нигезләнә, телдәге барлык үзгәрешләр индивидның гади сөйләм эшчәнлегендә мәйданга чыга. Телгә кеше психикасы белән бәйле төрле факторлар тәэсир итә, аерым фактларны һәм факторларны тасвирлау бу рәвешле лингвистик тикшеренүнең төп эшләү ысулы санала. Шушы эмпиризм, яки атомизм, тел өйрәнүнең тагын бер принцибы буларак кабул ителә һәм яшь грамматикачылар тарафыннан төгәллек һәм фәннилек сыйфаты дип табыла. Алар фикеренчә, бары тик фактлар ярдәмендә тикшерелерлек материаллар гына фәнни кыйммәткә ия һәм алардан бернинди дә гомумиләштерүләр һәм нәтиҗәләр ясалырга тиеш түгел. Позитивизм телгә карата әлеге карашның нигезе буларак кабул ителә. Позитивизм тикшеренүләрнең позитив нәтиҗәләрен абстракт фикерләүгә каршы куя, ә фәнни теория өлкәсендә бары тик эмпирик материал ярдәмендә аргументлаштырылган шәхси гомумилекләрне генә кабул итә.

Телнең ике ягы – физик һәм психик сыйфаты яшь грамматикачыларның тел үсеше процессларының тарихи өйрәнү методларын формалаштыруларында чагылыш тапкан. Бер яктан, тел яшәешенең физиологик законнарын чагылдырган фонетик законнарны табарга һәм тасвирларга, ә икенче яктан, ассоциациянең психик законнарына нигезләнгән аналогиягә таянып, яңалыкларны билгеләргә кирәк. Тел үсешенең фонетик законнары механик юл белән һәм катгый эзлеклелек рәвешендә тормышка ашырылган, ләкин искәрмәләргә ия булмаган регуляр аваз үзгәрешләре белән характерлана. Аваз законы төшенчәсен табигать законнары, шулай ук физика һәм химия законнары белән тәңгәлләштерергә кирәкми, дип ассызыклый Пауль. Аваз законы бары тик тарихи күренешләрнең аерым бер төркеменең даимилеген генә констатацияли һәм әлеге гомуми шартлар нәтиҗәсендә мәйданга нәрсә чыгарга тиеш икәнлеге турында үзенә хисап бирми. Табигать законнарыннан аермалы буларак, аваз законы “билгеле телдә һәм билгеле вакытта” барлыкка килә һәм бары тик бу тел һәм бу вакыт өчен генә кулланылырга

мөмкин (хәзерге көн лингвистикасы бирегә тагын “билгеле шартлар һәм территорияне” өсти). Яшь грамматикачылар фикеренчә, “механик юл белән тормышка ашырылганга күрә, һәртөрле аваз үзгәреше искәрмәләре булмаган законнарга нигезләнә, ягъни, диалектик бүленештән башка, аваз үзгәрешләре барлыкка килә торган юнәлешләр тел җәмгыятенең барлык вәкилләрендә дә бер үк һәм, аваз үзгәреше астында торган авазларга ия булган барлык сүзләр дә искәрмәсез әлеге процесста катнаша”. Яшь грамматикачылар фикеренчә, сүздәге аваз үзгәреше индивидуаль сөйләм принципларыннан читкә тайпылу белән бәйле. Аларның саны арту, индивидуальлекнең гомумилеккә әверелүен китереп чыгара. Әлеге үзгәрешләр сиздермичә һәм акрынлап кына барлыкка килә. Теге яки бу телдә сөйләшүчеләр бу үзгәрешләрне сизми дә калырга мөмкин. Пауль, мәсәлән, үзгәрешләр иң башта бик вак була, соңрак ул вак үзгәрешләр тупланганнан соң, сөйләмдә җитди үзгәрешләр сизелә башлый, дип ассызыклый. Бер буында кечкенә үзгәрешләр барлыкка килә ала. Аваз үзгәрешләре фонетик законнар нигезендә генә килеп чыкмаска да мөмкин, ләкин ул үзгәрешләрне законга нигезләнеп кенә кулланырга кирәк.

Фонетик үзгәрешләрне өйрәнгәндә яшь грамматикачылар кайбер аваз законнарын (мәсәлән, ачык иҗек законы, беренче һәм икенче палатализация, Лескин хезмәтендә чиркәү-славян телендәге **j** авазының сузык һәм тартыкларга тәэсире) билгелиләр һәм тасвирлыйлар, бер тел эчендә һәм берничә тел арасында аваз охшашлыкларын билгеләү өчен төзек һәм уңайлы система булдыралар.

Аналогия законы сөйләүче сөйләменең актив характерын кабул итү нигезендә барлыкка килә. Ул, пропорцион тигезләмәләрне чишүне хәтерләткән ассоциатив комбинатор эшчәнлеккә нигезләнә, ягъни, гади пропорцияләрне белеп, кеше әлеге мөнәсәбәтләр нигезендә пропорциянең икенче кисәген дә китереп чыгара. Мәсәлән, русчадагы *дом* сүзенең өч элемент мөнәсәбәтен белеп: *домов* = *стол* : *x*, бирдә *x* = *столов* формасын җайлы гына китереп чыгарырга була. Формаларның аналогия нигезендә барлыкка килүе балалар сөйләмендә аеруча

еш очрый. Мәсәлән, К.Чуковскийдан ике дүрт яшьлек кызчык арасындагы диалог:

- А я твоего петушка *спря-та-ю* (сузып).
- А я *отыскаю*.
- А ты не *отыскаешь*.
- Ну, тогда я *сядаю* и *заплакаю*.

Аналогиянең эшчәнлеге грамматик формаларга, сүз ясау типларына һәм аваз чиратлашуына да тарала. Яшь грамматикачыларда аналогия телнең грамматик системасының куәтле рәвештә сүтелеп корылыш факторы буларак кабул ителә. Моның белән берргәттән, аналогия, телнең үзгәрүчәнлеген юкка чыгара алмый, сүзнең мәгънәсе аеруча зур үзгәрешләр тәэсире астына эләгә. Сүзләрнең мәгънәсе үзгәрүен Пауль индивидуаль психиканың тотрыксыз булуында күрә, бу исә, үз чиратында, сүзнең узуаль һәм окказиональ мәгънәләре арасындагы чикләрнең бозылуына китерә. Аның фикеренчә, узуаль мәгънә – "теге яки бу тел җәмгыяте вәкиле өчен теге яки бу сүзнең булган барлык мәгънәләренең күплеге", ә окказиональ мәгънә исә "сөйләүче тарафыннан ул сүзне әйткән вакытта күз алдына китергән күзаллаулары" һәм бу күзаллауларны тыңлаучы да әлеге конкрет сүз белән бәйли. Сүзнең узуаль мәгънәсе – контексттан тыш мәгънә, ә окказиональ мәгънә индивидуаль сөйләм актында конкретлаша. Мәсәлән, рус телендәге *осёл* (хайван) сүзенең мәгънәсе узуаль, ә аның конкрет "акылсыз кеше" мәгънәсе – окказиональ мәгънә. Узуаль сүз күпмәгънәле дә булырга мөмкин, окказиональ сыйфатта исә ул берәү генә. Пауль сүз мәгънәләренең үзгәреше классификациясен барлыкка китерә, әлеге классификация бераз төзәтмәләр кертелгән хәлдә әле дә кулланылышта. Сүз мәгънәләре үзгәрүнең төп төрләренә ул түбәндәгеләрне кертә: мәгънәнең тараюы яки специальләшүе (татар телендәге *балык* сүзе русчадагы *ыслап какланган мәрсин балыгы сырты*на туры килә); мәгънәнең киңәюе (русча *дом* – бинаны аңлата, *дом* шулай ук – туып үскән җир); ассоциатив бәйләнешләр нигезендә мәгънәнең күчүе: метафора, метонимия, синекдоха; башка очраклар – литота, гипербола, эвфемизмнар.

Яшь грамматикачылар шулай ук тере телләрне һәм диалектларны өйрәнүнең мәҗбүрилегенә дә басым ясый.

Телләрне чагыштырма өйрәнү белән шөгыльләнгән галим, телнең үсеше хакында дөрес фикердә буласы килсә, үзе яшәгән чорга күз салырга тиеш. Бу телләрдә әле дә сөйләшәләр, алар безнең алдыбызда һәм бездә яши икән, димәк, ул телләрдәге психологик элементны тоярга була. Сөйләмнең физик һәм психик механизмнарына, элеккеге аваз формаларын саклап калган җанлы халык шивәләренә күз салу, язма ядкәрләрне генә куллануга караганда, тел гомере хакында тулы сурәт күз алдына китерергә ярдәм итә. Дөресен әйткәндә, яшь грамматикачылар шул ук һинд-европа баба теле материалларын бераз яңартылган методикалар нигезендә кулланганнар.

Чагыштырма-тарихи тел белемендәге романтик юнәлеш телне рухи башлангыч әсәре буларак кабул иткән, лингвистиканың максатын халык авыз иҗаты һәм борынгы әдәбият нигезендә һинд-европа рухи мәдәниятенең гомуми нигезләрен реконструкцияләүдә һәм тасвирлауда күргән. Тел системасы үсешенең төп факторлары һәм сәбәпләре халыкның рухи һәм мәдәни яшәеше үзгәрүдә, ягъни, телдән читтә каралган. Яшь грамматикачылар исә, тел үзгәрешләренең төп сәбәпләрен эчке лингвистик факторларда – телнең төзелешендә күрәләр. Ул төзелешнең эшчәнлеге нәтиҗәсендә тел үзеннән-үзе камилләшә, бу исә телне табигый-тарихи объектлар белән туганлаштыра. Телнең табигый-тарихи үсеше аваз сферасында һәм аваз барлыкка китерү физиологиясе өлкәләрендә индивидуаль яки коллектив психологик тайпылулар нәтиҗәсендә мәйданга чыга.

Яшь грамматикачылык юнәлеше, аның күренекле вәкилләре 50 елга якын вакыт эчендә тел белемендәге иң йогынтылы юнәлешләренең һәм мәктәпләренең берсе буларак кабул ителә. Мәсәлән, В.Д. Уитни, үзенең хезмәтләрендә телдә иҗтимагый һәм индивидуаль күренешләрне аера, тел турындагы мәсьәләне, беренче чиратта, иҗтимагый күренеш буларак карый. Тел тарихы белән җәмгыять арасындагы бәйләнешне Ф.Ф. Фортунатов җитәкчелегендәге Мәскәү лингвистика мәктәбе дә ассызыклый. Лейпциг яшь грамматикачыларыннан аермалы буларак, И.А. Бодуэн де Куртенэ җитәкчелегендәге Казан лингвистика мәктәбе исә, гомумлингвистик проблемаларны күтәрә, киң фәнни гомумилекләргә тартыла.

**Мәскәү лингвистика мәктәбе**

XIX-XX гасырлар чигендә Мәскәү университеты кысаларында үзенең методологик максатлары белән Лейпциг мәктәбенә якын булган тел белгечләре төркеме формалаша. Әлеге галимнәр төркеме *Мәскәү лингвистика мәктәбе* исемен йөртә башлый. Яшь грамматикачыларның индивидуаль психологизмының төп идеяләрен методологик принцип буларак кабул итеп, Мәскәү лингвистика мәктәбе бер үк вакытта үзенең лингвистик тикшеренүләрендә телне иҗтимагый феномен буларак өйрәнүгә дә зур игътибар бирә, әдәби тел формалашуга ярдәм итә, бу исә аны социологик юнәлеш һәм Прага лингвистика түгәрәге белән туганлаштыра. Мәктәпкә нигез салучы һәм киләчәктә аның җитәкчесе – Филипп Федорович Фортунатов (1848-1914) – XIX-XX гасырлар чигендәге иң бөек рус тел белгечләреннән берсе. Ф.Ф. Фортунатовның шәкертләре һәм дәвамчылары: иң күренекле компаративистларның берсе – Виктор Карлович Поржезинский (1870-1929), гомуми тел белеме буенча белгеч Александр Иванович Томсон (1860-1935), танылган грамматикачы Александр Матвеевич Пешковский (1878-1933), танылган лексикограф Дмитрий Николаевич Ушаков (1878-1942), рус теле тарихы белән шөгыльләнүче Алексей Александрович Шахматов (1864-1920), борынгы славян теле өлкәсендәге белгеч Борис Михайлович Ляпунов (1862-1943), чагыштырма-тарихи семасиологиягә нигез салучы Михаил Михайлович Покровский (1869-1942) һәм күп санлы чит ил тел белгечләре.

Ф.Ф. Фортунатов Вологда шәһәрендә укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Булачак галимдә бала чагыннан ук тел өйрәнүгә кызыксыну уяна. 1868 елда ул Мәскәү университетын тәмамлый, аның төп укытучысы Ф.И. Буслаев була. 1871 елда Фортунатов ике елга Германиягә, Франциягә һәм Англиягә җибәрелә, биредә ул борынгы һинд Ведаларын өйрәнү өстендә эшли, Лейпцигта Лескин һәм Курциус лекцияләрен тыңлый, Парижда М.Бреаль биргән дәресләрдә катнаша. 1875 елда Ф.Ф. Фортунатов магистрлык диссертациясен яклый, әлеге диссертациядә Ведаларның бер өлеше – Самаведаның рус теленә тәрҗемәсе һәм аңлатмасы тәкъдим ителә. 1876 елның гыйнвар аенда

Ф.Ф. Фортунатов Мәскәү университетында лекцияләр укый башлый һәм бу эшчәнлеген 1902 елга кадәр дәвам итә. 1898 елда аны Россия Фәннәр Академиясе әгъзасы итеп сайлыйлар һәм 1902 елдан башлап ул биредә Рус теле бүлеген җитәкли һәм кайбер академик басмаларны редакцияли. Төрле елларда Ф.Ф. Фортунатов Мәскәү университетында гот, литва, борынгы славян, санскрит телләре буенча, тел белеменең гомуми мәсьәләләре, һинд-европа телләренең чагыштырма фонетикасы һәм морфологиясе буенча лекцияләр алып бара. Аның язмалары еш кына матбугатта күренә, үзенең идеяләрен лекция материалларында камилләштерә. Ф.Ф. Фортунатовның төп хезмәтләре: “Чагыштырма тел белеме” (1898, 1900), “Һинд-европа телләренең чагыштырма фонетикасы” (1902), “Чагыштырма морфология” (1901), “Борынгы славян (чиркәү-славян) теле буенча лекцияләр” (1919). Бары тик Ф.Ф. Фортунатовның үлеменнән соң гына, 1956-1957 елларда аның сайланма хезмәтләре ике томда басыла. Әлеге эшне аның укучылары – М.М. Покровский, Б.М. Ляпунов, М.Н. Петерсон башкарып чыга.

Ф.Ф. Фортунатовның фәнни мирасы, бер яктан, телгә карата яшь грамматикачылык карашы белән, икенче яктан, гомумлингвистик проблематика һәм телнең иҗтимагый ягына игътибар белән характерлана. Үзенең хезмәтләрендә галим, беренче чиратта, һинд-европа телләренең чагыштырма фонетикасы һәм грамматикасына зур өлеш керткән бөек компаративист буларак танылa. Шулай ук славян телләрендәге беренчел һәм икенчел палатализацияләр, тарихи акцентологиянең барлыкка китерелүе һәм, Ф. де Соссюр белән бер үк вакытта диярлек, балтыйк һәм славян телләрендә басым күчү законын (Фортунатов-Соссюр законы) билгеләү аның исеме белән бәйле. Аның эшләрендә гомуми тел белеме мәсьәләләре, мәсәлән, тел һәм фикерләү мөнәсәбәте, телләрнең типологик классификациясе, грамматик теория һ.б. төп урынны алып тора.

Һинд-европа телләренең чагыштырма-тарихи грамматикасын Ф.Ф. Фортунатов гомуми тел белеменең бер өлеше буларак кабул итә. Аныңча, бу фәннең өйрәнү объекты – “аерым бер тел

яки аерым бер телләр төркеме түгел, ә бәлки үзенең тарихы эчендә гомумән кеше теле”. Һәр телнең билгеле бер вакытта яшәеше аның өзлексез үзгәрүеннән гыйбарәт, һәрбер тел үз чоры өчен алдагы чорга карата үзгәргән форма буларак кабул ителә. Тарихилык тел фактларын вакыт үзгәрешендә өйрәнүне кулай күрә. Барлык өйрәнелә алган телләрне тарихи яктан өйрәнү телләрне чагыштырма юл белән тикшерү өчен дә мөһим, чөнки, Ф.Ф. Фортунатов фикеренчә, конкрет бер телнең тарихын башка телләрнең тарихы белән чагыштырганда, лингвист бу телнең әле башка телләр белән кардәшлек чорындагы фактларына кадәр ачыкларга мөмкин. Аерым бер телнең тарихын өйрәнү тикшеренүчене халыкларның уртак бер баба телдә сөйләшә торган чорга кайтарырга мөмкин. Шулай итеп, телгә карата тарихи караш “телләр арасындагы кардәшлекне билгеләү һәм тарих битләрендә бер юлдан барган, ягъни кардәш телләрнең чагыштырма юл белән өйрәнелүен таләп итә”.

Моның белән беррәттән, Ф.Ф. Фортунатов өчен чагыштырма-тарихи юл белән тел өйрәнү бердәнбер метод түгел: “төрле телләрнең фактлары, охшаш һәм охшаш булмаган шартлардан чыгып та чагыштырылырга тиеш”. Беренче чиратта, халыкның нинди физик шартларда яшәвенә һәм аның рухи үзенчәлекләренә игътибар бирү зарур. Кеше табигатенең бердәмлеге, кешегә хас гомуми физик һәм рухи күренешләр тел белеме объекты булырлык бердәм кеше теле турында сөйләргә мөмкинлек бирә.

Тел белеменең өйрәнү объектлары һәм максатлары турында фикер йөртеп, Ф.Ф. Фортунатов аның филология, физиология һәм психология белән тыгыз багланышларын ассызыклый. Филология, халыкның рухи хәяте күренешләрен өйрәнеп, әлеге халыкның телен дә урап узмый. Сөйләм авазлары физик күренеш буларак кабул ителә, димәк, алар сөйләм авазлары физиологиясе тарафыннан өйрәнелә, ул сөйләм авазларын аларның барлыкка килү шартларында өйрәнә. Тел белеме һәм психология арасындагы багланыш исә сүз мәгънәләренең табигатен, сөйләм авазлары һәм аларның сүздәге мөнәсәбәтләре арасындагы нисбәтләрне өйрәнгәндә билгеләнә. Моннан тыш, кеше телен аның тарихында өйрәнү җәмгыятьнең табигате һәм

яшәеше турындагы фәннең бер өлеше буларак кабул ителә. Тел теге яки бу җәмгыять вәкиле булган кешенеке, ул җәмгыять вәкилләре арасында мөнәсәбәтләр барлыкка китерә һәм камилләштерә. Тел үзенең үсеш тарихы җәмгыятьтә уза, ә җәмгыять вакыт үтү белән үзе дә үзгәрә, үзенең тарихына ия була. Җәмгыять тарихының фактлары анда яшәгән телләр тарихы өчен кыйммәтле дәлилләр бирә. Үз чиратында тел фактлары исә җәмгыятьнең теге яки бу чордагы мәдәни хәлен билгеләргә мөмкинлек тудыра. Телнең иҗтимагый ягына игътибар юнәлткәндә, Ф.Ф. Фортунатов, тел бүленешенең иҗтимагый коллектив үсеше тәэсире астына элэгүен ассызыклый. Моның нигезендә ул телнең эчке һәм тышкы тарихын аерып чыга. Телнең тышкы тарихы тел һәм җәмгыять арасындагы багланыш нигезендә билгеләнә: "Һәрбер тел билгеле бер җәмгыятькә карый, ягъни, һәрбер тел теге яки бу җәмгыять кешесенеке. Җәмгыять эчендә барлыкка килгән үзгәрешләр телдәге үзгәрешләргә китерә: җәмгыятьнең бүленеше – телнең шивәләргә бүленүе, ә иҗтимагый берлекләр барлыкка килү – шивәләр берләшүе белән параллель бара". Телнең эчке тарихы исә һәрбер аерым индивидуумнан, шәхестән тора, фикерләү һәм сөйләм арасындагы индивидуаль-психологик мөнәсәбәтләргә бәйле була.

Телне иҗтимагый-тарихи күренеш буларак кабул итеп, Ф.Ф. Фортунатов, телнең камилләшүен аның теге яки бу мөстәкыйль телләргә яки шивәләргә таркалу, дифференциация буларак кына кабул итәргә ярамый дип билгели. Шивәләрнең таркалуы, вакыт үтү белән, аларның берләшүенә, интеграциягә китерергә мөмкин. Бу процесста аеруча мөһим рольне ул әдәби телгә, яки, Ф.Ф. Фортунатов терминологиясе буенча, "әдәби шивәгә" тапшыра. Нәкъ менә әдәби тел тотрыклылыкка ия. Шулай итеп, Ф.Ф. Фортунатов тарихилыгы Лейпциг мәктәбе яшь грамматикачыларының тарихи принципларыннан бераз аерылып тора.

Ф.Ф. Фортунатов үзенең хезмәтләрендә тел һәм фикерләү арасындагы мөнәсәбәтләргә зур игътибар бирә. Ул, бу мөнәсәбәтне, яшь грамматикачыларга ияреп, индивидуаль психологизм позициясеннән чыгып карый. Фортунатов буенча,

тел “фикерләү процессында һәм фикер чагылышы буларак безнең сөйләмебездә яшәп килә, моннан тыш, безнең сөйләм – хисләрнең чагылышы”. Галим тел һәм фикерләү арасында ике яклы мөнәсәбәт урын алган дип билгели: тел фикерләүгә генә бәйле түгел, ә бәлки фикерләү дә телдән башка тормышка ашырыла алмый. “Фикерләү үзе исә күзаллау дип исемләнгән рухи күренешләрдән гыйбарәт”. Ә “күзаллау – хисне барлыкка китергән сәбәпнең юкка чыгуыннан соң берникадәр вакыт узуга карамастан сакланып калган хисләр эзе, әлеге хисләр эзе психик ассоциация законы нигезендә яңадан туарга мөмкин”. Күзаллаулар ассоциациясе яки рухи күренешләр ассоциациясе охшашлыклар нигезендә дә мәйданга чыгарга мөмкин. Фикерләү процессы бербөтен фикер өлешләре буларак күзаллаулар арасында мөнәсәбәтлек хисе барлыкка килү нигезендә туа. Сүзне барлыкка китерә торган аваз комплекслары исә кеше аңында үз эзен калдыра. Тел һәм фикерләү арасындагы бәйләнеш нигезендә предметлар һәм аваз комплекслары арасындагы мөнәсәбәтләр калкып чыга. Ф.Ф. Фортунатов буенча, аваз күзаллаулары фикерләүдә башка күзаллауларның ярдәмчесе ролен үти, ягъни, фикерләү өчен билгеләр тәкъдим итә. Шулай итеп, фикерләүнең телгә буйсынуы, иң элек, түбәндәге фикергә бәйле: “сүзләр ярдәмендә, без теге яки бу тамгалар булмаган очракта, теге яки бу күренешнең күзаллануы мөмкин булмавы хакында уйлыйбыз, шулай ук, сүзләр ярдәмендә, без фикерләү өчен теге яки бу тамгалар булмаса, уйлый алмаячак формада фикер йөртә алабыз”.

Ф.Ф. Фортунатовның фикерләү һәм җөмләне психологик категория буларак кабул итүе, шулай ук аның тел һәм фикерләү арасындагы тыгыз мөнәсәбәтләргә басым ясавы белән бәйле. Аныңча, ике күзаллау берлеге тарафыннан барлыкка китерелгән аерым бер фикер – фикерләү буларак кабул ителә, ләкин биредә бер күзаллау өстенлек итүче, ә икенчесе буйсынучы ролен үти; бер күзаллау – психологик ия, икенчесе исә – психологик хәбәр. Реаль фикерләү процессында исә кеше фикерләүне җөмләдән аермый, ул үзара тыгыз мөнәсәбәттә булган җөмлә-фикерләүләр ярдәмендә төшенә.

Гомуми тел белеме өчен Ф.Ф. Фортунатовның грамматик теориясе игътибарга лаек, биредә грамматик форма турындагы өйрәтмә төп элементны тәшкил итә. Әлеге өйрәтмә тел белеме тарихында Ф.Ф. Фортунатовның иң мөһим казанышларыннан санала, ул тел белемендәге формаль юнәлеш исемен ала. Телдәге форма проблемасы Ф.Ф. Фортунатов тарафыннан аның барлык фәнни эшчәнлеге дәвамында өйрәнелә, телдәге форманы аңлау үзгәрешләр кичерә, чөнки галим тагын да төгәлрәк кагыйдәләрне эзләү өстендә эш алып бара. Ләкин үзенең төп һәм гомуми формаларында грамматик форманы, аеруча сүз формаларын аңлату үзгәрми. Галим фикеренчә, тел формалары – телнең грамматик фактлары, ә сүзләрнең формаларына карата төрлелегә аларның грамматик төрлелегенә тәңгәл килә.

Сүзнең грамматик формасын Ф.Ф. Фортунатов морфологик яктан, ягъни сүзнең нигез һәм кушымчаларга бүленүе буларак аңлый, сүзнең мондый бүленү мөмкинлеге сүзгә теге яки бу форманы бирә. Сүзнең формаль иялеге – теге яки бу конкрет аффикс, нигез иялеге – сүзнең нигезе. “Аерым сүзләрнең формасы – аерым сүзләрнең сөйләүче аңы өчен үзеннән формаль һәм төп сыйфатларны аеру. Сүзнең формаль сыйфаты исә – төп сүз авазының мәгънәсен үзгәртүгә сәләтле башка бер сүз авазы. Тулы сүз формалары исә – теге яки бу тулы сүз аермалыкларының формаль сыйфатларында барлыкка килгән тулы сүзләр аермалыгы”, – дип ассызыклый Ф.Ф. Фортунатов. Мәсәлән, рус телендәге сүзләр нигезендә берникадәр мисал китерергә була: *вед-у, вед-ешь, вед-ет; рук-а, рук-е, рук-у, рук-ой* һ.б. Ф.Ф. Фортунатов сүзнең тискәре формаль сыйфатын да билгели, бу исә нуль аффикска тәңгәл килә. Мәсәлән, рус телендәге *дом, человек* сүзләре баш килештә, берлек санда килә, бу сүзләрнең формаль сыйфаты – флексиянең булмавы (нуль аффикс). Ф.Ф. Фортунатов, формаларның функцияләре буенча, сүзләрнең ике тип формасын аера: алар аерым бер предметларның билгесе буларак кабул ителәме, әллә предметлар арасындагы мөнәсәбәтне белдерәме? Беренче очракта сүз ясалу формалары, икенче очракта исә сүз төрләнү формалары аерылып чыга. Ф.Ф. Фортунатовның сүз ясалышы һәм сүз төрләнеше

турындагы фикерләре рус лингвистикасында бердәм кабул ителә һәм киң кулланылыш таба.

Сүз формасы концепциясе исә Ф.Ф. Фортунатовның грамматик теориясенең үзенчәлекләрен дә алдан ук билгели. Ул грамматиканы сүз формаларын өйрәнү буларак кабул итә һәм аны морфология (бу бүлекнең иске исемен – "этимология"не алыштыра) белән синтаксиска бүлә. Морфология аерым сүзләрнең үзара мөнәсәбәтен билгели, ә синтаксис аерым сүзләрнең формасын сүзтезмәләрдә кулланылышында өйрәнә. Сүз төркемнәре сүзләрнең грамматик классы буларак кабул ителә, аффиксларның булу-булмавы аларның аермалы сыйфаты булып санала. Фортунатов өйрәтмәләрендә сүзтезмә синтаксисның төп берәмлеге ролен башкара, бу исә тел берәмлекләрен психологик нигездә билгеләү һәм аның тел формасы турындагы концепциясе белән аңлатыла. Сүз формасы турындагы өйрәтмә белән бәйле рәвештә, Ф.Ф. Фортунатов, дөнья телләренең морфологик классификациясенә ачыклык кертә һәм дүрт төп типка бишенче типны да өсти: флектив-агглютинатив телләр, биредә сүзнең нигезе эчке флексиягә ия (семит телләре).

Ф.Ф. Фортунатовның шәкертләре һәм дәвамчылары аның компаративистика, гомуми тел белеме, синтаксис һәм морфология өлкәсендәге фикерләрен дәвам итәләр, әдәби тел формалаштыруга зур игътибар бирәләр, сөйләм әдәбе, лексикография белән шөгыльләнәләр. Аның фикерләрен дәвам итүдә А.М. Пешковский, А.А. Шахматов һәм Б.М. Ляпунов кебек галимнәр аеруча зур уңышларга ирешә. А.М.Пешковскийның "Рус синтаксисының фәнни яктыртылуы" хезмәтендә төп төшенчәләр – сүз формасы һәм сүзтезмә формасы; җөмлә төшенчәсе әлеге формалардан китереп чыгарыла. А.А. Шахматов исә рус теленең тарихи фонетикасына, хәзерге рус теленең грамматик төзелешенә зур игътибар бирә. "Рус теле синтаксисы"нда ул остазының кайбер фәнни кысаларыннан читкә чыга һәм синтаксисның үзәк берәмлеге буларак җөмлә теориясен булдыра, бер составлы һәм ике составлы җөмләләрне төгәл рәвештә аерып күрсәтә. А.А. Шахматовның җөмлә теориясе барлык төр җөмләләр нигезе

буларак психологик коммуникация концепциясенә нигезләнә. Б.М. Ляпунов исә, борынгы славян теле материаллары нигезендә, укытучысының чагыштырма-тарихи идеяләрен алга сөрә. Рус грамматик традициясе (кайбер очракларда бу көнбатыш грамматикасына да кагыла), Ф.Ф. Фортунатовның үзе һәм аның шәкертләренең эшчәнлеге нәтиҗәсендә, аларның лингвистик карашлары тәэсире астында була. Грамматик төзелешләрнең формализмы, абстракция һәм схематизация тел белемендә структурализмның барлыкка килүенә сәбәп була.

### “Сүзләр һәм әйберләр” юнәлеше. Лингвистик география

XIX гасыр ахыры яшь грамматикачылар тарафыннан тел белемендә ясалган күп кенә ачышлар белән тарихка кереп кала. Ләкин XX гасыр башында шаулаган ачышлардан соң чагыштырмача тынлык урнашкач, яшь грамматикачылыкны һәм аның методларын тәнкыйть итү киң таралыш ала. Әлеге чор еш кына тел белемендәге кризис чоры буларак та телгә алына һәм тел белемендә яңа мәктәп һәм агымнар барлыкка килү белән характерлана. Шунысы мөһим, әлеге агымнар һәм мәктәпләр яшь грамматикачылыкка карата оппозицион характерда була. Беренче очракта австрияле лингвист Гуго Шухардтка (1842-1928) бәйле булган “сүзләр һәм әйберләр” юнәлешен атап узарга кирәк. Шулай ук немец лингвист-романисты Кар Фосслер (1872-1949) җитәкчелегендәге лингвистик география, эстетизм мәктәбе дә тел белемендә зур хөрмәткә ия була.

И.А. Бодуэн де Куртенэ аваз законнарына кагылышлы мәсьәләләр буенча яшь грамматикачылар белән төрле фикердә була, аның каравы, аваз законнары – төрле, еш кына бер-берсенә капма-каршы характердагы факторларның эшчәнлек нәтиҗәсе, бу яктан, хәтта аларны закон дип атарга безнең хакыбыз юк. Яшь грамматикачылык үсешенең югары ноктасына җиткән чорларда “Фонетик законнар (яшь грамматикачыларга каршы)” дип аталган мәкаләсе ярдәмендә Г.Шухардт та аваз законнарының яшь грамматикачылар биргән мәгънәсенә катгый рәвештә каршы чыга. Аның мәкаләсе шау-шу күтәрә, моннан соң яшь грамматикачылар фонетик законнар эшчәнлегенә үзгәрешләр кертергә мәҗбүр булалар. Г.Шухардт фонетик

законнар эшчәнлегенең абсолют характерын кире кага, аның фикеренчә, "спорадик фонетик үзгәрешләр генә бар". "Һәртөрле фонетик үзгәреш үзенең бер этабында спорадик характерда була. Бу очракта абсолют һәм чагыштырма закончалыклар турында сүз алып бару дөресрәк булыр", – дип ассызыклый Г.Шухардт.

Г.Шухардт, шулай ук тел тарихын төгәл чорларга бүлүнең дөреслеген дә шик астына куя, шивәләр, диалектлар һәм телләр арасындагы чикләрнең булмавын билгели. Аның фикеренчә, "җирле шивәләр, диалектлар һәм телләр – барысы да шартлы төшенчәләр, чөнки дөньяда ят элементны үз эченә алмаган яки башка теге яки бу тел белән кушылуларга дучар булмаган чиста бер тел дә юк". Тел үзгәрүчәнлекләренең төп сәбәбен ул телләрнең өзлексез кушылуында күрә. Әлеге фикергә нигезләнеп, Г.Шухардт, телләрнең генеалогик классификациясе урынына "географик тигезләшү", ягъни географик урнашуга карап, бер телнең икенче телгә өзлексез рәвештә күчеше теориясен тәкъдим итә. Г.Шухардт, яшь грамматикачылар кебек үк, телне сөйләшүче индивид эшчәнлегенең нәтиҗәсе буларак кабул итә. Моның белән беррәттән, аның фикеренчә, иҗтимагый урын, яшәү шартлары, индивидның яше телгә турыдан-туры тәэсир итә, индивидуаль стиль булдыра.

Г.Шухардт, шулай ук, этимология, семасиология һәм тел белеменең башка мәсьәләләренә дә зур игътибар бирә. Моның белән бергә, ул "лингвистлар гомумилекне хосусый әйберләрдә табарга өйрәнергә тиеш, тел белеме фәнендәге төп рольне үтәгән теге яки бу мөһим фактны дөрес аңлау, күренешләрнең хосусый формаларын аңлауга караганда әһәмиятлерәк", – дип басым ясый. Теге яки бу хосусый мәсьәләләрне ничек кенә җентекләп карамасын, тел белеме гомумилекне күз уңыннан җибәрмәскә тиеш. Әлеге кагыйдәләр яшь грамматикачыларның эмпиризмына каршы юнәлтелгән була.

1909 елда Г.Шухардт һәм аның австрияле коллегасы Рудольф Мерингер (1859-1931) "Сүзләр һәм әйберләр" дип исемләнгән журнал чыгара башлый, тел белемендәге юнәлешнең исеме дә әлеге журнал белән бәйле. Г.Шухардт һәм Р.Мерингер сүзләрнең тарихын бары тик лингвистик анализ нигезендә генә түгел, ә бәлки әйбернең тарихы белән бәйле рәвештә дә өйрәнүне максат

итеп куялар, чөнки, “сүз бары тик әйбер белән бәйле рәвештә генә кулланыла (яши)”. “Чегән гаиләсе иске сарай калдыклары арасында көн күреп, негрларның юлбашчысы башына таҗ буларак цилиндр кисә, иң нәфис негр кызы колак йомшагына консерв банкасы тагып йөри икән, сарай, цилиндр, консерв банкасы – боларның һичберсе дә халыкның мәдәни байлыгы түгел; бу чит сүзләргә карый торган ят әйберләр”, – дип яза Г.Шухардт. Мәсәлән, теге яки бу йортның тарихы белән, ат, инә, чүлмәк белән бәйле сүзләрне өйрәнер өчен, “төзү сәнгате тарихы турында, атларны өйрәтү, тимерчелек һәм чүлмәкчелек хакында сүз алып барырга кирәк, дөресрәге, бу эшләр белән шөгыльләнүченең тарихы турында уйланырга кирәк”, – дип ассызыклый ул. Кеше эшчәнлеге нәтиҗәсендә, “әйбер һәм сүз тарихы арасында параллельлек барлыкка килә”. Концепция характеры нигезендә, “сүзләр һәм әйберләр” юнәлеше этимология, лексикология һәм семасиологиягә каршы куела. Сүзнең семантик ягына бу кадәр игътибар, шулай ук, яшь грамматикачылыкка каршылык нигезендә ясала, чөнки яшь грамматикачылыкның үзәгендә фонетика һәм морфология була, ә менә семантика алар тарафыннан аз һәм өстән генә өйрәнелә. Яшь грамматикачыларның телне фонетик законнар нигезендә хәрәкәткә килә торган механизм буларак кабул итүләренә каршы рәвештә, Г.Шухардт, телне кешенең иҗтимагый һәм мәдәни эшчәнлеге коралы буларак аңлый.

Шул ук чорда Германиядә Георг Венкер (1852-1911), Франциядә Жюль Жильерон (1854-1926) Г.Шухардтның “географик тигезләү” һәм И.Шмидтның “дулкын теориясе” нигезләрендә лингвистик география барлыкка китерәләр. Ләкин лингвистик географиягә нигез салучылар булып И.А. Бодуэн де Куртенэ һәм Г.Асколи санала. 1876 елда Г.Венкер укытучыларга анкета тарата, ун ел узганнан соң ул бу анкетага 40 мең җавап ала. Әлеге анкеталарны карап чыкканнан соң, һәм шулай ук Г.Венкерның Фердинанд Вреде (1863-1934) исемле укучысының эшчәнлеге нәтиҗәсендә, немец теленең алты томлык диалектологик атласы дөнья күрә. Ул фонетикага багышлана. Ж.Жильерон һәм Эдмон (1848-1926) тарафыннан Франциянең диалектологик атласын әзерләү Г.Венкер эшчәнлегеннән соң

башланып китә, ләкин аларның 12 томлык хезмәте иртәрәк, 1902-1910 елларда чыга. Биредә исә күпчелек очракта лексика мәсьәләләре карала. Г.Венкерның анкета методыннан аермалы буларак, француз диалектологик атласы туры юл белән әзерләнә: сорау алуның 639 пунктына бирелгән җаваплар фонетик транскрипция нигезендә урыннарда ук язылып алына. 1903 елда исә Россиядә дә Мәскәү диалектологик комиссиясе барлыкка килә, биредә 1915 елда "Диалектологик карта. Рус теле Европада" дип аталган хезмәт дөнья күрә.

Лингвогеография, беренчеләрдән булып, территориаль һәм иҗтимагый мөнәсәбәттә телнең барлык катлаулыгын ачык күрсәтә. Г.Шухардтның телнең "географик алмашынучанлыгы" тезисы ачыклана: диалекталь массивларның бербөтен түгеллеге күренә, тел күренешләре аерым очракларда гына (сүзләр, форма һәм авазлар, ягъни изоглосслар) урын ала. Изоглосс чикләрен мәдәни-тарихи характердагы сәбәпләр белән аңлатырга мөмкинлек туа. Лингвистик география барлыкка килү белән, Г.Шухардтның "тел – ул континуум, өзлексезлек", дигән фикере дә исбатлана. Шухардтның кушылмаган тел яки сөйләм юклыгы турындагы фикере дә кабул ителә: шивәләр һәрвакыт үзара һәм язма тел белән бәйләнештә торалар. Лингвистик география бүгенге көн тел белеменең алыштыргысыз өлешенә әйләнә, тикшерү объектларын һәм методларын киңәйтә.

**Неолингвистика**

XX гасырның егерменче елларында яшь грамматикачылыкка каршы караштa булган һәм неолингвистика дип исемләнгән тагын бер юнәлеш барлыкка килә. Аның вәкилләре: итальян тел белгечләре Джулио Бертони (1878-1942), Маттео Бартоли (1873-1946), Витторио Пизани (1899-1990), Джулиано Бонфанте (1904-2005) һ.б. Әлеге яңа мәктәпнең принциплары иң элек "Неолингвистика буенча кыскача очерк" (1925) дип аталган хезмәттә басыла, аның авторлары – Дж.Бертони һәм М.Бартоли. Неолингвистиканың гомумтеоретик аңлатмасын чагыштырмача тулы һәм төзек рәвештә Дж.Бонфантеның "Неолингвистиканың тоткан урыны" (1947) дип исемләнгән хезмәтендә табарга мөмкин. Әлеге мәктәпнең исеме яшь грамматикачылык белән

чагыштыру нәтиҗәсендә барлыкка килә: яшь грамматикачылар бары тик грамматика белән шөгыльләнә, ә неолингвистлар исә лингвист булырга телиләр, ягъни, аларның максаты – тел турындагы фәннең барлык проблемаларын да өйрәнү була.

Неолингвистиканың методологик принциплары В.Гумбольдтның телне рухи эшчәнлек буларак кабул итүенә, итальян фәлсәфәчесе-интуитивист Бенедетто Кроче (1866-1952) һәм К.Фосслерның тел үзгәрүчәнлегенең сәбәбе буларак сәнгать эшчәнлегенә, Г.Шухардтның географик үзгәрүчәнлек һәм телләрнең кушылуы, И.Шмидтның дулкын теориясенә нигезләнә. "Неолингвистиканың тоткан урыны"нда Дж.Бонфанте яшь грамматикачылар һәм неолингвистлар арасындагы 51 теоретик аермалыкны күрсәтә. Неолингвистлар фикеренчә, телне өйрәнгәндә тел үсешенең конкрет шартларын күздә тотарга кирәк, тел үсешенең күп факторлылыгына һәм катлаулылыгына да игътибар ителергә тиеш. Чынбарлыкта исә, неолингвистлар тел өйрәнүдә географик факторга, географик урнашуга һәм тел-диалект арасындагы мөнәсәбәтләргә басым ясыйлар. Алар фикеренчә, бердәм тел юк, бары тик төрле изоглоссларның күплеге генә бар. Бу фикергә таянган хәлдә, алар, телне изоглосслар системасы буларак кабул итеп, "индивидуаль лингвистик актларны үз эченә алучы" дип карыйлар. Лингвистик география принцибын алар һинд-европа баба телен өйрәнгәндә дә кулланалар, алар фикеренчә, телләр арасында төгәл чикләр юк, ә бары тик эзлекле рәвештә күчә торган лингвистик өзлексезлек кенә бар. Неолингвистларның географик фактларга карата мөнәсәбәтен күздә тотып, аларның мәктәпләрен еш кына *ареаль лингвистика* дип тә йөртәләр. "Ареаль" терминын фәнни кулланылышка Ж.Жильерон кертә. Бу термин конкрет бер тел күренешенең аерым бер чорда, билгеле бер территориядә, бер тел яки диалект кысасында, яки кардәш телләр һәм диалектлар төркемендә таралыш табуын аңлата. Неолингвистларның концепциясендә ареаллар турындагы өйрәтмә, тикшерү методикасы һәм географик лингвистика нәтиҗәләре зур урын алып тора.

Неолингвистлар телләрнең яшь грамматикачылар аңлавындагы генетик кардәшлеген кире кага. Дж.Бонфанте

фикеренчә, “румын телен роман телләре кебек, инглиз телен немец теле кебек, болгар телен славян теле кебек классификацияләү – проблеманы тупас һәм фәнни булмаган рәвештә гадиләндермәктер, бу исә табигать тарафыннан да, телләрнең үсеш процесслары тарафыннан да хупланмый”, чөнки әлеге телләргә башка тел төркемнәре дә тәэсир итә. Неолингвистлар генетик кардәшлек урынына тел берлеге төшенчәсен тәкъдим итәләр. “Бер төркемдәге телләр (мәсәлән, француз, провансаль, итальян телләре) арасында чикләр булмаган кебек, бер гаилә телләре арасында да (мәсәлән, француз һәм немец, немец һәм чех телләре) чикләр юк яки хәтта төрле тел гаиләләренә караган телләр арасында да (мәсәлән, рус һәм фин телләре) чикләр сизелми”, – дип фикер йөртә Дж.Бонфанте. Бу фикерләргә таянып, неолингвистлар телләр кушылуына, алынмаларга зур игътибар бирә. Алар тарафыннан тел берлекләре озак вакыт буена янәшә яшәп килгән телләр кушылмасы буларак кабул ителә. Классик мисал булып саналган балкан тел берлеген ассызыкларга була. Биредә грек, албан, македон һәм румын телләре озын тарихи багланыш нәтиҗәсендә кайбер уртак үзенчәлекле сыйфатларга ия булган.

Неолингвистлар өчен тел – эстетик күренеш. Тел яңалыкларының барлыкка килүе һәм таралуы эстетик сайланышка нигезләнә, индивидуумның иҗади көченә, иҗтимагый хәленә, әдәби репутациясенә бәйле. Дж.Бонфанте фикеренчә, яшь грамматикачылар өчен тел – грамматика, грамматик категорияләр каталогы икән, димәк, неолингвистлар өчен тел – ул эстетик категорияләрнең күплеге. Әлеге күплектә, “теге яки бу инглиз грамматикасы, ничек кенә югары дәрәҗәдә язылса да, ул Шекспир яки Шеллины укуны, яки иң кечкенә сүзтезмәне дә алмаштыра алмый”. Телгә карата мондый караш неолингвистларны К.Фосслерның эстетик мәктәбе белән туганлаштыра.

**Тел белемендә эстетизм**

Тел белеме тарихында эстетик мәктәпкә, яки эстетик идеализм мәктәбенә, яки неофилологиягә нигез салган галим – немец лингвист-романтисты К.Фосслер. Телгә карата үзенең

карашларын ул яшь грамматикачыларга каршы “Тел белемендә позитивизм һәм идеализм” (1904) дип исемләнгән хезмәтендә ачыклый. “Иҗат һәм үсеш буларак тел” (1905), “Тел фәлсәфәсе буенча сайланма мәкаләләр” (1923), “Телдә рух һәм мәдәният” (1925) кебек хезмәтләрендә һәм күпсанлы мәкаләләрендә ул йә беренче китабының фикерләрен җентекләп карый, яки аларны киңрәк мәдәни-тарихи кысаларга кертә, тел һәм сөйләм, тел һәм дин, тел һәм фән, тел һәм шигърият багланышларын өйрәнә.

Немец идеализмы фәлсәфәсе, итальян фәлсәфәче-интуитивисты һәм эстетигы Бенедетто Кроченың карашлары, ә лингвистик планда исә В. фон Гумбольдтның тел фәлсәфәсе К.Фосслерның лингвистик концепциясенең методологик нигезе буларак кабул ителә. К.Фосслер концепциясенең башлангыч ноктасы: рух – һәртөрле эшчәнлекнең (шул исәптән тел эшчәнлегенең дә) сәбәбе. “Безнең өчен тел һәм аның авазлары автоном түгел, – дип ассызыклый К.Фосслер, – ә бәлки телне барлыкка китергән, формалаштырган рух автоном, бу яктан, тел белеменең бердәнбер максаты – барлык тел формаларының сәбәбе булып торган рухны нигез итеп алу”. Ул яшь грамматикачыларны позитивистлар дип атый һәм аларны тел күренешләрен өйрәнмәгәннәре, ә бары тик тел фактларын туплау белән генә шөгыльләнгәннәре өчен тәнкыйтьли. К.Флосслер фикеренчә, тел белемендәге идеализм – тел фактлары арасында багланышлар урнаштыру, чөнки тел үзгәрешләренең нигезендә телнең рухы тора. “Тел – рухи чагылыш дигән фикер дөрес икән, димәк, телнең үсеш тарихы – рухи формаларның тарихы, ягъни, киң мәгънәдә, сәнгать тарихы”, – ди ул. Бу фикергә таянсак, аныңча, “грамматика – гомумрухи тарихка яки мәдәният тарихына кергән “стиль һәм әдәбият тарихының бер өлеше”.

Б.Крочега ияреп, телне аерым шәхесләрнең интуициясе эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак кабул иткән хәлдә, теге яки бу тел үзгәрешенең нигезе – интуициягә ия булган кеше рухы, ә филологиянең бердәнбер югары ноктасы – эстетика, – дип ассызыклый К.Фосслер. Фонетика, акустика, сөйләм органнарының физиологиясе, аныңча, бары тик ярдәмче фәннәр генә, алар бары тик тел үсеш алган шартларны гына күрсәтергә

мөмкин, ләкин бу үсешнең сәбәпләрен атый алмыйлар. К.Фосслер индивидуализмының яшь грамматикачылар индивидуализмыннан аермалы булган сыйфаты – стилистика һәм синтаксисны чикләү. Телнең кагыйдәләр буенча кулланылуын синтаксис өйрәнә. Яшь грамматикачылар синтаксисында теге яки бу индивидуум тарафыннан күп тапкырлар кабатланган сүзләр тезмәсе кагыйдә буларак кабул ителә, телнең индивидуаль иҗат буларак кулланылышын стилистика өйрәнә. “Һәртөрле аңлату ысулы, синтаксик чарага әйләнгәнче һәм халык тарафыннан кабул ителгәнчегә кадәр, иң элек һәм күп тапкырлар индивидуаль һәм стилистик чара була, ә оригиналь иҗат кешесе сөйләмендә исә, гомумиләшкәннән соң да, индивидуаль булып кала бирә”, – дип яза К.Фосслер. Аның өчен “телнең һәртөрле элементы – стилистик аңлату чарасы”, чөнки һәрбер сөйләм – индивидуаль рухи эшчәнлек. Телнең барлык күренешләре, фонетикада теркәлгән һәм тасвирланган күренеш буларак, “стилистикада аңлатылырга тиеш”. К.Фосслер фикеренчә, грамматика телгә карата эстетик караштa тулысынча эреп югалырга тиеш.

К.Фосслерның тел эстетик концепциясе күп очракта Б.Кроченың эстетик фәлсәфәсенә нигезләнә. Б.Кроче кешенең танып белүен интуитив һәм логик төрләргә бүлеп караган. Беренчесе индивидуальлекне, аерым предметларны танып белергә ярдәм итә, ә икенче төре универсальлекне, предметлар арасындагы мөнәсәбәтләрне кешегә белдертә. Интуитив рәвештә танып белү образлар барлыкка китерә, ә логик танып белү төшенчәләр тудыра; беренчесе – сәнгатьтә, ә икенчесе фәндә урын ала. Фәлсәфәнең бер өлеше буларак эстетиканың өйрәнү объекты – тәгъбир, чөнки, интуициянең мәйданга чыгуы, образ барлыкка китерү – бер үк вакытта тәгъбир дә. Б.Кроче буенча, тел шулай ук индивидуаль тәгъбирләрдән тора, бу исә телне эстетика белән якынайта.

К.Фосслер, яшь грамматикачыларның тел үзгәрешләренең сәбәбе буларак аналогия һәм аваз законнары турындагы тезисларына каршы чыгып, фонетик үзгәрешләрнең рухи сәбәбен ачыклый. Ул бу очракта фонетик закон һәм аналогия арасында мөһим аермалыклар күзгә чалынмый дип билгели.

Фонетикадагы әлеге рухи сәбәпне ул телнең акценты дип атый. К.Фосслер фикеренчә, “акцент һәм мәгънә – бер үк күренеш өчен төрле сүзләр: һәр икесе дә психик эчтәлекне, эчке интуицияне һәм телнең эчке дөньясын аңлата. Һәр икесе дә аваз феноменына карата бер үк төрле эчке мөнәсәбәттә тора”. Аның өчен “акцент” – рух, һәм бары тик рух; “мәгънә” дә шулай ук. Акцентның рухи әһәмиятен ул түбәндәге мисал ярдәмендә аңлата: “Бер итальян артисты бердән алып йөзгә кадәр санаганда кешеләрне елатырлык итеп үзәкләренә үтеп керә ала иде, ләкин ул бу эшне шундый акцент белән башкара, хәтта аның тавышында кеше үтерүченең ялвару хисләрен тоярга була, кешеләр исә саннар турында бөтенләй диярлек оныта, аларның барлык хисләре явызны кызгану белән бәйле була иде. Акцент итальян саннарына кабатланмас мәгънә өсти. Ә тирән мәгънәле шигырьне хисчән итеп тәкъдир итсәң, ул нәрсәләр күрсәтер иде!” К.Фосслерда акцент – ул стилистика, фонетика һәм эстетика арасындагы бәйләгеч элемент.

Фосслерча, тел белеменең идеалогик системасы телгә карата эстетик һәм эстетик-тарихи карашларны гына күздә тота. Беренче очракта “аерым тәгъбир формалары бер-берсеннән аерым рәвештә аеруча индивидуаль булудан чыгып” өйрәнелә. Икенче очрак исә төрле халыкларның тел формаларын төрле чорларга карата хронологик күзлектән – период һәм чорларга, географик күзлектән – халык һәм расаларга, шулай ук “халык индивидуальлекләрен” һәм рухи кардәшлекне күздә тотып, “кушарга һәм төркемнәргә бүләргә тиеш”. Үзенең лингвистик принципларын К.Фосслер француз теленең тарихы буенча язылган “Тел үсеше нигезендә Франция мәдәнияте” хезмәтендә тулысынча диярлек чагылдыра.

Француз теленең һәрбер үсеш чорын К.Фосслер иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-сәнгати карашларга таянып характерлый. Борынгы француз чорының үзенчәлекле сыйфаты буларак милли хисләрнең мәдәни-дини хисләр белән багланышын аерып күрсәтергә була. Телдә исә бу багланыш тел төзелешенең бердәмлеге һәм гармониясендә чагылыш таба, бу аеруча фонетика һәм синтаксис гармониясенә карый. Урта француз теле чорының тел үсешендәге үзенчәлекле сыйфаты милли һәм

гамәли үзаң үсеш алу белән характерлана, бу исә фонетикада һәм сүз төрләнешендә берникадәр хаоска китерә, телнең сүзлек составы теге яки бу кагыйдәләрне санламыйча тулылана башлый. Француз теленең яңа чорын искә алганда, натурализм һәм рационализм юнәлешләре алгы планга чыга, бу исә телнең сүзлек составы икеләтә тулылануга китерә, яңа сүзләр француз теле "рухына" яраклаша башлый.

Шулай итеп, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында тел белемендә яңа карашларны эзләү яшь грамматикачылыкны эмпирик карашлары, теоретик проблемаларны урап узганнары һәм психологизмга аеруча игътибар биргәннәре өчен тәнкыйтьләү белән үрелеп алып барыла. Тел белеменә яңалыклар кертү теләге нәтиҗәсендә, югарыда саналып үткән мәктәпләр һәм юнәлешләр барлыкка килә. Алар ярдәмендә лингвистик тикшеренүләрнең чикләрен киңәйтү, тел күренешләрен яңача кабул итү өстендә эшләр алып барыла. Моның белән беррәттән, яшь грамматикачылар да, аларга каршы торган мәктәп-юнәлешләр дә төгәл рәвештә гомумлингвистик теорияне билгели алмый. Әлеге максатка XX гасырда Ф. де Соссюр эшчәнлеге нәтиҗәсендә һәм бүгенге көн тел белеме фәне ярдәмендә ирешелә.

### Ф. де Соссюрның лингвистик концепциясе

Фердинанд де Соссюр (1857-1913) – XX гасырның бөек тел белгечләреннән берсе. Ул Женевада галим гаиләсендә дөньяга килә. 1876 елдан башлап Лейпцигта Лескин, Остгоф, Бругман укыган лекцияләрне тыңлый. 1879 елда ул үзенең "Һинд-европа телләрендәге сузык авазлар системасы турындагы беренчел трактат" дип аталган хезмәтен бастыра. 1878-79 уку елларында Ф. де Соссюр Берлин университетында укый. 1879 ел ахырында ул Лейпцигка кире кайта һәм 1880 елның февраль аенда санскрит теле проблемасы белән бәйле темага докторлык диссертациясен яклый. Алдагы елларда Ф. де Соссюр Парижда лекцияләр укый, биредә ул А.Мейе (1866-1936), М.Граммон (1866-1946) кебек булачак галимнәрне укыта. 1891 елда Ф. де Соссюр Женева университетына кире кайта, санскрит һәм һинд-европа телләренең чагыштырма грамматикасы буенча профессор

дәрәҗәсенә лаек була. 1906 елда Ф. де Соссюр гомуми тел белеме кафедрасын җитәкли башлый. 1906-1911 елларда ул өч тапкыр гомуми тел белеме курсын укып чыга, биредә аның тыңлаучылары арасында Ш.Балли (1865-1947) һәм А.Сеше (1870-1946) да була. Ф. де Соссюрның үлеменнән соң, нәкъ менә шушы ике укучының лекцияләренә нигезләнеп, аның гомуми тел белеме буенча курслар җыентыгы эшләнә. Ул "Гомуми тел белеме курсы" дип атала һәм 1916 елда басылып чыга. 1933 елда аның рус телендәге тәрҗемәсе дөнья күрә. Әлеге хезмәт үзенең оригиналь концепциясенә нигезләнгән рәвештә зур кыйммәткә ия була һәм XX гасыр тел белеменең күп кенә тармакларына йогынты ясый.

"Гомуми тел белеме курсы" хезмәтендә Ф. де Соссюр тарафыннан тел һәм сөйләм, телнең системалылыгы, аның тамгачыл характеры, синхрония һәм диахрония, эчке һәм тышкы лингвистика кебек проблемалар карала. Әлеге проблемаларга бәйле рәвештә инде В. фон Гумбольдт, И.А. Бодуэн де Куртенэ, Н.Крушевский, В.Уитни эшләгән була.Ләкин лингвистик теориянең төп метод төзелеше буларак галим антиномияләр методын сайлый. Әлеге методны XIX гасырда В. фон Гумбольдт һәм башка тел белгечләре кулланган була (мәсәлән, 1896 елда француз лингвисты В.Анри "Лингвистик антиномияләр" дип исемләнгән хезмәтен бастыра).

1. Ф. де Соссюр концепциясенең беренче мөһим антиномиясе – *тел һәм сөйләм*. Тел һәм сөйләм арасындагы проблеманы, беренчеләрдән булып В.Гумбольдт күтәреп чыга, соңыннан бу юнәлештә А.А. Потебня һәм И.А. Бодуэн де Куртенэ эшли. Әлеге проблеманы чишкәндә Ф. де Соссюр сөйләм эшчәнлегенең гомуми төшенчәсенә таяна, әлеге төшенчәнең нигезендә исә тел һәм сөйләм ята. Сөйләм эшчәнлеге күпкырлы, ул физика, физиология, психология кебек фәннәр белән мөнәсәбәткә керә, аның тышкы (аваз) һәм эчке (психик) яклары бар. Сөйләм эшчәнлеге – кешегә генә хас үзенчәлек. Тел һәм сөйләм сөйләм эшчәнлеге кебек феноменның бер өлешләре генә. Тел һәм сөйләм "үзара тыгыз бәйләнгән һәм бер-берсенең булуын күздә тоталар: тел сөйләмнең аңлаешлы булуы һәм үзенең барлык хәрәкәтләрен дә тормышка ашыра алуы өчен

кирәк; сөйләм исә, үз чиратында, телнең билгеләнүе өчен мөһим: тарих буенча фикер йөрткәндә, сөйләм факты һәрвакыт телдән алда килә”. Моның белән беррәттән, тел һәм сөйләм үзара теге яки бу үзенчәлекләргә карап аерылалар да.

Тел һәм сөйләм арасындагы беренче аерма телнең – иҗтимагый, ә сөйләмнең индивидуаль булуында чагылыш таба. Тел ул сөйләм эшчәнлегенең индивидка карата тышкы иҗтимагый элементы, индивид телне барлыкка китерә дә, үзгәртә дә алмый. Иҗтимагый продукт буларак, тел һәр индивид тарафыннан әзер килеш үзләштерелә. Телнең иҗтимагый характерын искә алганда, Ф. де Соссюр аның психологик табигатен дә ассызыклый: тел – баш миендә урнашкан һәм коллектив ризалыгы белән законлаштырылган ассоциацияләр күплеге. Телдән аермалы буларак, сөйләм һәрвакыт индивидуаль, ягъни, ул “теләк һәм аңлауның индивидуаль эшчәнлеге”. Сөйләмдә коллективлык сыйфатлары юк, аның эшчәнлеге – индивидуаль һәм бик тиз. Икенчедән, көч тормышка ашырылуга каршы торган кебек, тел дә сөйләмгә карата каршылык күрсәтә. Тел индивидның баш миендә грамматик система һәм сүзлек буларак кабул ителә; әлеге потенциаль мөмкинлекләр тел чараларын коммуникация максатларында куллану нәтиҗәсендә тормышка ашырылуы. Өченчедән, сөйләмнең тотрыксызлыгы һәм бертөрлелегеннән аермалы буларак, тел тотрыклы һәм озак яши. Һәм ниһаять, тел сөйләмнән “әһәмиятле – өстәмәдән, яки ялгыш күренешләрдән аерылган кебек” аерыла. Тел практикасы белән ныгытылган телнең норматив фактлары әһәмиятле дип табыла, ә өстәмә һәм ялгыш күренешләр – үзгәрешләр һәм индивидуаль сөйләм кимчелекләре. Саналып үткән факторлар нигезендә, Ф. де Соссюр сөйләм эшчәнлегенең һәрбер ягын аерым өйрәнергә тәкъдим итә, тел һәм сөйләм лингвистикасын аерып күрсәтә һәм, аның фикеренчә, сөйләм лингвистикасы беренче рольне үтәми.

2. Икенче антиномия буларак Ф. де Соссюр *синхрония һәм диахрония антиномия*не атый. Синхрония – телнең билгеле бер моменттагы халәте, статик аспект, тел системасында – тел. Диахрония исә – телнең эволюциясе, тел фактларының вакытка карата бер-бер артлы килүе, тарихи яки динамик аспект.

Анынча, лингвистиканың “статик аспектына караган һәрбер күренеше синхрон”, “эволюциягә караган бар күренешләр исә диахрон”. Бу фикергә бәйле рәвештә мөстәкыйль фәннәрнең яңа парын барлыкка китерү зарурлыгы мәйданга чыга: сүз синхроник һәм диахроник лингвистика турында бара. Синхроник лингвистика тел системасын барлыкка китерә торган элементлар арасындагы логик һәм психологик мөнәсәбәтләрне өйрәнергә тиеш. Бу очракта синхроник лингвистика әлеге мөнәсәбәтләрне бер үк коллективның аңы тарафыннан кабул ителгәнчә карый. Диахроник лингвистика исә “бер үк коллективның аңы тарафыннан кабул ителмәгән” тел элементларын чират рәвешендә бәйли торган мөнәсәбәтләрне өйрәнергә тиеш; әлеге элементлар башка элементлар белән алышына, ләкин система барлыкка китерми. Шулай итеп, синхроник лингвистика телне система буларак өйрәнә, ягъни тел белән эш итә, ә диахроник лингвистика исә сөйләмне өйрәнә, аның объекты система барлыкка китерми. Шунысын әйтеп үтәргә кирәк, синхрония-диахрония антиномиясе инде И.А. Бодуэн де Куртенэ тарафыннан ук статика һәм динамика буларак өйрәнелә башлый.

3. Ф. де Соссюр концепциясенең тагын бер каршылыгы – *эчке һәм тышкы лингвистика антиномиясе*. Телдә тышкы һәм эчке проблемалар, тел үсешендә тышкы факторларның тәэсире теге яки бу формада В. фон Гумбольдт, И.А. Бодуэн де Куртенэ һәм кайбер башка галимнәрнең хезмәтләрендә чагылыш таба. Ләкин галимнең казанышы шунда ки, ул телдәге тышкы һәм эчке факторлар эшчәнлегенең чикләрен төгәл рәвештә билгели. Ул эчке факторлар тарафыннан билгеләнгән тел системасын тел яшәеше һәм үсешенең тышкы шартларыннан катгый рәвештә аера. Телгә карамаган факторлардан, ул, беренче чиратта, тел тарихы һәм җәмгыять тарихы, милләт һәм, гомумән, цивилизация арасындагы бәйләнешләрне күрсәтә. Тел тарихы белән җәмгыять тарихы үзара бәйләнгән һәм бер-берсенә тәэсир итәләр: халыкның гореф-гадәтләре аның телендә чагылыш таба; тел халыкны, милләтне формалаштыра. Яулап алулар, колонизацияләр, сәүдә мөнәсәбәтләре, кабилә һәм халыкларның күчеше, мәдәният хәле, дәүләтнең тел сәясәте телнең

таркалуына китерә, ул телнең башка телләр белән багланышына тәэсир итә, тел эчендәге диалектларның үзара мөнәсәбәтенә, әдәби тел формалашу үзенчәлекләренә йогынты ясый, тел тарихының үзенчәлеген характерлый. Тышкы лингвистикага Ф. де Соссюр, шулай ук, телләрнең географик таралуын һәм диалекталь бүленешен кертә. Галимнең фикеренчә, кайбер тел күренешләре, мәсәлән, алынмалар, тышкы факторлар ярдәмендә аңлатыла. Ләкин экстралингвистик факторлар тел системасына йогынты ясамый, "аларны урап узу телнең эчке механизмын аңларга комачаулый дип уйлау ялгыш". Телне система буларак өйрәнү өчен, "теге яки бу тел камилләшә торган шартларны белү зарур түгел", чөнки "тел – бары тик үз эшчәнлегенә таяна торган система". Соңгы мәгънәсендә тел эчке лингвистика объекты булып тора, системаны үзгәртергә мөмкин булган һәр нәрсә эчке күренешкә карый. Моның белән беррәттән, тел һәм аның үсеш-үзгәреше телне барлыкка китергән һәм аны камилләштергән җәмгыять белән мөнәсәбәттә өйрәнелергә тиеш. Алга таба әлеге бүленеш тел белемендә әһәмиятле урын тоткан социологик юнәлешнең һәм структурализмның барлыкка килүенә сәбәп була.

4. Ф. де Соссюрның лингвистикадагы тагын бер төп казанышы – *телнең системалыгын дәлилләү*. Ф. де Соссюрга кадәр И.А. Бодуэн де Куртенэ (аның хезмәтләрен Ф. де Соссюр югары бәяләгән) тел системасын үзара төрле мөнәсәбәтләр ярдәмендә багланышка кергән өлешләр күплеге буларак кабул итә. Ф. де Соссюрда исә тел системасы аның кисәкләрен чагыштыруга нигезләнә. Телне математик төгәл система буларак кабул итеп, ул система өлешләрен билгеләүдә "кисәк" кебек математик термин куллана. Аның фикеренчә, телдәге барлык мөнәсәбәтләр математик формулалар ярдәмендә билгеләнергә мөмкин. Система буларак тел ике үзенчәлеккә ия: системаның барлык кисәкләре үзара тигез; система ябык. Тел системасы аның кисәкләре арасындагы тәңгәллек һәм аермалыкларны билгеләү нигезендә формалаша. Ф. де Соссюр статиклыкны тел системасының төп үзенчәлеге буларак ассызыклый, ләкин системаның абсолют хәрәкәтсез халәте буларак кабул итми.

Системадагы элементлар арасында ике төр мөнәсәбәт – синтагматик һәм ассоциатив мөнәсәбәтләр беренче планга чыга.

Кайбер галимнәр фикеренчә, әлеге мөнәсәбәтләрне ачу Н.В. Крушевскийга бәйле. Синтагматик мөнәсәбәтләр ике яки икедән күбрәк булган система кисәкләре арасындагы мөнәсәбәтләргә нигезләнә, алар турысызыклылык принцибына карый. Әлеге принципка бәйле рәвештә, сөйләм берәмлекләре туры сызык буенча тезелә һәм һәрбер берәмлек күрше берәмлекләр белән мөнәсәбәткә керә. Берәмлекләрнең турысызыклы тезмәсен Ф. де Соссюр синтагма дип атый. Мөнәсәбәтләрнең икенче төрен ул ассоциатив мөнәсәбәтләр дип исемли, "әлеге мөнәсәбәт кисәкләрен виртуаль мнемоник (гр. mneme – хәтер) рәткә туплый". Ассоциатив мөнәсәбәтләр рәтенә ул морфологик мөнәсәбәтләрне генә түгел, ә бәлки сүзләр арасындагы мәгънәви мөнәсәбәтләрне дә кертә. Аның фикеренчә, синтагматик һәм ассоциатив мөнәсәбәтләрнең бердәм эшчәнлеге "телнең нигезен тәшкил итә һәм аның эшчәнлеген билгели".

5. Ф. де Соссюр *телнең тамга (знак) характеры*н да дәлилли. Телне төшенчәне аңлата торган тамгалар системасы буларак өйрәнү галимнең лингвистик концепциясендә зур урын алып тора. Ул телне тамгалар системасы буларак кабул итә. Тел тамгасы, аныңча, капма-каршы куелган психик нигез: аңлатучы (акустик образ) һәм аңлатылучы (төшенчә). Тел тамгалары – кешенең баш миендә урын алган чынбарлык. Тел механизмында сүз төп тамга ролен үти. Галим тамгалар турында мөстәкыйль фән – семиология фәнен булдырырга тәкъдим итә. "Аерым бер төрдәге тамгалар турындагы фән" буларак лингвистика семиологиянең төп өлеше булып торачак, чөнки тел – "иң катлаулы һәм иң киң таралган семиологик система".

Ф. де Соссюр тел тамгаларының үзенчәлекле сыйфатларына ишарәли. Боларга, ул беренче чиратта, тамганың иреклелеген кертә. Әмма, башка яктан, әлеге тамга (знак) иҗтимагый яктан шартлы. Тамганың иреклелеге аның мотивлашуын кире какмый, чөнки телнең гомуми системасындагы күпчелек сүзләр мотивлашкан. Тамганың иреклелеге принцибы *үзгәреш антиномиясе*н – *тамганың үзгәрмәүчәнлеге*н барлыкка китерә. Тел тамгасының үзгәрмәүчәнлеге кешенең аны традиция кысаларында гына куллануына бәйле. Тарихи үсеш процессында

тамгадагы аңлатучы һәм аңлатылучы компонентлар арасындагы мөнәсәбәтләр үзгәрергә мөмкин, ягъни, сүзнең аваз составы, аның мәгънәсе үзгәрә ала яки әлеге ике үзгәреш берьюлы булырга мөмкин. Бу исә тел үсешенең өзлексез булу принцибы белән тыгыз бәйләнгән.

Телне система һәм тамгалар буларак кабул итүдә Ф. де Соссюр тарафыннан тел һәм тамгалардагы аермалыкларның мөһимлеген ассызыклау зур роль уйный. Тел тамгасы психик күренеш булганга, аның өчен матди аермалыклар түгел, ә бәлки функциональ сыйфатлар мөһим. Аның фикеренчә, сүздә аваз түгел, ә бу сүзне башка сүзләрдән аерырга ярдәм иткән аваз аермалыклары әһәмияткә ия. Бу фикергә бәйле рәвештә, Соссюр фонеманы төрле сыйфатлар күплеге буларак кабул итә, алга таба бу идеяне Прага лингвистик түгәрәге дә кулланылышка ала.

Соссюрның шәкертләре һәм эшчәнлекләренә аның тәэсире булган галимнәр бердәмлек барлыкка китерми, чөнки аның концепциясендәге кайбер фикерләр каршылык тудыра һәм төрлечә аңлашылырга мөмкин. Соссюрның дәвамчылары да өч агымга аерыла. Беренче агым вәкилләре – остазларына карата тугры калган һәм аның фикерләрен дәвам иткән Ш.Балли, А.Сеше, С.О. Карцевский (Женева мәктәбе). Икенче агым вәкилләре чагыштырмача күпсанлы, алар Ф. де Соссюрның социологик карашларын тел белеменең чагыштырма-тарихи принциплары белән кушып кабул итәләр. Бу агымның вәкилләре – А.Мейе, Ж.Вандриес, Э.Бенвенист, А.Соммерфельт һ.б. Соңгы, өченче агым исә структурализм юнәлеше тармакларының күпсанлы галимнәрен үз эченә ала.

**Тел белемендә иҗтимагый юнәлеш**

XX гасырда телне индивид күзаллаулары системасы буларак кабул итүче яшь грамматикачыларның индивидуализмына карата реакция буларак, капма-каршы тенденция – телнең иҗтимагый табигатен ассызыклау югары үсеш ала. Үз вакытында инде В. фон Гумбольдт, И.А. Бодуэн де Куртенэ, Г.Пауль һәм Ф.Ф. Фортунатовлар телнең җәмгыять яшәешенә һәм үсешенә бәйле булуына басым ясый, ләкин әлеге проблеманы яктырту фрагментар һәм психологик характерда

була. Лингвистика тарихында төп иҗтимагый юнәлешләрне Ф. де Соссюр һәм аның шәкерте Антуан Мейе (1866-1936) исемнәре белән бәйләргә була, шушы ике галим әлеге юнәлешкә иҗтимагый тел белеме исемен бирәләр дә инде. Шулай ук әлеге юнәлешкә француз тел белгечләре Жозеф Вандриес (1875-1960), Шарль Балли (1865-1947), Эмиль Бенвенист (1902-1977), Альбер Сеше (1870-1956), норвегияле Альф Соммерфельт (1892-1965) һ.б. галимнәр керә. Иҗтимагый юнәлешнең төп вәкилләре А.Мейе һәм Ж.Вандриес чагыштырма-тарихи тикшеренү методларын тел социологиясе белән кушалар. Телнең социологик концепциясе тел белемендә әлеге юнәлешнең үзенчәлекле сыйфатларын билгели.

Тел белеме тарихында А.Мейе һинд-европа телләренең чагыштырма грамматикасы өлкәсендә эш итүче галим буларак билгеле. Аның "Һинд-европа телләрен чагыштырма өйрәнүгә кереш" дип исемләнгән китабы киң танылу таба. Бу китапның теоретик кереш өлешендә А.Мейеның лингвистик концепциясе аеруча аңлаешлы итеп бирелә. Әлеге хезмәттә галим тел күренешләрен социологик күзлектән аңлатырга тырыша. А.Мейе фикеренчә, "тел, бер яктан, аерым шәхесләргә караса, икенче яктан, ул аларга мәҗбүри бирелә; бу яктан ул бары тик физиологик яки психик чынбарлык кына түгел, ә бәлки, беренче чиратта, иҗтимагый чынбарлык ролен үти". "Тел җәмгыять булганга гына яши", җәмгыять үзе дә телдән башка яши алмас иде. Телне иҗтимагый категория буларак кабул иткән хәлдә, тел үзгәрешләренең этәргече – тел хәятенең иҗтимагый шартлары, дип ассызыклый А.Мейе. Ул, телнең иҗтимагый кулланылышына бәйле рәвештә, тел үзгәрешләренең өч факторын аерып күрсәтә. Беренче факторга ул телнең спонтан үсешен кертә. Тел үсешенең икенче мөһим факторы – башка телләрдән алынмалар керү һәм сүзләрнең диалекттан төп телгә күчүе. "Бер иҗтимагый төркем вәкилләре башка төркем вәкилләре белән сату-алу, сәяси, дини һәм интеллектуаль мөнәсәбәтләргә керү һәм кайбер аерым вәкилләр чит телне өйрәнү белән, туган телгә чит элементлар керү мөмкинлеге туа". Тел үзгәрешләренең өченче факторы исә "халык телен алыштырганда" мәйданга чыгу. Халык яулап алучылар, чит ил

колонистлары яки югары цивилизацияле халык телен кабул итә икән, бу күренеш субстрат барлыкка китерә. Бу очракта халык теле яулап алучы халык теле эчендә эреп югала, ләкин ул телдә үзенең кайбер сыйфатларын саклап кала, ягъни, җиңелгән тел җиңүче тел өчен нигез ролен үти. Җиңүче тел – ул суперстрат, җирле халык теле өстендә барлыкка килгән тел, җиңелгән тел көчлерәк телнең нигезенә тәэсир итмичә юкка чыга. Моннан тыш, бер үк халык, һәр ике телгә караган сүзләрне дә файдаланып, ике төрле тел кулланырга мөмкин. Икетеллелек телләрнең кушылуына китерә.

А.Мейе аваз үзгәрешләрен дә иҗтимагый факторлар ярдәмендә аңлатырга тырыша. Ул җәмгыять телгә индивидуаль яңалыкларны кертүгә каршы дип саный. Телдә бары тик җәмгыять тарафыннан кабул ителерлек яңалыклар гына сеңеп кала. Сүз мәгънәсенең үзгәрешен дә ул иҗтимагый сәбәпләр ярдәмендә аңлата: сүз киң иҗтимагый төркемнән таррак иҗтимагый төркемгә күчкән очракта, аның мәгънәсе дә тарая; ә сүз киресенчә, киң иҗтимагый төркемгә күчкәндә исә аның мәгънәсе киңәя. Моннан тыш, әлеге сүз белән белдерелгән предметның яки күренешнең иҗтимагый функциясе үзгәргән очракта да аның мәгънәсе үзгәрергә мөмкин.

Ж.Вандриес, компаративистика белән беррәттән, тел белеменең гомуми проблемалары белән дә шөгыльләнә. Аның “Тел. Тарихка лингвистик кереш” дип аталган хезмәтендә француз мәктәбенең тел белеме проблемаларына карашлары чагылыш таба. Биредә Ж.Вандриес “кешеләр үзара аралашу зарурлыгын тойган көнне җәмгыятьтә тел барлыкка килә,” ди. Кеше, беренче чиратта иҗтимагый зат булганга, шулай ук тел кешенеке булу сәбәпле иҗтимагый факт булып тора; телнең иҗтимагый ролен өйрәнеп кенә аның нәрсә икәнлегенә җавап бирергә мөмкин. Беренче сөйләшүче индивидлардан башлап, тел үзенең тотрыклы формаларын кабул итә башлый. Бу яктан тел – иҗтимагый күренеш. Тамгалар (знаклар) системасы буларак тел кешеләрнең аралашуы өчен хезмәт итә. Ж.Вандриес телне “билгеле бер иҗтимагый төркем индивидларыннан өстен булган идеаль лингвистик форма” дип атый. Тел үсеше ике капма-каршы тенденция – дифференциация һәм унификация нигезендә

билгеләнә. Дифференциация телнең тагын да вак өлешләргә бүленүенә китерә. Ләкин җәмгыятьтә мондый дифференциация беркайчан да ахырга кадәр барып җитми, чөнки кешеләр бертуктаусыз бер-берсе белән аралашалар. Шул рәвешле, дифференциациягә каршы һәрвакыт унификация процессы бара. Унификация бозылган мөнәсәбәтләрне торгыза. Телләрнең төрле типлары һәм диалектлары шушы ике процессның капма-каршы эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килә. Ж.Вандриес фикеренчә, телне кешедән башка камилләшә торган һәм үзенең шәхси максатларын куйган мөстәкыйль күренеш буларак кабул итү ялгыш. "Тел әлеге телдә сөйләшүчеләрдән һәм уйлаучылардан башка яши алмый. Ул индивидуаль аң тирәнлегендә ята; биредә ул кеше сөйләменең авазларында чагылыш табар өчен көч туплый. Ләкин индивидуаль аң – индивидуумга үзенең законнарын тәкъдим итүче коллектив аңның бер элементы гына. Телләр үсеше җәмгыять үсешенең бер төре генә".

Шулай итеп, иҗтимагый юнәлеш телне, беренче чиратта, үсеше иҗтимагый факторларга бәйле булган иҗтимагый күренеш буларак кабул итә. Әлеге мәктәп вәкилләре фикеренчә, тел үзгәрешләрен психологик яки физиологик сәбәпләр түгел, ә иҗтимагый-тарихи шартлар билгели. Аралашу чарасы буларак тел барлык индивидуаль күренешләрне кире кага, тел коллективы белән бәйле булмаган һичбер күренеш белән дә мөнәсәбәткә керми. Индивид, үзенең теләге буенча, тел тамгасын (знагын) барлыкка китерә дә, үзгәртеп кора да алмый. Шартлы билгеләр системасы буларак, тел үз коллективында традиция нигезендә буыннан буынга күчә, шул ук вакытта, ул бу телдә сөйләшүче теге яки бу индивид өчен тамгалар (знаклар) системасы булып тора. Иҗтимагый юнәлеш идеяләре бүгенге көн социолингвистика фәнендә үстерелә. Социолингвистик агымнар төрле методологик карашлар белән аерылып тора: антропологик лингвистика, этнолингвистика, бихевиоризм һ.б. Ләкин бу барлык карашларны берләштергән бер максат бар – ул да булса, иҗтимагый күренеш буларак телнең табигатенә тирәнрәк үтеп керү.

**Тел белемендә структурачылык**

“Структурачылык” термины иң элек 1939 елда голландия лингвисты Х.Пос мәкаләсендә кулланыла, ләкин әлеге терминның тарихи тамырлары һинд тел белеме традицияләренә карый: борынгы һинд галиме Панини телне төгәл рәвештә тасвирларга тырышканда әлеге терминны куллана. Урта гасырларда әлеге юнәлеш гомуми рациональ грамматикада урын ала, соңрак Р.Декарт һәм В.Лейбниц хезмәтләрендә чагылыш таба. Структурачылыкның барлыкка килүенә һәм үсеш алуына И.А. Бодуэн де Куртенэ, Ф.Ф. Фортунатов, Л.Блумфилд, Н.С. Трубецкой, Л.Ельмслев, Э.Сепир, Ф. де Соссюр һәм башка галимнәрнең идеяләре тәэсир итә. XX гасырның 20-40 нчы елларында структурачылыкның концепция һәм методларын барлыкка китерүдә зур роль уйнаган мәктәпләр формалаша: Прага лингвистик мәктәбе, Дания структурачылыгы, яки глоссематика, АКШдагы дескриптив лингвистика. Структурачылыкның барлыкка килүендә әдәбият белемендәге рус формаль мәктәбе дә зур роль уйный (Е.Д. Поливанов, Л.П. Якубинский, Ю.Н. Тынянов һ.б.).

Структурачылык, беренче чиратта, яшь грамматикачылыкны кире кагу белән бергә, телнең тарихына һәм психологиясенә, эмпиризмга карата югары игътибар бирү нәтиҗәсендә барлыкка килә. Структурачылыкның барлыкка килүе фән үсеше белән дә бәйле (фәнгә бу чорда элемент һәм структура идеяләре үтеп керә). Төрле фәннәрнең терминологиясендә төрле мәгънәләргә туры килүенә карамастан, XX гасыр урталарында структура төшенчәсе бик нык популярлаша. Гомуми мәгънәсендә структура төшенчәсе теге яки бу күренешнең элементлары арасындагы бәйләнеш төрен аңлата.

Структура төшенчәсе тел белеменә дә үтеп керә, ләкин структурачылыкның аерым юнәлешләрендә ул төрле мәгънәгә ия була. Әлеге лингвистик юнәлеш тарихында берничә чорны аерып күрсәтәләр.

Беренче чор (XX гасырның 50 нче елларына кадәр) телдәге аңлату планы структурасына карата игътибар үсү белән характерлана. Бу тел системасының формаль элементлары арасындагы мөнәсәбәтләр ролен күпертеп кабул итүгә, кайбер

очракларда тел нигезләре буларак элементларны санга сукмауда чагыла. Бу чорда тел теориясенең статикасына зур игътибар бирелә, тел яшәешенең һәм вариативлыгының психологик һәм иҗтимагый факторлары бөтенләй диярлек өйрәнелми.

Структурачылыкның икенче чорында (50 нче еллардан башлап) телнең эчтәлек планына, тел системасының динамикасына карата кызыксыну уяна.

70 нче еллардан алып структурачылыкта өченче этап башлана. Тел системасының төгәл тасвирлау аппаратын барлыкка китерү белән, структурачылык тел белемендә мөстәкыйль юнәлеш буларак яшәүдән туктый. Структурачылык методлары һәм алымнары социолингвистикада, чагыштырма-тарихи тел белемендә, психолингвистикада кулланыла башлый, бу исә аны яңа юнәлешләргә һәм традицион тел белеменә каршы куелудан азат итә.

Структурачылык мәктәпләре телне өйрәнү мәсьәләләрендә кайбер аермалыкларга ия булуына карамастан, гомуми концептуаль платформада кушылалар: 1) тел – системалы структура барлыкка китерә, биредә барлык берәмлекләр үзара төрле юллар белән бәйләнә; 2) тел – башка тамга (знак) системалары белән барысы өчен дә гомуми булган семиотика кысаларында мөнәсәбәткә кергән тамгалар (знаклар) системасы; 3) теге яки бу табигый телне өйрәнгәндә тел һәм сөйләмне аерырга кирәк; 4) тел системасы нигезендә универсаль мөнәсәбәтләр – барлык баскычларда да тел берәмлекләре арасындагы синтагматик һәм парадигматик мөнәсәбәтләр ята; 5) тел синхроник һәм диахроник караштан чыгып өйрәнелергә мөмкин, телне структур яктан өйрәнгәндә синхрониягә басым ясала; 6) статика һәм динамика телнең бер үк вакытта мәйданга чыга торган ике халәте; статика ярдәмендә телнең система буларак balанслашуы барлыкка килә, ә динамика телдәге үзгәрешләргә мөмкинлек тудыра; 7) тел – үзенең эчке законнарына ия булган мөстәкыйль күренеш, аны, беренче чиратта, эчке факторларын искә алып өйрәнергә кирәк; 8) тел өйрәнүдә лингвистиканы табигый фәннәр белән якынлаштыра торган төгәл, катгый методларны кулланырга кирәк.

Структурачылык юнәлешләренең берсе – Прага лингвистик түгәрәге, яки Прага лингвистик мәктәбе.

**Прага лингвистик мәктәбе**

Прага лингвистика мәктәбе 1926 елда чех германисты Вилем Матезиус (1882-1945) инициативасы буенча барлыкка килә. Әлеге мәктәпнең исеме географиягә бәйле, чөнки мәктәпнең төп идеяләре Прага лингвистик түгәрәгенең эшчәнлеге нәтиҗәсендә формалаша. Әлеге түгәрәк телгә һәм әдәбиятка карата структур һәм функциональ карашларны алга сөргән славян, герман телләрен һәм әдәбиятларын өйрәнүче галимнәрне үз эченә ала. Түгәрәкнең “рус нигезен” Н.С. Трубецкой (1890-1938), С.О. Карцевский (1884-1955) һәм Р.О. Якобсон (1896-1982) тәшкил итә. Алардан башка әлеге түгәрәккә Богумил Трнка, Богуслав Гавранек, Владимир Скаличка һ.б. чех лингвистлары керә. Рәсми рәвештә түгәрәк 1952 елга кадәр яшәп килә, ләкин чынбарлыкта исә Икенче Бөтендөнья сугышына кадәр яши, бу вакыт эчендә ул “Труд”ының 8 санын чыгарырга өлгерә. А.Мартине (Франция), Л.Блумфилд (АКШ), К.Бюлер (Австрия), Л.Ельмслев (Дания), Д.Джоунз (Англия), В.Дорошевский (Польша), Г.О. Винокур, Е.Д. Поливанов, Ю.Н. Тынянов (Россия) кебек галимнәр түгәрәк утырышларында чыгыш ясый һәм мәкаләләр бастыра. Прага лингвистик мәктәбенең девизы ике сүз ярдәмендә аңлатыла: структура һәм функция, шуңа күрә аны кайвакыт *Функциональ лингвистика мәктәбе* дип тә атыйлар. Прага лингвистик мәктәбенең бер вәкиле булган Й.Вахек, структурачылык һәм функциональлек – әлеге мәктәпнең ике үзенчәлекле сыйфаты, дип ассызыклый.

Прага лингвистик мәктәбенең концепциясе, беренче чиратта, телне һәм аны өйрәнү методларын яшь грамматикачыларча аңлатуга каршы юнәлдерелгән була. Яшь грамматикачыларның атомик һәм генетик принципларын урап узып, Прага түгәрәге вәкилләре Ф. де Соссюр һәм И.А. Бодуэн де Куртенэ, Ф.Ф. Фортунатов, А.А. Шахматов хезмәтләрендә чагылыш тапкан рус лингвистик традициясенең кайбер идеяләрен кабул итәләр һәм алга таба үстерәләр. Прага түгәрәге тарафыннан Ф. де Соссюрның лингвистик концепциясенең кайбер өлешләре

башкарак мәгънәдә аңлатыла һәм камилләштерелә. Прага лингвистик мәктәбенең гомумтеоретик системасы славистларның 1929 елда уздырылган I съезды “Тезислар”ында чагыштырмача тулы рәвештә чагылыш таба. “Тезислар”дагы гомуми кагыйдәләр, беренче чиратта, славян телләрен өйрәнүдә килеп чыккан кыенлыклар белән бәйле.

Телне функциональ система буларак кабул итү “Тезислар”ның беренче битләреннән үк күзгә ташлана. Функциональ караштан чыгып фикер йөрткәндә, “тел – теге яки бу максатларга эшли торган аңлату чаралары системасы”. Биредә телнең системачылык сыйфатына да басым ясала: “Телдәге һичбер күренеш тә телгә бәйле булган системаны күздә тотмыйча аңлатыла алмый”. Мәсәлән, Ф. де Соссюрда “Үз-үзендә һәм үзе өчен тикшерелгән тел – лингвистиканың бердәнбер чын объекты” булса, прагалылар тел һәм телдән тыш чынбарлык арасындагы бәгланышны ассызыклыйлар, алар фикеренчә, “телдән тыш чынбарлыктан башка телнең мәгънәсе дә, яшәргә хакы да юк”. Прага структурачылары телнең иҗтимагый табигатен яклыйлар, алар фикеренчә, “телнең структурасы аны уратып алган структуралар белән тыгыз бәйләнгән”. Моның белән бәйле рәвештә, прагалылар әдәби тел структурасын өйрәнүгә зур игътибар бирәләр. Алар фикеренчә, әдәби тел структурасы хосусый системалардан барлыкка килә, ул иҗтимагый һәм функциональ сыйфатларга ия. Шулай ук алар телнең әдәбиятка, сәнгатькә һәм мәдәнияткә карата мөнәсәбәтен өйрәнүне уңай күрәләр. Тел структурасын мондый киң рәвештә өйрәнү теләге тел тамгасын (знагын) аның реальләшүендә, әйләнә-тирә чынбарлык белән мөнәсәбәттә өйрәнү зарурлыгына бәйле. Прага структуралистлары фикеренчә, тел системасының иң мөһим сыйфаты – аның функциональ максаты, гамәли кулланылышы, моның белән бергә тел системасы эчендәге мөнәсәбәтләр генә түгел, ә бәлки тел системасының телдән тыш эшчәнлеккә карата мөнәсәбәте дә мөһим.

Прага лингвистик түгәрәге Ф. де Соссюрның синхрония һәм диахрония хакындагы антиномиясен бераз башка мәгънәдә кабул итә. Прагалылар фикеренчә, телгә карата синхроник һәм диахроник карашлар бер-берсенә тәңгәл. Тел үзгәрешләренең

тарихи һәм хронологик тасвирламасы гына алып барылырга тиеш түгел, ә бәлки әлеге үзгәрешләрнең систематик сәбәпләрен дә табарга кирәк. Прагалылар фикеренчә, структур тел белемендә диахроник законнар синхроник законнардан бары тик беренчесенең вакыт эчендә чагыштырма хронологик чикләрдә һәм тарихи эзлеклелектә килүе белән генә аерыла. Прага структурачылыгында синхрония һәм диахрония мөстәкыйль өлкә һәм телне өйрәнү аспектларына карамый.

Дөнья тел белемендә Прага лнгвистик мәктәбенең төп казанышшы фәнни дисциплина буларак фонологияне барлыкка китерү белән бәйле. Фонологик проблемалар аеруча төгәл һәм ачык рәвештә Н.С. Трубецкойның “Фонология нигезләре” (1939) дип аталган хезмәтендә чагылыш таба. Бу китапта Н.С. Трубецкой, беренчеләрдән булып, телнең системалылыгын күрсәтә, якынча 100 телнең фонологик системасын өйрәнә. Биредә ул фонетика һәм фонологияне чагыштыра, аларның максатларын билгели. “Фонология нигезләре”ндә автор яңа фәннең барлык төп төшенчәләрен – фонеманы һәм аның сыйфатларын, фонема оппозицияләрен, фонемаларны нейтральләштерүне, фонема тезмәләрен һәм аларның тел системасындагы урынын анализлый.

Структур һәм функциональ карашларның принципларын прагалылар морфология һәм синтаксис проблемаларын өйрәнүдә дә кулланырга телиләр. Алар фикеренчә, морфология – сүз функцияләре, сүз формалары системасы һәм аларның төркемнәре белән бәйле лингвистик номинация бүлеге. Синтаксис исә синтагматик ысуллар теориясе буларак кабул ителә, биредә синтагматик эшчәнлек нәтиҗәсендә барлыкка килгән сүзләр тезмәсе өйрәнелә. Функциональ синаксис юнәлешләреннән берсе В.Матезиус хезмәтләрендә чагылыш таба, биредә ул җөмләне ситуация контексты белән чагыштыра һәм аның формаль, грамматик бүленешенә каршы торган җөмләнең актуаль бүленеше турындагы идеясен тәкъдим итә.

Функциональ грамматиканың башка бер юнәлеше Р.Якобсон тарафыннан эшләнә. Ул телнең грамматик оппозицияләре системасын булдыра. Р.Якобсон үз системасын рус теленең падежлар белән төрләнү системасын анализлауда куллана.

В.Скаличканың грамматик теориясенең үзәгендә исә грамматик системаның нигезе саналган минималь берәмлекләрне эзләү ята. Ул сүздә морфологик элементны (морфеманы) түгел, ә бәлки грамматик элементны ассызыкларга тәкъдим итә. Грамматик элемент буларак ул бөтенләй морфеманы түгел, ә берьюлы функциональ һәм формаль элемент ролен үтәгән семаны кабул итә.

Телне типологик яктан өйрәнүгә карата кызыксынуның уянуы Прага түгәрәге эшчәнлеге белән дә бәйле. Прагалылар фикеренчә, телдәге грамматик һәм фонологик типларны аерып чыгу белән бәйле фонологик һәм грамматик проблемаларның эшләнеше телләр үсешенең гомуми закончалыкларын ачуга ярдәм итәргә мөмкин. Прага тел белгечләре үзләренең тикшеренүләрендә түбәндәге күренешкә тап булалар: кайбер күрше телләр, хәтта төрле тел гаиләләренә карасалар да, еш кына уртак үзенчәлекле сыйфатларга ия булырга мөмкин. Аларча, әлеге географик яктан уртак, ләкин кардәш булмаган, синтаксис, морфология, фонология структуралары буенча уртаклыкларга ия булган телләр тел берлекләрен барлыкка китерә. Тел берлегенә мисал буларак үз эченә грек, албан, болгар һәм румын телләрен алган балкан тел берлеген китерәләр.

Прага структурачылык мәктәбе тел белеме үсешенә зур өлеш кертә. Фонологиянең әлеге мәктәп тарафыннан эшләнелгән төп идеяләре, телләрне фонологик яктан тасвирлау принциплары, функциональ грамматика кагыйдәләре, әдәби тел һәм функциональ стильләр турындагы, сөйләм культурасы һәм тел берлекләре хакындагы өйрәтмәләр тел белемен тел өйрәнү өлкәсендәге яңа карашлар һәм ысуллар белән баета.

**Глоссематика**

“Глоссематика” (иң элек ул фонематика дип атала) дигән исем 1936 елда пәйда була һәм грек элементларына барып тоташа (glossa – тел + sema – тамга). Әлеге исем телгә карата принципиаль яңа карашны ассызыкларга тиеш була. Глоссематикага 1931 елда Прага түгәрәгеннән соң барлыкка килгән Копенгаген лингвистик түгәрәге нигез сала. Структурачылыктагы бу юнәлешнең күренекле вәкилләре –

Виго Брёндаль (1887-1942), Ханс Ульдалль (1907-1957) һәм әлеге юнәлешнең төп теоретигы һәм нигез салучысы – Луи Ельмслев (1899-1965). Глоссематиканың нигезен ачыклаган хезмәтләр рәтенә түбәндәгеләр керә: В.Брёндальның “Структураль лингвистика” (1939) дип исемләнгән мәкаләсе, Х.Ульдалльнең “Глоссематика нигезләре” (1957) китабы, Л.Ельмслевның “Тел теориясенә пролегоменнар” (1943) һәм “Гомуми грамматика принциплары” (1928) дип аталган хезмәтләре һ.б.

Глоссематика теориясе Ф. де Соссюрның лингвистик концепциясе буенча, аның телне “үз эчендә һәм үзе өчен” өйрәнү тәкъдиме нигезендә барлыкка килә. Л.Ельмслев фикеренчә, лингвистика телне телдән тыш күренешләрнең (физик, физиологик, психологик, логик һ.б.) конгломераты буларак түгел, ә бәлки бербөтен, структура буларак өйрәнергә тиеш. Тел структурасында һәрбер телдә мәйданга чыккан даими, “телдән тыш чынбарлыкка” бәйле булмаган элементларны аерырга кирәк. Л.Ельмслев буенча, традицион лингвистиканың негатив ягы – аның төп эчтәлеге тел системасын өйрәнүгә генә түгел, ә сөйләм эшчәнлегенең психологик, физиологик, иҗтимагый һәм тарихи үзенчәлекләренә юнәлдерелү. Ә чын фәнни тел белеме исә имманент булырга, ягъни конкрет теге яки бу телгә түгел, ә гомумән кеше сөйләменә караган конструктив элементларны өйрәнергә тиеш. Моның белән беррәттән, Л.Ельмслев универсаль лингвистик теория барлыкка китерүне максат итеп куя.

Ф. де Соссюрның “тел-сөйләм” каршы куелышын өйрәнеп, Л.Ельмслев түбәндәге нәтиҗәгә килә: бу каршы кую, аз дигәндә дүрт төшенчәгә кагыла: схема – норма – узус – акт. Тел схемасы – иҗтимагый реализация һәм гамәли формалашуга кагылышсыз рәвештә билгеләнә торган чиста форма. Тел нормасы исә иҗтимагый реализация белән бәйле гамәли форма. Тел узусы – теге яки бу иҗтимагый коллективта кабул ителгән һәм өйрәнелә торган күренешләрнең фактлары тарафыннан билгеләнгән күнекмәләр күплеге. Л.Ельмслев билгеләвенчә, әлеге өч төшенчә Ф. де Соссюрдагы “телне” барлыкка китерә дә инде. Галим фикеренчә, акт – индивидуаль сөйләм эшчәнлеге, сөйләшү.

Әлеге төшенчә Ф. де Соссюрның “сөйләм” мәгънәсенә тәңгәл килә. Л.Ельмслев буенча, узус белән сөйләм телнең гамәли булмаган ягы дип саналган тел схемасына каршы куелган гамәли ягын барлыкка китерә. Прага мәктәбе телне индивидуаль сөйләм процессында реализацияләнүче иҗтимагый нормалар системасы буларак кабул итсә, Л.Ельмслев буенча, норма лингвистта кызыксыну уятмый. Аның фикеренчә, тел системасы – гамәли булмаган схема, биредә гамәли элементлар үзләре түгел, ә тел элементлары арасындагы мөнәсәбәтләр әһәмиятле. Шушы очракта тел берәмлекләренең үзара мөнәсәбәте, “форма”, “чиста схема” гына телдә даимилеккә ия, ә менә “форманың” ни рәвешле чагылдырылуы мөһим түгел. Аның чагылышы (аваз, график форма буларак чагылу, Морзе алфавиты яки башка бер сигналь система нигезендә чагылу һ.б.) үзгәреп торырга мөмкин.

Л.Ельмслев телне коммуникатив чараларның киң системасына караган һәм семиотика тарафыннан өйрәнелгән мәгълүмати системаларның хосусый очрагы буларак кабул итә. Кайбер семиотик системаларны өйрәнгәндә ул телнең биш үзенчәлекле сыйфатын ачыклый. Тел түбәндәге категорияләрдән гыйбарәт: 1) эчтәлек һәм мәгънә белдерү (выражение); 2) эчтәлек һәм мәгънә белдерү арасындагы бәйләнеш; 3) текст һәм система; 4) текст һәм система арасындагы мөнәсәбәт; 5) тел тамгаларының кечерәк компонентларга таркалуы. Телдәге мәгънә белдерү планын һәм эчтәлек планын аерып, Л.Ельмслев, мәгънә белдерү планын – телнең тышкы ягына, ягъни фикернең аваз яки башка катламына, ә эчтәлек планын телдә чагылыш тапкан фикергә бәйли. Мәгънә белдерү планында субстанция һәм форма аерыла. Субстанция – авазлар, тел тышында урын алган телдән тыш материал, форма исә – материалның теге яки бу телдә кулланылыш ысулы, мөнәсәбәтләр күплегеннән торган тел үзе. Форма даими бер күренеш буларак, төрле субстанцияләрдә реализацияләнә алган абстракт автоном нигез итеп кабул ителә. Мәгънә белдерү һәм эчтәлек арасындагы охшашлыклар элементлар арасындагы тәңгәллекне дәлилләми, тел тамгалары тагын да кечерәк компонентларга таркалырга мөмкин. Мәгънә белдерү планында әлеге компонентлар ролен – фонемалар, эчтәлек планында исә фигуралар, ягъни, эчтәлекнең

таркалмас берәмлекләре үти. Л.Ельмслев фикеренчә, фигуралар элементар мәгънә буларак кабул ителә, аларның комбинациясе телгә бер мәгънә өсти. Мәсәлән, малай – кыз парында <җенес> фигурасы аерылып чыга, кыз – хатын-кыз парында исә <яшь> фигурасы өстенлек итә (яшь – җитлеккән) һ.б. Нинди генә телне алсак та, мәгънә белдерү фигуралары саны 70-80 нән артмый, ә эчтәлек фигуралары саны исә бераз күбрәк. “Шул рәвешчә, берникадәр фигура ярдәмендә һәм аларның үзгәрешләрен күздә тотып, тамгалар (знаклар) легионын барлыкка китереп була. Тел шундый булмаган очракта, ул үзенең максатлары өчен кирәксез корал булыр иде”, – дип ассызыклый Л.Ельмслев.

Л.Ельмслев фикеренчә, бербөтенлек (тел) предметлардан (элементлардан) тормый, ә мөнәсәбәтләрдән гыйбарәт; бу яктан субстанция түгел, ә аның тышкы һәм эчке мөнәсәбәтләре фәннилеккә ия. Әлеге мөнәсәбәтләрне аңлатыр өчен Л.Ельмслев “функция” дигән төшенчә куллана. Функция текст өлешләре арасында бәйләнеш барлыкка китерә, анализ ярдәмендә алардан система барлыкка килә. Текстта да, системада да глоссематик функцияләрнең өч гомуми тибы аерылып чыга.

1. Икеяклы бәйлелек (интердепенденция). Бер-берсеннән аерым яши алмаган ике элемент (исем һәм фигыль, ия һәм хәбәр) арасында мәйданга чыга.

2. Берьяклы бәйлелек (детерминация). Бер элемент икенче бер элементны күздә тота: рус телендәге *около* бәйлек сүзе родительный падежны күздә тота, ләкин бу очракта кире бәйлелек юк.

3. Ирекле бәйлелек (констелляция). Бу очракта бер элемент башка элементсыз да яши ала, мәсәлән, рус телендәге зат һәм род категорияләре.

Фигура һәм функцияләрне аеру Л.Ельмслевка “тел – бәйлелекләр, функцияләр системасы” дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Телдәге мөнәсәбәтләрне өйрәнү өчен математик бәйлелекләрне куллану, глоссематикларны үз теорияләрен телнең имманент алгебрасы дип йөртергә нигез бирә. Глоссематикларның теориясе конкрет телләрнең материалын һәм телдән тыш чынбарлык белән булган багланышны өйрәнүгә бик үк туры килеп бетмәсә дә, телдәге

теге яки бу тел берәмлекләре арасындагы барлык багланыш һәм мөнәсәбәтләрне теоретик яктан билгеләргә тырышу яхшы нәтиҗәләргә китерә. Телнең формализациясе математик лингвистикага нигез сала, телнең гомуми теориясенең алга таба үсешенә уңай яктан тәэсир итә.

**АКШдагы дескриптив лингвистика (Америка структурачылыгы)**

Дескриптив, яки тасвири тел белеме XX гасырның 20-30 елларында АКШда барлыкка килә. Әлеге юнәлешкә нигез салучы буларак Франц Боас (1858-1942), Эдуард Сепир (1884-1939), Леонард Блумфилд (1887-1949) санала. Үзләренең методологик принципларында һәм тикшерү ысулларында әлеге юнәлеш структур принципларга таяна, бу яктан аны структурачылыкның бер юнәлеше буларак кабул итүчеләр дә бар. Америка структурачылыгы берничә идеягә нигезләнә, шуңа күрә бер мәктәп турында сүз алып бару дөрес булмас.

Франц Боас Германиядә дөньяга килә һәм биредәге университетларның берсен тәмамлый. Иң элек ул физиология өлкәсендә эшләргә уйлый, ләкин арктик экспедицияләрдә катнашу аны эскимос һәм индеецлар теле белән шөгыльләнүгә тарта. Аның гомумлингвистик карашлары “Америка индеецлары телләре буенча кулланма” (1911-1922) дип аталган хезмәтендә чагылыш таба. Әлеге хезмәткә керештә Ф.Боас һинд-европа телләре нигезендә билгеләнгән анализ методларының индеец телләрен өйрәнүгә һәм тасвирлауга туры килмәвен күрсәтә. Индеецлар телләрендә сүз һәм җөмлә кебек үзенчәлекле тел категорияләре урын алган. Әлеге телләрдә сүз һәм җөмләне аеру кыен максатка әйләнә. Ф.Боас фикеренчә, индеецлар телләрен өйрәнгәндә өч моментны күздә тотып эш итәргә кирәк: 1) телне барлыкка китергән фонетик элементлар; 2) фонетик төркемнәр ярдәмендә чагылдырылган төшенчәләр; 3) фонетик төркемнәрне барлыкка китерү һәм модификацияләү ысуллары. Америка индеецларының телләре язма рәвештә теркәлмәгән, аларның кардәшлек мөнәсәбәтләре билгеле түгел, шуңа күрә, Ф.Боас фикеренчә, алар тарихи һәм чагыштырма интерпретациягә бирешми. Моның белән бәйле рәвештә, аларны өйрәнү өчен,

телнең формаль сыйфатларына нигезләнгән методлар булдырырга кирәк.

Ф.Боасның традицияләрен Э.Сепир дәвам итә. Ул Америкадагы индеецлар телләрен өйрәнүче иң танылган галимнәрнең берсе. Ләкин Ф.Боастан аермалы буларак, Э.Сепир телнең үзенчәлеген аның бары тик тышкы сыйфатларында яки формаль критерийларында гына күрми, бәлки мәдәният, җәмгыять, тарих белән бәйли. Аның фикеренчә, менә шушы күренешләр телнең эчке табигатен һәм һәр халыкның үзенчәлекле сыйфатларын чагылдыра. Үзенең “Тел” (1921) дип аталган китабында ул телдәге физик һәм идеаль системаларны аерып чыгара, аныңча, икенче система иң мөһим рольне үти. Э.Сепир фикеренчә, һәр тел үзенчәлекле модель нигезендә барлыкка китерелгән, шуңа күрә ул әйләнә-тирә чынбарлыкны тарката һәм аны бу телдә сөйләшүче һәркемгә тәкъдим итә. Төрле телләрдә сөйләшүче кешеләр дөньяны төрлечә кабул итә, әйләнә-тирәне кабул итү, аңсыз рәвештә, тел категорияләренә нигезләнә. Әлеге идеяләр алга таба Б.Уорф хезмәтләрендә чагылыш таба һәм Сепир-Уорф гипотезасы, яки лингвистик чагыштырмалылык гипотезасы дип исемләнә.

Э.Сепир телне иҗтимагый күренеш буларак билгели һәм телнең кешенең үз-үзен тотышының башка формалары белән, беренче чиратта мәдәният белән мөнәсәбәте турындагы проблеманы күтәрә. Мәдәниятне халык эшчәнлеге буларак кабул итсәк, тел – халыкның уйлавы, дип фикер йөртә Э.Сепир. Моның белән беррәттән, ул, тел төзелеше һәм халык мәдәнияте арасында турыдан-туры тәңгәллек юк дип ассызыклый; аныңча, мәдәният белән бары тик телнең сүзлек составы гына бәйле.

Л.Блумфилдның теоретик карашлары америка дескриптив лингвистикасы өчен бер нигез ролен үти. Л.Блумфилд, мөгаен, позитивизмга нигезләнгән дескриптив лингвистика системасына нигез салучы булып торадыр. Лингвистиканың төп максаты – тел фактларын тасвирлау, ләкин аларны аңлату түгел. Әлеге юнәлешнең исемендәге “дескриптив” сүзе дә бу фикерне дәлилли (ингл. to describe – тасвирларга).

Үз эшчәнлегенең башында Л.Блумфилд яшь грамматикачылар идеяләренә уңай караштa була, ләкин инде

1926 елда “Тел турындагы фән өчен кайбер постулатлар” дип исемләнгән мәкаләсендә ул яңа лингвистик теория һәм метод тәкъдим итә. Яңа теория математик формалар, ягъни, каршылыкларны күздә тотмаган гипотеза һәм аксиома белән бәйле була. Телнең постулатларын билгеләү Л.Блумфилд тарафыннан “Тел” (1933) дип исемләнгән китабында теоретик тел белеменең төп максаты буларак кабул ителә. Ф. де Соссюрның “Гомуми лингвистика курсы” хезмәте Европа тел белеме тарихында нинди зур урын алып торса, XX гасыр америка тел белемендә Л.Блумфилдның әлеге хезмәте дә шундый ук бәяләүгә лаек. “Тел” дип аталган китапта чагылыш тапкан лингвистик принциплар, методлар һәм максатлар дескриптив лингвистика үсешенең нигезе буларак кабул ителә. Әйтергә кирәк, әлеге дескриптив лингвистика чирек гасыр буе Америка тел белемендә алдынгы позицияләрдә бара.

Л.Блумфилд лингвистик теориясенең психологик нигезе буларак бихевиоризм (XIX – XX гасыр психологиясендәге юнәлеш; ингл. behaviour – үз-үзеңне тотыш) кабул ителә. Әлеге психологик юнәлешкә буенча, кешенең психологик эшчәнлеген аның үз-үзен тотышына, тышкы реакцияләренә карап кына билгеләргә була. Л.Блумфилд исә телне – кешенең үз-үзен тотышының бер төре итеп, тел процессларын – бер рәттәге күренешләрнең биологик процесслар белән мөнәсәбәте буларак кабул итә. Үзенең гомуми тел теориясен ул механицизм яки физикализм дип атый һәм аны менталь төзелешләргә каршы куя.

Л.Блумфилд тарафыннан күтәрелгән тагын бер фундаменталь проблема – тел мәгънәсе проблемасы. Аның фикеренчә, тел формасының мәгънәсе ситуатив, ул “сөйләүче – сөйләм – тыңлаучы реакциясе” ситуациясендә тормышка ашырыла. Ситуацияләр күпсанлы булганга күрә, тел мәгънәсен билгеләү – тел белемендәге “иң зәгыйфь” күренеш.

Тел баскычлары теориясенең барлыкка килүе дә шулай ук Л.Блумфилд эшчәнлеге белән бәйле. Аның фикеренчә, телне тасвирлау процессын иң гади баскычтан – фонологик баскычтан, беренче чиратта, бөтен фонемаларны һәм аларның барлык комбинацияләрен билгеләүдән башларга кирәк. Фонологик баскычны тасвирлаганнан соң, бераз катлаулы баскычка –

семантик баскычка күчәргә кирәк; семантика исә, аныңча, грамматика һәм лексикага бүленә.

Америка лингвистларының яшь буыны исә Л.Блумфилдның теоретик карашларын төрле юнәлешләрдә үстерә. Аның шәкертләренең һәм дәвамчыларының бер төркеме (Дж.Трейгер, З.Харрис, Б.Блок), Йель мәктәбе исеме астында, тел анализының формаль методларын дәвам итә, лингвистик анализның камилләштерелгән техникасын – дистрибутив лингвистиканы барлыкка китерә. Әлеге мәктәп вәкилләре мәгънә факторын лингвистик тикшеренүләрдән тулысынча алып ташларга тәкъдим итәләр. Дескриптивизмның башка бер юнәлеше – Энн-Арбор лингвистлар төркеме (К.Пайк, Ю.Найда, Ч.Фриз), Л.Блумфилдның теоретик идеяләреннән ваз кичеп, юнәлешнең тикшерү техникасын камилләштерәләр. Әлеге мәктәп вәкилләре лингвистик анализда экстралингвистик – иҗтимагый, этник һ.б. факторларны киң кулланалар, бу күренеш аларны Э.Сепир өйрәтмәләре белән якынайта. Америка структурачылыгының өченче төре трансформацион анализ мәктәбе (Н.Хомский, Р.Лиз һ.б.) тарафыннан ассызыклана.

Америка дескриптив лингвистикасының өч юнәлеше дә лингвистик анализ методикасына, тасвирлау ысулларына, тасвирлауның төзек һәм формаль процессын булдыруга игътибарларын юнәлтәләр, ягъни, аларның максаты – телне тасвирлау техникасын камилләштерү була.

Шулай итеп, структурачылыкның барлыкка килүе турыдан-туры XX гасырның урталары һәм ахырындагы фәнни фикерләрнең гомуми закончалыкларына бәйле. Структурачылыкның төрле юнәлешләрендә теоретик шартлар һәм максатлар белән билгеләнгән милли-специфик сыйфатлар урын ала. Структурачылыкның каралып үткән һәрбер юнәлеше дә бүгенге көн тел белеменең үсешенә үзенең өлешен кертә. Структурачылык XX гасыр тел белеменең иң төп принцибын – телне система буларак карауны алгы планга чыгара.

### Телнең тамга (знак) теориясе

Стуктурачылык идеяләре белән телнең тамга (знак) табигате проблемасы тыгыз бәйләнгән, бүгенге көн тел белемендә дә ул

төп рольне уйный. Телнең тамга теориясе формалашу инде антик фәлсәфәдә ук башланып китә. Бу юнәлештә аеруча актив булган стоикларның эшчәнлеген аерым билгеләп үтәргә кирәк. Алар фикеренчә, тел тамгасы – аваз һәм мәгънә бәйләнешы нәтиҗәсендә барлыкка килгән икеяклы нигез. Тел тамгасын аваз һәм мәгънә берлеге буларак кабул итү урта гасыр фәлсәфәсе аша уза. Бүгенге көн тел белемендә тел тамгалары идеясен исә В. фон Гумбольдт тәкъдим итә, ул “тамга законын” барлыкка китерә. В.Гумбольдт буенча, телдәге форма һәм мәгънә берлеге “фикер үсешенең ихтыяҗлары белән бәйләнгән эчке тел аңында һәм авазда урын ала”, алар исә, үз чиратында, бер-берсе белән мөнәсәбәттә тора. Телнең тамга теориясенең формалашуына Ф. де Соссюр, И.А. Бодуэн де Куртенэ, А.А. Потебня, Ф.Ф. Фотунатов, Н.С. Трубецкой кебек XX гасыр тел белгечләренең эшчәнлеге дә өлеш кертә.

Тамга теорияләренең төп принциплары табигый тел сыйфатларын берьюлы берничә фәннең – фәлсәфә, логика, математика, психология, лингвистиканың анализлавы нигезендә формалаша. Бу исә тамга теорияләрен фәлсәфи, логик-математик, психологик һәм лингвистик юнәлешләргә бүлеп карарга мөмкинлек бирә. Тамга системаларының төзелешендәге һәм функцияләрендәге гомуми күренешләрне тамгалар турындагы фән – семиотика өйрәнә.

*Фән буларак – семиотика.* Семиотика (грек. semiotikon, semeion – билге, тамга, знак, сыйфат) кеше тарафыннан кулланылган төрле тамга системаларын, аларның төрләрен, төзелешен, тамгаларның гомуми сыйфатларын, шулай ук киноның, рәсем сәнгатенең, әдәбиятның һәм кеше мәдәниятенең башка төрләренең тамга функцияләрен өйрәнә. Семиотиканың тарихи тамырлары Блаженный Августин (IV-Vгг.), XII-XIV гасыр схоластикасының логик-лингвистик өйрәтмәләрендә, Дж.Локк өйрәтмәләрендә, Г.В. Лейбницның ясалма тел турындагы идеяләрендә (XVII гасыр ахыры – XVIII гасыр башлары) чагылыш таба. “Семиотика” терминын фәнни әйләнешкә аны уйлап табучыларның берсе – америкалы галим Чарльз Сандерс Пирс (1839-1914) кертә. Нигездә, ул

семиотиканы кеше коллективында кулланыла торган тамга системасы турындагы фән буларак кабул итә.

Ч.Пирс уйлап тапкан яңа фәненең объектларын да (кеше тарафыннан кулланылган һәртөрле тамгалар системасы) билгели, тамгалар классификациясен барлыкка китерә, тамгаларның нигезен, сыйфатларын һәм мөнәсәбәтләрен характерлый. Ч.Пирс семиотикада математик логиканың аерым бер вариантын булдырырга теләсә, Ф. де Соссюр тамгалар системасы буларак табигый телне өйрәнә һәм лингвосемиотикага нигез сала. Тел белеменең әлеге юнәлеше аның тарафыннан семиология дип аталып йөртелә башлый. Иң элек семиология һәм семиотика төрле мәгънәләрдә йөри: семиотика – фәндәге формаль, логик-математик юнәлеш, ә семиология – лингвистик юнәлеш. Соңрак исә ике термин да синонимнар буларак кулланыла башлый.

Ч.Пирсның семиотик идеяләрен дәвам итеп, америкалы фәлсәфәче Чарльз Уильям Моррис (1901-1979) семиотиканы синтактика, семантика һәм прагматикага бүлә. Синтактика тамга системасы кысаларындагы тамгалар төзелешенең кагыйдәсен өйрәнә, семантика – тамгаларның билгеләнү һәм төшенчәгә карата мөнәсәбәтен, ә прагматика тамгаларның субъект һәм адресат белән бәйләнешләрен билгели. Бүгенге көн тел белемендә бераз аныкланган классификация кулланыла, биредә тамгалар чынбарлыкка карата (сигматика), телдә сөйләшүчеләргә карата (прагматика), системадагы башка тамгаларга карата (семантика), тексттагы башка тамгаларга карата (синтактика) мөнәсәбәтләрендә карала.

Семиотика һәм тел тамгалары белән бәйле күп кенә әдәбият дөнья күрсә дә, тел белемендә хәзергә кадәр чишелеш тапмаган лингвосемиотик проблемалар бар: семиотик карашка телнең төзелеше, тел тамгасын билгеләү, башка тамгалар белән чагыштырганда аның үзенчәлекле сыйфатлары, тамга сыйфатларын төрлечә аңлау һ.б.

*Тамга турындагы төшенчә.* Семиотикада тамга турында сүз алып барганда, күп очракта теге яки бу мәгълүматны адресатка җиткерү өчен кулланган һәртөрле матди-идеаль әйбер күздә тотыла. Тамгалар буларак әйберләр, предметлар, чынбарлык

күренешләре, кеше тарафыннан барлыкка китерелгән күпсанлы тамга системалары: юл йөрү билгеләре, реклама билгеләре, олимпия символикасы, хәрбиләрнең погоннарындагы аеру билгеләре, математик тамгалар, кеше сөйләменең акустик һәм визуаль билгеләре, төрле приборларның күрсәткечләре, шәһәр урамнарындагы сурәтләү билгеләре, кисәтү, тәкъдим итү, тыю, игълан итү тамгалары – болар барысы да кешене тормышның барлык өлкәләрен уратып алган.

Тамгалар кешегә хис-тойгы күренешләреннән читкә чыгарга, пространство һәм вакытны узарга, теге яки бу мәгълүматны кабул итәргә һәм башка кешегә тапшырырга, чынбарлыкны күп төрле аспектларга карап бүләргә мөмкинлек бирә. Кешеләрнең гомере, аларның үзара һәм дөнья белән мөнәсәбәте күп төрле тамгалар белән бәйле. Моның белән беррәттән, теге яки бу тамганың төп максаты – үзендә теге яки бу мәгълүматны тоту, саклау.

Мәгълүматтан башка, тамга күп санлы үзенчәлекләргә ия, алар гадәттә тоемлау органнары тарафыннан кабул ителгән тышкы (хис-тойгы, сенсор) һәм кеше аңы ярдәмендә билгеләнгән эчке үзенчәлекләргә аерыла.

Тамганың төп тышкы үзенчәлекләренә аның гамәлилеге, кулланылыш күплеге, турысызыклылык, ягъни вакытта сузылганлык (акустик тамга) яки пространствода сузылганлык (визуаль тамга), стуктурачылык, ягъни, тамганың мөһим булмаган компонентлардан төзелүе керә. Тамганың гамәлилегенә аның зарури рәвештә тоемлау органнары тарафыннан кабул ителеше карый. Киң таралган гамәли формалар рәтенә ишетеп тою органнары тарафыннан кабул ителгән акустик яки аваз формасы һәм күреп тою органнары тарафыннан кабул ителгән оптик форма керә. Кулланылыш күплеге коммуникатив актта аның яңадан барлыкка килмәве, ә бәлки шул ук эчтәлектә яңадан кулланылуы белән бәйле. Турысызыклылык исә, беренче чиратта, һәрбер гамәли объектның пространство-вакыт сыйфатларына ия булулары белән бәйле.

Тамганың эчке сыйфатлары – тамганың гомумилеге, аның системага салынуы, аның кулланылачагын алдан белеп тору,

коммуникатив һәм ситуатив булуы. Тамганың гомумилеге – аерым бер объектны, күренешне, сыйфатны түгел, ә бәлки аерым бер классларны чагылдыру. Бу тамганың фикерләү коралы буларак кулланылуына китерә. Тамганың системага салынуы исә аның кеше яшәешенең теге яки бу өлкәсендә башка тамгалар (знаклар) белән янәшә кулланылуы белән аңлатыла. Тамгаларның үзенчәлекле сыйфаты – кеше тарафыннан мәгълүмати максатларда аңлы рәвештә алдан ук кулланачагын белеп файдалану, бу исә аларны бер коллектив яки җәмгыять кешеләре бертөрле аңлауга китерә. Тамганың коммуникатив булуы – мәгълүматның бер кешедән икенче кешегә җиткерелә алуы. Бу күренеш турыдан-туры тамганың иҗтимагый булуы белән бәйләнгән, ягъни, теге яки бу тамга аерым бер социумда кулланыла һәм биредә әлеге тамга аралашу чарасы булып тора. Тамганың тагын бер мөһим эчке сыйфаты – аның ситуатив булуы – бер үк тамганың шартларга карап үз эчтәлеген алмаштыра алуы, ә кайбер очракта бер үк тамга капма-каршы мәгънәгә дә ия булу ихтималы. Мәсәлән, дәрескә керү һәм дәрестән чыгуны белдереп яңгыраган кыңгырау, исәнләшкәндә һәм саубуллашканда кул бирешүләр – гамәли яктан эквивалент, ләкин мәгълүмати яктан – контраст.

Тамганың эчке (идеаль) һәм тышкы (гамәли) сыйфатларының кушылмасы аны икеяклы матди-идеаль нигез буларак кабул иттерә. Тамганың тышкы һәм эчке якларын күрсәтү өчен төрле парлы терминнар кулланыла: “мәгънә белдерү планы” һәм “эчтәлек планы”, “билгеләүче” һәм “билгеләнүче”, “форма” һәм “мәгънә” һ.б.

Ф. де Соссюр буенча, тел тамгасы өчен характерлы сыйфат – билгеләүче һәм билгеләнүче арасындагы мотивацияләнгән багланышның булмавы, чөнки төрле телләрдә бер үк предмет яки күренеш төрле сүзләр ярдәмендә билгеләнә. Моның белән беррәттән, ул тамганың абсолют булмаган иреклелеген ассызыклый. Э.Бенвенистның, мәсәлән, соңгы идеягә карата фикере мондыйрак була: “Иреклелек бары тик гамәли дөньяның күренешенә яки объектына карата гына кулланыла, һәм тамга төзелешенең эчке структурасындагы фактор ролен уйнамый”. Ягъни, телнең эчке төзелешенә карата тамга формасы һәм

эчтәлеге арасындагы бәйләнеш ирекле түгел, бәлки зарури, ягъни табигый телләрдәге күпчелек сүзләр мотивацияләнгән характерда була. Мәсәлән, рус телендә сүз барлыкка китерү юлы белән генә дә 90% сүз мотивацияләнгән санала, һәм бары тик аз сандагы борынгы лексемаларының гына билгеләүче һәм билгеләнүче арасындагы мотивацияләнгән бәйләнешын ачыкларга мөмкин түгел. Сүз билгесенең нигезендә яткан мотивацияләнгән сыйфат эчке форма дип атала. Телдән тыш тамгаларга кайтып калганда исә, биредә күпчелек очракта форма һәм эчтәлек арасындагы мотивацияләнгән бәйләнеш юк (Морзе әлифбасы, флаг сигнализациясе, математик символлар). Шулай итеп, бер төр тамгалар һәм тамга системалары тулысынча яки өлешчә мотивацияләнгән санала, ә башкалары исә – мәгънә белдерү планы һәм эчтәлек планы арасында мотивацияләнмәгән, шартлы бәйләнешкә ия.

Тамга мотивациясенең булуы яки булмавы һәм аларның характеры Ч.Пирс тарафыннан семиотик берәмлекләр классификациясен барлыкка китерүдә нигез итеп алына. Тамганың тышкы ягы һәм билгеләнүче чынбарлык арасындагы характерны һәм охшашлык дәрәҗәсен күздә тотып, ул семиотик берәмлекләрнең дүрт төрен аерып күрсәтә. Тамгаларның беренче төре формасы тәңгәл килгән предметлар белән тышкы охшашлыкларга ия, бу – копия-тамгалар. Алар табигый (бармак эзләре, кардагы аяк эзләре һ.б.) һәм ясалма (фотосурәт, рәсем, һ.б.) төрләргә бүленә. Ясалма копия-тамгаларга исә язуларның кайбер төрләре – пиктографик һәм аз дәрәҗәдә иероглифик язулар якын. Тамгаларның икенче төре – сыйфат-тамгалар, яки симптомнар – бу очракта тәңгәл килгән күренешләр арасында табигый, сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләре урын ала. Мәсәлән, кара болыт – яңгыр сыйфаты, төтен – ут сыйфаты, кешенең югары температурасы – авыру сыйфаты һ.б. Тамгаларның өченче төрендә билгеләнә торган предметлар яки күренешләр белән структур охшашлык мәйданга чыга – бу символ-тамгалар, алар билгеләнүче объект яки күренешнең аерым бер элементы нигезендә аның тулы образын чагылдыра. Мәсәлән, герблар, значоклар, эмблемалар, башка күренешләрне символлаган предмет сурәтләре (маска – театр символы, бублик –

кондитерлар символы, кайчы – парикмахерлар символы). Ч.Пирс буенча, тамгалар һәм билгеләнүче предметлар яки күренешләр арасында тышкы, структур, яки табигый охшашлыклар юк. Әлеге төр тамгаларга күпчелек тел тамгалары, юл-йөрү билгеләренең бер өлеше, математик тамгалар һ.б. керә.

Тамгаларның тышкы форма структурасы, тамга системаларын төгәл иерархик төзелеш буларак кабул итәргә ярдәм итә һәм биредә аз дигәндә үзара бәйле өч ярус аерыла: субтамгалар ярусы, тамгалар ярусы һәм супертамга ярусы. Субтамгалар түбәнге ярусны тәшкил итәләр һәм, төп элементлар ролен үтәп, алдагы ярусның берәмлекләренә – тамгалар ярусына керәләр. Тамгалар ярусы, үз чиратында, югары ярус берәмлекләренә – супертамгаларга керә. Семиотик системаларда субтамгалар саны күп түгел. Гадәттә алар икедән алып (Морзе әлифбасындагы нокта һәм сызык) берничә дистәгә кадәр (һәртөрле табигый телнең хәрефләре яки авазлары) булырга мөмкин. Субтамгалар, үзара мөнәсәбәткә кереп, алдагы ярусның күпсанлы семиотик берәмлекләрен (мәсәлән, табигый телләрдәге дистәләгән һәм йөзләгән сүзләрне) төзиләр. Катлаулы хәбәрләрне җиткерү өчен, тамгалар үзара комбинацияләнеп, югары ярус – супертамга берәмлекләрен барлыкка китерә. Аларның саны чиксез (мәсәлән, табигый телләрдәге җөмләләр). Берәмлекләрнең тамга системасының һәрбер ярусындагы комбинацияләнүе берьюлы синтагматик (горизонталь) һәм парадигматик (вертикаль) дәрәҗәләрдә тормышка ашырыла. Берәмлекләрнең синтагматик комбинацияләнүе – тамгаларның турысызыклы рәттә тәңгәлләшүе, ә парадигматик комбинацияләнүе – билгеләүче һәм билгеләнүчеләрнең төрле оппозиция, группировка, парадигмалары ярдәмендә белдерелүе. Үзара бәйле һәм аерым бер тәртипкә салынган элементлар берлеген барлыкка китерә торган тамгаларның бертөрле төркеме тамга системасын барлыкка китерә.

*Тамга системасы турында төшенчә.* Тамга системалары табигый һәм ясалма була. Табигый булган очракта элементлар һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләр кеше ихтыярыннан башка барлыкка килә һәм камилләшә, ә ясалма булса, элементлар һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләр кеше тарафыннан барлыкка

китерелә (мәсәлән, юл йөрү билгеләре, хәрби аермалык билгеләре һ.б.).

Шулай ук, детерминацияләнгән һәм ихтимал семиотик системаларны аералар. Детерминацияләнгән системаларда элементлар билгеле бер ысул белән бирелә һәм бертөрле мөнәсәбәттә була. Мәсәлән, өч төсле светофорда кызыл, сары һәм яшел төсләрнең кабыну тәртибе бер һәм үзгәрми. Ихтимал семиотик системалар өчен исә элементларның тәртибе аерым бер кагыйдәгә буйсынмый, ә ихтималлы характерда була: теге яки бу халәтендә бер элемент башка бер элементның мәйданга чыгачагын фаразларга мөмкин, ә бу очракта ихтималлык дәрәҗәсе исә 0 дән алып 100%-ка кадәр тирбәлә ала. Ихтималлы системага табигый тел керә, бу, мәсәлән, сүздәге хәрефләрне, яки җөмләдәге сүзләрне белеп алу белән дәлилләнә.

Шулай ук беркырлы һәм күпкырлы семиотик системаларны да аерып йөртәләр. Күпкырлы системалар үзара күптөрле мөнәсәбәтләр белән бәйләнгән бертөрле дип табылмаган элементлардан тора, ә беркырлылар исә үзара билгеле бер төр мөнәсәбәттә генә булган бертөрле элементлардан гыйбарәт. Беркырлы системалар, система тәшкил итүче буларак, күпкырлы системалар эченә керә һәм аларның бер өлеше буларак кабул ителә. Табигый телләр төрле элементлардан тора – фонема, морфема, сүз, җөмлә һ.б., алар арасындагы мөнәсәбәтләр катлаулы һәм күпкырлы, ягъни алар күпкырлы системалар буларак эш итәләр. Табигый телнең күпкырлы системасы кайбер беркырлы системаларны – фонетик системаны, фонемалар системасын һ.б. үз эченә ала.

Семиотик системаларны, шулай ук, динамик, хәрәкәтчән һәм статик, хәрәкәтсез төрләргә бүләләр. Динамик системаларның элементлары хәрәкәттә, камилләшүдә булып, бер-берсенә карата мөнәсәбәтләрен үзгәртеп торалар, ә статик системалардагы элементлар исә хәрәкәтсез, тотрыклы. Мәсәлән, юл йөрү билгеләре, урамдагы язулар, географик картадагы тамгалар – статик системалар. Табигый телләр динамик тамга системасына карый, ләкин аларда статик система сыйфатлары да юк түгел.

Бүгенге көн тел белемендә тел үзенчәлекле семиотик сыйфатларга ия булган тел системасы буларак өйрәнелә.

Беренчедән, башка тамгалар белән чагыштырганда, тел беренчел. Башка тамгалар системасы табигый тел нигезендә формалаша. Барлык ясалма тамга системалары, табигый тел белән чагыштырганда, икенчел, уйлап табылган. Моның белән беррәттән, башка тамгаларга карата телнең беренчеллеге генетик план белән бәйле.

Икенчедән, башка тамга системалары чикләнгән мәгълүмат тапшыру өчен барлыкка китерелгән, алар кеше тормышының конкрет бер өлкәсе өчен генә кирәкле. Тел исә мәгълүмат саклау һәм тапшыруда универсаль чара, ул кешегә, яки аерым бер җәмгыятькә тормышның барлык өлкәләрендә дә кирәк.

Телнең башка тамга системаларыннан тагын бер аермасы – телнең фикер барлыкка китерү һәм тапшыру чарасы булуы. Ул, шулай ук, кешенең хис-тойгыларын, ихтыярын белдерә, ә башка системалардагы тамгалар исә, музыкаль тамгалар һәм жестлардан калганнары, эмоциональ яктан нейтраль.

Телнең башка системалардан аермалы тагын бер сыйфаты – аның һәрвакыт камилләшүе, бу исә аңа иң көчле фикерләү чарасы исемен бирә. Тел, күп очракта, үзеннән-үзе үсә, аның сәбәпләре, хәтта, сизелмәскә дә мөмкин.

Ясалма тамга системалары үзләреннән үзләре камилләшә алмый. Телдән аермалы буларак, алар статик. Алардагы үзгәрешләр яңа шартлар нигезендә теге яки бу тамга системасын камилләштерергә кирәк булган очракта кеше ихтыярына бәйле барлыкка килә.

Тел башка тамга системаларыннан берәмлекләр саны, алар арасындагы тагын да төрлерәк һәм катлаулырак мөнәсәбәтләр буенча да аерылып тора. Телдә, традиция буенча, өч төрле тамгаларны аерып йөртәләр: субтамгалар (үзләрендә тулы мәгълүмат йөртмиләр, ә чикләү функцияләрен үтиләр: авазлар, хәрефләр, тыныш билгеләре), мәгълүмати функция үтәгән тамгалар (сүзләр) һәм супертамгалар – катлаулы күренешләрне тасвирлау, фикерләрне җиткерер өчен кулланыла торган тамгалар комбинациясе (җөмләләр). Моннан башка, телдә телнең урта дәрәҗәсендәге тамгалар – иҗекләр, морфемалар, сүзтезмәләр бар. Иҗекләр субтамгаларга, ә морфемалар һәм сүзтезмәләр – тел тамгаларына карый, чөнки алар мәгънәгә ия.

Тел тамгаларын башка төрле дә төркемлиләр, мәсәлән, фонеманы – сигналь тамга, морфеманы – ярым тамга, сүзне – өлешчә тамга, ә менә җөмләне тулы тамга буларак кабул итәләр. Телнең төп тамгасы – сүз, аның эчтәлеге кумулятив характерда, ягъни тарихта тупланган мәгълүмат нигезендә барлыкка килә.

Шулай итеп, телнең тамга теориясе игътибарын беренче чиратта телнең эчке төзелешен өйрәнүгә, телнең универсаль структур сыйфатларын һәм элементларын, аларның системалы мөнәсәбәтләрен билгеләүгә юнәлтә. Тел тамгалары, аның структур элементлары буларак, аң системасы белән берләшкән, аң системасы аша исә кешеләрнең иҗтимагый тормыш системасы белән мөнәсәбәттә тора. Ләкин телнең тамга концепциясендә "бердәнбер һәм иң дөрес лингвистика объекты – үз-үзендә һәм үзе өчен өйрәнелә торган тел" (Ф. де Соссюр), бу идея исә аны структурализм белән якынайта.

**Казан лингвистика мәктәбе**

Казан лингвистика мәктәбе турында бөтен дөньяның лингвистик җәмәгатьчелеге яхшы белә. XIX гасырның 70-80 нче елларында Казанда эшләгән И.А. Бодуэн де Куртенэ һәм аның шәкертләре – Н.В.Крушевский, В.А. Богородицкий, А.А. Анастасиева һ.б. үз хезмәтләрендә әлеге мәктәпнең асылы хакында язалар.

Лингвистик фән тарихында аңа кадәр 30-40 ел элек үк Казан университетында ***Казан төрки лингвистик мәктәбе*** оешканлыгы игътибардан читтә кала. Бу мәктәпнең кайбер идеяләре, мәсәлән, өйрәнелә торган барлык телләргә карата бертөрле тигез карашта булу, телләрне синхроник һәм диахроник өйрәнүнең чикләрен билгеләү, лингвистиканың башка гуманитар юнәлешләр белән тыгыз бәйләнештә торуы кебек фикерләре И.А. Бодуэн де Куртенэ җитәкләгән Казан лингвистика мәктәбе тарафыннан кабул ителә.

Казан төрки лингвистик мәктәбе XIX гасырның беренче яртысында, 1804 елда ачылган Казан университетында оеша. Аның формалашу һәм үсеш тарихын берничә чорга бүләләр.

*Беренче чор* – XIX гасырның беренче яртысы (Казан университетының көнчыгыш бүлеге 1855 нче елда Санкт-Петербург университетына күчкәнчегә кадәрге чор).

*Икенче чор* – татар лингвистларының Казан төрки лингвистик мәктәбенең төп традицияләрен дәвам итү чоры. Ул XIX гасырның 60 нчы елларында башланып, 1917 нче елда төгәлләнә. Казан тюркологларының традицияләрен татар мәдрәсәләренең укучылары-тәрбияләнүчеләре дәвам иткәнлектән, университет тюркологларының күп кенә концепцияләрендә гарәп-фарсы грамматик тәгълиматларының йогынтысы сизелә.

*Өченче чор* – 1917 елдан башланып, XX гасырның 50 нче елларына кадәр дәвам итә. Бу совет җәмгыятендә һәм бөтен лингвистик фән үсешендә иң катлаулы һәм каршылыклы чор. Әлеге чорның беренче елларында милли азчылыкның ирекле үсешенә шартлар булдырыла. Октябрь революциясе большевикларның вәгъдәләренә ышанган милли азчылыкның катнашуы нәтиҗәсендә генә җиңү яулый. Милли азчылыкның ирекле үсешеннән татар лингвистлары да файдалана. Совет хакимиятенең беренче елларында татар лингвистикасы зур уңышларга ирешә.

Әмма 20 нче еллардан соң җәмгыятьтә Сталинның шәхес культы башлана. Татарлар арасында инде 30 нчы еллар башында ук репрессияләр була, татар лингвистлары да бу шаукымга эләгә. Сталинның шәхес культы чорында гомуми тел белеме өлкәсендә Н.Я. Маррның “Новое учение” (“Яңа тәгълимат”) хезмәте өстенлек ала. Ул татар тел белеменә Г.Алпаровның мәкаләләре аша гына керә. Н.Я. Маррның шәхес культы 1950 нче елда лингвистик дискуссиядә фаш ителә. Әлеге дискуссия илнең алдынгы тел белгечләре тарафыннан оештырыла, алар Сталинга совет тел белемен сәламәтләндерү буенча шактый җитди сораулар бирәләр.

Казан төрки лингвистик мәктәбе үсешенең *дүртенче чоры* XX гасырның 50-60 нчы елларыннан башлап, бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Ул галимнәрнең лингвистик фикерләвендә берникадәр иркенлек башлану белән характерлана. Әмма 80 нче

елларга кадәр әлеге ирек шартлы була, чөнки күп милләтләрдән бердәм совет халкы төзү бурычы куела.

80 нче еллар ахырында бердәм совет халкы булдыру сәясәте милли азчылыкны яңарту, саклау һәм үстерү сәясәтенә алышына. Шуңа күрә гуманитар фән галимнәре, бигрәк тә әле үзгәртеп коруга хәтле формалашып өлгергән тел белгечләре үзләренең тикшеренү эшләрен башлап җибәрәләр. Яңарышның котылгысыз булуын, төбәк һәм милли азчылык телләренең үсешен һәм саклануын истә тоталар.

***Казан төрки лингвистика мәктәбенең формалашуы һәм үсеше***

Төрки кабиләләрнең теле һәм көнкүреше белән беренчеләрдән булып (якынча X гасырдан башлап) гарәпләр кызыксына башлый. Бу практик ихтыяҗлар белән аңлатыла, тулырак әйткәндә, гарәпләргә икътисади, сәяси һәм мәдәни бәйләнешләрдә торган халыклар телен һәм гадәтләрен белү мөһим булган.

Күренекле тюрколог Г.М. Мелиоранский билгеләп үткәнчә, төрки телләр белән кызыксыну “чагыштырмача борынгы заманнан ук (мәсәлән, һиҗри буенча IV гасырдан) килә”, “төрки халыклар гарәп-мөселман мәдәниятен кулланып кына калмый, ә аның үсешенә дә ярдәм итә”. Моннан тыш, Нәҗип Әмир сүзләренчә, XIV гасырда Алтын Урда кыпчаклары Мисырда дәүләт белән идарә итүдә катнашканнар. Шунысы да игътибарга лаек: гарәпләрнең безгә килеп җиткән төрки кабиләләр турындагы хезмәтләре барысын да гарәпләр язмаган. Аларның кайбер өлешләре гарәп телендә, гарәп мәдәнияте нигезендә төрки кабиләләрдән чыккан вәкилләр тарафыннан төзелгән.

Төрки телләр турындагы безнең көннәргә килеп җиткән беренче хезмәтне – “Диване лөгатъ-эт-төрк” әсәрен (Хрестоматия, яки Төрки телләр җыентыгы) Мәхмүт Кашгарый 1074 елда яза. Җыентык зур сүзлекне хәтерләтә. Шуңа да карамастан, ул фонетика, морфология, төрки шәвәләр диалектологиясе, шулай ук төрки кабиләләрнең этнографиясе турында үз вакыты өчен бик тулы мәгълүмат бирә. Мәхмүт Кашгарый хезмәтен ул вакыттагы төрки кабиләләрнең телен һәм

көнкүрешен өйрәнү энциклопедиясе дип карау кабул ителгән. Кереш өлештә авторның тагын "Синтаксис энҗеләре" дигән китап язуы турында әйтелә. Кызганычка каршы, әлеге китап бүгенгәчә табылмаган.

XIV гасыр башында М.Кашгарый эшен Ибне Мөһанна дәвам итә. Ул "Фарсы, төрки, монгол телләренә тәрҗемә китабы" дигән филологик хезмәте белән билгеле. Монда автор төрки телгә хас фонетик, морфологик, кайбер синтаксик күренешләрне аңлата һәм күп кулланылышлы сүзләр кертә. Бу китапның теле турында тикшерүчеләр тарафыннан әйтелгән уртак фикер юк. П.М. Мелиоранский "Китап-тәрҗемә"нең төрки өлеше теле борынгы әзербайҗан теленә якын ди, ә С.Е. Малов бу өлешнең телен Төркестанда яшәүчеләр теле – уйгыр теле дип аңлата.

Моннан тыш, XIII-XIV гасырлар арасында төрки телләр буенча Мисырда, Персиядә, Алтын Урдада һ.б. җирләрдә башка хезмәтләр дә дөнья күрә. П.М. Мелиоранский фикеренчә, гарәп телендәге андый хезмәтләр дистәгә якын. Алар арасыннан XIV гасырда Әбү Хәян хезмәтләрен аерып күрсәтергә кирәк.

Латин, француз һәм башка телләрдә дә тюркология турындагы хезмәтләр шактый элек үк барлыкка килгән. Шунысын да әйтеп узарга кирәк, Көнчыгышта Алтын Урда татарларының, Синьцзян төркиләренең, ил тарихында зур урын тоткан һ.б. телләрнең тарихы һәм этнографиясе белән кызыксынганнар. Шулай да, рус вәкилләренең хезмәтләрен исәпкә алмаганда, якын чит ил һәм Россия территорияләрендә яшәүче төрки халыкларның тарихы, тормыш-көнкүреше, теле һ.б. фән ягыннан тикшерелмәгән диярлек.

Руслар төрки телләр белән XVII-XVIII гасырларда кызыксына башлый. Бу әлеге чорда патша хакимиятенең көнчыгыш илләренә, бигрәк тә Урта Азиягә аяк басуы белән аңлатыла. Монда сәүдә, дипломатик һәм башка мөнәсәбәтләр өчен мөселман вәкилләре кирәк була. Күп очракта андый вәкилләр руслар белән тыгызрак мөнәсәбәттә торган казан татарлары була. Алар инде XVII-XVIII гасырларда Россиягә Алгы Азия һәм Көнчыгыш Азия дәүләтләрнең үзара мөнәсәбәтләрендә зур ярдәмгә киләләр. Татар теле күпмедер вакыт эчендә Россия һәм Персиядә дипломатик мөнәсәбәтләр

теле була. Барлык төрки телләр арасыннан татар теленә аерым игътибар бирелә. Шулай итеп, төрки халыклар телен һәм көнкүрешен өйрәнү практик таләпләргә барып тоташа.

Төрки телләр буенча беренче лингвистик материалларны җыю Петр I чорына карый. Бу эшне Петр I эшчәнлеге белән бергә чит ил вәкилләре тормышка ашыра.

Бу чор галимнәренең безнең көннәргә кадәр кульязма һәм басма хәлдә килеп җиткән хезмәтләре тематик сүзлекләрне хәтерләтә. Төрки телләргә караган әлеге филологик хезмәтләр Екатерина II инициативасы белән языла башлый. Ул җир шарындагы бөтен телләрнең чагыштырма сүзлеген булдырырга тели. Шул уңайдан Сәгыйть Хәлфиннең якынча 23000 сүзне үз эченә алган русча-татарча сүзлеге төзелә.

XVIII гасырның икенче яртысында төрки телләрнең рус телендә язылган беренче грамматикалары дөнья күрә. Төрки телләр рус гимназияләрендә һәм университетларында мөстәкыйль предмет буларак укытыла башлагач, Россиядә грамматикалар һәм сүзлекләр төзү, әлеге телләрне фәнни яктан өйрәнү эше киң тарала. Башта Казан Рухани училищесында, аннан 1769 нчы елда Беренче Казан гимназиясендә төрки-татар теле укытыла башлый. 1783 нче елда татар телен өйрәнү Тобол семинариясенә һәм халык училищесына кертелә.

1783 нче елда Түбән Новгород Рухани семинариясендә татар, мордва, чуваш телләре укытыла башлый. Татар телен өйрәнү Омскидагы Азиат мәктәбенең укыту программасына да кертелә. Алга таба әлеге гимназияләрдә төрки телләр буенча гамәли кулланмалар дөнья күрә. Мәсәлән, 1778 нче елда Мәскәүдә Казан гимназиясенең татар теле укытучысы Сәгыйть Хәлфиннең "Татар теле әлифбасы (...)" дигән хезмәте басылып чыга. 1801 нче елда Иосиф Гигановның татар теле грамматикасы дөнья күрә. Әлеге хезмәтендә галим, рус теле грамматикаларына нигезләнеп, татар теленең грамматик төзелешен тасвирлап бирә. Ә 1804 нче елда Санкт-Петербургта Иосиф Гигановның русча-татарча сүзлеге басылып чыга. 1902 нче елда Ниятбакый Атнометов та үзенең әлифбасын бастырып чыгара. 1809 нчы елда Ибраһим Хәлфин "Татар теленең әлифбасы һәм грамматикасы (...)" хезмәтен яза.

XVIII гасыр ахырында Казанда Рухани академиясе ачыла. Анда беренче көннән алып татар теле укытыла башлый. Татар теле укытучысы А.Троянский 1814 нче елда “Татар теленең кыскача грамматикасы (...)” дигән хезмәтен яза. 1824 нче елда китап икенче тапкыр басылып чыга.

Алда санап үтелгән хезмәтләр барысы да Казан университеты ачылганчыга кадәр язылган. Алга таба алар Казан университеты тюркологлары тарафыннан актив файдаланыла.

Казан төрки лингвистик мәктәбе вәкилләре бер үк вакытта тел белгечләре дә, тарихчылар да, фольклорчылар да булган. Шуңа күрә аларның эшләрен характерлаганда тел белеме чикләреннән чыгарга туры килә.

1804 елның ноябрендә Казан университеты ачыла. Шул ук елның 5 ноябрендә кул куелган беренче устав буенча тел гыйлеме бүлегендә мөстәкыйль көнчыгыш телләр кафедрасы оеша. Шушы устав нигезендә бер татар теле лекторы штаты, ике француз һәм немец теле лекторы билгеләнә.

Татар теленең 1769 елдан гимназиядә укытылуын һәм университетның аннан 1811 елның көзенә кадәр аерылмавын истә тотып, университетта татар теленең беренче көнчыгыш теле булуын кыю рәвештә раслап була. 1807 елда гарәп һәм фарсы телләрен укыта башлыйлар.

1828 елның ахыры – 1829 елның башында университет ректоры Н.И. Лобачевский тәкъдиме белән көнчыгыш бүлек булдырыла. Монда тагын төрек, монгол, маньчжур, кытай, әрмән, сүрия, еврей телләре укытыла. Көнчыгыш телләр кафедрасы гарәп-фарсы һәм төрек-татар кафедраларына бүленә. Моннан соң Н.И. Лобачевскийның турыдан-туры ярдәме белән башка көнчыгыш телләр кафедралары ачыла.

1837 елның 11 маенда кытай теле кафедрасы ачыла. Монда бер үк вакытта маньчжур теле дә укытыла. Университетның тибет теле кафедрасын оештыру өчен аерым белгеч әзерләнә, ләкин кайбер сәбәпләр буенча ул ачылмый кала. 1841 елдан санскрит теле кертелә һәм ул 1856 елга кадәр (рус теле кафедрасы составында) дәвам ителә. 1842 елда әрмән теле кафедрасына нигез салына, тик 1851 елда ул ябыла.

Шулай итеп, XIX гасырның беренче яртысында Казан университетында уннан артык көнчыгыш теле укытыла, шунлыктан бу халыкларны, аларның телләрен, яшәешен, йолаларын һ.б. өйрәнү буенча фәнни эшләр алып барыла. Бу вакытта көнчыгыш телләрне мондый колач белән өйрәнү Россиянең Мәскәү, Петербург, Харьков университетларында да булмаган. Аларда көнчыгыш тел белеме XIX гасырның икенче яртысында гына киң масштабларда үсә башлый. Шуңа күрә, XIX гасырның беренче яртысында Казан университетын гомумән көнчыгыш тел белеме, аерым алганда рус тюркологиясе үзәге дип әйтеп була.

1855 елда көнчыгыш бүлек тулаем Петербург университетына тапшырыла. Моннан соң Казан университетында гарәп һәм татар телләре генә укытыла.

Университетта беренче татар теле укытучысы *Ибраһим Хәлфин* була. Ул гимназия штатында торып, университет хезмәткәре санала. Бу ике уку йорты арасында тыгыз бәйләнеш була. 1811 елның көзендә, университет аерылып чыкканнан соң, И.Хәлфин рәсми рәвештә университет штатына күчерелә, бер үк вакытта гимназиядә дә үзенең эшен дәвам итә. 1846 елның 19 мартында ул гарәп һәм фарсы телләре кафедрасына күчерелә, ә төрек-татар телләре кафедрасы шул көнне Казем-Бек шәкерте *И.Н. Березин*га тапшырыла. Ул бу кафедра белән көнчыгыш разрядын Петербург университетына күчергәнче (сентябрь,1855 ел) җитәкчелек итә.

Төрки татар теле кафедрасында *Абусаттар Казем-Бек* та эшли. Ул 1839 елдан алып 1855 елга кадәр 1-2 нче курсларда төрки-татар теле буенча гамәли курсларны укыта, ягъни студентларга уку һәм язу кагыйдәләрен, төрки телнең грамматикасын аңлата һәм алар белән әдәби, тарихи, язма истәлекләрне тәрҗемә итә. 1840-1848 елларда Казан гимназиясендә дә шундый ук дәресләр алып бара.

Бу кафедрада 1843 елның 25 феврālеннән 1855 елның мартына кадәр *Мөхәммәтгали Мәхмүдов* студентларга көнчыгыш каллиграфиясе буенча дәресләр бирә, ул шул елның мартыннан беренче Казан гимназиясенең төрки-татар телләре классы буенча өлкән укытучы булып билгеләнә.

Көнчыгыш телләре факультеты Петербург университетына күчкәч, Казан университетында төрки-татар телен укытмаганнар булса кирәк. Бары тик 1861 елда яңадан ачылган төрки-татар кафедрасында университетта үзенең миссионерлык максатларында керәшен сөйләм телен керткән Н.И. Ильминский төрки тел белеме буенча лекцияләр укый башлый.

Үз вакытында Ибраһим Хәлфин татар әдәби телен укытканда материалларны рус һәм татар сөйләм телен кулланып аңлаткан. И.Хәлфиннан соң Казан университетында XIX гасырның беренче яртысында татар телен укытмаганнар диярлек, әмма кафедра төрек-татар исемен йөрткән. Күпчелек очракта төрек әдәби теле буенча дәресләр биргәннәр. Тюркология белән төрек, гарәп-фарсы телләре укытучылары шөгыльләнгән. XIX гасырның унынчы елларында, уртак эшчәнлек нәтиҗәсендә, рус тюркологиясе өлкәсендә тикшеренү эшләре сизелерлек арта.

30-40 нчы елларда университетта *Казан тюркология мәктәбе* оеша. Әлеге мәктәпкә университет һәм Беренче Казан гимназиясе вәкилләре, Оренбург Неплюев хәрби училищесының һәм башка уку йортларының кайбер укытучылары кергән. Бу мәктәпкә үзләренең төрки телләр буенча күп кенә фәнни эшләре белән төрле уку йортларының укытучылары да кушылган.

Казан тюркология мәктәбе вәкилләренең тел белеменә караган хезмәтләрендә шул заманның рус тикшерүчеләре эшләрендә чагылган теоретик нигезләмәләр тәэсире сизелә. Әлеге мәктәпне характерлаганда кайбер билгеләрне ассызыклап үтәргә кирәк.

Бу мәктәп вәкилләренең күпчелеге, тел укытучылары буларак, тел гыйлеме белән генә түгел, тарих, этнография, халык авыз иҗаты белән шөгыльләнә. Алар фикеренчә, телне өйрәнү халыкның рухи тормышын гына түгел, бәлки тарихны да өйрәнергә ярдәм итә.

Казан тюркология мәктәбенең танылган вәкилләре беренче планга телләрне чагыштырып өйрәнү методын куялар, шуның белән бу методның башкаларыннан өстенлеген исбатлыйлар.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: бу мәктәп вәкилләре раса-ара дискриминациягә каршы булалар, фән өчен бөтен телләр дә бертигез дип саныйлар. Шуңа күрә алар төрки халыкларның

әдәби теленә генә түгел, ул вакытта язулары да булмаган халыкларның сөйләм теле формаларына да зур игътибар бирәләр. Алар теләсә нинди җанлы сөйләм телендә теләсә нинди әсәр, хәтта фәнни хезмәт тә язып була дип раслыйлар. Бу бигрәк тә Мөхәммәтгали Мәхмүдов хезмәтләре белән исбатлана.

Бу мәктәпнең төп казанышы шул була: монда беренчеләрдән булып телләре фәнни тикшеренүләрнең объекты итеп алынган халыкларның вәкилләрен филология буенча фәнни эшләргә тарту идеясе карала. Бу идея бигрәк тә И.Н. Березин тарафыннан формалаштырылып, соңыннан тормышка ашырыла. Бу университеттан Ибраһим Хәлфин, Доржи Банзаров, Мөхәммәтгали Мәхмүдов, Каюм Насыйри, Салихҗан Кукляшев, Әбдүш Ваһапов кебек галимнәр үсеп чыга.

Казан тюркология мәктәбенең бөтен вәкилләре, нинди профессия кешеләре булуга карамастан, көнчыгыш халыклары телен, фольклорын, әдәбиятын пропагандалыйлар. Әмма аларның төп казанышы – җирле халыкны рус мәдәнияте белән таныштыруга омтылу. Бу мәктәптән татарларның беренче мәгърифәтчеләре – И.Хәлфин, М.Мәхмүдов белем алып чыга. Татар халкының бөек мәгърифәтчесе К.Насыйри да бу мәктәп традицияләрендә тәрбияләнә.

Көнчыгыш бүлекне Петербург университетына күчерү сәбәпле, Казан тюркология мәктәбенең төп фәнни көчләре Петербургка чакырыла. Әмма Казан университеты бу мәктәпнең традицияләрен саклый, алай гына түгел, аның яхшы традицияләре җирле халык, бигрәк тә татарлар тарафыннан дәвам иттерелә.

Көнчыгыш телләр кафедрасын беренче булып *Христиан Мартин Френ* җитәкли (ул Казанга Германиядән 1807 елның 3 августында килә, 1817 елның 3 августында Казаннан Петербургка китә). Ул – Казан университетында беренче ориенталист, Санкт-Петербург Фәннәр академиясе әгъзасы. Гарәп теле белгече булуына карамастан, тарихны, җирле халыкның телен өйрәнүгә зур көч куя. Х.М. Френ, Казан университетына килгәнче үк, Казан татарларын һәм башка Азия халыкларын күрү теләге белән яна. Ул беренче булып бу якның борынгы истәлекләрен өйрәнә башлый. Х.М. Френ борынгы

материалларны өйрәнү һәм нумизматика фәне нигезендә Алтын Урда һәм борынгы болгар ханлыгының тарихын яза. Ул Казанда көнчыгыш телләрнең үзәк училищесын ачу турында хыяллана, әмма аның бу теләге тормышка ашмый.

Х.М. Френ Беренче Казан гимназиясенең татар теле укытучысы Ибраһим Хәлфин белән тыгыз элемтәдә тора. Мәчетләргә, мәктәпләргә барып, И.Хәлфин аркылы ул шул чор татар галимнәре белән таныша. Шул рәвешчә, Х.М. Френ көнчыгыш телләрен укытуда куллану максаты белән төрле китаплар, кулъязмалар, тәңкәләр җыя. Бу материаллар И.Хәлфин ярдәме белән эшкәртелә.

Х.М. Френ һәм И.Хәлфин Хива ханы Габделгази Баһадурның (1605-1663) төркиләрнең нәсел агачы турындагы кулъязмасын басмага әзерлиләр. Бу хезмәт 1825 елда университет типографиясендә джагай телендә басыла. Моннан тыш, И.Хәлфин белән Х.М. Френ 1810 елда татар сыйныфларында укыту өчен ярдәмлекләр төзиләр, әмма аларга бастырырга ярдәм итүче булмый. Һичшиксез, бу эшчәнлектә төп рольне Х.М. Френ үти, ә төп практик эшне И.Хәлфин башкара.

И.Хәлфин 1809 елда “Казан гимназиясендә гарәп кагыйдәләре белән укытыла торган татар теленең әлифбасы һәм грамматикасы”н бастыра. Ул Казан университетының рус типографиясендә басылган беренче басма хезмәт булып санала. И.Хәлфин әлеге хезмәтне язганда шул заманның рус грамматикаларыннан файдалана. Бигрәк тә гимназиядә рус телен укыту буенча төп китап булып саналган М.Ломоносовның Россия грамматикасына таяна. Рус теле грамматикасын белми торып, И.Хәлфин бу хезмәтне яза алмаган булыр иде. Алай гына да түгел, ул татар телен белмәгән, әмма рус теле грамматикасын аңлаганнарга бу телне укыта алмас иде. Бу хезмәтне татар һәм рус телләрен чагыштырып өйрәнгән беренче әлифба һәм грамматика дип саныйлар. И.Хәлфин рус теленнән татарчага, татарчадан русчага тәрҗемә белән дә шөгыльләнә. Ул татарлар арасында беренче гыйльми дәрәҗәгә ия була.

Профессор *Эрдман Франц* (1793-1863) университетта гарәп, фарсы телләрен укыта, көнчыгыш халыкларының, аеруча татарларның тарихын өйрәнүгә, төрки халыкларының

филологиясен һәм тарихын күрсәткән чыганакларны ачыклауга зур игътибар бирә. Казан университетында эшләгән дәвердә (1818-1845) гарәп, фарсы, төркиләрнең тарихы һәм филологиясе турында 30 дан артык фәнни хезмәт яза. 1830 ел башында Эрдман татар теленең тулы сүзлеген төзү турында программа эшли. 1829 елның 20 сентябрендә университетның филологик фәннәр бүлеге утырышында декан Э.Франц татар теленең тулы грамматикасын һәм сүзлеген төзү турында язма юллама тәкъдим итә. Утырышның махсус карары буенча, 7 октябрьдә профессор Эрдманның фикерләре университет советына җиткерелә. Совет бу фикерне хуплап кабул итә. Эрдманның программасына Шмидт белән Х.М. Френ үз программаларын каршы куялар. Алар сүзлеккә барлык төрки телләрне, шул исәптән госманлы (төрек) телен дә кертергә тәкъдим итәләр. Профессор Эрдман үз фикерендә кала: әлегә Казан, Әстерхан, Оренбург һәм Тубыл өлкәләрендә яшәүче татарлар теленең генә сүзлеген төзеп була, дип раслый.

Сүзлек турында бәхәс барган арада, материалны туплау вазифасы йөкләнергә тиешле студент Де-Мезон, университетны тәмамлап, Оренбург өлкәсенә китә. Шулай итеп, төрки лингвистика үсешенә ярдәм итәрдәй татар теленең тулы сүзлеге төзелмичә кала. Ләкин совет карары шуны дәлилли: Казан университеты, чыннан да, тюркологиянең үзәге булган.

Казан тюркология мәктәбенең башында *Александр Касимович Казем-Бек* (1802-1870) тора, ул тюркология тарихында беренчеләрдән булып берничә төрки телнең чагыштырма грамматикасын төзегән кеше. Аның бу эше университет типографиясендә 1839 елда “Төрки-татар телләренең грамматикасы” дигән исем астында басылып чыга, икенче басмасы 1846 елда “Төрки-татар теленең гомуми грамматикасы” дигән исем белән дөнья күрә. Бу фәнни эш үз вакытында немец теленә дә тәрҗемә ителгән булу сәбәпле, А.К. Казем-Бекны Британия һәм Ирландия корольлекләренең Лондондагы җәмгыятенә вәкил итеп тә билгелиләр.

Әйтергә кирәк, моңа кадәр дә Россия һәм чит ил авторларының шушы юнәлештәге фәнни эшләре булган. Ләкин алар шул вакытта ук сирәк очрау, югары уку йортлары

таләпләренә туры килмәү һәм, күбрәк төрек теле грамматикасы гына бирелү сәбәпле, төрек-татар телен укытуда кулланма була алмаган. Шушы сәбәпләр аркасында 1836 елда А.Казем-Бек төрек-татар грамматикасын төзү эшенә керешә дә инде. Төрек-татар грамматикасын эшләгәндә А.Казем-Бек И.Н. Березин тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителгән Г.Жоберның төрек грамматикасыннан, И.Хәлфин, А.Троянский, И.Гигановларның татар теле грамматикаларыннан файдалана. Шул ук вакытта төрки телләр татар теле белән генә түгел, ә чуваш, монгол һ.б. телләр белән дә чагыштырып бирелә.

Үзенең грамматикасын А.Казем-Бек өч өлешкә бүлә: беренче өлеш алфавит, исем, сыйфат, сан, алмашлык кебек грамматик категорияләрне иңләп ала; икенче өлеше, нигездә, фигыльләргә багышлана һәм монда шулай ук теркәгечләр, ымлыклар, рәвешләр дә карала; өченче өлештә сүзтезмәләр, ягъни синтаксис мәсьәләләре тикшерелә.

А.Казем-Бек грамматикасы һинд-европа тел белеменең турыдан-туры тәэсире астында язылуы белән дә кызыклы. Әлеге грамматикада төрки телләр буенча бирелгән чагыштырма материалның әһәмиятен кыскача күзаллау гына да махсус тикшеренү таләп итә. Эшнең өченче өлешен тулаем А.Казем-Бек яза. Ул аны өч кисәккә бүлә. Беренче кисәктә ярашу очраклары тасвирлана. Монда А.Казем-Бек, фигыль хәбәрләрнең ярашуына зур басым ясап, ия белән хәбәрләрнең ярашуы турында төп кагыйдәләрне җиткерә. Шушы кисәктә гарәп, рус һәм башка грамматикалар үрнәгендә исемнең сыйфат белән ярашуы турында яза, һәм шунда ук, фикереннән кире кайтып, төрек телендә сыйфат үзенең исеме белән берничек тә ярашмый, ди.

Икенче кисәктә А.Казем-Бек сүзләрнең башкарылулы һәм башкарылусыз ярашуы өлкәсеннән төп мәгълүматлар бирә. Монда беренче очракта янәшәлек ярдәмендә төзелгән сүзтезмәләр турында, ә икенче очракта башкарылу ярдәмендә төзелгән сүзтезмәләр турында әйтелә. Фигыльләрнең төрле килешләр белән башкарылуы турындагы өлеш киң итеп сурәтләнә. Шушы кисәктән фигыльнең фигыль белән ярашуы, фигыльләрнең заман һәм юнәлеш белән төрләнүенең

кулланылышы, җөмләдә кире кагу, сорау һ.б. күрсәткечләрне куллану турында мәгълүмат алырга була.

Өченче кисәк җөмләләрнең ярашуына яки фразалар конструкциясенең гомуми системасына багышланган. Бу бүлек җөмләдә сүзләр тәртибен аңлатудан башлана. Ләкин А.Казем-Бекның әлеге эшендә катлаулы җөмләләрне иярченле кушма җөмләләргә һәм тезмә кушма җөмләләргә бүлү, алар арасындагы бәйләү чараларын күрсәтү булмый әле.

Теоретик яктан А.Казем-Бек логицизм ягына зур борылыш ясый. Мәсәлән, ул җөмләнең өч баш кисәген фикерләүнең өч кисәгенә – субъект, предикат һәм бәйләгечкә тиңләп карый.

А.Казем-Бек үз фәне буенча иң яхшы методистлар рәтендә була. Кайбер кимчелекләре булуга карамастан, ул үз эшенең остасы, төрек-татар теленең югары дәрәҗәдәге белгече булып санала. Унҗиде ел буена төрек-татар теле кафедрасы мөдире булуы өстенә, ул фәнни эшләрне дә талантлы итеп оештыра.

А.Казем-Бек киң профильле көнчыгыш телләре белгече, ягъни ул филолог кына түгел, тарихчы да була. Филологик эшчәнлеге төрки телләрне өйрәнүне генә түгел, бәлки, гарәп, фарсы филологиясе белән дә кызыксынуны үз эченә ала. Казан университетында эшләү дәверендә (1826-1849) ул 20 дән артык фәнни эш яза.

Профессор *Илья Николаевич Березин* үзенең укытучысы А.Казем-Бек кебек үк киң профильле көнчыгышны өйрәнү белгече була. Студент елларында ук гарәп, фарсы һәм төрек телләре белән кызыксына. Шул дәвердә үк ул Р.Жоберның төрек грамматикасын француз теленнән рус теленә тәрҗемә итә. Әлеге эшенә аның укытучысы А.Казем-Бек та уңай бәяләмә бирә.

И.Н. Березинның төрек-татар теле буенча икенче хезмәте – А.Казем-Бек грамматикасына өстәмә, ул 1846 елда аерым китап булып (“Төрки грамматикага өстәмә”) басылып чыга.

И.Н. Березинның төрки телдә язылган тарихи-филологик истәлекләрне тикшерүгә багышланган эшләре аерым игътибарга лаек. Әлеге өлкәгә караган хезмәтләре 1850 нче елларда “Хан ярлыклары” дигән китапта басылып чыга. Әлеге эшне башкару дәверендә И.Н. Березин монгол галиме Д.Банзаров белән төрки халыклар хәтта Ислам дине кертелгәч тә уйгур алфавитын

кулلануны дәвам итәләр дигән фикергә килә. Бары дини документларда гына гарәп язуы кулланыла.

1849-1854 елларда Казанда И.Н. Березинның “Көнчыгыш тарихчылары китапханәсе” дигән хезмәте басылып чыга.

И.Н. Березин төрек һәм иран халыкларының тарихын өйрәнү буенча уңышлы эш алып бара. Казанда яшәгән вакытта тарихи-филологик характерда 30 лап хезмәт яза. Моннан тыш, шушы чорда, бигрәк тә Көнчыгышка экспедицияләр вакытында, бик күп фактик материал җыя һәм нәтиҗәдә алар Петербургта басылып чыга. Алар 1857-1876 нчы елларда дөнья күргән төрки телләрнең өч томлы хрестоматиясенә фактик материал өчен бик яхшы чыганак була.

Казанда яшәгән чорда “Төрек кабиләләренең халык мәкальләре” дигән хезмәте 1856 елда “Уку өчен китапханә”нең 136, 137 нче томнарында басыла. Һичшиксез, мәкальләрнең күп өлешен автор Көнчыгышка сәяхәтләре вакытында җыйган.

Шулай итеп, И.Н. Березинның төп тюркологик хезмәтләре Казан чоры эшчәнлегенә туры килә. Ул Казан тюркологлар мәктәбенең күренекле вәкиле була, Казан төрки мәктәбе үсешенә зур өлеш кертә.

Шул ук кафедрада көнчыгыш каллиграфиясе мөгаллиме – *Мөхәммәтгали Мәхмүдов* та эшли. Галим-тюрколог буларак ул университет каршындагы Казан төрки лингвистик мәктәбендә формалаша. М.Мәхмүдов түбәндәге хезмәтләр бастыра: “Мәрткә киткәннәрне җирләүдән саклау” (1851) исемле китапның русчадан татарчага тәрҗемәсе; “Татар телен өйрәнү өчен практик кулланма” (1857); крестьяннарны азат итү манефестының татарчага тәрҗемәсе (1861) һ.б. 1859 елны М.Мәхмүдов русча-татарча сүзлек төзү өстендә эшли, әмма ул сүзлекнең язмышы билгесез. 1851 елны русчадан татарчага зур күләмле медицина китабын тәрҗемә итә.

“Татар телен өйрәнү өчен практик кулланма” (1857) дигән хезмәт М.Мәхмүдовны тюрколог дип атарга хокук бирә. 1855 елны әлеге хезмәт Казан университетының көнчыгыш факультетына тәкъдим ителә һәм хуплана. Беренче Казан гимназиясенең 100 еллык юбилеена (1867 ел) грамматиканың тулыландырылган икенче басмасы әзерләнә. Икенче китапның

басылуы билгеле түгел. Беренче басмасының кереш сүзендә М.Мәхмүдов болай дип яза: “Бу китапны нәшер иткәндә минем бердәнбер максатым рус ватандашларымны татар теленең казан сөйләше белән таныштыру иде”. Димәк, ул казан татарларының сөйләм теле буенча беренче хезмәт. Алга таба, XIX гасырның 50 нче елларында татар теле гимназиягә М.Мәхмүдов тарафыннан мөстәкыйль фән буларак кертелә.

М.Мәхмүдовның татар телен өйрәнүгә практик якын килүе гарәп хәрефләрен тасвирлаудан башлана. Шул ук вакытта күп кенә татар авазларының әйтелеше аларга туры килгән рус теленең авазлары белән чагыштырыла. Лексикология һәм лексикография өчен татарча-русча тематик сүзлек зур әһәмияткә ия. Анда Казан сөйләменә караган 3000 нән артык сүз теркәлгән. Татар сүзләре гарәп графикасында бирелгән. Шул ук вакытта алар рус графикасында да язылган. Бу хезмәтнең грамматика өлеше исем сүз төркемен кыскача гына тасвирлаудан башланып китә. Алмашлыклар турындагы бүлек зур әһәмияткә ия. Ләкин иң оригиналь һәм талантлы башкарылганы – фигыльләр турындагы бүлек. Фигыль формаларының семантикасы төрле яктан аеруча җентекләп тикшерелгән. Шуны әйтергә кирәк, М.Мәхмүдов билгеләгән иң авыр фигыль формаларының мәгънәсе хәтта рус һәм татар телләренең заманча чагыштырма грамматикаларында да очрамый.

Бу китапта шулай ук татар синтаксисы буенча да кайбер белешмәләр китерелгән. Мисал өчен, III затта “фигыльнең үз исеме яки алмашлыгы белән санда ярашуы мәҗбүри түгеллеге” турында ачык һәм төгәл әйтелә. Бу күренеш ия булып торган предметның җанлы яки җансыз булуына бәйле түгел. Хезмәтнең бу өлешендә татар теле синтаксисы буенча башка күзәтүләр дә бирелгән. Мәсәлән, “сан сүз төркеме ачыклый торган сүз һәрвакытта да берлек санда куела” һәм “татар телендә фигыльнең иялек килешне таләп иткән очраклар юк”, дип М.Мәхмүдов дөрес билгеләгән.

Китапның ахырында татар һәм рус гыйбарәләре бирелә. Бу гыйбарәләргә игътибар иткәндә, анда татар телен өйрәнүчеләр өчен татар җөмләләренең төп калыпларын күрергә була.

*Габдүш Ваһапов* – Казан төрки лингвистик мәктәбендә тәрбияләнүчеләрнең берсе. 1835 елда ул хәрби кантончылар арасында Беренче Казан гимназиясен тәмамлый. Гимназияне тәмамлаганнан соң Казан хәрби идарәчелек училищесына укытучы итеп билгеләнә. Соңыннан Г.Ваһапов Казан университетының физика-математика факультетында лекцияләр тыңлый. 1866 елда Казан университетында гарәп, фарсы һәм татар телләреннән сынауларны уңышлы гына үтеп чыга.

Г.Ваһапов укыган Беренче Казан гимназиясе университет белән тыгыз бәйләнештә була. Ул университет укытучылары ярдәмендә тюркологик белем ала. Гимназияне тәмамлаганнан соң, университетның танылган галиме И.Н. Березин белән тыгыз бәйләнештә эшли.

Г.Ваһаповның филологик хезмәтләре Казан тюркология мәктәбе йогынтысы астында язылa. Аның "Русларга – татарча, татарларга – русча үзөйрәткеч"е киң танылу ала. Ул 1850 елдан 1911 елга кадәр 18 тапкыр басылып чыга. Бу хезмәтенә ул практик максатлар куя: русларны – татарча сөйләшергә, ә татарларны – русчага өйрәтү, шул рәвешле аларны рус мәдәниятенә яраклаштыру. Г.Ваһаповның икенче хезмәте "Русча-татарча әлифба". Аңа сөйләм телендә кулланыла торган сүзләр, сөйләшүләр, кыска повестьлар һәм төньяк татарларның 30 җыры тупланган. Ул шулай ук берничә тапкыр нәшер ителә. Беренче басмасы 1852 елда университет типографиясендә чыга. Бу хезмәт Г.Ваһаповны халык җәүһәрләрен җыючыларның берсе итеп таныта.

Казан университетының турыдан-туры йогынтысын тойган XX гасырның тагын бер күренекле тюркологы *Мартиньян Иванов*. Ул Оренбургтагы Неплюев кадет корпусында татар теле укытучысы була.

М.Иванов 1831 елда, ягъни 19 яшендә әлеге корпусны тәмамлый. Күрәсең, ул татар телен бик әйбәт белгәндер, чөнки укыган вакытында ук укыту белән шөгыльләнә. 1832 елның мартында М.Иванов Казан университетында татар һәм фарсы телләреннән имтиханнарын уңышлы гына тапшыра. Университет советы карары белән, ул гимназияләрдә татар теле укытуга һәм фарсы телендә укырга, язарга, телнең

грамматикасына өйрәтергә хокук ала. 1832 елдан ул Неплюев хәрби училищесында татар теле укыта башлый. Шул елның октябреннән исә, укытучылык эшеннән тыш, канцеляриядә көнчыгыш телләрдән тәрҗемә итү белән шөгыльләнә. Үзенең лекцияләре нигезендә М.Иванов өч томнан торган татар теле грамматикасы, татар теле сүзлеге, татарча хрестоматия яза. Әлеге хезмәт югары бәягә лаек була.

М.Иванов беренчеләрдән булып татар укучыларына И.А. Крыловның, И.И. Дмитриевның мәсәлләре белән үз телләрендә танышырга мөмкинлек бирә. Шулай ук рус теленнән татар теленә мәсәлләр тәрҗемә итүчеләр арасында да ул беренчеләрдән була. М.Иванов барлыгы 17 мәсәл тәрҗемә итә.

*Салихҗан Кукляшев* үзенең хезмәтләрен шулай ук Казан лингвистик мәктәбе йогынтысында язган галим. С.Кукляшев Оренбургта Неплюев хәрби училещесын тәмамлаганнан соң, чик буендагы комиссиядә тәрҗемәче булып эшли. 1832 елның мартында ул җирле халык яшьләре белән Казан университетының медицина факультетына укырга җибәрелә. С.Кукляшев үзенең иптәшләре белән Казан гимназиясенә урнаша. Ләкин егет үзенең тырышлыгы белән шул ук елның сентябрендә университетка кабул ителә. Шулай да С.Кукляшевка университетны тәмамларга насыйп булмый.

1933 елның апрелендә сәламәтлеге начараю сәбәпле университеттан китәргә мәҗбүр була. 1834 елның февралендә ул үзен медицина факультетыннан көнчыгыш телләре факультетына күчерүләрен сорый. Сентябрь аенда күчерелүгә ризалык та бирелә. Дөресрәге, С.Кукляшев көнчыгыш бүлегендә 1832 елдан ук укый башлый. Университетны 1835-1836 елларда тәмамлый һәм кандидат исеменә лаек була. Университетны тәмамлаганнан сон, С.Кукляшев Оренбургтагы Неплюев кадет корпусында өлкән укытучы булып эшли. Аның исеме 1859 елны Казан университетында нәшер ителгән “Татар хрестоматиясе” һәм “Татар хрестоматиясенә сүзлек” хезмәтләре аша таныш. С.Кукляшевның “Татар хрестоматиясе”, М.Иванов хезмәтеннән соң, икенче урында тора. Тюрколог гади, эшлекле һәм фәнни стильләрне аерып карый. Шул рәвешле, С.Кукляшев татар язма теленең стилен өйрәнә һәм аларга караган материаллар туплый

башлый. Мәсәлән, ул хрестоматиясенә мәкальләр, хикмәтле сүзләр, эш кәгазьләре, тарихи истәлекләрдән өзекләр, шигъри әсәрләр кертә. Сүзлек тюркология, аеруча татар лексикологиясе һәм лексикографиясе өчен әһәмияткә ия. С.Кукляшевның әлеге хезмәтләре тулырак өйрәнүгә лаек.

### *1918 нче елга кадәр Казан төрки лингвистик мәктәбе традицияләренең дәвам ителеше*

Казан төрки лингвистик мәктәбе традицияләре Санкт-Петербург университетында дәвам ителә, алар Казанда төрки телләр укытыла торган күпсанлы рус урта һәм югары уку йортлары тәҗрибәләре белән дә баетыла. Әлеге уку йортларының төрки телләр өйрәнү өлкәсендәге әһәмияте А.Н. Кононовның “Россиядә төрки телләрне өйрәнү тарихы. Октябрьгә кадәрге чор” хезмәтендә җентекләп яктыртыла.

Казан университетының көнчыгыш бүлеге Петербург университетына күчерелгәч, Казан төрки лингвистика мәктәбе концепцияләре күбесенчә татар лингвистлары тарафыннан күтәрелеп чыга. Алар бу идеяләрдән тыш, гарәп, фарсы, кайвакыт Көнбатыш Европа галимнәренең лингвистик хезмәтләреннән файдалана. Гарәп лингвистик хезмәтләре тәҗрибәсенә таянмый торган, Казан төрки лингвистик мәктәп традицияләрен дәвам итүче лингвистлар да барлыкка килә.

Монда беренчеләрдән танылган татар мәгърифәтчесе *Каюм Насыйри*ны атарга кирәк. Ул 1860 елда рус булмаганнарга татар теле дәреслекләре һәм татарларга рус телен өйрәтү өчен “Мисалларда аңлатылган кыскача татар теле грамматикасы”н бастыра. Әлеге хезмәтләрдә борынгы татар язма һәм сөйләм телләре нормаларына нигезләнгән татар милли әдәби теленең грамматик категорияләре бирелә. Соңрак К.Насыйри татар теленең фәнни грамматикасын тәмамлый, ул 1895 елда Казанда “Әнмүзәҗ” исеме астында басылып чыга. К.Насыйри 1895-1896 нчы елларда “Ләһҗәи татари” исемле татар теленең ике томлык аңлатмалы сүзлеген чыгара.

Татар балаларына татар теле дәреслекләре төзүдә *Габделгалләм Фәезханов* нәтиҗәле эш алып бара. Ул 1881 елда

Казанда “Татар телигә кыскача гыйлем-сарыф” исемле дәреслек төзеп бастыра.

Рус укучыларына татар теле укыту өчен рус телендә дәреслекләр таләп ителә. Мондый хезмәтләргә Х.Фәезхановның “Татар теленең кыскача грамматикасы” (1862), Н.И. Ильминскийның “Татар фигыленең ешлык формасы” (1863), Н.Остроумов, А.Архангельский, Н.Ф. Катанов һ.б.ның грамматикалары керә.

Танылган тюрколог *Н.Ф. Катанов* урянхай теле өлкәсендәге тикшеренүләргә багышланган хезмәт авторы буларак билгеле. Ул татар тел белеменә дә зур өлеш кертә.

XIX гасыр ахырында, дәреслек һәм уку ярдәмлекләреннән тыш, фәнни лингвистик хезмәтләр дә барлыкка килә. Татар теленең аерым проблемалары Ш.Әхмәров, А.Бессонов, Г.Әхмәров хезмәтләрендә яктыртыла.

XX гасыр башы татар балалары өчен күпсанлы татар теле дәреслекләре чыгу белән характерлана. Мәсәлән, 1990-1907 нче еллар аралыгында Г.Тәүфыйк, Г.Начиз, М.Өметбаев, А.Сираҗетдин, А.Мөхәммәдрәхим, А.Мостафа, Х.Макки һ.б.ның хезмәтләре дөнья күрә. Бу дәреслекләр гамәли характерда була һәм хәзерге көндә бары тарихи әһәмияткә ия.

1905 нче елгы Беренче рус инкыйлабы тәэсирендә татарлар арасында да җәмәгатьчелек фикеренең үсеше күзәтелә. Шуңа бәйле рәвештә татар әдәби теле проблемаларын яктырткан күпсанлы хезмәтләр, татар теленең грамматик төзелешенең мөһим үзенчәлекләрен татар телендә тасвирлаган грамматик ярдәмлекләр дөнья күрә.

Беренче күләмле ярдәмлек буларак *Ш.Иманаев*ның “Татар теленең нәхүе вә сарыфы” хезмәтен атарга мөмкин. Ул рус һәм француз теле грамматикалары үрнәкләренә таянып языла. Монда сүз төркемнәре һәм аларның категория системалары яктыртыла. Беренче тапкыр бер составлы җөмләләр төшенчәсе кертелә, билгелелек һәм билгесезлек төшенчәләре җентекләп тасвирлана, сүзләрнең туры һәм кире тәртибе турындагы мәсьәлә дөрес хәл ителә.

1910 елда *Әхмәтһади Максудов*ның “Төрки сарыфы” исемле китабы басыла. Әлеге хезмәтне төзегендә автор гарәп, фарсы, француз һәм рус теле грамматикаларыннан иҗади файдалана.

*Г.Нугайбәк*нең “Төрлек” исемле хезмәте башкалардан аерылып тора. Беренчедән, автор рус теле грамматикасындагы бөтен категорияләрне татар теленнән эзли; икенчедән, алынма терминология урынына татар лингвистик терминологиясен кертеп җибәрергә омтыла.

*Г.Ибраһимов*ның “Татар сарфы” һәм “Татар нәхүе” хезмәтләре 1911 елда басыла. Әлеге хезмәтләрендә автор, рус тел белеменең теоретик нигезләмәләрен иҗади файдаланып, үз грамматикасында тюркология традицияләрен гомумиләштерә. Мәктәп дәреслекләренең һәм татар грамматик терминологиясенең ныклы нигезе Г.Ибраһимовның әлеге хезмәтләрендә салына. Бу китаплар шул дәрәҗәдә популяр була ки, алар Октябрь инкыйлабына кадәр берничә тапкыр басыла.

Революциядән соң Г.Ибраһимов җитәкчелегендәге авторлар коллективы, бу хезмәтләрне нигез итеп алып, 3 кисәктән торган төпле мәктәп дәреслеге чыгара. Башка дәреслек авторлары, Г.Ибраһимов хезмәтендәге мәгълүматларны теге яки бу дәрәҗәдә кабатлап, үзләренең хезмәтләренә берникадәр ачыклык һәм аңлатма гына кертәләр.

Моңа *Х.Кәбүтәри*ның “Кыскача татарча сарыф”, *Г.Сәгъди*нең “Үз телемезгә мөкәммәл сарыф, нәхү”, *Җ.Вәлиди*нең “Татар теле имла һәм сарыф вә нәхү кагыйдәләре” хезмәтләрен мисалга китереп була.

Шулай итеп, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар теле грамматикасын эшкәртү Казан төрки лингвистик мәктәбе эшчәнлегенең нәтиҗәсе булып тора. Аның төп казанышларын үзләренә кабул итеп алып, галимнәр милли татар теленең конкрет мисаллары белән тулыландыралар, баеталар, тюркология нигезләрен эшкәртүгә лаеклы өлеш кертәләр. XX гасыр башында татар грамматикалары авторлары, тюркологлар арасында беренчеләрдән булып, чит ил һәм рус лингвистларының казанышларын иҗади рәвештә файдалана башлыйлар.

Билгеле булганча, XX гасыр башы Казан төрки лингвистик мәктәбе галимнәренең һәм 20 нче еллар татар

грамматикларының хезмәтләре татар телендә бастырыла. 30 нчы елларда Сталин репрессиясе корбаннарының хезмәтләре, тиешле органнар боерыгы белән, Республика һәм Казан дәүләт университеты китапханәләренең махсус саклау бүлекләренә урнаштырыла. Ул вакытта бу хезмәтләр белән Мәскәү үзәк китапханәсендә генә танышып була. Шуңа күрә XX гасыр башы татар лингвистларының хезмәтләре төрки дөньяга мәгълүм булмый. Әмма "Кумык теле грамматикасы" һәм "Башкорт теле грамматикасы"н төзегәндә СССР ФАнең әгъза-мөхбире Н.К. Дмитриев татар галимнәре хезмәтләреннән иркен файдалана, алар аша татар лингвистларының казанышлары гомуми тюркологиягә җиткерелә.

***XX гасырның 18 нче елларыннан 50 нче елларга кадәр Казан төрки-татар лингвистик мәктәбе***

Бу елларда төрки-татар лингвистикасының үсешендә ике чорны билгеләп үтәргә була.

*Беренче чор* 1917-1939 елларны үз эченә ала. Бу чорда Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешу (1920 ел), 1922 елда Казан халык белем мәгарифе институтын Көнчыгыш педагогика институты, ә 1934 елда Казан дәүләт педагогика университеты дип үзгәртү тел белеме үсешенә уңай тәэсир итә.

Әгәр дә 1917 елга кадәр фәнни һәм фәнни-популяр стиль иске татар әдәби теле традицияләрен саклаган булса, әлеге чорда татар милли әдәби теле формалаша.

1918 елда Уфада Г.М. Чыгтайның "Сарыф" (Морфология), "Нәхү" (Синтаксис) хезмәтләре басыла. Җ.Вәлидинең гомуми характердагы "Татар теленең грамматикасы" укытучылар курсы өчен чыгарыла, ул зур әһәмияткә ия була.

Тел белеменең гасыр дәвамындагы уңышлары Г.Ибраһимов җитәкчелегендә М.Корбангалиев, Г.Ходаяров, Ф.Сәйфи-Казанлы, Х.Бәдигый тарафыннан төзелгән "Гамәли тел сабаклары" мәктәп грамматикасында гомумиләштерелә. Бу чорга Г.Алпаровның "Шәкли нигездә татар грамматикасы" хезмәте дә карый. Анда татар тел белеме тарихында беренче тапкыр телнең формаль модельләрен өйрәнү максаты куела. Шунда ук һәрбер модельнең мәгънәсе аңлатыла. Казан

лингвистик мәктәбе вәкилләренең берсе, Петербург академиясенең әгъза-мөхбире И.А. Бодуэн де Куртенэның шәкерте В.А. Богородицкийның “Төрки-татар тел белеменә кереш” (Казан, 1929), “Татар һәм төрки тел белеме буенча этюдлар” (Казан, 1933), “Башка төрки телләр белән бәйләнештә татар тел белеменә кереш” (Казан, 1934) хезмәтләре фәнни-гамәли әһәмияткә ия.

Телнең килеп чыгышына һәм яшәешенә кагылышлы теоретик сорауларга аерым игътибар бирелә башлый. Моңа мисал итеп, Г.Гобәйдуллинның “Иске тел һәм милләт”, “Татар теленең килеп чыгыш мәсьәләсе”, Г.Сәгъдинең “Кешелек тарихында тел, язу һәм аларның тарихи үсүләре” кебек хезмәтләрен атарга була.

Татар диалектологиясе, лексикографиясе, әдәби теле тарихы, рус һәм татар телләрен чагыштырып өйрәнү кебек өлкәләрдә алга китеш күзәтелә.

Махсус диалектологик экспедицияләр оештырыла һәм шуларның нәтиҗәсе буларак, Җ.Вәлидинең “Татар теленең казан диалекты турында”, “Карино һәм глазов татарларының рәвешләре” кебек хезмәтләре басыла, бер-бер артлы русча-татарча сүзлекләр, төрле фән тармакларына караган терминнар сүзлеге һәм Җ.Вәлиди төзегән “Татар теленең тулы сүзлеге”нең ике томы дөнья күрә. Тарих һәм тел теориясенә Г.Рәхим, Г.Алпаров, Җ.Вәлиди һәм Х.Бәдигов хезмәтләре зур өлеш кертә. Рус һәм татар телен чагыштырып өйрәнүдә М.Корбангалиев һәм Р.Газизов зур хезмәт куя.

Әлеге чорда татар теленең фонетик төзелешен эксперименталь рәвештә өйрәнә башлыйлар. В.А. Богородицкийның һәм Г.Шәрәфнең эксперименталь тикшеренүләре бүгенге көнгә кадәр әһәмиятен югалтмаган.

1927 елда латин графикасының кабул ителүе җитди бәхәс тудыра. Латин графикасын кабул итү һәм татар теленең терминнарын камилләштерү өлкәсендә С.Атнагулов, Х.Бәдигый, Г.Шәрәф, Х.Кәримов, М.Корбанов, Г.Нугайбәк, Ф.Сәйфи-Казанлы, Н.Хәким, М.Фазлуллин, Ш.Рамазанов һ.б. актив эшли.

1939-50 нче елларга кадәр булган *икенче чор*да оештыру чаралары күренә, татар филологиясенең үсешен нәкъ менә шуларга бәйләп карыйлар. 1939 елда Татар тел, әдәбият һәм

тарих институты оештырыла, 1945 елда ул СССР ФАнең Казан филиалы составына кертелә. 1944 елда Казан университетында татар филологиясе бүлеге ачыла. Аз санлы татар тел белгечләре төрле юнәлешләрдә эшләрен дәвам итә.

Югары уку йортларында фән буларак татар теле диалектологиясе, тарихи грамматика һәм әдәбият тарихы буенча курслар барлыкка килә.

Һәр елны мәктәп дәреслекләре чыгарыла, урта мәктәптә татар телен укыту методикасы эшкәртелә. Моннан тыш, русча-татарча, төрле тармакларга караган терминологик сүзлекләр бастырыла. Татар теленең сүзлек составы, бигрәк тә, терминологиясе фәнни яктан тикшерелә. Әлеге өлкәдә Ш.Рамазановның хезмәтләре әһәмиятләрен югалтмый.

Казанда төрки-татар тел белеменең үсешенә шәхес культы тискәре тәэсир ясый. Әйдәп баручы киң профильле телчеләр Җ.Вәлиди, Г.Ибраһимов репрессияләнә. Калган галимнәр дә җитди теоретик хезмәтләр язарга батырчылык итмиләр.

***XX гасырның II яртысында Казан төрки-татар лингвистик мәктәбе***

XX гасырның II яртысында төрки-татар тел белеме үсешен ике чорга бүлеп карарга мөмкин.

*Беренче чор* XX гасырның 50 нче елларыннан алып 90 нчы елларына кадәр дәвам итә. Ул тел белеменең кайбер сораулары буенча бәхәстән башлана. Бәхәс гомуми һәм рус тел белеменә генә түгел, ә татар лингвистикасы үсешенә дә уңай тәэсир итә.

50 нче еллар ахырында ук инде татар тел белемендә татар теленең грамматик системасы буенча зур гомуми хезмәтләр барлыкка килә. Шундый хезмәтләрнең берсе – М.З. Зәкиевның Казан университеты нәшриятында басылган “Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис” хезмәте. Икенчесе –В.Н. Хангилдинның 1959 елда басылган “Татар теле грамматикасы. Морфология һәм синтаксис” китабы.

Татар тел белгечләре СССРның төрле төбәкләрендә яшәүче тюркологлар белән эшлекле мөнәсәбәт булдыруга игътибар бирә. 1960 елда КДУның татар теле һәм әдәбияты кафедрасыннан (мөдире – проф. Хатип Госман) татар теле

кафедрасы аерылып чыга һәм шунда ук Казан университетында тюркология һәм көнчыгышны өйрәнү тарихы проблемалары буенча Бөтенсоюз конференциясе әзерләнә башлый. Конференция 1963 елда уза, анда Мәскәү, Ленинград, Алма-Ата, Баку, Фрунзе, Ташкент, Ашхабад, Уфа һ.б. шәһәрләрнең әйдәп баручы тюркологлары катнаша.

СССР ФАнең әгъза-мөхбире Б.А. Серебренников конференциядә катнашучыларны шул елда Казан университеты нәшриятында аерым китап булып басылган “Татар фигыленең заман системасы” хезмәте белән таныштыра. СССР ФАнең Тел белеме институты директоры, профессор Е.И. Убрятова Казан университетының татар теле кафедрасы белән эшлекле бәйләнештә торачаклары турында сүз бирә.

Уфа профессоры Җ.Г. Киекбаев, бер яктан, Башкорт университетының башкорт теле белән татар теле һәм әдәбияты кафедралары, икенче яктан, Казан университетының татар теле кафедрасы белән килешү төзи. Аның буенча фән кандидатларын әзерләү эше оеша һәм татар теленнән диссертация яклаганда проф. Җ.Г. Киекбаев, ә башкорт теленнән диссертацияләр яклаганда М.З. Зәкиев оппонент буларак катнаша.

Татар лингвистикасында иске татар һәм хәзерге татар теленә кергән 12 мең гарәп-фарсы сүзе һәм сүзтезмәләреннән тупланган “Гарәпчә-татарча-русча сүзлек”не төзү һәм бастыру зур уңышлардан санала (К.З. Хәмзин, М.И. Мәхмүтов, Г.Ш. Сәйфуллин. Гарәпчә-татарча алынмалар сүзлеге (Татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре). – Казан, 1965. – 855 б.). Сүзлеккә нигез лингвистика буенча булган бәхәсләргә кадәр үк К.З. Хәмзин һәм Г.Ш. Сәйфуллин тырышлыклары белән салына. Бу эшнең инициаторы М.И. Мәхмүтов була, ул аны төзүгә зур өлеш кертә. 1966 елда М.И. Мәхмүтов “Татар әдәби телендә гарәп алынмаларының фонетик һәм грамматик үзләштерелеше” темасына кандидатлык диссертациясе яклый. Ул шулай ук мәктәп укучылары өчен русча-татарча сүзлекләр, рус һәм татар икетеллелеге турында мәкаләләр авторы да. М.И. Мәхмүтов ТР мәгариф министры вазифаларын башкарганда педагогика өлкәсендә эшли башлый, ТР ФА академигы була.

60 нчы еллар уртасында Тел, әдәбият, тарих институтының Казан филиалында югары уку йортлары өчен “Хәзерге татар әдәби теле” (Х.Курбатов, Р.Шакирова, К.Сабиров) курсын төзү өчен коллектив оештырыла. 1965 елда Татарстан китап нәшриятында “Хәзерге татар әдәби теле. Лексика. Фонетика. Орфоэпия. Графика һәм орфография. Морфология” дигән китап чыгаралар. Курсның икенче өлеше “Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис” 1966 елда М.З. Зәкиев тарафыннан Казан педагогика университетында басыла. Бу хезмәтләр гомуми характерда булсалар да, татар телен белүчеләргә генә адреслана.

60 нчы еллар ахырында татар тел белеме казанышларын киң җәмәгатьчелек укучыларына һәм белгечләргә, беренче чиратта, бөтен төрки телле республикалардагы, илнең тюркологик үзәкләрендәге һәм чит ил лингвистларына җиткерү максаты белән, хәзерге татар әдәби теле курсын рус телендә төзү өчен мөмкинлекләр туа.

60 нчы елларда рус телендә мондый хезмәт ике китап булып чыгарыла. 1969 елда “Фән” нәшриятында “Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. Фонетика. Морфология” китабы басыла (авторлары: Н.Б. Борһанова, М.З. Зәкиев, Х.Р. Курбатов, А.М. Латыпов, Л.Т. Мәхмүтова, К.С. Сабиров, М.А. Сәгыйтов, Д.Т. Тумашева, В.Х. Хаков, Ф.Ю. Юсупов). Икенче китап 1971 елны чыга (Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис. М.: Фән. – 310 б. Авторлары: М.З. Зәкиев, Х.Р. Курбатов). Бу гомумиләштерелгән хезмәт чагыштырмача кечкенә күләмле булса да, татар теленең лексик һәм грамматик төзелешен өйрәнүгә сизелерлек өлеш кертә.

1977, 1979, 1981 нче елларда өч томлык “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге” басылу татар лингвистикасы үсешенең мөһим күрсәткече булып санала. I томны төзүчеләр (А – И): И.А. Абдуллин, Г.Х. Ахунҗанов, Ф.М. Газизова, Л.Р. Гайнанова, М.Г. Мөхәммәдиев, Р.К. Рәхимова, Ш.С. Ханбикова, Р.Г. Әхмәтьянов; II томны (К – С) төзүчеләр: И.А. Абдуллин, Г.Х. Ахунҗанов, С.Б. Вахитова, Ф.М. Газизова, Ф.Ә. Ганиев, Р.Р. Мингулова, М.Г. Мөхәммәдиев, Ш.С. Ханбикова, Р.Г. Әхмәтьянов; III томны (Т – Һ) төзүчеләр: И.А. Абдуллин,

С.Б. Вахитова, Ф.М. Газизова, Л.Р. Гайнанова, Ф.А. Ганиев, М.Г. Мөхәммәдиев, Ш.С. Ханбикова, Р.Г. Әхмәтьянов.

Бу аңлатмалы сүзлек төзүне оештыручы һәм җитәкче – Л.Т. Мәхмүтова була. Һәр өч томлыкның редколлегиясенә Л.Т. Мәхмүтова, М.Г. Мөхәммәдиев, К.С. Сабиров, Ш.С. Ханбикова кергән.

*Икенче чор* XX нче гасырның 90 нчы еллар ахырыннан башлана һәм төрек-татар лингвистикасының көчле үсеше белән характерлана. Бу елларда бердәм бер тел, бердәм мәдәният перспективасында совет халкын оештыру сәясәте яңарыш сәясәте, милли телләрне үстерү һәм саклау сәясәте белән алышына. Испаниянең, бигрәк тә Каталониянең милли өлкәләре үрнәгендә, союздаш республикаларда дәүләт телләре турында законнар кабул ителә башлый. Тел турындагы законнар элеккеге СССРның автономияле республикаларында да әзерләнә.

1988-1989 нчы елларда СССР ФАнең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында "Татарстан халыклары телләре" турындагы Закон проекты эшләнә. Ул Министрлар Советында яңадан редакцияләнә, аннары 1992 елда депутатлар тарафыннан кабул ителә. 1994 елда бу институт тарафыннан Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча дәүләт советы программасы проекты республиканың югары органнарына тәкъдим ителә. Ул шулай ук депутатлар тарафыннан яңадан карала һәм Татарстан парламенты тарафыннан 1994 елда кабул ителә.

Лингвистларның соравы буенча, республиканың Министрлар Кабинеты каршында Премьер-министр рәислеге белән Телләр турындагы законны гамәлгә ашыру Комитеты төзелә. Бу законны тормышка ашыру ТР Министрлар Кабинеты каршында ТР халыкларын һәм телләрен үстерү һәм саклау турында махсус бүлек төзүне таләп итә. Әлеге бүлек 1999 елда эшли башлый. Бүлекнең беренче җитәкчесе итеп К.М. Миңнуллин билгеләнә, анда Р.Р. Җамалетдинов, А.М. Гыймадиев төп эшне алып бара.

Татар теленең функциональ үсеше татар лингвистикасы өлкәсендә фән кандидатлары һәм докторларның саны артуга китерә. Әлбәттә, боларның барысы да татар теле һәм әдәбияты укытучыларының гомуми саны артудан башлана. Аларны

әзерләү өчен күп кенә уку йортларында татар филологиясе бүлекләре ачыла. Мәсәлән, Казан һәм Башкорт университетларында, Тобол, Стәрлетамак, Ульяновск, Оренбург педагогика университетларында шундый бүлекләр эшли башлый. Әлеге югары уку йортларын белгечләр белән тәэмин итү өчен Тел, әдәбият һәм тарих институтында кандидатлык һәм докторлык диссертациясен яклау советлары эшләрен тизләтә, Тобол педагогика институтында шундый совет ачыла. Нәтиҗәдә, татар филологиясе буенча фән кандидатлары һәм докторларның саны арта.

Татар лингвистикасының үсешенә 1991 елда Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе ачылу да уңай йогынты ясый.

1992 елның 9-13 июнендә Казанда “Төркиләрнең теле, рухи мәдәнияте һәм тарихы: традицияләр һәм заман” дип аталган төрки конференция үткәрелә. Ул башта VI Бөтенсоюз төрки конфренция буларак әзерләнә, ләкин алга таба ул халыкара статус ала.

Бөтендөнья төрки конференциянең оештыру комитетына Россия Федерациясенең ерак һәм якын чит ил тюркологларыннан, Татарстан, Башкортстан, Удмуртия, Мари-Эл һ.б республикалардан 560 тан артык галим катнашырга теләк белдерә. Конференциядә 262 кеше, шул исәптән АКШ, Франция, Италия, Төркия, Кипр, Япония, Венгрия, Германия, Финляндия һ.б. илләрдән 20 дән артык кеше чыгыш ясый.

1992-1993 нче елларда чыккан өч томлык академик грамматиканы татар лингвистикасының икенче чор үсешендә зур казаныш итеп санарга кирәк. Фонетика, фонология, орфоэпия, морфемика, морфонология мәсьәләләрен чагылдырган беренче томда татарларның этник тарихы турында да мәгълүмат бирелгән. Беренче томда “Кереш сүз”, “Кереш”, “Грамматиканың төп төшенчәләре”, “Морфемика” бүлекләрен М.З. Зәкиев; “Фонетика”, “Фонология”, “Просодика” бүлекләрен – Х.Р. Курбатов; “Морфонология” бүлеген – М.З. Зәкиев һәм Д.Ә. Сәлимова; “Сүз ясалышы” бүлеген Ф.Ә. Ганиев яза.

Икенче томның авторлары: Н.Б. Борһанова (“Сан сүз төркеме”); З.М. Вәлиуллина (“Исем сүз төркеме”); Ф.Ә. Ганиев (“Фигыльләрне өйрәнүнең кыскача тарихы”, “Фигыльгә кыскача

характеристика”, “Сан категориясе”, “Инкарь һәм раслау категориясе”, “Инфинитив формалары”); М.З. Зәкиев (“Кереш”); К.З. Зиннәтуллина (“Сыйфат”, “Алмашлык”); С.М. Ибраһимов (“Теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр”); М.А. Сәгыйтов (“Модаль сүзләр”, “Кисәкчәләр”, “Ымлыклар”) һ.б.

III томның авторы һәм төзүчеләр коллективының җитәкчесе – М.З. Зәкиев. Редколлегия: М.З. Зәкиев, Ф.Ә. Ганиев һәм К.З. Зиннәтуллина.

1998, 1999, 2002 нче елларда “Татар грамматикасы”ның өч томы татар телендә басыла. Бары икенче томда гына кайбер тема авторларында үзгәрешләр бар. Бу татар академик грамматикасы Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясенә лаек була. Ике елдан кабат басыла. Рус телендә академик “Татар әдәби теле тарихы (XIII-XX гасырның беренче чирегe)” языла һәм 2003 елда басыла.

ИЯЛИнең гыйльми хезмәткәрләре Д.Рамазанова, Ф.Баязитова, Т.Хәйретдинова, З.Садыкова, Р.Барсукова татар халык сөйләшләренең зур атласын төзиләр. Ул татар халкының этник тарихын өйрәнү белән турыдан-туры бәйләнгән.

Татар мәдәни тормышында бер томлык “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге” басылу зур вакыйга була (2005). Сүзлекнең редколлегиясе: Ф.Ә. Ганиев (баш мөхәррир), К.С. Миңнебаев, Ф.М. Газизова, Г.Г. Саберова, Ф.Ф. Гаффарова. Төзүдә һәм нәшер итүдә И.Абдуллин, Р.Абдуллина, А.Алеева, Р.Әхмәтьянов, С.Вахитова, Ф.Газизова, Л.Габдрахманова, Ф.Ганиев, Л.Мортазина, К.Миңнебаева, А.Рәхимов, Р.Рәхимов, Д.Рамазанова, Г.Саберова, Ф.Таһирова, М.Хәйруллин катнаша.

Татар теленең ике томлык диалектологик сүзлеген төзү, тулы татарча-русча сүзлекне һәм күпсанлы тармак сүзлекләрен, алынмалар сүзлекләрен төзү татар теленең күп томлы идиографик академик сүзлеген төзи башлауга мөмкинлек ача.

Соңгы елларда тюркологиядә этнолингвистика буенча эзләнүләрнең җанлануы күзәтелә, ягъни төрки халыкларның этник тарихын өйрәнүдә лингвистик мәгълүматлардан файдалану күзгә ташлана. М.З. Зәкиевның “Төрки һәм татарларның барлыкка килүе” (2003) китабында булган тарихи чыганакларны анализлау юлы (бигрәк тә тарихи-лингвистик)

белән б.э. кадәр V-IV меңьеллыкларга караган төрки һәм татарларның этник тамырлары ачыла. Тарихи эзләнүләрдә лингвистик мәгълүматлар куллану белән лингвистик палеонтология шөгыльләнә. М.З. Зәкиев бу юнәлешне лингвистик археология дип атарга тәкъдим итә. Археология матди мәдәниятнең борынгы калдыкларын өйрәнә. Лингвоархеология табылган борынгы лингвистик мәгълүматларны тикшерә. Алар борынгы халыкның этник төзелешен төгәл билгеләргә ярдәм итәләр. М.З. Зәкиевның мондый тикшеренүләре белән төрек галимнәре дә кызыксына. Алар М.З. Зәкиевның алда әйтелеп үткән китабын төрек теленә тәрҗемә итәләр һәм 2006 елда Истамбулда бастырып чыгаралар.

Татар теленең функциональ үсешенә, аның фәнни терминологиясе тулылануга телче булмаган вуз доцентлары, татар профессорларының 1991 елдан башлап үз фәннәрен татар телендә укыта башлаулары, физика-математика, техник фәннәр буенча вуз дәреслекләре һәм терминологик сүзлекләр төзү тәэсир ясый. Бу эшне координацияләү өчен ТР Фәннәр Академиясенең гуманитар бүлегендә "Гуманитар вуз фәннәрен татар телендә укыту" фәнни-методик советы төзелә. Советның рәисе Казан архитектура-төзелеш институты деканы, профессор В.Ш. Фәтхуллин була. Гуманитар бүлеккә (академик-сәркатиб М.Зәкиев) бүлеп бирелгән акчага татар телендә беренче вуз дәреслеге төзелә. Алдагы елларда мондый дәреслекләр ТРның "ТР халыклары телләре турында" Законын тормышка ашыру максатында бүлеп бирелгән акчага бастырыла.

1999 елдан башлап Казан архитектура-төзелеш академиясендә даими рәвештә "Фән һәм тел" исемле фәнни журнал чыгып килә. Аны оештыручылар – техник фәннәр докторы, профессор Ф.Әхмәдиев (баш мөхәррир), техник фәннәр кандидаты, доцент Р.Шакирҗанов (баш мөхәррир урынбасары). Монда татар лингвистикасы буенча гына түгел, ә башка фәннәр буенча да татарча язылган мәкаләләр басыла. Нәтиҗәдә, татар әдәби теленең фәнни стиле камилләшә. Лингвистика өчен иң мөһиме – бу стиль лингвистик тикшеренүләр предметына әверелә.

Татар лингвистикасы үсешендә филология фәннәре докторы дәрәҗәсенә үсәргә сәләтле булган фән кандидатлары әзерләү мөһим роль уйный. Доктор дәрәҗәсенә үсәрлек кандидатларны әзерләүдә беренче доктор *Латыйф Җәләй*нең (Җәләлетдинов) өлеше зур. Аның мәктәбеннән М.З. Зәкиев, В.Х. Хаков, Ф.Ә. Ганиев, Г.Х. Ахунҗанов кебек докторлар чыга.

*М.З.Зәкиев* тарафыннан әзерләнгән фән кандидатларыннан Г.Ф. Саттаров, С.Ш. Поварисов, Ф.С. Сафиуллина, Р.А. Юсупов, А.Г. Садыйкова, Н.Н. Фәттахова, М.Б. Хәйруллин, В.Г. Фәтхетдинова, Д.Ә. Салихова-Сәлимова, В.Н. Хисамова, Ф.Т. Галләмов фән докторлары булып китәләр һәм үзләре дә фән кандидатлары әзерләү белән шөгыльләнәләр. *Г.Ф.Саттаров*ның укучысы Ф.Г. Гарипова гидрономия буенча докторлык диссертациясен яклый. Филология фәннәре докторы *Р.А. Юсупов* М.Н. Закамулина һәм Н.Х. Шәрипованың докторлык диссертацияләрен консультацияли. *Ф.Ә. Ганиев* тарафыннан әзерләнгән фән кандидатларыннан А.А. Тимерханов фән докторы булып китә, *В.Х. Хаков* әзерләгәннәрдән И.М. Низамов, *Н.Б. Борһанов* укучысы Ф.Й. Йосыпов, *С.Фасеев* укучысы М.И. Әхмәтҗанов докторлык дәрәҗәсенә ирешә.

*Н.К. Дмитриев*ның татар лингвистикасы буенча фән кандидатлары әзерләү эшчәнлеге нәтиҗәле була. Аның шәкертләре – фән докторлары Л.З. Шакирова һәм Д.Г.Тумашева.

*Д.Г. Тумашева* әзерләгән галимнәрдән Ф.М. Хисамова, Х.Х. Сәлимов, В.З. Гарифуллин, Х.Ч. Алишина фән докторлары булып китә һәм аспирантлык эшләре белән уңышлы җитәкчелек итә.

*Л.З. Шакирова*ның элекке аспирантлары Ф.Ф. Харисов, Р.Р. Җамалетдинов, Ч.М. Харисова шулай ук фән докторлары. *Р.Р.Җамалетдинов* татар тел белемендә яңа – лингвокультурология юнәлешен өйрәнүгә нигез салып, үз укучыларын – фән кандидатларын тәрбияли (Л.Р. Гарипова, Э.Р. Җиһангирова, Ф.Х. Хәсәнова, Д.Х. Хөснетдинов, Р.Р. Закирова, Р.Р. Данилова һ.б.).

*В.Н. Хангилдин* укучыларыннан Х.Р. Курбатов фән докторы дәрәҗәсенә ирешә, ул Г.С. Нуриевның докторлык диссертациясен консультацияли.

*М.А. Фазлуллин* укучыларыннан Г.Х. Әхәтов фән докторы була, ул Р.Г. Сибгатовның докторлык диссертациясен җитәкли.

*Э.Р. Тенишев* укучылары Ф.С. Хәкимҗанов һәм А.Х. Нуриева докторлык дәрәҗәсенә ирешә, ә Ф.С. Хәкимҗановның укучысы Н.Х. Шәрипова докторлык диссертациясен уңышлы яклый.

Академик *Е.Н. Кононов* җитәкчелегендә Л.Т. Мәхмүтова кандидатлык диссертациясен яклый. Ә аның шәкертләре Л.Ш. Арсланов, Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова – филология фәннәре докторлары.

*Э.В. Севортян* җитәкчелегендә Ү.Ш. Байчура кандидатлык диссертациясе яклый, соңрак ул филология фәннәре докторы булып китә.

XIX гасыр ахырында Казан лингвистика мәктәбе вәкилләренә, Россия һәм чит ил тюркологиясенә тәэсир ясаган Казан төрки лингвистик мәктәбе үз традицияләрен татар тюркологларының, бигрәк тә лингвистик тикшеренүләрен дөньяви казанышлар дәрәҗәсенә җиткерергә омтылучы татар тел белгечләренең хезмәтләрендә үсешен дәвам итә, алар исә барлык милләтләрнең, бигрәк тә татарларның яңарыш, саклану, үсеш проблемалары белән бәйле барлык гуманитар фәннәр үсешенә зур өлеш кертергә тырышалар.

## XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы тел белемендә яңа фәнни юнәлешләр

Тел безнең өчен шулкадәр гадәти булып тоела ки, хәтта аның асылы турында бик еш уйлап та тормыйбыз, аны кешедәге күрү, сулау һәм ишетү сәләтләре кебек кабул итәбез. Әмма борынгы чорлардан алып бүгенге көнгә кадәр, ягъни берничә меңьеллык дәвамында, кешелек телнең һәм аның асылын әле ахырына хәтле ачып бетерә алганы юк. Моңа инану өчен, тел үзенчәлекләрен аңлату белән бәйле төрле фәннәр тарихының аерым этапларына күз салу да җитә. Һәр үсеш этабында телнең табигате һәм асылын аңлатуга багышланган яңадан-яңа теорияләр һәм хезмәтләр дөнья күргән. Ләкин алардан соң килгән буыннар икенче теорияләр булдырган һәм тагын телнең башка билгеләрен һәм функцияләрен ачкан. Бүгенге көндә тел белемендә XX гасыр ахырында кабул ителгән парадигма

кысаларында эшчәнлек алып барыла. Аның нигезендә хәзерге лингвистика өчен телгә аралашу һәм танып белү чарасы итеп кенә түгел, ә милләтнең мәдәни коды буларак карау да хас.

Кешелек һәм фән тарихында әйләнә-тирә дөньяны танып белүдә телнең роле, тел һәм мәдәният, аларның үзара бәйләнеше һәм тәэсир итешүе, дөнья тел күренешен формалаштыру белән бәйле проблемалар инде бик күптәннән акыл ияләренең игътибарын үзенә җәлеп итүе беркемгә дә сер түгел. Мондый эзләнүләрнең, тел белеме һәм фәлсәфә белән беррәттән, мифология, дин һәм шулай ук табигый фәннәр кысаларында да алып барылуы билгеле. Ләкин бу мәсьәләләр тел белемендә бары тик XX гасырның ахыры – XXI гасыр башында гына махсус, комплекслы рәвештә өйрәнелә башлады һәм киң танылу тапты дип әйтсәк ялгыш булмас. Чөнки әлеге чорга хәтле алып барылган эзләнүләрдә тел билгеле бер яссылыкта гына, аерым алганда, мәдәниятнең бер өлеше буларак фрагменталь рәвештә генә тикшерелде. Бары соңгы берничә дистә ел дәвамында тел һәм мәдәният белән бәйле аерым теоретик мәсьәләләр махсус өйрәнелде, күләмле монографияләр дә дөнья күрде.

Дөнья күләмендә социомәдәни процессларның үсү-үзгәрүе, мәдәният феномены һәм тел шәхесе кебек проблемаларга игътибарның артуы фәндә *тел – мәдәният, тел – кеше аңы һәм фикерләү, тел – җәмгыять* мөнәсәбәтләрен өйрәнүче махсус тармаклар һәм мәктәпләр оешуга этәргеч бирде. Болар арасында тел белемендә *антропологик лингвистика* (тел үсеше һәм яшәеше аркылы кеше аңының үсешен һәм яшәешен өйрәнә), *когнитив лингвистика* (дөньяны танып белүдә һәм кешелек тәҗрибәсен гомумиләштерүдә телнең ролен, кешенең фикерләү сәләте белән тел арасындагы бәйләнешләрне тикшерә), *социаль лингвистика* (телнең барлыкка килү, үсү һәм яшәешенең бәйләнгәнлеген, җәмгыятьнең телгә һәм телнең җәмгыятькә тәэсирен өйрәнә), тел белеме һәм башка фәннәр чигендә барлыкка килгән *лингвострановедение, этнолингвистика* һәм *лингвокультурология* аерым урын алып тора.

*Лингвострановедение* – нигездә яңа телне үзләштерү максатында илләрнең мәдәни чынбарлыгын өйрәнә торган дисциплина. Ул тикшерә торган мәсьәләләр ике төркемгә бүлеп

карала: филологик (тел үзенчәлекләре, милли-мәдәни семантика) һәм лингводидактик (теге яки бу милләтнең телен шул ил үзенчәлекләре белән бәйле рәвештә тәкъдим итү, аларны истә калдыру һәм куллану күнекмәләре формалаштыру). Монда шулай ук өйрәнелә торган тел вәкилләре яшәгән илнең тарихы, гадәтләре, әдәбияты, сәнгате һәм мәгарифе торышы да тикшерелә. Безнең илдә лингвострановедение XX гасырның икенче яртысында барлыкка килә дип исәпләнелә, аның чишмә башында торучылардан В.В. Молчановский, Е.М. Верещагин, В.Г. Костомаров һ.б. исемнәре атала.

*Этнолингвистика* – тел белеменең телне мәдәнияткә мөнәсәбәтле рәвештә, шулай ук аның үсеше һәм яшәешендә этномәдәни һәм этнопсихологик факторларның үзара тәэсир итешүен өйрәнүче бер юнәлеше. Ул – тарихи фән. Этнолингвистика, мөстәкыйль фәнни юнәлеш буларак, XIX-XX гасыр чикләрендә этнография фәне нигезендә формалаша. Россиядә әлеге юнәлештәге беренче тикшеренүләр алып баручы галимнәр буларак Ф.И. Буслаев, А.Н. Афанасьев, А.А. Потебня һ.б. билгеле. Соңрак безнең илебездә этнолингвистика өлкәсендә Н.И. Толстой һәм аның фикердәшләре, укучылары нәтиҗәле эшчәнлек алып бара.

### *Лингвокультурология фәненең барлыкка килүе*

*Лингвокультурология* – тамырлары белән этнолингвистика һәм лингвострановедение фәннәренә тоташып, гуманитар фәннәрнең мәдәният һәм тел чигендә торган, турыдан-туры тел һәм мәдәниятнең үзара бәйләнеше һәм тәэсир итешү мәсьәләләрен өйрәнә торган яңа дисциплина. Кызганычка каршы, соңгы елларда бу термин еш кулланылса да, бүгенге көндә әле аның теоретик-методологик базасы бары формалашу хәлендә генә; статусы һәм билгеләмәсе буенча шулай ук әлегә галимнәр арасында бердәм фикер юк, тикшеренү алымнары һәм терминологиясе буенча да төгәллек сорала. Ләкин бүген инде аның үз *өйрәнү объекты* һәм *предметы* булу бәхәссез, болар: мәдәният һәм телнең яшәеш процессында үзара бәйләнеше һәм тәэсир итешүе; әлеге мөнәсәбәтләр тасвирламасын бербөтен система буларак тикшерү; кешелек тарафыннан барлыкка

китерелгән һәм телдә чагылыш тапкан матди һәм рухи мәдәният. Лингвокультурологиянең *төп бурычларыннан* системалы рәвештә халык (милләт) мәдәниятен телдә, мәдәният һәм телне үзара диалектик тәэсир итешүендә һәм үсешендә чагылдыру, заманча лингвомәдәни фикерләү формалаштыруга юнәлтелгән тәгълиматлар һәм терминнар булдыру исәпләнә.

Хәзер лингвокультурологиянең түбәндәге юнәлешләре билгеле:

1) билгеле бер социаль төркем яки этносның аеруча зур казанышларга ирешкән чордагы мәдәни халәте чагылышын (төгәл лингвомәдәни үзенчәлекләрне) өйрәнү;

2) диахроник лингвокультурология, ягъни этносның билгеле бер вакыт аралыгындагы лингвомәдәни халәте үзгәрешләрен өйрәнү;

3) бер тугандаш телләр төркеменә керүче халыкларның лингвомәдәни үзенчәлекләрен чагыштырып өйрәнү;

4) төрле тугандаш булмаган төркемнәргә керүче халыкларның лингвомәдәни үзенчәлекләрне чагыштырып өйрәнү;

5) лингвомәдәни лексикография, ягъни әлеге юнәлештәге сүзлекләр теориясен эшләү һәм аларны төзү белән шөгыльләнә торган юнәлеш.

Лингвокультурология XX гасырның соңгы чирегендә, тел белемендә антропологик парадигма нәтиҗәсе буларак барлыкка килә. Аның чишмә башында XIX гасырда ук үзенең “О различии строения человеческих языков и его влиянии на духовное развитие человеческого рода” дип исемләнгән хезмәтендә, иң беренче булып, тел холкы һәм халык холкының үзара бәйләнеше турындагы нигезләмәсен тәкъдим иткән Вильгельм фон Гумбольдт тора. Галимнең тел һәм дөньяны аңлау-төшенүгә бәйле рәвештә әйтелгән, аерым алганда, “тел – халык рухы чагылышы, ул кешелек яшәеше тарихы һәм халыкның энергиясе белән турыдан-туры бәйле; тел – тәмамланган эш яки әйбер түгел, ул – эшчәнлек; тел – үле продукт түгел, ә төзү, яңаны барлыкка китерү процессы; тел – кешенең барлык төр эшчәнлекләре нигезендә ятучы, кешене кеше итүче төп көч; тел – кеше рухының төп эшчәнлеге; телләр – милләтләрнең үзләренә

генә хас фикерләү органнары” кебек фикер-гыйбарәләре, шулай ук төрле тел формаларында фикерләү һәм чынбарлыкны кабул итүдәге аермалыкларны ачыклавы һәм, моннан чыгып, телдә мәдәният төрлелеге чагыла, дигән нәтиҗәләре аннан соң килгән буын галимнәр тарафыннан, шул исәптән, бүгенге көндә дә аеруча зур кызыксыну белән җентекләп өйрәнелә һәм фән дөньясында зур әһәмияткә ия.

XIX-XX гасырларда В. фон Гумбольдт фикерләре яңагумбольдтчылар тарафыннан алга таба үстерелә. Әйтик, аның европадагы вәкилләре Л.Вайсгербер, Х.Глинц, Х.Хольц һ.б. төрле телләрнең охшаш һәм аермалы якларын игътибар үзәгендә тотып, аларның семантика өлкәсен тикшерәләр. Шулай ук әлеге галимнәрнең бу чорда фикерләү эчтәлеге һәм фикернең логик төзелеше тел структурасындагы үзенчәлекләргә турыдан-туры бәйлелеген исбатлау буенча эшчәнлек алып барулары мәгълүм. АКШта бу юнәлеш тарафдарлары булып дескрептив (тасвирлама) лингвистика вәкилләре У.Д. Уитни, Д.У. Пауэлл, Ф.Боас, Э.Сепир, Б.Л. Уорф һ.б. исәпләнә. Мәсәлән, Э.Сепир һәм Б.Л. Уорф, остазларының фикерен дәвам итеп, *лингвистик нисбәтлелек гипотезасын* тәкъдим итәләр һәм аерым телдә төрле категорияләрнең булуы һәр тел вәкиле тарафыннан әйләнә-тирә дөньяны үзләренчә кабул итүенә китерүен исбатлыйлар. Шулай ук алар танып белү процессында телгә өстенлек бирәләр.

Э.Сепир фикеренчә, дөньяны ничек күрү, аны кабул итү турыдан-туры телгә бәйле. Аныңча, мәдәният – “әлеге җәмгыять нәрсә уйлый һәм эшли, шул ул. Тел исә, ничек уйлыйлар – шуны күрсәтүче”; “чынбарлык дөнья” теге яки бу социаль төркемнең тел гадәтләренә нигезләнеп корыла; “төрле җәмгыятьләр яшәгән дөньялар төрле ярлыклар гына сугылган бер үк дөнья түгел, бәлки төрле дөньялар”.

Россиядә А.А. Потебня В. фон Гумбольдт фикерләрен дәвам иттерүче буларак билгеле. Ул үзенең хезмәтләрендә (XIX гасыр) телнең эшчәнлек буларак үзенчәлекләрен сурәтли.

XX гасырның беренче яртысында югарыда атап үтелгән галимнәрнең фикерләре, теорияләре тәнкыйтькә дучар ителә. Бары XX гасырның икенче яртысында әлеге тәгълиматлар аерым

игътибар үзәгенә алына һәм бу юнәлештә яңа тикшеренүләр башлана. Мисалга Д.Хаймз, Д.Льюси, А.Дуранти, П.Ли, Г.Брутян, А.Вежбицкая һ.б.ның хезмәтләрен китерергә мөмкин. Шулай ук 1998 нче елда Германиянең Дуйсбург шәһәре университеты базасында “Humboldt and Whorf Revisited. Universal and Culture-Specific Conceptualizations in Grammer and Lexis” дип исемләнгән халыкара симпозиумның узуы аерым әһәмияткә ия. Чөнки анда В. фон Гумбольдт һәм Э.Сепир, Б.Л. Уорфлар үз вакытында күтәргән проблемалар, тел һәм мәдәният мәсьәләләрен өйрәнү белән бәйле рәвештәге яңа карашлар һәм ачышлар яңгырый, болар буенча нәтиҗәле фикер алышу була. Алга таба лингвокультурология өлкәсендәге тикшеренүләрне җанландыру, аларны яңа баскычка күтәрүдә дә бу фәнни җыенның әһәмияте бәяләп бетергесез.

Соңгы елларда турыдан-туры лингвокультурологиягә багышланган бик күп саллы хезмәтләр дөнья күрде. Болар: Е.М. Верещагин һәм В.Г.Костомаровның “Язык и культура: Лингвострановедение в преподавании русского языка как иностранного” (1990), В.В. Воробьевның “Культурологическая парадигма русского языка. Теория описания языка и культуры во взаимодействии” (1994), В.Н. Телияның “Русская фразеология: Семантический, прагматический и лингвокультурологический аспекты” (1996), Ю.С. Степановның “Константы: Словарь русской культуры (Опыт исследования)” (1997), А.Вежбицкаяның “Язык. Культура. Познание” (1997), Н.Д. Арутюнованың “Язык и мир человека” (1999), Р.Х. Хәйруллинаның “Фразеологическая картина мира: от мировидения к миропониманию” (2000), З.Х. Бижеваның “Культурные концепты в адыгской языковой картине мира” (2000), В.А. Маслованың “Лингвокультурология” (2001), В.В. Красныхның “Этнопсихолингвистика и лингвокультурология” (2002), О.А. Корниловның “Языковые картины мира как производные национальных менталитетов” (2003), Р.Р. Җамалетдиновның “Национально-языковая картина мира” (2004), М.В. Зәйнуллин һәм Л.М. Зәйнуллинаның “Общие проблемы лингвокультурологии” (2008), Л.А. Городецкаяның “Лингвокультура и лингвокультурная компетентность” (2009),

Н.Ф. Алефиренконың “Лингвокультурология: Ценностно-смысловое пространство языка” (2010) хезмәтләре һ.б. лингвокультурологларның “өстәл китабы” вазифасын үти.

Болардан тыш, бүгенге көндә әлеге өлкәдәге мәсьәләләрне яктыртуга багышланаган С.Г. Воркачев, Е.И. Зиновьева, В.И. Карасик, Е.Н. Лучинина, Р.А. Османова, Л.Г. Саяхова, Е.И. Шейгал, Е.Е. Юрков һ.б.ның зур күләмле хезмәтләре бу өлкәдә эшләүче галимнәр һәм аспирантлар өчен зур фәнни-методик база булып тора.

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында татар теле материаллары нигезендә лингвокультурологик тикшеренүләр, шул исәптән, концептлар белән бәйле эзләнүләр, нигездә, Казан федераль университеты базасында эшләүче галимнәр тарафыннан алып барыла. Бу вакыт аралыгында әлеге фәнни мәктәп вәкилләре (җитәкчеләре – филология фәннәре докторы, профессор Р.Р. Җамалетдинов) тарафыннан берничә докторлык (Р.Р. Җамалетдинов, Ф.Х. Тарасова, Г.Ч. Фәйзуллина) һәм кандидатлык (Л.Р. Гарипова (Мөхәммәтҗанова), Р.Р. Данилова, Э.М. Җиһангирова, Р.Р. Закирова, З.Ә. Мотыйгуллина, Ф.Р. Сибгаева, Ф.Х. Хәсәнова (Габдрахманова), Д.Х. Хөснетдинов, Л.Х. Шәяхмәтова һ.б.) диссертацияләре якланды, дистәләгән монография нәшер ителде. Исемнәре аталган әлеге яшь укытучы-галимнәр, уку йортының шушы актуаль тема буенча эшләүче махсус кафедрасы укытучылары (Г.Ф. Җамалетдинова, Р.С. Нурмөхәммәтова, М.Р. Саттарова, Ә.Ш.Юсупова һ.б.), аспирантлары һәм магистрантлары тарафыннан соңгы елларда Россия гуманитар фәнни фонды һәм Татарстан Республикасы хөкүмәте матди ярдәме белән үтә үзенчәлекле, әлегә хәтле аналогы булмаган татар теленең этнокультура сүзлегенең өч томы төзелде; бу өлкәдә эшләүче галимнәр катнашында студентлар һәм мәктәп укучыларының татар лингвокультурологиясенә багышланаган фәнни-гамәли конференцияләре оештырыла. Татар лингвокультурологиясе өлкәсендә тикшерәсе һәм ачыклыйсы мәсьәләләр бихисап, шул ук вакытта бүген әлеге эшләрне башкару ысуллары һәм юнәлешләренең чикләре инде якынча билгеләнгән булуы алдагы тикшеренүләр өчен уңай җирлек тудыра.

*Лингвокультурология терминнары һәм төшенчәләре*

Лингвокультурологиянең башка аерым фәннәр һәм дисциплиналар кебек үз категориаль-терминологик аппараты бар. Бу өлкәдә аеруча еш кулланыла торган термин һәм төшенчәләрдән *концепт, концептосфера, лингвокультурема, дөнья тел картинасы* һ.б. атарга мөмкин. Болар арасында аерым урынны *концепт* термины алып тора. Фәнни әдәбиятта ул бик еш кулланылуга һәм аның турында күп санлы фәнни карашлар булуга карамастан, бүген бу юнәлештәге тикшеренү һәм бәхәсләрнең әле тукталганы юк.

Концептлар турындагы дискуссия бик күптәннән килә. Шунысы үзенчәлекле: әлеге термин соңгы вакытта тел белеме өлкәсендә генә түгел, әдәбият белеме, мантыйк, фәлсәфә һәм культурологиядә дә бик еш кулланыла. Тел беелменә килгәндә, бу термин турында рус һәм татар телләренең аңлатмалы сүзлекләрендә дә, чагыштырмача күптән түгел нәшер ителгән күләмле лингвистик сүзлекләрдә дә әлегә тулы мәгълүмат бирелми.

Бүгенге көндә аеруча киң танылу тапкан кайбер хезмәтләргә һәм фикерләргә тукталып үтик.

*Концепт* – алынма сүз, аның килеп чыгышы һәм кайсы телдә ни дәрәҗәдә кулланылуын ачыклау максатында, В.З. Демьяноков “Понятие и концепт в художественной литературе и научном языке” (2001) хезмәтендә, төрле жанр һәм телләрдәге (латин, француз, итальян, испан, немец, инглиз, рус) күпсанлы хезмәтләрне анализлап, болай ди:

1) фәнни латин телендә *conceptus* сүзе “төшенчә” буларак түгел, ешрак “яралган” мәгънәсендә кулланылган. Француз теленнән аермалы буларак, итальян һәм испан телләрендәге идиомаларда һәм матур әдәбият әсәрләре текстларында ул бик күптәннән *concetto, concepto* буларак очрый;

2) немец телендә *концепт*ның (*konzept, koncept*) рус телендәге “конспект” мәгънәсендә йөртелүе мәгълүм. Инглиз телендә *concept* “төшенчә”не аңлатучы философик термин буларак XIX гасырның икенче яртысыннан, рус телендә – бу мәгънәдә 1920-1970 нче елларда кулланыла.

Безнең илдә концепт табигатен тикшерү омтылышы иң беренче С.А. Аскольдовның “Слово и концепт” мәкаләсендә очрый. Монда автор “танып-белү характерындагы” һәм “иҗади концептлар”ны аерып куя. Ул концептка түбәндәге билгеләмәне бирә: “Концепт – фикер барлыкка китергән төзелмә, ул фикерләү барышында безнең өчен бер үк төрдәге күп санлы предметларны алыштыра”. Автор концептның алыштыру вазифасын ассызыклап күрсәтә. Аның өчен концептның когнитив роле мөһим. Танып-белү концептларын һәм иҗади концептларны аерып, С.А. Аскольдов аларның гомуми характерына, күп санлы предметлардан торуына һәм соңгыларының индивидуальлегенә игътибар итә. Аныңча, иҗади концептларга төшенчәләр, күзаллаулар, сизү-тоюлар, хис-тойгылар, хәтта ихтыяр чагылышлары, шулай ук ассоциатив характер хас.

Н.Д. Арутюнова концептларны гадәти, гамәли фәлсәфә төшенчәләре буларак аңлата, аларның “милли традицияләр һәм фольклор, дин һәм идеология, тормыш тәҗрибәсе һәм сәнгать образлары, тойгылар һәм кыйммәтләр системасының үзара йогынтысы нәтиҗәсендә барлыкка килүләрен” ассызыклый. Аныңча, концептлар кеше белән дөнья арасында арадашлык вазифасын башкаручы мәдәни катлам барлыкка китерә.

В.Н. Телия фикере буенча, концепт – ул безнең объект турында белгән мәгънәнең барлык киңлектәге чагылышы.

Когнитив терминнарның кыскача сүзлегендә (1996) исә концептка мондый билгеләмә бирелә: ул – сүзләр һәм экстралингвистик чынбарлык арасындагы арадашчы. Сүз мәгънәсе бары тик төзүче концептларга гына кайтарып калдырылырга тиеш түгел. Мөгаен, концептлар турында сүз мәгънәсе белән туры килгән төшенчәләр дип сөйләү дөресрәк булыр иде.

Ю.С. Степанов “Константы. Словарь русской культуры” (1997) дигән күләмле хезмәтендә концептка бик тирән аңлатма бирә. Галим фикеренчә, “концепт ул – сүзгә кушылып китүче күзаллаулар, төшенчәләр, белемнәр бәйләме”. Аныңча, төшенчәләрдән аермалы буларак, концептлар уйланып кына калмыйлар, алар кичереләләр дә. Концептлар аерым шәхеснең

һәм тулаем әлеге телдә аралашучыларның хис-кичерешләре, симпатия һәм антипатиясе белән бәйләнгән. Ю.С. Степанов концепт структурасының катлаулылыгын, күп баскычлылыгын билгеләп үтә: бер яктан караганда, аңа “төшенчә төзелешенә кергән бар нәрсә дә керә”, икенче яктан исә концепт структурасында “аны мәдәният факты итүче” барлык нәрсә дә күзәтелә. Концепт төзелешенең төрле баскычларында аның килеп чыгышы, этимологиясе, төрле заманча ассоциацияләр, бәяләмәләр чагылыш таба.

Г.Г. Слышкин фикере буенча, концепт – фәнни тикшеренү коралы. Ул – мәдәният, аң һәм тел белеме өлкәләрендәге тикшеренүләрне бергә туплау бурычын үтәүче берәмлек. Шул ук вакытта концепт турыдан-туры тел белеме өлкәсенә дә, мәдәнияткә дә карамый.

Тел концептларының эчтәлеге турындагы күзаллаулар күпмедер күләмдә аерылырга да мөмкин. Мәсәлән, структуралистлар аеручы элементларның роленә зур игътибар юнәлтәләр. Психологик юнәлеш тарафдарлары өчен мәгънәдә тышкы дөньяны турыдан-туры зиһенгә алу түгел, ә беренчел мәгълүматларны “икенче тапкыр” когнитив эшкәрткәннән соң туган күзаллаулар чагылыш табу турындагы нигезләмә аеруча мөһим.

“Төшенчә” һәм “концепт”ны дөрес кулллану, төрле телләрдәге концептларның тәңгәллеге яки тәңгәл булмавы турындагы проблемалар фәнни әдәбиятта һаман да бәхәсле булып кала бирә. “Төшенчә” һәм “концепт”ны терминологик яктан аерып карамаучы тикшеренүчеләрне төшенчәнең рациональ үзәге, аның эчтәлек ягы башка формада бирелә алуы, төрле тел чаралары ярдәмендә нәкъ шул мәгънәне җиткерә алу мөмкинлеге кызыксындыра.

Бу мәсьәләгә В.З. Демьяноковның (2001) карашы кызыклы. Аның фикеренчә, рус телендә, бигрәк тә гуманитар фәннәрдә, “концепт” һәм “төшенчә” синонимнар буларак кулланылмый. “Төшенчә” кешеләр тарафыннан теге яки бу мәсьәлә буенча “уртак тел” табу өчен барлыкка китерелә (“конструирование”), ә “концепт”лар инде яшиләр, аларны бары яңадан төзү (“реконструирование”) турында сүз бара. Бу уңайдан, “концепт” латиндагы *conceptus*, ягъни “яралган” мәгънәсеннән

ераклашмыйча, “яралучы хакыйкать”кә туры килә. Галим фикеренчә, “концепт” инде ул, күрәсең, “яралган”, аның шулай булуына без бары тиешле яңарту нәтиҗәсендә генә инанабыз.

Күпчелек галимнәр фикеренчә, төрле тел һәм мәдәниятләрдәге концептлар тәңгәл түгел. Чөнки концепт яки төшенчә барлыкка килгәндә беркадәр уртак билгеләр булса да, күзәтелгән процесс һәм күренешләрнең төрле яклары булуы мәгълүм. Моның нигезендә кеше фикерләвенең гомуми законнары белән фикерләү эшчәнлеген тормышка ашыруга ярдәм иткән чаралар дифференциациясе арасындагы бик зур каршылык ята.

Телне логик анализлау белән шөгыльләнүче галимнәр концептны башкача аңлаталар. Р.И. Павиленис концептуаль системага үзенчәлекле аңлатма бирә: ул [концептуаль система] телдә булмаган һәм телдәге текстларның төп аңлатмалары контекстын тәшкил итә.

Аның фикеренчә, концепт бары тик тулаем телнең концептуаль системасы кысаларында гына аңлашыла һәм аерым концептларның эчтәлек катламнарын да, үзенчәлекләрен дә системадан читтә күз алдына да китереп булмый. Телдә ирекле сөйләшә алу ул концептларның кодлаштыру күнекмәләренә ия булу гына түгел. Концептларны символик теркәү, тел тамгалары ярдәмендә эш итеп, алардан файдалану мөмкинлеге бирә һәм шул рәвешчә яңа мәгънә төзелмәләре корырга булыша, дип яза Р.И.Павиленис.

Ю.Е. Прохоровның концептлар белән бәйле дистәләгән фәнни хезмәттәге фикерләргә тулы күзәтү ясау һәм бәя бирүгә багышланган “В поисках концепта” (2009) монографиясенең бу мәсьәлә белән кызыксынучылар өчен әһәмияте аеруча зур. Алты бүлектән торган әлеге китапта *концепт*, аның килеп чыгышы, өйрәнү предметы, максаты һәм бурычлары, кулланылыш үзенчәлекләре җентекләп сурәтләнә.

Концептларны өйрәнү, аның теориясен булдыруда Д.С. Лихачевның өлеше бик зур. Галим концептның фикер төзелмәсе буларак аңлатмасын эшли. Ул концепт телдән һәм язма сөйләмдә мәгънәнең “алгебраик” гәүдәләнеше, дигән фикердә. Д.С. Лихачев концепт сүз өчен түгел, ә сүзнең һәр төп

мәгънәсе өчен хезмәт итә, концепт турыдан-туры сүзнең мәгънәләреннән барлыкка килми, ә сүз мәгънәләренең кешенең шәхси яки халык тәҗрибәсе белән очрашуы нәтиҗәсе булып тора дип исәпли. Ул шулай ук “*концептосфера*” теориясен дә тәкъдим итә. Аның турында галим болай ди: аерым кешенең, шулай ук тулаем барлык телнең сүзлек запасында саклanучы мөмкинлекләр – концептосфералар була. Д.С. Лихачев тәкъдим иткән теория концепт һәм тел семиотикасы бәйләнеше проблемасын лингвистика кысаларыннан киң колачлы мәдәни һәм милли контекстка алып чыга. Ул концептосфера төшенчәсенең мөһимлеген ассызыклап, аның телне гади аралашу чарасы гына булып калмыйча халык мәдәниятен туплау вазифасын аңлатудагы мөһимлегенә дә басым ясый; терминны исә, В.И. Вернадскийга ияреп, “ноосфера”, “биосфера” мисаллары үрнәгендә тәкъдим итүе турында әйтә.

Теге яки бу халык (милләт) мәдәнияте концептосферасын аның төп концептлары системасы тәшкил итә.

Концептосфера кысаларында В.И. Убийко суперконцептлар, макроконцептлар, төп концептлар һәм микроконцептларны аерып карарга тәкъдим итә. Мәсәлән, *кеше* лексемасы суперконцепт булып тора. “Кешенең эчке дөньясы” концептосферасы нигезендә ятучы *җан* һәм *рух* концептлары макроконцептлар булалар. Алар эчке дөньяның хис-тойгылар өлкәсен *(хис-тойгы* концепты), менталь *(акыл* концепты), императив сфераны *(ихтыяр* концепты), әхлак өлкәсен *(мәрхәмәтлелек* һәм *явызлык* концептлары) бербөтен итеп туплый. В.И. Убийко фикеренчә, концепт күләмле менталь төзелмә буларак күзаллана, ул үзен тәкъдим итүче сүзнең чит мәгънәләре вариантларын гына түгел, ә сүзьясагыч тамырдаш сүзләрнең һәм семантик кырның башка вариантларын да үзендә туплый. Аның “Концептосфера внутреннего мира человека” дигән сүзлегендә башлангыч лексемалар, аларның дериватлары, антонимик һәм синонимик рәтләре тәкъдим ителгән.

Лингвокультурологиядә еш кулланыла торган төп термин һәм төшенчәләр арасында *лингвокультурема* да бар.

*Лингвокультурема* – лингвистик һәм экстралингвистик эчтәлекнең диалектик бердәмлеген чагылдыручы комплекслы

берәмлек. Тел берәмлекләре һәм сүздән аермалы буларак, лингвокультурема үз эченә тел сегментыннан башка мәдәният мәгънәсен дә ала һәм махсус билге аша белдерелә. Сүз билге һәм мәгънәдән генә торса, лингвокультуремага исә болардан тыш тагын төшенчә/предметның да керүе хас.

“Лингвокультурема” терминын фәнгә В.В. Воробьев кертеп җибәрә. Аның тарафыннан шулай ук әлеге терминның барлык үзенчәлекләре дә сурәтләнә. Галим фикеренчә, лингвокультурема аерым сүз, сүзтезмә, абзац яки текст белән бирелергә мөмкин. Ә аның чыганаклары буларак, В.В. Воробьев түбәндәгеләрне күрсәтә:

- халык поэтик иҗаты әсәрләре;
- тарих һәм җәмәгать фикере истәлекләре, шулай ук тарих, фәлсәфә, тел белеме, әдәбият белеме, социология, эстетика һ.б. өлкәләрдәге махсус фәнни хезмәтләр;
- фән, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә зур уңышлар казанган бөек шәхесләр тарафыннан әйтелгән сүзләр һәм гыйбарәләр;
- аерым әдәби әсәрләр;
- халык геройлары буларак танылган бөек шәхесләр;
- теге яки бу халык, аның мәдәнияте турында башка ил кешеләренең фикерләре.

Лингвокультурология *дөнья тел күренеше*н өйрәнүгә бик зур игътибар бирә. Әлеге төшенчә В. фон Гумбольдтның фикерләү һәм чынбарлык арасында телнең “арадашчы дөнья” буларак яшәве турындагы фикеренә барып тоташа. В. фон Гумбольдт фикеренчә, тел – тарихи яктан беркетелгән мәгънәләр системасы ул, аның ярдәмендә телдән тыш чынбарлыкның аң объектларына әверелү бара. Тел – алдан билгеләнгән әйберләргә әзер этикеткалар рәте түгел, ә “арадашчы реальлек” ул. Тел предметларның атамасын түгел, ә аларның безгә ничек бирелүен хәбәр итә. Анда телдән тыш дөньяның субстанциональ сыйфатлары түгел, ә кешенең бу дөньяга мөнәсәбәте чагылыш таба. Аныңча, дөньяны акыл тарафыннан бүлгәләү һәм аңа караш формалашу процесслары “телнең эчке формасы” эшчәнлегенә кайтып кала, ә ул энергияле һәм системачыл төзелешкә ия асылны тәшкил итә; төрле телләр – һәр милләтнең үзенә генә хас фикер йөртү һәм дөньяны кабул итү органы ул.

XX гасыр ахырында бу мәсьәләне өйрәнүгә багышланган бик күп хезмәтләр барлыкка килә. Бу уңайдан Г.А. Брутян, С.А. Васильев, Г.В. Колшанский, Н.И. Сукаленко, М.Блэк, Д.Хаймс һ.б., шулай ук “Человеческий фактор в языке. Язык и картина мира” (1988) дип исемләнгән коллектив монографияне һ.б. атарга мөмкин. Бүгенге көндә шулай ук дөньяның милли күренеше үзенчәлеген өйрәнүгә мөнәсәбәтле күп теорияләр һәм хезмәтләр дә мәгълүм. Алар бер (Ю.Д. Апресян, З.Х. Бижева, Р.Р. Җамалетдинов, Ю.Н. Караулов, Р.Х. Хәйруллина һ.б.) яки берничә тел (С.Г. Воркачев, Г.Д. Гачев һ.б.) материаллары нигезендә өйрәнүгә корылган. Милли менталитет яссылыгында дөнья тел күренеше мәсьәләләре аеруча тирән һәм җентекләп О.А.Корнилов тарафыннан тикшерелгән.

Асылда, *дөнья тел күренеше* – ул бары метафора гына, чөнки билгеле бер милләт вәкилләренең уникаль тарихи һәм иҗтимагый тәҗрибәсен үзендә туплаган һәр тел үзенчәлекләре ниндидер кабатланмас *дөнья күренеше* барлыкка китерми, бары тик моңа, әлеге халыкның яшәү рәвеше һәм мәдәни дәрәҗәсенә бәйле рәвештә предмет, эш-гамәл һәм күренешләргә күпмедер күләмдә бер төс кенә бирә.

Дөнья тел күренеше кешенең дөньяны анализламыйча гына, спонтан рәвештә зиһенгә алуын чагылдыра. Һәрбер тел дөньяны үзенчә бүлгәли, ягъни үз концептуальләштерү алымнарына ия. Моннан чыгып, һәр телнең үз дөнья күренеше бар һәм, теге яки бу телдә сөйләшүче милләт вәкиле сөйләмен оештырганда, аны әлеге күренеш кысаларында башкара дигән нәтиҗә ясала.

Дөнья тел күренеше төзелешен тасвирлау ике баскычтан тора: беренчесе, тел тамгаларының гомумкешелек, универсаль эчтәлеген яки, дөнья тел күренеше компонентлары буларак, концептларны ачыклау; икенчесе, билгеле бер этномәдәният гомумилегенең дөньяны танып-белү тәҗрибәсен беркетү ысулы буларак, милли тел үзенчәлеген сурәтләү.

Шулай итеп, югарыда күрсәтелгән хезмәтләрдәге теория һәм фикерләрне йомгаклап, мондый нәтиҗәләр ясарга мөмкин.

1. Бүгенге көндә телгә аралашу һәм танып белү чарасы итеп кенә түгел, ә милләтнең мәдәни коды буларак карау формалашты. Мәдәният һәм телнең үзара тәэсир итешүе һәм

бәйләнеше мәсьәләләрен комплекслы өйрәнү аерым фәнни дисциплина кысаларында алып барыла.

2. Лингвокультурология – лингвистика һәм культурология чикләрендә барлыкка килеп, халыкның телдә сакланган һәм телдә чагылыш тапкан мәдәни үзенчәлекләрен өйрәнә торган фәнни дисциплина.

Лингвокультурологиянең тамырлары этнолингвистика һәм лингвострановедение фәннәренә барып тоташа. Алар бер-берсенә бик якын торалар, ләкин һәркайсының үз өйрәнү объекты һәм предметы, максат һәм бурычлары бар. Шул ук вакытта бүгенге көндә лингвострановедение лингвокультурологиянең ярдәмче бүлеге вазифасын башкара дигән фикер бик еш яңгырый.

Лингвокультурологиянең махсус фәнни тармак яисә дисциплинамы, яки тел белеменең бер тармагымы дигән мәсьәлә әлегә ачык кала бирә.

3. Лингвокультурологиядә аеруча еш кулланыла торган термин һәм төшенчәләрдән *концепт*, *концептосфера*, *лингвокультурема*, *дөнья тел картинасы* һ.б. исәпләнә.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Тел белеме үсешендә урын алган лингвистик мәктәпләрне атагыз.
2. Тел белемендә натурализм юнәлеше формалашу, аның төп вәкилләре һәм аларның телгә карата фикерләре турында сөйләгез.
3. Тел белемендә психологик юнәлеш барлыкка килүне тасвирлагыз.
4. Психологик юнәлеш вәкилләре Г.Штейнталь һәм В.М. Вундтның эшчәнлеген чагыштырып сурәтләгез.
5. А.А. Потебняның тел белеме үсешенә керткән өлеше, аның хезмәтләре турында сөйләгез.
6. Тел белемендә логик юнәлеш формалашу тарихын тасвирлагыз.
7. Ф.И. Буслаевның тел белемендәге логик юнәлеш үсешендәге ролен аңлатыгыз.
8. Яшь грамматикачылык (младограмматизм) мәктәбенең төп идеяләре нидән гыйбарәт?
9. Мәскәү лингвистика мәктәбе, җитәкчесе Ф.Ф. Фортунатов һәм аның күренекле вәкилләренең эшчәнлеге турында сөйләгез.
10. Лингвистик география юнәлешенә кемнәр нигез сала?
11. Тел белемендә неолингвистлар нинди эшчәнлеге алып бара?
12. Тел белемендә эстетизмның асылын ачып бирегез.
13. Күренекле галим Ф.де Соссюрның тел белеме үсешендә тоткан урыны турында сөйләгез, төп хезмәтләрен атагыз.

14. Тел белемендәге иҗтимагый юнәлеш белән бәйле төп идеяләрне аңлатыгыз.

15. Дөнья тел белемендә структурачылык фомалашуга күзәтү ясагыз.

16. Прага лингвистика мәктәбенең тел белеме фәнендә тоткан урыны турында сөйләгез.

17. Глоссемантикага кемнәр нигез сала?

18. Америка структурачылыгының үзенчәлеге нәрсәдә?

19. Телнең тамгалар (знаклар) системасы булуын ничек аңлыйсыз?

20. Казан лингвистика мәктәбенең формалашу тарихы турында сөйләгез. Төп үсеш этапларын тасвирлагыз.

21. Казан лингвистика мәктәбенең күренекле вәкилләреннән кемнәрне беләсез?

22. Казан лингвистика мәктәбенең күренекле вәкиле буларак К.Насыйриның тел белеме өлкәсендә эшчәнлеген тасвирлагыз.

23. Казан лингвистика мәктәбенең бүгенге көндәге торышын тасвирлагыз.

24. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы тел белемендә тикшеренүләр нинди яңа фәнни юнәлешләрдә алып барыла?

# ИҖТИМАГЫЙ КҮРЕНЕШ БУЛАРАК ТЕЛ

**Тел һәм җәмгыять**

Тел – кешеләр аралашуында иң мөһим чараларның берсе. Телдән башка кешеләр аралаша алмый, аралашудан башка җәмгыять тә, шул исәптән кеше үзе дә була алмас иде. Бу аның иҗтимагый күренеш булуыннан килә.

Кеше телен хайваннарның аваз сигнализациясе белән чагыштырганда аның иҗтимагый асылы аеруча ачык күренә. Кеше сөйләм авазларын әйткәндә (сөйләшкәндә) билгеле бер органнардан файдалана. Кешеләрдәге кебек органнар, шул исәптән ми, сизү-тою органнары, борын һәм авыз куышлыгы һ.б. хайваннарда, кошларда да бар. Әмма алар чыгарган төрле авазларны сөйләшү дип әйтеп булмый, чөнки алар фикерләү белән бәйләнмәгән. Кеше хайваннарны да кешеләр куллана торган сүзләрне әйтергә һәм кабул итергә өйрәтә ала. Карола Шульц исемле хатынның тутый кошы 120 сүз "белгән". Л.Дуров этен "ма-ма" дип әйтергә өйрәткән. Ат кеше сөйләменең аерым авазларын аңлый: "на-а" – киттек, "тпру" – тукта һ.б. Башка күп кенә хайваннарны, кошларны да төрле авазлар һәм сүзләр әйтергә өйрәтү очраклары билгеле. Әмма бер генә хайван һәм кош та авазларны конкрет ситуациядән тыш кабул итә һәм кабатлый алмый. Хайваннар "тәрбиясендә" үскән балаларның да сөйләшергә, фикер йөртергә, кешеләр кебек эшләргә өйрәнә алмавы гыйбрәт алырлык. Гәрчә кешеләр арасында тусалар да, бу коллективтан аерылып, башка шартларга эләккән балалар кешечә сөйләшергә өйрәнә алмый. Кайвакыт вакытлы матбугат битләрендә, телевидениедә хайваннар арасында, ялгызлыкта үскән балалар турында мәгълүматлар бирелә. Аларның күп гадәтләре кешеләрнекенә охшамаган: төнлә күп йөриләр, дүрт аяклап чабалар, ризыкны иснәп карыйлар, кешеләрне күргәч качалар, контактка кермиләр һ.б. Болар – телнең җәмгыятьтә генә яши һәм формалаша, үсә алуын дәлилли.

Баланың кайсы телдә сөйләшә башлавы тәненә, чәченә, күзенә һ.б. билгеләренә карамый, ә аның тирәсендәге кешеләрнең нинди телдә аралашуына бәйле була. Чөнки ул телне башкалар, әйләнә-тирә (гаилә, балалар бакчасы, мәктәп,

урам һ.б.) тәэсирендә өйрәнә. Бала чакта башка телдә сөйләшә торган гаиләгә эләккән балаларда туган (ата-анасының) телләрен оныту очраклары еш була; әгәр янында туган телендә сөйләшүче кешеләр булмаса, олы кеше дә үз телен онытырга мөмкин.

Тел буыннан-буынга күчми, баланың нинди телдә сөйләшәчәге генетик яктан алдан билгеләнми. Баланың аерым органнары гына сөйләм механизмына яраклаштырылган. Әмма бу механизм тиешле шартлар (тел әйләнәсе, социум) булганда гына хәрәкәткә килә. Әгәр бала телсез-чукрак булып туа икән, җәмгыятьтә яшәү генә аны сөйләшергә өйрәтә алмый, чөнки аның кирәкле физиологик механизмы формалашмаган була. Физиологик механизм эшчәнлегенә зыян килгәндә (төрле имгәнүләр, һәлакәтләргә очрау һ.б.), олы кешедә дә төрле сөйләм кимчелекләре килеп чыгарга мөмкин.

Тел тулы бер җәмгыятькә, коллективка, бер төркемгә генә хезмәт итеп калмый, ул аерым кешенең индивидуаль үзенчәлекләрен дә чагылдыра. Телдәге индивидуальлек биологик һәм иҗтимагый факторлар белән билгеләнә. Биологик фактор сөйләмнең темпына, тембрына, сөйләмдә кимчелекләр булу-булмауга, кешенең чит телләрне үзләштерү сәләтенә, язма һәм сөйләмә телне өйрәнүенә дә тәэсир итә. Әмма шәхеснең соңгы ике сәләте өйрәтү һәм тәрбияләү ярдәмендә, ягъни иҗтимагый гамәлләр аркасында үсәргә мөмкин. Тик бар кеше дә полиглот, талантлы язучы һәм матур сөйләүче булып тумый.

Кешенең телне үзләштерүе һәм аны куллануы сайланма характерга ия. Гомумхалык лексикасын, сүзләрнең төрләнешен һәм кулланылышын, сүз ясалыш модельләрен белү мәҗбүри. Ә әйтелеш, сүз төрләнеше һәм сүзләрнең ярашу вариантларын, синонимнарны сайлауга килгәндә исә, индивидуаль тайпылышлар булырга мөмкин. Сөйләм эшчәнлегенең бу ягы бик үк мәҗбүри түгел, ул фикернең темасына һәм жанрына, аралашу ситуациясенә, шәхеснең индивидуаль стиленә бәйле.

Кешелек җәмгыяте тоташ бертөрле коллективтан гыйбарәт түгел. Аның эчендә төрле бүленешләр күзәтелә. Әлеге бүленешне сыйнфый, милек, һөнәри, җирле һ.б. сәбәпләр тудырырга мөмкин. Болар телдә дә чагылыш таба.

Тел үзе таралыш алган территориядә һәм кулланылыш өлкәләрендә бердәй була алмый. Аның үз эчендә аермалыклар табыла: әдәби тел, гадәттә, әлеге социумның эчке бүленешен чагылдырган диалектларга, шулай “профессиональ тел”гә һәм башка төрләргә каршы куела.

*Әдәби тел* гомумхалык теленең нормалаштырылган вариантыннан гыйбарәт, аңа норматив сүзлекләргә теркәлгән, кешеләр тарафыннан аңлы рәвештә кулланыла торган кагыйдәләр, ягъни нормалар хас. Әлеге нормаларга мәктәпләрдә өйрәтәләр. Аның сөйләмә һәм язма формалары була.

*Диалект* – теге яки бу телнең билгеле бер территориядә таралган фонетик, лексик һәм грамматик үзенчәлекләре җыелмасы, ул бары тик сөйләмә формада гына яши. Мисал өчен, татар теленең урта диалектын мишәр диалектыннан аерып торган фонетик, лексик, грамматик билгеләрне шактый санарга була. Рус теленең о-лаштыручы һәм а-лаштыручы сөйләшләре белән дә шул ук хәл.

Гомумхалык теле шулай ук *профессиональ* билгеләр буенча да бүленә: теге яки бу һөнәр ияләре телендә үз эшчәнлек өлкәләренә генә хас махсус лексика һәм терминология өстенлек итә. Мәсәлән, укытучылар, тимер юлчылар, физиклар һ.б. телендә аермалыклар шактый.

Теге яки бу тар иҗтимагый төркем телендә генә очрый торган үзенчәлекләр гомумхалык теленнән тайпылышның тагын бер формасын тәшкил итә. Боларны *жаргоннар* дип йөртәләр. Мисал өчен, студентлар, машина йөртүчеләр, сәүдәгәрләр, диңгезчеләр һ.б. сөйләме. Җәмгыятьнең түбән катламы – караклар, хәерчеләр, йорт-җирсез кешеләр (бомж) һ.б. теле дә үзенчәлекләре белән аерылып тора. Болары *арго* дип аталган сөйләм төрен барлыкка китерә.

Җәмгыятьтә башка күренешләр дә бар. Тел аларга күп яктан охшаган, әмма аермалар да шактый. Тел, кешелек җәмгыятенең яшәеше-үсеше өчен төп шарт һәм рухи мәдәният элементы буларак, башка иҗтимагый күренешләр кебек үк матдилыктан аерып карала алмый. Әмма телнең функцияләре, яшәеш һәм тарихи үсеш закончалыклары аны башка иҗтимагый күренешләрдән кискен аера. Мисал өчен, ул мәдәният белән

тәңгәл килә алмый; ул сыйнфый характерга да ия түгел; тел һәм хуҗалык, тел һәм җитештерү арасында турыдан-туры бәйләнеш юк. Шулай булуга да карамастан, тел үзенчәлекле иҗтимагый күренеш, ул бер үк вакытта аралашу коралы да, фикер алмашу чарасы да. Тел – коллектив казанышы, ул бер коллектив кешеләренең аралашуына хезмәт итә, кеше тормышындагы теләсә кайсы матди һәм рухи күренешләр турында мәгълүматны хәбәр итәргә, сакларга мөмкинлек бирә. Тел гасырлар дәвамында формалаша һәм яши.

Иҗтимагый күренеш буларак тел мөстәкыйль, аның бу үзенчәлеге дәүләт һәм тел берләшмәләренең, кешеләрне дини һәм тел билгеләре буенча бүлүнең туры килмәвендә дә чагыла. Мәсәлән, төп милләт халкы 90% тәшкил иткән дәүләтләр бермилләтле санала, аларда гомумхалык теле, әдәби тел һәм дәүләт телләре туры килә. Әмма мондый дәүләтләр күп түгел. Хәзерге көндә Европада чама белән 20 ләп бермилләтле дәүләт бар дип исәпләнә.[2]

Тел һәм дәүләтчелекне килештерүгә омтылыш ике яки берничә телне дәүләт теле итеп игълан итүдә дә күренә: Канадада ике дәүләт теле (инглиз һәм француз телләре); Швейцариядә дүрт тел рәсми рәвештә дәүләт теле итеп танылган (немец, француз, итальян, ретороман телләре); Һиндстанда берничә дәүләт теле һ.б. Бөекбритания, Испания, Югославия, Һиндстан, Кытай һ.б. күпмилләтле илләр булып санала. Индонезиядә 150 ләп кабилә һәм халык яши. Азия һәм Африка аеруча күптелле.

Бу фактлар, мөһим аралашу коралы һәм милли мәдәният формасы буларак, телнең җәмгыять, андагы категорияләр һәм күренешләр белән тыгыз бәйләнешен исбатлый. Әмма үзенчәлекле билгеләнеше һәм төзелеше аны мөстәкыйль иҗтимагый күренеш итә.

Җәмгыятьтәге демографик үзгәрешләр шулай ук телдә билгеле бер рәвештә чагылырга мөмкин. Мәсәлән, үз вакытында авыл кешеләренең эре сәнәгать үзәкләре булган шәһәрләргә агылуы әдәби телгә сизелерлек йогынты ясаган. Рус әдәби теле тарихын өйрәнүче белгечләр фикеренчә, узган гасырның 50-60

[2] В.И. Кодухов хезмәтеннән алынган мәгълүмат.

нчы елларында рус телендә әдәби булмаган гыйбарәләр, гади сөйләм элементлары күпләп пәйда була. Халыкның тыгыз яки таралып урнашуы кебек демографик факторлар фонетик үзгәрешләр, яңа сүзләр һ.б. таралышына юл куярга яки киртә булырга мөмкин. Халыкның яңа урыннарга күченеп утыруы диалектлар кушылуга яисә вакланугa китерә. Дөньяның һәр төбәгендә кешеләр аз сөйләшә торган телләр, диалектлар арта бара. Төрле илләр арасында һәртөрле багланышлар үсү нәтиҗәсендә халыкара телләр барлыкка килә.

Җәмгыятьтәге һәртөрле үзгәрешләр телләрнең дә үсеш-үзгәрешенә китерә: алар уңай да (телләр көчәеп, күтәрелеп китә), тискәре дә (телләр юкка чыгуга, “үлемгә” дучар ителә) булырга мөмкин. Шул ук вакытта тел үзе дә җәмгыятьнең үсешенә йогынты ясый ала. Җәмгыятьтә барлык кешеләргә дә хезмәт итә торган, аңлаешлы, язуда беркетелгән бер әдәби тел булу дәүләтнең үсешенә тәэсир итә, мәдәни һәм икътисади бәйләнешләрне көчәйтә, аның дөньядагы урынын билгели. Дәүләттә телләрнең күплеге, таркаулыгы, күбесенең язуы булмау (мәсәлән, Африка дәүләтләрендә) бу илләрдә рәсми өлкәдә колонизаторлар телен куллануга сәбәп була.

Шул рәвешчә, тел – иҗтимагый күренеш, ул билгеле бер җәмгыятьтә генә, кешеләр арасында гына барлыкка килә, үсә, ныгый ала; тел һәм җәмгыять үзара тыгыз мөнәсәбәттә яши.

**Телнең функцияләре**

Телнең функцияләре һәм аларның характеры турында хәзерге лингвистикада уртак фикер юк. Бу мәсьәләне кабат-кабат тикшерү нәтиҗәсендә телнең *иҗтимагый* һәм *эчке төзелеш функцияләре* аерып карала башлады.[3]

Телнең ***иҗтимагый функцияләре*** аның кешелек җәмгыятендәге роленнән килеп чыга. Бу функцияләр арасында иң мөһиме – *коммуникатив функция*, ягъни телнең кешеләр аралашуында универсаль чара булуын билгели торган функция. Бу – телнең төп функциясе. Тел ярдәмендә кешеләр бер-берсенә фикерләрен, хис-тойгыларын, эчке кичерешләрен җиткерәләр, шуның белән бер-берсенә тәэсир итәләр һәм иҗтимагый аң

[3] Гируцкий А.А. Введение в языкознание. – С.40.

формалаштыралар. Тел кешеләргә үзара аңлашырга ярдәм итә, тормышның барлык өлкәләрендә бердәм эшчәнлек оештырырга мөмкинлек бирә. Тел – кешелек җәмгыятенең яшәве һәм үсешендә төп көчләрнең берсе.

Аралашу чарасы буларак тел аерым кешегә дә, тулаем җәмгыятькә дә хезмәт итә. Тел чаралары кешеләр тарафыннан күп төрле эчтәлекне белдерү өчен кулланыла, бу эчтәлек дөрес һәм ялгыш, кызыклы һәм кызыксыз, файдалы һәм зыянлы булырга мөмкин. Тел хуҗалык, иҗтимагый-сәяси, көнкүреш, матур әдәбият, фән, уку-укыту, эш кәгазьләре башкару, хат алышу, дин һ.б. төрле аралашу өлкәләрендә файдаланыла. Телнең кулланылыш өлкәләре киңәю, аның аралашуда башкарган вазыйфалары арту халыкның, дәүләтнең иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни үсеше белән турыдан-туры бәйләнгән.

Кеше үзе генә сөйләгәндә дә (монологик сөйләм), ике яки берничә кеше сөйләшкәндә дә (диалогик яки төркем сөйләме) тел аралашу чарасы булып тора. Тел ярдәмендә аралашу әйтмә сөйләм формасында гына түгел, язмача да була ала. Ике кешенең телдән сөйләшүе – табигый аралашу юлы. Техник чаралар (радио, телевидение һ.б.) барлыкка килү белән телдән монологик аралашу киң таралыш алды, чит сөйләмне кабул итү һәм аңлау роле үсте.

Телнең икенче төп иҗтимагый функциясе – *аккумулятив функция*[4], ягъни телнең иҗтимагый тәҗрибә һәм белемнәр туплау чарасы, матди һәм рухи мәдәниятне формалаштыру һәм үстерү коралы булуын күрсәтә торган функциясе. Телдә, язма текстларда мәгълүмат туплана һәм шәхестән шәхескә, буыннан буынга тапшырыла. Бу мәгълүматта табигать законнары һәм җәмгыять турындагы белемнәр җыйнала, эстетик һәм мәдәни кыйммәтләр саклана. Кешелекнең һәр буыны үзенә мирас булып калган белемнәрне үстерә, шул рәвешчә мәдәният, фән, җитештерүчәнлек үсешен канәгатьләндерә, иҗтимагый аңны үстерә.

*Когнитив функция* – телнең эчтәлекне белдерү, тапшыру һәм саклау функциясе. Ул әйләнә-тирәдәге предмет һәм күренешләрне атауда, аларга бәя бирү мөмкинлегендә чагылыш

[4] Кайбер хезмәтләрдә аккумулятив һәм когнитив функцияләрне гносеологик (танып белү) функциясе дип тә күрсәтәләр.

таба. Когнитив функция дигәндә, җөмләнең аралашуда тапшырыла торган мәгънәсеннән тыш, аның абстракт, формаль мәгънәсен дә аера белү мөһим. Ул фикерләү нәтиҗәсен, җөмләнең конкрет эчтәлеген – мәгънәне формалаштыру һәм тапшыру чарасы булып кына хезмәт итә. Мәсәлән, *Болында печән исе аңкый* дигән җөмләдә печән турында, чабылган үләннең үзенчәлекле ис чыгаруы хакында әйтелә. Әмма бу җөмләдә субъект, урын хәле, халәт турындагы мәгънәләр дә бар, алар конкрет бер эчтәлеккә карамый, чөнки алар ярдәмендә бик күп конкрет фикерләр формалаштырырга була: *Кырда арыш исе аңкый. Урамда яңгыр ява.* Когнитив функция аерым кешеләр аралашканда гына күзәтелми, ул халыкның тел тәҗрибәсендә чагылыш таба, киләчәк буыннар өчен җәмгыять һәм табигать, фикерләү һәм тел турында төрле белемнәрне саклый. Мәсәлән, *сөңге, чикмән, киле* кебек предметлар кулланылыштан чыксалар да, аларны белдерә торган сүзләр текстларда сакланып калган.

Телнең алда әйтеп үтелгән төп иҗтимагый функцияләреннән башка, икенчел функцияләрен дә аерып карыйлар, алар телнең төп функцияләренә бәйле һәм бер-берсенә тәэсир итәләр. Тел зыялы, акыллы хәбәрләрне белдереп һәм тапшырып кына калмый, шул ук вакытта хисләрне, тойгыларны да чагылдыра. Шул җирлектә телнең *эмотив* (хис-тойгыларны белдерү), *волюнтив* (ихтыярны тапшыру) һәм *интеррогатив* (сорау) кебек өстәмә функцияләре дә барлыкка килә. *Раслау (констатацияләү) функциясе* – нинди дә булса факт турында “битараф” хәбәр итү; *экспрессив функция* – сөйләүченең кәефен һәм хисләрен чагылдыру функциясе; *контакт урнаштыру* яки *фатик функция* – әңгәмәдәшләр арасында җитди мәгълүмат тапшыру ихтыяҗы булмаган очракта (һава торышы, сәламәтлек һ.б. турында репликалар алмашу) контакт урнаштыру һәм контактны саклау функциясе; *эстетик функция* – тел ярдәмендә шәхескә эстетик тәэсир итү функциясе (әдәбият, театр, кино һ.б.); *апеллятив функция* – нинди дә булса эш-гамәлләргә чакыру, өндәү функциясе һ.б. Өстәмә функцияләр арасында билгеле бер төркем кешеләргә караганлыкны белдерә торган *индикатор (күрсәткеч) функциясе* аерым урын алып тора. Бу

функциядән аңлы рәвештә файдаланган очракта ул җәмгыятьтә шәхеснең үзенчәлекле үзбилгеләнү чарасына әверелә.

Төп функцияләргә коммуникатив, аккумулятив, когнитив функцияләр керә; өстәмә функцияләрдән экспрессив, эмотив, директив (өндәү), поэтик (эстетик), контакт урнаштыру (фатик), дейктик (күрсәтү функциясе – телнең кайбер элементларын жетслар белән берләштерү күздә тотыла), магик, суггестив (телне кеше психикасына тәэсир итү коралы итеп файдалану: гипноз, ышандыру), инструменталь, символик, уен, перформатив (сүз хәрәкәтен аңлата торган сүзләр һәм җөмләләр: *котлыйм, бәхет телим, утырышны ябык дип белдерәм* һ.б.) кебек функцияләрне атарга мөмкин.

***Эчке төзелеш функцияләре*** телнең асылын һәм табигатен чагылдыра. Гомумән, бу функцияләр турында сүз йөрткәндә, билгеле бер эчтәлекне, мәгънәне тел формалары белән белдерүне аңлыйлар. Моннан телнең мөһим функцияләреннән берсе – *фикер формалаштыру функциясе* килеп чыга, ягъни тел фикерләрне формалаштыру һәм белдерү чарасы булып хезмәт итә. Фикер тел формалары аша белдерелгәндә һәм сөйләмдә әйтелгәндә генә оеша һәм кабул ителә ала. Тел фикерне иң беренче чиратта сүз аша матдиләштерә һәм белдерә, ә сүз предметлар, күренешләр, эш-гамәлләрне атый.

Сүзнең предмет һәм күренешләрне атау сәләте тагын бер мөһим эчке төзелеш функциясен – *номинатив функция*сен билгели. Сүзнең әйберләрне атау үзенчәлеге атаманы фикер коралы итеп файдалану мөмкинлеге бирә. Әйбер атамалары фикернең тамгасына әйләнә, ә бу исә җисем (матдә) турындагы фикерләргә таянырга ярдәм итә: предметлар турында төшенчә чыгарырга, аларның үзлекләрен чагылдырырга, хөкем һәм нәтиҗә формалаштырырга булыша.

Телнең кеше фикерләве һәм аның чынбарлыкка мөнәсәбәте белән бәйле эчке структур (фикер формалаштыру һәм номинатив) функцияләреннән тыш, тел системасының төзелешенә бәйле тел берәмлекләренең функцияләрен аера белергә кирәк. Бу очракта сүз фонема, морфема һ.б. тел төзелеше берәмлекләре; ия, хәбәр, тәмамлык һ.б. функцияләре

турында сүз бара. Телнең бу функциясен *метател функциясе* дип атыйлар, ул телнең үзен тасвирлау өчен хезмәт итә.

Телнең төрле берәмлекләре тел функцияләрен үтәүдә, хәбәрне белдерү һәм тапшыруда төрлечә катнашалар. Аралашу акты телнең номинатив һәм предикатив берәмлекләре – сүз һәм җөмләләрдән башка була алмый. Коммуникатив берәмлекләрдән тыш, телдә номинатив һәм предикатив берәмлекләрне төзүдә катнаша торган төзелеш берәмлекләре дә бар. Болар – фонема һәм морфемалар, сүз формалары һәм сүзьясалыш, сүз төрләнү һәм җөмлә модельләре. Телдә алар да үзенчәлекле функцияләр үти.

Барлык тел берәмлекләре дә күрү һәм ишетү органнары ярдәмендә кабул ителә. Аларның бу үзенчәлеген *перцептив функция* дип атыйлар.

Тел берәмлекләре ниндидер башка, идеаль һәм матди әйберне белдерү һәм чикләү өчен кулланылалар. Тел берәмлекләренең белдерү һәм чикләү сәләте *сигнификатив функция* дип атала.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, телнең җәмгыятьтә үтәгән функцияләре түбәндәгеләр:

– мәгълүмати / аралашу (шәхесара һәм массакүләм аралашуда мәгълүматны тапшыру һәм кабул итү),

– танып белү / когнитив (индивид һәм җәмгыять хәтерендә белемне эшкәртү һәм саклау, дөньяның концептуаль һәм тел картинасын төзү),

– анализ / аңлату (кабул ителгән фикерләрнең / текстларның мәгънәләрен өйрәнү),

– регулятив / социатив / интерактив (аралашучыларның тел ярдәмендә бер-берсенә тәэсир итешүе һәм мәгълүмат алмашуын максат итеп куйган үзара аралашуы),

– контакт урнаштыру (коммуникатив мөнәсәбәтләрне булдыру һәм дәвам итү),

– эмоциональ-экспрессив (хис-тойгы, кичереш, кәеф һәм тирә-юньдәгеләргә мөнәсәбәт белдерү),

– эстетик (әдәби әсәрләр иҗат итү),

– магик (дини йолаларда һәм экстрасенслар тарафыннан кулланылу),

– этномәдәни (туган тел буларак бер телдә сөйләшүче билгеле бер этнос вәкилләрен берләштерү),

– метател / метасөйләм (тел һәм бу телдәге сөйләм актлары фактлары турындагы мәгълүматны тапшыру) һ.б.

Соңгы вакытларда телнең һәм тел берәмлекләренең 25 тән артык функциясен билгелиләр.

**Тел һәм фикерләү**

Фикер алышу, мәгълүмат туплау, тапшыру, саклау коралы һәм милли мәдәниятнең бер формасы буларак, тел аң һәм фикерләү белән, кешеләрнең объектив дөньяны танып белүгә юнәлдерелгән рухи эшчәнлеге белән турыдан-туры бәйләнгән.

“Аң” һәм “фикерләү” терминнарын еш кына синонимик мәгънәләрдә кулланалар. Тыгыз бердәмлек тәшкил итсәләр дә, аң һәм фикерләү тулысынча тәңгәл төшенчәләр түгел: алар үзара бәйле күренешләр, аларның өлкәләре кисешә, әмма тулысынча туры килми. *Аң* – беренчедән, кешенең интеллекты, хисләре һәм ихтыяры белән берлектә, психик эшчәнлек җыелмасы; икенчедән, теоретик һәм гамәли эшчәнлек нәтиҗәсе, кешенең, җәмгыятьнең, халыкның үз яшәешен һәм дөньяга мөнәсәбәтен аңлавы. Бу очракта идеология, тәгълимат, милли үзаң кебек махсус терминнар да кулланалар. *Фикерләү* – уйлау һәм фикер йөртү сәләте. Фикер – фикерләүнең конкрет нәтиҗәсе.

Фикерләү вербаль (телдән) һәм вербаль булмаган (телдән булмаган) төрләргә бүленә. *Вербаль булмаган* фикерләү чынбарлык тәэсирләрен кабул итү нәтиҗәсендә туган, хәтердә саклау һәм күзаллау ярдәмендә яңадан барлыкка китерелгән хисси-күрсәтмә образлар ярдәмендә тормышка ашырыла. Бу төр фикерләү күпмедер дәрәҗәдә кайбер хайваннарда да үсеш алган, менә шул хайваннарга дөрес ориентлашырга, максатчан карарлар кабул итәргә булыша. Вербаль булмаган фикерләүнең югары үсешкә ия формалары кешедә табыла. Техник характердагы иҗади биремнәр (мәсәлән, пространстводагы координация һәм механизм өлешләре белән бәйле) үтәгәндәге фикер эшчәнлеге вербаль булмаган фикерләүгә керә. Бу төр мәсьәләләрне хәл итү гадәттә эчке һәм тышкы сөйләм формаларында чагылмый. Бу – аерым бер “техник”, яки

“инженер” фикерләү. Шахматчының фикерләве шуңа якын. Хисси-күрсәтмә фикерләүнең аерым бер төре рәссам, скульптор, композиторларга хас.

*Вербаль фикерләү* сүзләрдә теркәлгән төшенчәләр, хөкем, фикри нәтиҗәләргә таяна, анализлый һәм гомумиләштерә, гипотезалар һәм теорияләр кора. Ул телдә ныгыган формаларда бирелә, тышкы һәм эчке сөйләм процессында тормышка ашырыла. Тел кешенең дөнья турындагы белемнәрен билгеле бер тәртиптә оештыра, тарката, аларны ныгыта һәм алдагы буыннарга тапшыра. Төшенчәле фикерләү икенчел, ясалма телләргә, кеше уйлап тапкан махсус аралашу системаларына да таянырга мөмкин. Мәсәлән, математик яки физик шартлы символларда теркәлгән төшенчәләр белән эш итә, сүзләр белән түгел, ә формулалар ярдәмендә фикер йөртә, шулар ярдәмендә яңа белемнәр эзләп таба.

Бу фактлар фикерләүнең күп компонентлылыгы турында сөйли, аның һәрдаим бер-берсен алыштыра торган, еш кына бергә, үзара укмашкан төрле тип фикерләү эшчәнлекләренең катлаулы җыелмасы булуын дәлилли. Вербаль (телдән) фикерләү – кеше фикерләвенең иң әһәмиятлеләреннән саналса да, ул аның нибары бер компоненты гына.

Фикер йөртү, нәтиҗәләр ясау һәм бәя бирү сәләте буларак фәндә фикерләүне образлы, техник һәм логик төрләргә бүлү дә кабул ителгән. *Образлы фикер йөртү* чынбарлыкны кабул итүнең җанлылыгын, күзаллауларның, төшенчә һәм бәяләрнең бердәмлеген күздә тота. Ул поэтик сөйләмдә, рәсем һәм сынлы сәнгатьтә, музыка һәм архитектурада, кино- һәм телефильмнарда, телеспектакльләрдә һ.б. чагылыш таба. *Техник фикерләү* образ һәм төшенчәне аларның техникадагы чагылышы белән берләштерә. *Логик фикерләү* төшенчәләр куллану һәм хөкемләү төзелеше кагыйдәләрен катгый саклауга корыла.

Тел – фикерләү чарасы һәм коралы, ул аңны, беренче чиратта, сүзләр ярдәмендә матдиләштерә һәм белдерә. Сүзләр предметларны атый һәм белемнәрне чагылдыра.

Телнең барлыкка килүе фикер әйтү зарурияте булуга бәйләнгән. Фикер үзе чынбарлыкның кеше аңында чагылышы буларак туа. Чынбарлыктагы әйберләрне, күренешләрне кеше

сизү органнары аркылы үзенчә танып белә, димәк, чынбарлыктан яңа мәгълүмат ала. Кешенең баш миендә бу яңа мәгълүматлар элек истә калганнар белән анализлана, уй йөртү тәртипкә салына, нәтиҗәдә эчке сөйләм ярдәмендә фикер формалаша һәм тышкы сөйләм ярдәмендә тыңлаучыга җиткерелә.

Димәк, тел һәм фикерләү бер-берсеннән аерым яшәмиләр. Кешенең фикерләре музыкада, рәсем сәнгатендә, формулаларда, аның эшләрендә һ.б. төрлечә белдерелсә дә, фикерләүнең универсаль чарасы бары тел генә була ала.

Фикерләү процессында сүз турыдан-туры катнаша. Ул фикерләрне чагылдыру өчен кирәк. Кеше сүзләрне кычкырып, башкаларга ишетелерлек итеп сөйләгәндә генә түгел, үзалдына уйлаганда да куллана. Сөйләмнең мондый формасы *эчке сөйләм* дип атала. Эчке сөйләм нәрсәне дә булса ятлаганда, истә калдырырга теләгәндә, нәрсәнедер әйтергә әзерләнгәндә, язганда һ.б. вакытта файдаланыла. Эчке сөйләм вакытында сөйләм органнары эшләп тора, ләкин кычкырып сөйләгәндәге кебек, кискен, киеренке хәлдә булмыйлар.

Тел кешегә конкрет күзаллаулардан абстрактлашкан фикерләүгә, гомумиләштерүгә күчәргә мөмкинлек бирә. Телнең иң характерлы үзенчәлеге итеп аның гомумиләштерү үзенчәлеген күрсәтәләр. Гомумиләштерү һәр сүздә чагыла. Теге яки бу предметны атаганда, аерым бер предмет кына түгел, бу предмет кергән бөтен бер төркемне күздә тотыла. Телнең бу үзенчәлеге фикерләү өчен аеруча әһәмиятле, чөнки ул аерым предметларны, күренешләрне танып белүдән аларның төшенчәләр формасында гомумиләштерелгән чагылышына күчәргә мөмкинлек бирә.

Тел һәм фикерләү аерылгысыз бәйләнгән, әмма аларны тәңгәлләштерергә дә, бер-берсеннән аерырга да ярамый. Фикерләүнең камилләшүе, үсеше, яңа төшенчәләрне белдерү өчен, үзенә тәңгәл формалар таләп итә. Шул ук вакытта фикерләүнең дә алга таба үсеше телдән башка мөмкин булмас иде. Фикерләү белән тел тыгыз бәйләнештә яши: фикерләү никадәр төзегрәк булса, аның телдә белдерелүе дә шулкадәр төгәлрәк була һәм, киресенчә, фикер никадәр ачыграк белдерелсә, ул шулкадәр тулырак, төгәлрәк аңлашыла да.

***Тел һәм логика нисбәте***

Антик дөньяда ук кешенең фикерләү формаларын һәм законнарын өйрәнә торган фән – *логика* (мантыйк) барлыкка килгән. Шул заманнарда ук фикерләүнең күзаллаулар (представления), төшенчәләр (понятия), хөкемләү (суждение), уйлау нәтиҗәләре (умозаключения) аркылы объектив чынбарлыкны чагылдыру икәнен аңларга тырышканнар. Фикерләүнең төп берәмлеге – хөкемләү; хөкемләүнең төп өлешләре – субъект, предикат һәм бәйләгеч (связь) булуын ачыклаганнар. Ләкин башта әле фикерләү белән телне (сөйләмне) аерып карый белмәгәннәр. Шул чорда логика эчендә *синтаксис* дигән фән туган. Синтаксик берәмлекләр дә турыдан-туры логикадан чыгып билгеләнгәннәр; хәтта башта алар фикерләү берәмлекләренең исемнәре белән аталып йөртелгәннәр.

Телнең фикерләү белән бәйләнешен, логик берәмлекләрнең тел берәмлекләренә нисбәтен, бер-берсе белән тәңгәл килү-килмәүләрен төрле яссылыкта күзәтергә була.

*I яссылык* – сөйләм (тел) белән фикерләү яссылыгы. Болар арасында форма белән эчтәлек арасындагы кебек бәйләнеш ята. Җәмгыятьтә фикерләү эчке һәм тышкы сөйләмнән башка булмый, башкаларга фикер әйтү, алардан фикер алу, шул юл белән фикерне тагын да үстерү сөйләм аркылы тормышка ашырыла. Фикер әйтергә кирәклектән сөйләм оеша, димәк, сөйләм фикерләүне формалаштыра һәм аралашу процессында шул фикерне тыңлаучыга җиткерә. Әмма сөйләм фикерләү түгел, фикерләү сөйләм түгел; шул ук вакытта сөйләм фикерләүдән башка, фикерләү сөйләмнән башка яши алмый.

*II ясылык* – җөмлә белән хөкемләү яссылыгы. Хөкемләү нәрсәнеңдер булу-булмавын раслый, ягъни анда нәрсә дә булса раслана яки инкарь ителә. Хөкемләү һәрвакыт җөмлә белән бирелә, ләкин барлык җөмләләр дә хөкемләүне тулы килеш бирә дип әйтеп булмый. Мәсәлән, хикәя җөмләләр һәрвакыт хөкемләүгә туры килә, ә сорау һәм боеру җөмләләр күбрәк хөкемләүне әзерләүдә яки аны дәвам иттерүдә катнаша. Бу яссылыкта сөйләм һәм фикерләүнең үзләренә генә хас үзенчәлекләре арта бару күзәтелә.

*III яссылык* – субъект һәм ия, предикат һәм хәбәр яссылыгы. Субъект – аның турында нииндидер яңалык әйтү өчен алынган төшенчә. Предикат – алынган төшенчә турында әйтелгән яңалык. Алар, икесе бәйләнешкә кереп, алынган төшенчәдә ниндидер билгенең булу-булмавын хәбәр итәләр. Кайбер очракларда субъект – ия яки ия төркеме белән (җәенке җөмләдә), ә предикат хәбәр яки хәбәр төркеме белән бирелә. *1) Көн салкын. 2) Мәктәп укучылары спортзалга җыелдылар.* Бу хөкемләүләрдә һәм җөмләләрдә субъект (S) *көн* һәм *мәктәп укучылары*, ә ияләр – *көн* һәм *укучылар*; предикат (P) *эссе* һәм *спортзалга җыелдылар*, ә хәбәр – *эссе* һәм *җыелдылар*. Беренче мисалда логик һәм синтаксик берәмлекләр ныграк туры килә, икенчесендә синтаксик берәмлекләр логик берәмлекләрнең үзәгендә генә торалар.

Димәк, сөйләм белән фикерләү бер үк нәрсәләр түгел, аларның үзләренә генә хас үзенчәлекләре, төзелешләре һәм закончалыклары бар. Шуңа күрә аларның икесен ике фән – логика һәм синтаксис өйрәнә.

*IV яссылык.* Телнең төп берәмлекләреннән берсе булган *сүз* һәм ул белдергән *төшенчә* (логик категория) арасында да катлаулы бәйләнеш бар. *Төшенчә* – чынбарлыктагы предметларның, күренешләрнең гомуми һәм әһәмиятле билгеләрен чагылдыра торган фикерләү берәмлеге. Төшенчәләр барлык халыклар өчен дә уртак, әмма алар милли характерга ия булган сүзләр аша биреләләр. Төшенчә сүздә генә яши. Сүзнең төп функцияләреннән берсе – төшенчә белдерү. Әмма сүзнең мәгънәсен төшенчә белән тиңләштерергә ярамый. Сүзнең мәгънәсе төшенчә мәгънәсеннән ярлырак була. Билгеле бер тел коллективының тел практикасында кабул ителгән төшенчәнең бер өлеше генә сүздә чагылыш таба. Төшенчәне *эчтәлекле* һәм *формаль* төрләргә бүлеп карыйлар. Эчтәлекле төшенчә кешенең теге яки бу предмет турында бөтен белгәнен үз эченә ала. Ул кешенең белеменә, тормыш тәҗрибәсенә, профессиясенә һ.б. бәйле була. Формаль төшенчәләр шушы тел коллективы өчен бертөсле, аларда предметларны, билгеләрне аера торган иң характерлы билгеләр генә чагыла.

Шул рәвешчә, тел һәм фикерләү аерылгысыз, әмма алар тулысынча тәңгәл килми. Бу төрле халыкларда логик фикерләү төзелешенең бердәй булып та, дөньядагы телләрнең бер-берсеннән шактый аерылуында чагыла.

Төп логик категорияләр барлык халыклар өчен дә уртак. Телдә, аның сүзлек составында матди дөнья кисәкләргә (предметлар, эш-хәрәкәтләр, үзлекләр, билгеләр һ.б.) бүлгәләнгән хәлдә чагылыш таба. Бу – барлык телләр өчен дә уртак сыйфат. Төрле телләрнең күпчелек сүзләре бер үк күренеш, предмет һ.б чагылышы булып торалар. Шуңа күрә алар төрле телләрдә төрлечә яңгырасалар да, үзләренең эчтәлеге (мәгънәсе) белән туры киләләр.

Ләкин дөньяны танып-белү һәм телдә чагылдыру процессында күпмедер милли үзенчәлекләр дә була. Халыкның дөньяны танып белүе фәнни түгел, ә якынча танып-белү, ул көнкүреш ихтыяҗларын гына канәгатьләндерә. Этнографларның күпсанлы тикшеренүләре шуны күрсәтә: күп кенә халыкларда теге яки бу шөгыль, климат шартлары белән бәйле киң тармаклы һәм төгәл лексика яши. Мәсәлән, Скандинавия халыкларында *диңгез* һәм *балык тоту*га бәйле лексик катлам зур. Гарәпләрдә *дөя, ат, салкын корал* атамаларының бай синонимик рәте бар. Төньякта яшәүче халыкларның телләрендә *боз, кар, эрү* һ.б. төшенчәләрне белдерә торган сүзләр аеруча күп.

Бу үзенчәлекләр халыкның тормыш-көнкүреш шартлары һәм аерым предмет-күренешләрнең хуҗалыкта тоткан роленә бәйле. Еш кына бер җәмгыятьтә яшәүче һөнәрчелек вәкилләре лексикасында да шундый тар специализация чагылыш таба.

Әмма телнең фикерләүгә һәм кешенең үз-үзен тотышына тәэсире чикле. Тел кешенең тормыш турында күзаллауларын билгели алмый, чөнки ул үзе фикерләү коралы. Төрле телләрдә сөйләшүче халыклар бер үк ситуацияләрдә үзләрен бертөрле тоталар. Мәсәлән, яңгыр ява башлагач күпчелек кешеләр ышыкка кача яки зонтикларын ача; салкыннан саклану өчен җылы киемнәр кию дә барлык кешеләргә хас һ.б.

Шулай да фикернең характеры, аның тирәнлеге, чынбарлыкны танып белү һәм чагылдыру мөмкинлеге турыдан-туры телгә бәйле. Барлык халыкларга да хезмәт итә торган

гомум бер тел юк. Телләр бик күп һәм төрле, шуңа күрә тел ярдәмендә чынбарлыкны танып-белү һәм аны телдә чагылдыру милли характерда була. Һәр телнең үз төзелеше, анда дөньяны кисәкләргә бүлгәләү дә үзенчәрәк булырга мөмкин. Кардәш телләр бу яктан охшашрак. Кардәшлек ерагайган саен телләрдә дөнья сурәтенең чагылышы да аерыла бара.

**Тел һәм сөйләм**

Кеше теле аерым телләр (рус, инглиз, кытай, татар һ.б.) рәвешендә яши. Ә һәр аерым тел бөтен барлыгы белән шушы телнең хуҗалары аңында гына яши.

Инде әйтелгәнчә, тел кешегә тумыштан бирелми, нәселдән-нәселгә мирас булып күчми. “Туган тел” дигән термин “тумыштан” дигәнне түгел, бәлки “кечкенәдән үзләштерелгән” булуны гына аңлата. Тел кеше аңына “читтән” үтеп керә, чөнки бу телдә аның әйләнә-тирәсендәгеләр аралаша. Шулар үрнәгендә кеше кечкенәдән билгеле бер телдә сөйләшә башлый. Кеше нинди дә булса берәр сәбәп белән әлеге телдән файдаланмаса, тел акрынлап онытыла, ахыр чиктә хәтердән бөтенләй юкка чыга. Димәк, тел аннан файдаланганда гына яши дигән сүз. Тел кулланылышта булганда гына тере тел булып яши ала. Ә телнең кулланылышы сөйләм дип атала.

Гәрчә физиологларның һәм психологларның сөйләм белән генә эш итүе билгеле булса да, педагогикада балаларның сөйләм телен үстерү турында фикер йөртелсә дә, медицинада сөйләм кимчелекләрен төзәтү һ.б. белән шөгыльләнсәләр дә, тел һәм сөйләм төшенчәләрен еш кына бутыйлар. Алда атап үтелгән очракларда “сөйләм”не “тел” белән алыштырып булмый, чөнки сүз психофизиологик процесс турында бара. Ә тел белеме күзлегеннән сөйләм һәм тел нисбәтен ачыклау тагын да кыенрак.

*Тел* термины белән телнең төзелешен дә, әдәби телне дә, аерым бер кеше телен дә (мәсәлән, Пушкин теле, Тукай теле) атыйлар. Бу билгеле бер дәрәҗәдә дөрес тә, чөнки тел – катлаулы күренеш, ул иҗтимагый һәм шәхси кулланылыштан башка яши алмый. “Сөйләм”не “тел”гә каршы куеп, сөйләм күнекмәләрен, сөйләм актын, сөйләм нәтиҗәсе – текстны һәм хәтта сөйләм эшчәнлеген гомумиләштереп *сөйләм* дип йөртәләр.

“Тел” һәм “сөйләм” төшенчәләрен беренче мәртәбә швейцар галиме Ф. де Соссюр (1857-1913) аерып карый. Соңрак алар бездә Л.В. Щерба (1880-1944) һәм аның шәкертләре тарафыннан тирәнрәк эшкәртелә. “Сөйләм” дигәндә хәзерге тел белемендә телдән сөйләм генә түгел, ә язма сөйләм дә аңлашыла. Киң мәгънәсендә “сөйләм” төшенчәсе “эчке сөйләм”не, ягъни тел чаралары ярдәмендә үз эчеңнән, тышка чыгармыйча гына фикер йөртүне дә күздә тота.

*Тел* төп төшенчә буларак саналырга хаклы. Ул кешеләр аралашуында иң әһәмиятле чара. Тел – билгеле бер коллективның иҗат җимеше һәм тарихи күренеш. Ул билгеле бер вакыт аралыгындагы барлык сөйләш һәм диалектларны, телдән һәм язма сөйләм формаларын берләштерә. Аерым бер кеше теле булмый һәм аны бер генә кеше уйлап чыгара да алмый, чөнки ул гомуми телдән төрлечә файдалана торган бик күп кешеләрне һәм төрле төркемнәрне туплый. Шуңа күрә элек һәм хәзерге көндә инглиз, француз, кытай, гарәп телләре һ.б. яшәгән һәм яши; шул рәвешчә хәзерге татар теле, иске татар теле, борынгы төрки тел турында да әйтергә була.

*Сөйләм* белән эш катлаулырак тора. Ул тел дә, аерым сөйләм акты гына да түгел. Телдән һәм язма сөйләм, бала, укучы, яшьләр сөйләме, сәхнә сөйләме диләр, туры һәм кыек сөйләмнәр, эшлекле сөйләм, монологик һәм диалогик сөйләмнәр һ.б. аерылып карала. Болар барысы да – телне куллану мөмкинлекләре, телне төрле аралашу ситуацияләрендә куллану формалары. Һәм болар тел белеменең предметын тәшкил итә.

Тел – аралашу коралы, сөйләм – аралашу ысулы, димәк, сөйләм – телнең хәрәкәттәге формасы. Сөйләм – телнең кулланылышы дигән сүз. Шулай булгач, аралашу чарасы булган тел нәрсәдән торса, сөйләмдә шул (телнең төрле берәмлекләре һәм аларның бәйләнеш кагыйдәләре) чагыла. Сөйләм тел белән чагыштырганда, үзгәрүчәнрәк, хәрәкәтчәнрәк. Яңа күренешләр башта сөйләмдә барлыкка килә, аннан телгә күчәләр.

Сөйләмне турыдан-туры күзәтергә мөмкин. Тел белән танышу нәкь менә сөйләмнән башлана. Сөйләмнең төзелү шартларын тикшергәндә, аның сөйләүчедән тыңлаучыга хәрәкәтен дөрес итеп күз алдына китерергә кирәк. Аралашу

процессында сөйләүче һәм тыңлаучы әледән-әле рольләрен алмашып торалар. Язмача аралашканда сөйләм язу һәм язганны укудан (күз ярдәмендә кабул итү һәм уку) гыйбарәт, бу очракта аралашучылар вакыт һәм урын ягыннан бер-берсеннән ерак булырга да мөмкин.

М.З. Зәкиев тел һәм сөйләм мөнәсәбәтен түбәндәгечә күрсәтә: “Тел – үзенең билгеле бер күләмдәге сүзлек байлыгы, фонетик составы һәм грамматик кагыйдәләре, калыплары белән аралашу өчен әзер тора торган корал. Шул корал (тел) хәрәкәткә килдеме, ягъни ул телдә сөйли башладылармы – без анысын инде сөйләм дибез. Сөйләм ул – аралашу ысулы”. Димәк, тел һәм сөйләм икесе ике күренеш түгел, ә бер үк күренешнең төрлечә чагылышы гына.

Телдән файдалану өчен иң элек аны белергә кирәк, ә бу исә тәрбия һәм өйрәтү нәтиҗәсе, аны шулай ук башкаларның сөйләмен күзәтеп тә камилләштерергә була. Телнең байлыгын үзләштерү – туктаусыз, өзлексез процесс. Телне үзләштерү – билгеле бер белемнәр, күнекмәләр кабул итү, кешенең телгә сәләтен тәрбияләү дигән сүз. Телне үзләштерү һәм аны куллану сайланма характерга ия. Бигрәк тә тел берәмлекләренең модельләрен, сүзләрнең ярашу һәм үзгәрү кагыйдәләрен, гомухалык лексикасы сүзләрен белү мәҗбүри. Әйтелеш вариантлары, сүзтезмәләр һәм сүзләр тезмәсе, синонимнарны сайлауга килгәндә исә, сөйләм эшчәнлегенең бу ягы бик үк зарури түгел, аларда кайбер тайпылышлар да булырга мөмкин. Шунлыктан сөйләм эшчәнлеге тел системасын гадәти рәвештә куллану гына түгел, бәлки сөйләүченең аны актив рәвештә файдалануы дигән сүз.

***Тел һәм сөйләмнең гомуми билгеләре һәм сыйфатлары***

*Тел:*

1. Аралашу коралы.
2. Фикер формалаштыру һәм белдерү чарасы.
3. Чынбарлыкны чагылдыру һәм танып белү ысулы.
4. Телнең структур берәмлекләре: авазлар, сүзләр, грамматика, мәгънәләр һ.б.
5. Тел берәмлекләренең күпмәгънәлелеге.

6. Әйтмә һәм язма формалар.

7. Әдәби нормалашканлылык һәм стильләргә бүленү.

8. Тарихи процесста чагыштырмача тотрыклылык / үзгәрүчәнлек.

Телнең төп формалары: гомумкешелек теле; этник коллектив теле; индивид теле.

Кешелек аңының гаҗәеп казанышы булган телдән башка аралашу да, әйләнә-тирәне танып белү дә булмас иде. Тел – теләсә кайсы җәмгыятьнең яшәү шарты. Көндәлек тормышта кешеләр телнең нәрсә икәнлеге турында уйланмыйлар. Телгә бирелгән билгеләмәләр күпсанлы, кагыйдә буларак, алар телнең теге яки бу функциясен ассызыклыйлар, шулай ук аның төрле сыйфатларын аерып күрсәтәләр. Телнең функцияләре – аның төп, асыл билгеләре, тел нәкъ менә шуларны башкару, үтәү өчен яши дә. Телнең гомуми иҗтимагый һәм хосусый (өстәмә) функцияләрен аерып карыйлар.

*Сөйләм.*

Аралашу ике яки берничә кеше арасында бара торган сөйләм актыннан гыйбарәт. Аралашу төрләрен түбәндәгечә төркемләргә мөмкин:

- аралашу темасы буенча: сәяси, фәнни, көнкүреш, дини, укыту-педагогик һ.б.
- максаты буенча: эшлекле һәм күңел ачу;
- рәсмилек дәрәҗәсенә карап: рәсми һәм рәсми булмаган;
- формасына карап: ачык, ябык, катнаш;
- әңгәмәдәшне сайлауга мөнәсәбәттә: инициативалы (ихтыяри) һәм мәҗбүри;
- форма һәм эчтәлек нисбәтенә карап: туры һәм кыек (Тәрәзәне ябыгыз. Салкынайтып җибәрде).

Кешенең сөйләм эшчәнлеге – әйләнә-тирәдәгеләр күз алдында әлеге кешенең билгеле бер образын тудыра торган элементлар: сөйләү рәвеше, кулланылган сүзләре, интонация, жестлары, яраткан гыйбарәләре, риторик алымнары һ.б. Бу образны икенче төрле *кешенең тел паспорты* дип йөртәләр. Тел паспорты кеше турында бик күп мәгълүмат бирә: туган төбәге, яше, эмоциональлеге, грамоталылыгы, укымышлылыгы һ.б. Кешенең тел паспорты буенча аның гомумкультуралылык,

тәрбиялелек дәрәҗәсе турында фикер йөртергә, хәтта якынча кайда эшләвен дә чамаларга була. Язу (почерк) биргән мәгълүматлар да тел паспортына керә. Почерклар буенча кешенең характерын өйрәнү белән *графология* шөгыльләнә.

***Телдән һәм язма сөйләм төрләре***[5]

Сөйләм нәтиҗәсендә текст барлыкка килә, ул нинди дә булса сөйләм материалында ниндидер сөйләм коралы белән башкарыла. *Сөйләм материалы* дип сөйләм текстын үзенә алган предметларны әйтәләр – боларга һава (әгәр текст телдән төзелсә), балчык яки балавыз такта, папирус, пергамент, кәгазь, электромагнит тасма һ.б. керә. Текст бу материалларда *сөйләм кораллары* (әйтү органнары, язу әсбаплары, басу кораллары, электрон җайланмалар) ярдәмендә барлыкка килә. Сөйләмне нинди сөйләм материалында барлыкка килүенә һәм нинди кораллар белән башкарылуына карап төркемлиләр: телдән (әйтмә), язма һәм әйтмә-язма сөйләм төрләрен аерып карыйлар.

Телдән сөйләм текстлары һава кисәкчәләренең тирбәнешләре буларак яши, аларны ишетү органнары тотып ала һәм сөйләм сигналы буларак кабул итә; бу тирбәнешләр кешенең артикуляция аппаратын барлыкка китерә. Әгәр сөйләм ишетү буенча язып алынса, башка материал (кәгазь яки башка язу материалы) кулланырга кирәк була: бу очракта ул икенче сөйләм төренә күчә. Язганда магнитофон кулланылса, сөйләм магнитлы тасмага теркәлә һәм массакүләм коммуникация тексты оеша.

Яңа сөйләм төрен уйлап чыгару шактый кыен, кешелек бүген яши торганнарын да бик авырлык белән барлыкка китергән. Кешеләр язарга өйрәнеп, *язма сөйләм* барлыкка килгәнче дә күп меңнәрчә еллар үткән. Бары XX, гасырда радио, кино, магнитофон, телевизор һәм компьютерлар пәйда булгач кына, *массакүләм коммуникация*не формалаштырган *әйтмә-язма сөйләм* дип аталган катлаулы сөйләм төре оешкан.

Сөйләмнең төрле төрләре мәгънә-эчтәлек белдерүдә төрле мөмкинлекләргә ия. Телдән сөйләм әйтүгә юкка чыга: ул бары әйтү моментында гына яши, шунлыктан аны кешедән аерып

[5] Ю.В.Рождественский, А.В.Блинов. Введение в языкознание. – С.25-36.

карап булмый һәм телдән сөйләм текстын саклау мөмкинлеге дә хәтергә генә бәйле.

Язма сөйләм текстларын исә язучы һәм укучыдан аерырга һәм кешедән читтә озак вакытлар сакларга мөмкин. Алар теләсә нинди әйбер кебек саклана, аларны кирәк вакытта яңадан укып була, истә калдыру да мәҗбүри түгел.

Массакүләм коммуникация текстларында тиз, оператив файдалану (телдән сөйләм кебек) һәм озак вакытлар саклану (язма сөйләм кебек) сыйфатлары берләшә.

Текст озак саклана икән, димәк, андагы мәгълүматның кешеләргә теләсә кайчан кирәге чыгарга мөмкин һәм аларның эчтәлеге, гадәттә, әһәмиятле һәм кирәкле була. Сакланмый торган текстлар шул моментта гына актуаль, аларда конкрет очракларга бәйле аерым фикерләр генә була. Сөйләм текстларын шул рәвешчә аеру мәдәният өчен гаять мөһим, чөнки аңа бары тик мәңгелек кыйммәте булган сөйләм текстлары гына керә.

Телдән (әйтмә), язма һәм әйтмә-язма сөйләм үз эчләрендә тагын да вграк төрләргә аерылалар.

***Әйтмә һәм язма сөйләмнең үзенчәлекләре***

Язма һәм әйтмә сөйләм вакыт ягыннан хәрәкәтләре белән аерылып торалар. Язма сөйләмне күзәтеп була: график тамгалар ярдәмендә барлыкка китерелгән текстны тулаем күрү мөмкинлеге бар; ә авазлар әйтүгә үк югалалар, шунлыктан сөйләмә текстны яңгыраш элементлары аша гына кабул итеп була. Әйтмә сөйләмнән аермалы буларак, язма сөйләмне барлыкка китерү тизлеге кабул итү темпына туры килми.

Кулдан башкарылган текстларның вакытка бәйле икенче бер аермасы – аны бер үк кеше яки күпләр яңадан уку өчен файдалана алалар, аларны куллану вакыты чикләнмәгән. Шунлыктан мондый сөйләм, әйтмә формадан аермалы буларак, язучы (автор) түгел, бәлки укучы сайлап алган, теләгән вакытта укыла ала. Бер үк текстка кабат-кабат мөрәҗәгать итә алу мөмкинлеге аның эчтәлеген аңлауны тирәнәйтә; моның өстенә, бер үк кеше текстны берничә кат укый торгач, аны төрлечә аңлый, шәрехли башлый.

Кулдан язылган сөйләм билгеле бер кул күнекмәләрен таләп итә. Кулдан язу – үзенчәлекле бер һөнәр; өйрәнү барышында хәрефләрне эзлекле рәвештә язу күнекмәләре формалаша. Язуга өйрәнгән кеше грамоталы кеше дип санала.

Аралашуның күрү һәм ишетү-әйтү каналларын файдаланган хәлдә, язма сөйләм язуга кадәр булган мәдәният формаларына өстәмә чара булып кына калмый, бәлки аларны алыштыра да. Мәсәлән, сынамышларны җыеп язуда теркәү табигый тормыш картинасын тудыра; төрле әйберләр ярдәмендә генә түгел, ә тексттагы язу тамгаларының комбинацияләре буенча да багарга мөмкин; музыканы да язу тамгалары аша биреп була; гореф-гадәтләргә бәйле гамәлләр яки уеннар, язма сценарий рәвешенә кергәч, театрга әйләнә. Шулай итеп, язу барлыкка килгәч, тел мәдәниятнең барлык башлангыч формаларын мәгънәви яктан алыштыра башлый, аларның тамга атамасына әверелә.

Әйтмә сөйләм музыка (җырлау) белән тулыланырга мөмкин, ә язма сөйләм төрле графика, рәсемнәр, таблица һ.б. белән баетыла ала. Язма сөйләмдә рекомбинация ясау, аерым график элементларның урынын алмаштыру, язу тамгаларын икенче конфигурацияләрдә бирү (*а* – а – *А* – А), график сүздә хәрефләрнең эзлеклелеген үзгәртү мөмкин; хәтта аерым сүзне аерым хәреф символлары белән биреп була: % (процент), & (нем .und), + (кушу) һ.б.

Әйтмә сөйләмдә басым һәм интонация сүзләрне аерып билгеләү өчен кулланыла, ә язма сөйләмдә бу график рәвештә башкарыла: хәрефләрнең кеглен (тамганың зурлыгын, күләмен), авышлыкны (курсив), калынлыкны үзгәртү, төрле сызыклар (дулкынлы, туры, өзек-өзек, ике катлы сызык, штрихлар) тыныш билгеләре ярдәменә аерымлана.

Әйтмә сөйләмнән аермалы буларак, язма сөйләмне чикләнмәгән ераклыктагы араларга тапшырырга була, ул озак вакытлар саклана. Барлыкка китерелүгә язу “хуҗасыннан” читләшә һәм хезмәт продукты кебек яши, кешедән-кешегә тапшырыла, саклана башлый. Бу тел коммуникациясенең структурасын үзгәртә: текстның бер нөсхәсе (күчереп язмыйча да) күп санлы укучылар аша үтә ала.

Саклана алганлыктан, язма сөйләм кешенең һәм җәмгыятьнең хәтерен үзгәртеп кора: элек бик күп белемнәрне хәтердә (баштa) сакларга кирәк булса, язу барлыкка килгәч, ул ихтыяҗ кими, белемнәрне текст рәвешендә теркәп, кирәк булганчыга кадәр читкә алып куярга мөмкинлек туа. Икенче төрле әйткәндә, аерым кеше хәтеренә караганда күбрәк белемнәрне туплаган текстларны җыю мөмкинлеге барлыкка килә.

Язма текстларны күп тапкырлар күчереп язарга, кабатларга мөмкин, ә әйтмә сөйләм текстлары белән моны эшләп булмый, чөнки кешенең хәтере чикле.

Язма текст авторы һәм аны кабул итүченең аудиовизуаль контактлардан тыш аралаша алуы мондый текстларның автордан читтә дә яшәү мөмкинлеген күрсәтә. Араларында төрле вакыт һәм урын аермасы яткан кешеләр дә язу ярдәмендә җиңел аралаша. Бу, барыннан да элек, телнең төрле җиргә сибелеп яшәгән кабилә һәм халыкларны берләштерү, бердәм идарә системасына туплау мөмкинлеген күрсәтә: язу уйлап табылу дәүләтләр барлыкка килүгә этәргеч бирә.

### *Телдән (әйтмә) сөйләм төрләре*

Телдән сөйләм төрләре җәмгыятьнең телдән сөйләм мәдәниятен тәшкил итә, ул язуга хәтле булган (фольклор, имеш-мимешләр, диалог) һәм әдәби әйтмә сөйләмнән (ораторика һәм гомилетика) гыйбарәт. Язуга кадәр уйлап табылган әйтмә сөйләм төрләренә җәмгыятьтә мөнәсәбәт төрле. Алар язып алынмыйлар, чөнки җәмгыять кануннары буенча һәрбер текст язылырга тиеш дигән кагыйдә юк. Әдәби әйтмә сөйләм язылып та алынырга мөмкин, әмма язылмау ихтималы да зур. Дөрес, техник яктан караганда теләсә нинди әйтмә текст теркәлә ала, әмма кайбер очракларда җәмгыять моны эшләүне тыя. Аерым диалоглар, имеш-мимешләр язылырга тиеш түгел, ә менә фольклор текстлары, фәнни максатлардан чыгып, соңгы вакытларда теркәлә башлады.

*Фольклор* текстларында мәңгелек хакыйкать, алар яттан күп тапкырлар кабатлауны күздә тота: әкиятләр, мәкальләр, халык җырлары, мәсәлләр, тизәйткечләр һ.б. шундыйлардан. Аларны бер үк аудитория алдында да күп мәртәбә кабатларга мөмкин,

тыңлаучылар моңа каршы килми, хәтта инде яхшы белсәләр дә, халык акылын кабат тыңлаудан баш тартмыйлар. Фольклор текстлары гомуми фикерләрне берләштерү сыйфатына ия, аларда конкрет бер кеше күздә тотылмый. Димәк, аларда һәркемгә кирәкле белемнәр тупланган була. Фольклор – җәмгыятьнең мәдәни байлыгына керә, шунлыктан аларны киләчәк буыннар өчен саклау мөһим.

*Имеш-мимеш*ләрдә текст чылбыр буенча кешедән-кешегә тапшырыла, ягъни һәрвакыт аерым аудитория алдында әйтелә. Шунлыктан мондый текстлар бер генә тапкыр кабул ителә, бер үк кешегә шул ук имеш-мимешне ике кат әйтү кирәк түгел. Имеш-мимешнең эчтәлеге билгеле бер вакыт аралыгына караган проблемага юнәлтелә, аларда хакыйкать юк, бары тик агымдагы мөһим мәгълүмат кына бар, кирәге беткәч, ул юкка чыга. Имеш-мимешләр иҗтимагый мәдәнияткә карамый.

*Диалог*ларга алдагы эш-гамәлләр турында фикерләр салына. Бу текстлар кабатланмый, алар диалогта катнашучыларга гына мәгълүм була, чакырылмаган кешеләр диалогны тыңларга тиеш түгел. Шул рәвешчә, диалог билгеле бер аралашучыларның булуын таләп итә һәм диалогның эчтәлеге алар арасыннан чыкмаска тиеш. Кайбер диалогларны иҗтимагый мәдәният дип санарга мөмкин.

Язу пәйда булгач, халык алдында әйтмә әдәби сөйләм белән чыгыш ясаулар барлыкка килә. Аның төп төрләре – ораторика һәм гомилетика.

*Ораторика* – билгеле бер аудиториягә юнәлгән сөйләм, ул аерым темага багышланмый, бер генә тапкыр сөйләнә. Башкача әйткәндә, аны кешеләр ике тапкыр тыңларга риза түгел. Ул үзе өч төрле була:

- *судтагы сөйләм* – анда һәрвакыт үткәндәге хәлләр тикшерелә;

- *күрсәтмә чыгыш* – үткән киләчәк белән бәйләп бирелгән сөйләм. Бу – үткәннәрне сурәтләү, аларга бәйләп киләчәккә теләкләр теләү. Мондый сөйләмне, гадәттә, төрле тантаналарда, кемне дә булса мактаганда яисә яманлаганда һ.б. ишетергә мөмкин;

- *фикер алышу* – күпчелек очракта киләчәккә юнәлтелә. Кешеләр киләчәктә нәрсә эшләргә кирәклеге турында киңәшләшәләр, үткәндә булганнар хакында фикер йөртәләр.

*Гомилетика* – оратор күп тапкырлар бер үк аудитория каршында бер зур тема буенча чыгыш ясагандагы сөйләм. Шулай ук өч төре бар:

- *нәсыйхәт* (вәгазь) – булган белемнәрне искә төшерү, яңарту һәм ныгытуга юнәлтелә. Нәсыйхәтче аудиториягә алдан таныш булган хакыйкатьне аңлатырга һәм киңрәк итеп ачарга тиеш. Шуңа күрә мондый сөйләм яңалык алып килми, бары элеккеләр нигезендә тыңлаучыларны рухи яктан, гомуми идеяләр ярдәмендә берләштерү максатына хезмәт итә;
- *уку-укыту сөйләме* – тыңлаучыларга яңа белемнәр алып килә. Мисал өчен, лекцияләрдә укытучы укучыларга акрынлап үз предметының эчтәлеген ача;
- *пропаганда* – агымдагы конкрет вакыйгаларга багышлана. Мондый чыгышта аудиториягә билгеле булмаган мәгълүматлар хәбәр ителә (уку-укыту сөйләмендәге кебек) һәм яңача гомумиләштерә (нәсыйхәттәге кебек).

Ораторика һәм гомилетика арасында төп аерма шунда: ораторика теге яки бу ситуация һәм әлеге ситуациядәге эш-гамәлләр хакында турыдан-туры белемнәр бирә; ә гомилетика эш-гамәлләргә сәләтне үстерүгә хезмәт итә. Эчтәлеге ягыннан караганда, ораторика объектив: ул эшләрне хәл итә, аңга юнәлтелә; гомилетика субъектив: ул шәхес формалаштыра, кешенең рухи дөньясына, күңеленә тәэсир итә.

Ораторика һәм гомилетика ике шартны үтәгәндә иҗтимагый мәдәният булып санала ала: беренчедән, мондый сөйләм текстлары язма формага күчерелергә, ягъни язып алынган булырга тиеш; икенчедән, бу язмаларның әдәбиятка әйләнгән булуы зарур.

***Язма сөйләм төрләре***

Язма сөйләмнең үзенә генә хас психологик, иҗтимагый һәм оператив мөмкинлекләре бар.

Язуның психологик сыйфатлары:

- күзәтү (күрү) мөмкинлеге;

- текстка кабат мөрәҗәгать итү мөмкинлеге;

- кул хәрәкәте күнекмәләре кирәк булу.

Язуның оператив сыйфатлары:

- техник фәннәр графикасы белән кушылу мөмкинлеге;

- хәреф һәм авазларны рекомбинацияләү (аеру) мөмкинлеге;

- сөйләмнең мәгънәви яктан әһәмияле булган өлешләрен график аерып күрсәтеп булу.

Язуның иҗтимагый сыйфатлары:

- текстларның саклануչанлыгы;

- текстларны яңадан кабатлый алу;

- текстларның автордан читтә яши алуы.

Язма сөйләмнең *эпиграфика, сфрагистика, нумизматика, палеография* һәм *неография* кебек формалары бар. Эпиграфика, сфрагистика, нумизматика кебек язма сөйләмнәр нинди дә булса матди предметларга бәйләнгән, алар матди мәдәният әйберләренә, документлар һәм акчаларга төшерелгән язулар. Палеография – язу материалларындагы язмалар, алар әйберләр белән бәйле түгел. Эпиграфика һәм палеография текстлары аерым хәрефләр белән эзлекле рәвештә языла; сфрагистика һәм нумизматикада текст бөтен килеш сугыла.

*Эпиграфика*га мөнәсәбәтле текстларда язу текстлары язу материалы булмаган әйберләргә (таш плитәләр, металл әйберләр, балчык эшләнмәләр һ.б.) төшерелә, аларда әйберне җитештерүче, хуҗасы, файдалану ысулы күрсәтелергә мөмкин, кайчак кайбер эш-гамәлләр буенча киңәшләр яки тыюлар да чагылыш таба.

*Сфрагистик* язмалар шәхси ышанмаклык тамгаларының (документларга куела торган мөһерләр һәм штамплар) бер өлешен тәшкил итә. Текст юридик затны атый һәм шуның белән кул куелган документның аңа нисбәтле икәнен дәлилли.

*Нумизматик* язма текстлар бәһа тамгалары һәм регалияләрнең бер компонентыннан гыйбарәт. Болар – акча тамгаларындагы, орден-медаль, жетоннардагы һ.б. язулар. Мондый текстлар һәрвакыт стандартлашкан була һәм бәя үлчәмнәренә ишарә итә, девиз яки лозунгтан тора, алар ялган эшләнмәләрне тыя.

*Палеография* – язу тамгаларын тарихи үсештә тикшерә, кульязма текстларны уку кагыйдәләрен эшли һәм шул рәвешчә язма чыганакларның эчтәлек һәм формасын дөрес шәрехләүгә ярдәм итә торган фән. Язу кораллары белән язу материалларында башкарылган һәртөрле язуларны, ягъни кульязмаларны *палеографик текстлар* дип йөртәләр. Язу ысулларына бәйләп, аларны *хатлар* (эпистоллар), *документ* һәм *әдәби иҗат әсәрләре*нә бүлеп карыйлар. Иҗат ителгәннән соң язма текст авторыннан аерыла һәм алга таба мөстәкыйль яши кебек. Мондый текстка ия булган кеше аны әйбер кебек кабул итә ала һәм аны укымаска мөмкин, яисә текстны алып, эчтәлеге белән таныша. Алган кеше аны укып, күчермәсен дә эшли ала. Күчермә икенче кешегә тапшыру яки саклау максаты белән дә эшләнә. Беренче очракта берничә кеше әлеге текстның эчтәлеге белән таныша, икенче очракта ул белемнәрне үстерү һәм туплау өчен хезмәт итә.

*Документлар* кешенең эш-гамәлләре белән идарә итә, шуңа күрә кешегә зыян китермәс өчен төп нөсхә бер генә була. Документларның күчермәсен эшләүнең өч ысулы бар: *отпуск, күчермә* (копия) һәм *дубликат*. *Отпуск* – контроль өчен урында калдырылган нөсхә, аңа кул куелмый һәм расланмый. *Күчермә* (копия) – расланган, имзаланган һәм адресатка җибәрелгән юридик чын документ. *Дубликат* адресат документның төп нөсхәсен югалткан очракта махсус карар белән эшләнә.

*Хатлар* – кешеләрнең телдән диалог рәвешендә аралашуына охшаган сөйләмнең язма формасы. Документ тибында булмаган хатларның күчермәсе эшләнми; аларны бары тик я документка, я иҗат әсәренә әйләндерү максаты белән генә күчермә ясалырга мөмкин. Күренекле шәхесләрнең хатлары архивларда саклана.

Шәхси хатларны алырга кирәк, аларны уку-укымау адресатның ниятенә бәйле. Укылмаган яки кабул ителмәгән хатлар мөнәсәбәтләр өзелүне аңлата. Хатлар архивка эләккәндә генә мәдәни байлыкка керә, әмма мондый очраклар сирәк була.

*Иҗат әсәрләре* (әдәбият) – мондый текстларда кеше күңеле, хисләре чагыла; алар кешенең аңы һәм ихтыяры белән идарә итә. Боларның күчермәләрен иркен рәвештә эшләргә була. Укыр өчен кеше иҗат әсәрләрен саклана торган җирдән (гадәттә ул

китапханә була) үзе сайлап ала, укыганнан соң кайберләрен конспектлаштыра.

Басу җайланмалары барлыкка килгәч, *неография* дип аталган язу төре пәйда була. Неография дип басылган һәм тиражланган текстларга әйтәләр. Боларга шул ук документлар, хатлар һәм әдәби иҗат әсәрләре керә.

***Әйтмә-язма сөйләм (массакүләм коммуникация)***

Массакүләм коммуникация текстлары заманча массакүләм җитештерү һәм кулланылыш өлкәсенә хезмәт итә. Алар яңа көчле техник чаралар (күбәйтү аппаратлары, аваз яздыру җайланмалары, телевидение, радио, кино, компьютер һ.б.) ярдәмендә ясала һәм таратыла, кулланучыга текстларның эчтәлегендәге иң кирәкле мәгълүматлар җиткерелә.

Әгәр әйтмә сөйләм ишетүгә, ә кульязма һәм басма сөйләм күз белән кабул итүгә корылса, массакүләм коммуникациядә күреп кабул ителә торган басма сүз әйтмә сүз белән үрелеп бирелә. Шуңа күрә бу төр сөйләмне *әйтмә-язма сөйләм* дип тә йөртәләр. Аларга массакүләм мәгълүмат, реклама һәм информатика керә.

*Массакүләм мәгълүмат* – зур күләмдәге кулланучыны, ягъни киң җәмәгатьчелекне күздә тоткан һәм агымдагы яңалыкларны хәбәр итә торган сөйләм. Боларга шулай ук күңел ачу текстлары да керә. Мондый сөйләмне кино, телевидение, радио, газета-журналлар һ.б. иҗат итә. Аларның күбесе, имеш-мимешләр кебек, кабул ителгән моментта гына актуаль була, сакланмый, буыннан-буынга тапшырылмый. Фото, кинотасмалар, аудио һәм видеоязмаларның кайберләре генә сакланырга мөмкин. Күп очракта мондый сөйләм кешегә белемнәр бирми, ә төрле фикерләрне генә җиткерә, шунлыктан аларның мәдәни әһәмияте юк дәрәҗәсендә.

*Реклама* – массакүләм коммуникациянең үзенчәлекле бер төре. Анда кулланучыга төрле товарлар, хезмәт төрләре һ.б. турында мәгълүмат бирелә һәм ул бу әйберләргә карата сорау, ихтыяҗ тудыру максаты белән эшләнә. Реклама бик борынгы заманнарда ук барлыкка килә. Бүгенге көндә ул кешедә билгеле бер предметны сатып алу яисә нинди дә булса хезмәттән файдалану теләген уяту өчен көчле корал булып тора. Тәэсирне

көчәйтүдә төрле сурәт һәм сөйләм алымнары кулланыла. Реклама текстлары, кагыйдә буларак, мәдәнияткә карамый.

*Информатика* – электрон чаралар ярдәмендә фактларны, белемнәрне гомумиләштерү формаларын һәм ысулларын җәелдерүне күздә тоткан сөйләм төре. Мондый текстларның максаты – кулланучыны кызыксындыра торган мәгълүматлар белән тәэмин итү; нәрсә турында булса да үз фикерен формалаштырырга һәм тиешле карарлар кабул итәргә мөмкинлек тудыру.

Компьютер технологияләре мәгълүмати системаларга бүленгән төрле тип текстлар оештырырга ярдәм итә, алар компьютер хәтерендә "яшәү" тибы һәм саклану ысулы белән аерылалар. Боларга уеннар, модельләштерү программалары, компьютер анимацияләре, музыка синтезлау, автомат проектлау, математик хисап системалары, машина тәрҗемәләре һ.б. керә. Әгәр алар зур күләмдәге мәгълүматларны тиз арада тапшыра торган элемтә системалары белән бәйләнгән булса, барысы бергә *мультимедиа* дип аталалар. Мондый системаларда саклана торган мәгълүмат күләме чикләнмәгән була. Мисал итеп Интернет системасын китерергә мөмкин. Информатика – XX гасырның мәдәни казанышы.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Тел һәм җәмгыять үзара нинди бәйләнештә тора?
2. Телнең иҗтимагый күренеш булуын конкрет фактлар ярдәмендә исбатлагыз.
3. Телнең функцияләрен атагыз.
4. Телнең төп иҗтимагый функцияләре турында сөйләгез.
5. Телнең эчке төзелеш функцияләренә нәрсәләр керә?
6. Телнең нинди өстәмә функцияләрен беләсез?
7. Тел һәм фикерләү үзара нинди мөнәсәбәттә тора?
8. Фикерләүнең нинди төрләре бар?
9. Тел һәм логика нисбәтен нинди яссылыкларда карап була?
10. Нәрсә ул тел?
11. Сөйләм дип нәрсәгә әйтәләр?
12. Тел һәм сөйләмнең гомуми билгеләре һәм сыйфатлары нидән гыйбарәт?
13. Сөйләмнең нинди төрләре бар?
14. Әйтмә (телдән) сөйләм формалары турында сөйләгез.
15. Язма сөйләм формаларының төп үзенчәлекләрен сурәтләгез.
16. Әйтмә-язма сөйләм кайчан барлыкка килә һәм ул нинди формаларда яши?

# ДӨНЬЯДАГЫ ТЕЛЛӘР ҺӘМ АЛАРНЫ ТӨРКЕМЛӘҮ

Җир шарында төрле чорларда төрле сандагы халык яшәгән. Чама белән палеолит чоры ахырында (б.э.к. 2 меңенче ел) җирдә 3 миллион тирәсе кеше булган. Неолит ахырына бу сан 50 миллионга җиткән. Безнең эра башында Җир шарында 230 миллион халык тормыш иткән. Беренче меңьеллык ахырында аларның саны 275 миллион булган. 1800 елда – 1 млрд.; 1900 елда – 1,6 млрд.; 1960 елда – 3 млрд.; 1999 елның 12 октябренә – 6 млрд.; 2009 елның 1 июленә китерелгән мәгълүмат буенча Җир шарында барлыгы 6 768 167 712 кеше яши дип исәпләнә[6]. 2011 елның 31 октябрендә Җир шарындагы кешеләр саны 7 миллиардка җитте[7]. Шушы кадәр халык үзара бик күп телләрдә сөйләшә һәм аралаша.

Җир шарындагы табигый юл белән (кешенең һәм аерым этносларның биологик-социаль үсеше нәтиҗәсендә) килеп чыккан телләрнең санын төгәл генә билгеләү мөмкин түгел. Күп очракларда, хәтта, бер телнең ике диалекты яисә мөстәкыйль тел белән эш итүне дә төгәл аерып булмый. Кайбер телләр борынгы авторларның тарихи, географик, этнографик хезмәтләрендәге лексик мәгълүматлар аша фрагментар рәвештә генә билгеле. Бу хезмәтләрдә еш кына юкка чыккан этнослар турында да сүз бара, ләкин бу этнонимнарга таянып, кабиләләрнең нинди телдә сөйләшкәннәрен әйтеп булмый. Этносларның күбесе исә, безгә һичбер мәгълүмат калдырмыйча, тарих битләреннән төшеп тә калган булырга мөмкин. Моннан тыш әле дешифрланган язма истәлекләр дә бар. Аларның нинди телдә язылуы һәм генетик статуслары билгеле түгел. Аерым яшәгән кайбер кабиләләрнең телләре хәзергә кадәр лингвистика тарафыннан каралмаган.

Фәндә мең ярым-ике мең тел турында сүз алып барыла, ләкин бик еш аларның саны өч, дүрт, биш, сигез меңгә кадәр җитә. 1982 елда СССРның ФА Тел белеме институты тарафыннан әзерләнгән “Дөнья телләре һәм диалектлары” дип аталган белешмәлегендә, 30 меңнән “диалект” дигән тамга астындагы лингвонимнарны исәпләмәгәндә, барлыгы 8 меңнән артыграк

[6] Википедия энциклопедиясе мәгълүматлары буенча.

[7] БМО фаразларына караганда, 2100 елга кешеләр саны 10 миллиардка җитәргә мөмкин.

“чиста” тел бирелә. АКШдагы Лингвистика җәйге институты (Summer Institute of Linguistics) тарафыннан әзерләнгән исемлектә исә барлыгы 6 700 дән артык тел күрсәтелә.

Шул рәвешчә, дөньядагы телләрнең төгәл санын билгеләү бик кыен. Моның сәбәпләре төрле булырга мөмкин:

– телләр барысы да бертигез дәрәҗәдә өйрәнелмәгән, кайбер телләрнең барлыгы турында мәгълүматлар гына теркәлгән;

– тел һәм диалект арасындагы мөнәсәбәтләр ачыкланып җитмәгән. Кайчак диалектны телдән аеру мөмкин дә түгел. Мәсәлән, кайвакыт телләр арасындагы аермалар диалектлар арасындагы аермаларга караганда да азрак була, ике ят телдә сөйләшүче бер-берсен бик яхшы аңлый. Ә менә немец, кытай, гарәп телләренең төрле диалектларында сөйләшүчеләр, әдәби телдә сөйләшүгә күчмәсәләр, бер-берсен бөтенләй төшенмиләр. Кайбер артта калган телләр кулланылышы белән дә диалект дәрәҗәсендә;

– телләр таралышлары һәм кулланылышлары ягыннан да бик нык аерыла: кайбер телләр тар әйләнә сөйләшүчеләргә генә хезмәт итә (Африка, Полинезия, Америка индеецлары кабиләләре, Дагестандагы бер аул телләре һ.б.); икенче бер төркем телләр халыклар һәм милләтләргә хас, әмма шушы халык (Кыргызстан һәм Казахстандагы *дунган* теле, төньяк Урал арты *мансий* яки *вогуль* теле һ.б.) яисә милләт белән генә чикләнәләр (мәсәлән, *чех, поляк, болгар* телләре); өченчеләре берничә милләткә хезмәт күрсәтә (мәсәлән, *португал* теле – Португалия һәм Бразилиядә, *француз* теле – Франция, Бельгия һәм Швейцариядә, *инглиз* теле – Англия һәм Америкада, *немец* теле – Германия һәм Австриядә, *испан* теле Испания, Көньяк һәм Үзәк Американың 20 илендә кулланыла).

Халыкара телләр дә була, алар халыкара оешма (БМО, Тынычлыкны саклау комитеты һ.б.) материалларын бастырганда кулланылалар (рус, инглиз, француз, испан, кытай, гарәп телләре); рус теле гәрчә бер генә халыкка хезмәт итсә дә, элеккеге СССРда яшәүче халыклар өчен милләтара аралашу теле буларак кулланыла һәм бөтен дөнья күләмендә берничә генә булган халыкара телләрнең берсе дә. Россиядә ике әдәби варианты

булган телләр дә бар, мәсәлән, коми-зырян һәм коми-пермяк теле. Дөньяда шулай ук икетелле халыкларның да булуы мәгълүм;

– телләрнең саны тотрыклы түгел: кайчак яңа телләр барлыкка килә, кайбер телләр исә тарихи үсеш нәтиҗәсендә үле телләргә әйләнәләр. Билгеле бер телдә сөйләшүче халык юкка чыкса, ул тел *үле тел* дип йөртелә, чөнки телне яшәтә торган төп шарт – аның кулланылышта булуы. Үле телләр дә башка халыклар тарафыннан төрле максатларда (дин, фән, мәдәният һ.б.) кулланылуларын дәвам итәргә мөмкин. 1996 елда Америкада Яшенле Кызыл Болыт кушаматлы кеше үлә. Ул Сиу индеец кабиләсенең катоуба телен белгән соңгы кеше була, үлгәнче ул Смитсонов институты өчен үз теленең сөйләм үрнәкләрен һәм йола җырларын язып бирергә өлгерә. Кызганычка, һәрвакытта да болай булмый, гадәттә, телләр әкрен генә, сиздермичә генә үлеп китәләр. Галимнәр фикеренчә, йөз елдан 3000 нән алып 6000 гә кадәр телнең юкка чыгу куркынычы бар. Тел күпмедер вакытлар саклансын өчен, ул телдә 100 мең чамасы кеше сөйләшергә һәм аның ким дигәндә яртысы яшьләр булырга тиеш. Бүгенге көндә 400 тел югалып бара торган телләр исемлегенә кергән, аларда бик аз санлы халык һәм, нигездә, картлар гына сөйләшә, шул соңгы могиканнар белән ул телләр Җир йөзеннән мәңгегә юкка чыгачак;

– телләр һәм аларның тарихы турында мәгълүматлар да бердәй түгел. Кайбер телләр инде берничә гасыр буе өйрәнелеп-тикшерелеп килсәләр, XVII-XVIII, хәтта XIX-XX гасырда гына билгеле булган телләр бар һ.б.

Шунысы мәгълүм: дөньяда телләр бик күп һәм аларны бер-берсеннән аерып тора торган билгеләр дә, охшаш сыйфатлар да җитәрлек. Менә шулар телләрне төркемләүгә этәргеч бирәләр.

***Телләрне төркемләү*** – дөнья телләрен билгеле бер уртак сыйфатлары буенча бүлү дигән сүз. Әлеге уртак сыйфатлар тикшеренүләр нәтиҗәсенә бәйле рәвештә табыла. Шунлыктан телләрне төркемләүгә төрле яклап якын килергә мөмкин. Тел белемендә шундый берничә классификация яшәп килә, алар арасында дүртесе төп классификация[8] (ареаль (географик),

[8] Классификацияләр саны шулай ук төрле хезмәтләрдә төрлечә. Шул ук А.А.Гируцкий 4 классификация турында искә ала; Ф.С.Сафиуллина хезмәтендә генеалогик һәм морфологик классификацияләр турында гына сүз алып барыла; А.А.Реформатский ике

генеалогик, типологик һәм функциональ) санала. Шулай да генеалогик һәм типологик классификацияләр чагыштырмача яхшырак эшкәртелгән.

Телләр әле җитәрлек өйрәнелмәгән очракта, алар турында мәгълүматлар аз булганда телләрне төркемләүдә *географик* яки *территориаль принцип* сайлап алына. Телләр турында мәгълүматлар тирәнәйгән саен, алар арасындагы кардәшлек мөнәсәбәтләренә, типологик охшашлыкларына игътибар арта. Шул рәвешчә, телләрне төркемләүдә *генеалогик* һәм *типологик принциплар* барлыкка килә. Генеалогик классификация телләрнең кардәшлегенә, бер уртак баба телдән килеп чыгуларына нигезләнә. Типологик яки структур-типологик классификация нигезендә телләрнең тышкы охшашлыклары ята. *Ареаль классификация* генеалогик һәм типологик классификацияләрнең казанышларыннан файдалана, ул дөньяда телләрнең һәм тел күренешләренең таралыш ареалларын өйрәнүне күздә тота. *Функциональ классификация* телләрнең җәмгыятьтә үтәгән иҗтимагый-мәдәни функцияләрен барлый.

### Телләрнең генеалогик классификациясе

Телләрнең генеалогик классификациясе һинд-европа телләре материалында эшкәртелә. Аны барлыкка китерүдә XIX йөзнең беренче яртысында яшәгән немец филологы Ф.Бопп, рус лингвисты А.Х. Востоков, немец галиме А.Шлейхер, француз галиме Ф.Дицның өлеше зур була. Һинд-европа телләреннән соң, калган тел гаиләләре дә аерып чыгарыла һәм төркемләнә.

*Генеалогик классификация* телләрнең тарихи кардәшлегенә нигезләнә һәм ул халыкларның тарихи язмышы белән тыгыз бәйләнгән. Телләрнең кардәшлеген өйрәнү чагыштырма-тарихи тел белеменә карый. Чагыштырма-тарихи метод телләрнең тарихи үткәнен ачыклауга багышланган чагыштыруларны күздә тота. Дөнья телләрен кардәшлек буенча төркемләү теге яки бу телләрнең бер телдән килеп чыгуын өйрәнә. Мондый телне *нигез тел* яки *баба тел* диләр. *Баба тел* – кардәш телләр төркеменең

---

классификация бар дип билгели; В.И.Кодуховта 4 классификация турында мәгълүмат бирелә һ.б.

нәсел башы, ул телләрнең үсеш тарихында төрле кардәш телләргә таркала. Генеалогик классификациянең асылы теге яки бу телне баба тел таркалган заманнан күпме “адым” аерып торуы күзлегеннән кардәшлек дәрәҗәсен исәпкә алудан гыйбарәт. Мәсәлән, хәзерге рус әдәби телен һинд-европа баба теленнән шартлы рәвештә өч адым аерып тора дип санарга мөмкин: *гомумһинд баба тел – гомумславян баба теле – борынгы рус теле (борынгы көнчыгыш славян теле) – хәзерге рус теле.* Әгәр гомумславян теленнән алда балтославян бергәлеге булган дигән фикер белән килешкәндә, тагын бер адым өстәргә була[9].

Кардәшлекне билгеләү өчен иң элек чагыштырмалы-тарихи метод ярдәмендә телләрнең охшаш сүзләре һәм сүз формалары чагыштырыла, аларның беренчел рәвешләре торгызыла. Мондый формалар *праформалар* дип йөртелә. Шул рәвешчә, тел төзелешенең телләр аерымланганга кадәр булган аерым яклары якынча реконструкцияләнә. Телләрнең матди охшашлыгы һәрвакытта да күзгә ташланып тормаска мөмкин. Кайчак яңгырашы ягыннан бөтенләй охшамаган сүзләр дә закончалыклы тәңгәллекләр белән бәйләнгән булалар һәм генетик яктан бер сүзгә барып тоташалар. Кайвакыт киресенчә дә була: сүзләр һәм аффиксларның охшашлыгы генетик тәңгәллекне аңлатмый.

Кардәшлекне билгеләгәндә аерым сүзләрнең охшашлыгы әллә ни әһәмиятле түгел, ә бер төркем сүзләрнең тамырлары охшаш булу мөһим. Гадәттә телнең үз сүзләре (алынмалар түгел) дип билгеләнгән берәмлекләрнең (туганлык атамалары, саннар, алмашлыклар, кешенең тән төзелешенә караган сүзләр, ел фасыллары, табигать күренешләре һ.б.) тамырларындагы охшашлык очраклы гына була алмый, чөнки бу сүзләр иң кирәкле төшенчәләрне белдерәләр һәм телдә бик борынгыдан яшиләр. Андый тәңгәллекләр телләр бер уртак телдән килеп чыкканда гына мөмкин. Димәк, телләрнең кардәшлеген билгеләгәндә иң беренче шарт – тамырлар охшашлыгы. Дөрес, бу сүзләр дә төрле телләрдә авазы авазга туры килеп тормаска мөмкин, ягъни фонетик яктан алар күпмедер дәрәҗәдә аерыла да

---

[9] И.П.Сусов. Введение в языкознание. - С.286

ала. Аваз чиратлашулары даими кабатлана икән, бу үзе кардәшлеккә ишарә. Кардәшлекне билгеләүдә икенче шарт – флексияләр охшашлыгы. Аларның туры килүе тагын да ышанычлырак дәлил, чөнки флексияләр бер телдән икенче телгә алынмый дип исәпләнелә.

Кардәшлек билгеләре буенча телләр берничә зур төркемгә бүленә. Бөтен кардәш телләрне үзенә җыйган телләр берләшмәсе *гаилә* дип атала. Бер тел гаиләсенә кергән телләрнең төзелешендә нигез телгә барып тоташа торган уртак сыйфатлар була. Ә төрле гаиләләргә караган телләрдә тарихи кардәшлек билгеләре табылмый, аларда, бер телдән икенче телгә үтеп кергән алынмалардан тыш, охшаш сүзләр дә, формалар да булмый. Гаилә эчендәге телләрнең кардәшлеге якын да, ераграк та булырга мөмкин, шуңа бәйле рәвештә гаилә эчендә телләр *төркем*нәргә, төркемнәр – *төркемчә*ләргә туплана.

Хәзерге тел белемендә тел гаиләләренең саны төгәл билгеле түгел, бу күпмедер дәрәҗәдә Африка, Көньяк-Көнчыгыш Азия, Океания, Америкада яшәүче халыкларның телләре әлегәчә җентекләп өйрәнелеп бетмәве белән дә аңлатыла. Гаиләләргә бүленештә, гаиләләрне төркемнәргә бүлүдә уртак фикер юк. Гәрчә генеалогик класификация ныграк эшкәртелгән классификацияләрдән саналса да, кешелекнең телләр тарихы картинасы хәзерге лингвистикада бик якынча гына сурәтләнә.

Телләрнең генеалогик классификациясе фонетик законнарның яшәеш тарихыннан гыйбарәт. Яңа фактлар ачылуга, әлеге системага кергән яңа телләр табылуга, яңа фонетик законнар ачылуга бәйле рәвештә аңа даими төгәллек кертелеп тора.

Хәзерге чагыштырма-тарихи тел белемендә тел гаиләләрен тагын да зуррак генетик берләшмәләргә – макрогаиләләргә берләштерү омтылышлары да еш очрый[10]. Макрогаилә төшенчәсе, тел гаиләсе төшенчәсе кебек үк, гаять чагыштырма төшенчә. Шунлыктан, дөньяда күпме кечкенә һәм зур тел гаиләләре яшәвен әйтү кыен. Телләрне тел гаиләләренә урнаштыра торган генеалогик классификация еш кына тел берәмлекләренең матди гомумилегенә түгел, бәлки географик

[10] И.П.Сусов. Введение в языкознание. – С.287

тәртипкә дә таяна. Шуңа күрә генеологик классификация, нигездә, тел гаиләләрен һәм макрогаиләләрне санап чыгуга кайтып кала дисәң дә була. Алар белән шулай ук дөнья лингвистик картасы буенча сәяхәт иткәндә дә танышып була.

Барлык телләрне дә гаиләләргә кертеп бетереп булмый. Кайбер телләр гипотеза рәвешендә генә теге яки бу тел гаиләсенә кертелергә мөмкин. Телләрне ныклап өйрәнү элеккеге классификацияләргә үзгәрешләр дә кертә. Шулай да әле генеалогиясе ачыкланып бетмәгән телләр кала бирә.

Генеалогик классификацияләрнең күпчелегендә искә алынган тел гаиләләре әллә ни күп түгел. Алар түбәндәгеләр (бәхәсле моментларның да булуын истә тоткан хәлдә, 15 тел гаиләсен билгеләгән бүленеш бирелә)[11]: *һинд-европа, семит-хәмит (афразия), кавказ, дравид, урал, алтай, чукот-камчатка, нигер-кордофан, нил-сахара, койсан, кытай-тибет, тай, австро-азиат, австронезия, эскимос-алеут телләре гаиләләре.* Әлеге тел гаиләләрен күзәтеп чыгу максатка ярашлы булыр [12].

***Һинд-европа телләре гаиләсе*** иң күп таралган һәм күпсанлы халыклар сөйләшә торган телләрне үз эченә ала. Һинд-европа халыклары Европаның (Россияне дә кертеп) зур өлешендә, Әрмәнстан, Таҗикстан, Иран, Әфганстан, Көньяк Азиянең төньяк һәм үзәк районнарында, Америка, Австралиядә яшиләр. Һинд-европа телләре 12 төркемгә бүленә:

1) *һинд* төркеменә һинди һәм урду (һиндустани), бенгали, панджаби, непали, чегән һ.б. телләр керә. Үле телләр – санскрит һәм пракрит;

2) *иран* төркеме һинд төркеменә аеруча якын. Аңа фарсы, әфган, таҗик, көрт, осетин һ.б. телләр керә. Бу төркемдә үле телләр дә шактый – борынгы фарсы, авеста, лидий, пәхләви, скиф һ.б.;

3) *славян* төркеме үз эчендә өч төркемчәгә аерыла: көнчыгыш төркемчә (рус, украин, белорус телләре), көнбатыш төркемчә (чех, словак, поляк, кошуб, үле полаб телләре), көньяк төркемчә (болгар, серб-хорват, македон, словен, үле иске славян телләре);

---

[11] Сафиуллина Ф.С. Тел белеменә кереш. – Б. 269-270

[12] Кайбер мәгълүматлар төрле хезмәтләрдә берникадәр аерылырга мөмкин.

4) *балтыйк* төркеме зур түгел. Аңа литва, латыш телләре һәм үле прусс теле керә;

5) *герман* төркемен гадәттә икегә бүләләр: төньяк герман (Скандинавия) төркемчәсе (дат, швед, норвег, исланд, фарёр телләре һ.б.), көнбатыш герман төркемчәсе (инглиз, голланд, фриз, немец, идиш телләре). Өченчесе – көнчыгыш герман төркемчәсе, ул үле вестгот һәм остгот телләреннән тора;

6) *роман* төркеменә француз, итальян, испан, португал, румын, молдаван һ.б. телләр, үле телләрдән латин теле керә;

7) *кельт* төркеменә ирланд, шотланд, бретон, валлий телләре һәм үле галль, корноуль телләре керә.

*Әрмән, грек, албан* телләре үзләре генә аерым төркем хасыйл итәләр. *Хетт* һәм *тохар* төркемнәрендә бары тик үле телләр генә булуы мәгълүм.

***Семит-хәмит (афразия) телләре гаиләсе.*** Бу гаилә дөньядагы 5% халыкны үз эченә ала дип исәплиләр, алар Төньяк һәм Төньяк-көнчыгыш Африкада, Гарәбстан ярымутравында һәм аңа төньяктан чиктәш булган илләрдә (Сирия, Ливан, Иордания, Иордан елгасының көнбатыш яры, Гыйрак) яшиләр. Афразия макрогаиләсе безнең эрага кадәр X-VIII гасырларда аерым гаиләләргә таркалган дип фаразлана. Бу гаилә алты тел төркемен берләштерә:

1) *бәрбәр-ливий телләре* төркеменең тере телләре Төньяк Африкада Мисыр һәм Ливиядән Мавританиягә кадәр таралган, шулай ук Сахара оазисларында, Нигерия, Сенегалда да очрый. Марокко халкының 40%-ы, Алжирда 25% халык бәрбәр телендә сөйләшә. Тере телләрнең күбесендә язу юк. Туарег кабиләсендә (Сахарада) көнкүрештә тифинаг дигән язу кулланыла;

2) *борынгы Мисыр теле* – үле телдән торган төркем. Нилның урта һәм түбәнге үзәнлекләрендә таралган була (хәзерге Мисыр). Беренче язма истәлекләр б.э.к. IV гасыр ахыры – III гасыр башы белән билгеләнә. Бу тел б.э.ның V гасырына кадәр яшәгән. Аңа якын кардәш телләр табылмаган;

3) *кушит телләре* төркемендә тере телләр генә билгеле, алар Төньяк-Көнчыгыш Африкада (Суданның төньяк-көнчыгышында, Эфиопия, Джибути, Сомали, Кениянең төньягында, Танзаниянең көнбатышында) таралган;

4) *омот телләре* төркеменә тере, язусыз телләр керә, алар Эфиопиянең көньяк-көнбатышында таралган;

5) *семит телләре* төркеме – телләр саны ягыннан караганда бу гаиләдә иң зурысы. Хәзерге тере телләрдән гарәп, мальта, иврит, эфиосемит (амхар, тигре, тиграй) һ.б. телләр керә. Бу телләр Гарәп Көнчыгышы, Израиль, Эфиопия һәм Төньяк Африкада таралган, урыны-урыны белән Азия һәм Африканың башка илләрендә дә очрыйлар;

6) *чад телләре* төркеменә якынча 150 тере тел һәм диалект төркемнәре керә, алар Үзәк һәм Көнбатыш Суданда, Чад күле районында, Нигерия, Камерунда таралганнар.

***Кавказ телләре гаиләсе*** үз эченә Кавказ төбәгендә таралган 40 тан артык җирле телне ала. Бу телләрдә сөйләшүчеләрнең саны 7 млн. нан артык, аларның 50% чамасы – грузиннар, 10%-тан артыгы – чеченнар. Бу гаилә телләренең кардәшлеге фән тарафыннан хәл ителеп бетмәгән, бүленеш күбрәк аларның географик таралышына нигезләнә булса кирәк. Бу телләрдә сөйләшүчеләрне, Төркиядә һәм Якын Көнчыгыш илләрендә дә күрергә була, алар анда соңгы миграция процесслары нәтиҗәсендә пәйда булгандыр, мөгаен. Әлеге гаилә телләрен тарихи-генетик яктан өч төркемгә бүләргә мөмкин:

1) *көнбатыш төркем – абхаз-адыг телләре* (абхаз, абазин, адыгей, кабардин, убых һ.б. телләр);

2) *көнчыгыш төркем – нах-дагестан телләре* (чечен, ингуш, авар, даргин, лак, лезгин, табасаран һ.б. телләр);

3) *көньяк төркем – картвель телләре* (мегрель, лаз, грузин, сван һ.б. телләр). Кайбер классификацияләрдә бу төркем аерым гаилә итеп карала башлады.

***Дравид телләре гаиләсе*** Һиндстанның үзәгендә һәм көньягында, Шри-Ланканың төньяк-көнчыгышында, шулай ук Әфганстанда һәм Иранның көнчыгышында яшәүчеләрнең телләрен берләштерә. Бу гаиләгә, нигездә, Һиндстанга европалылар килгәнчегә кадәр яшәгән җирле халыкларның телләре керә. Дравид телләренең төгәл санын билгеләү шактый кыен, чөнки бу телләрнең материалы тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Хәзерге минималь бәяләүләр буенча 25 ләп, ә максималь 80 ләп тел керә. Дравид телләрендә сөйләшүчеләрнең

саны Һиндстан халкының гомуми саны артуга бәйле рәвештә үсә бара. Бу гаилә телләренең генеалогик классификациясе бүгенге көндә бәхәсле кала. Дравид телләрендә сөйләшүчеләрнең 90%-ы дүрт “зур” телдә – *телугу, тамиль, малаялам, каннада* телләрендә сөйләшә: Тел гаиләсе эчендә дүрт төркем аерыла (башка классификацияләр дә бар):

1) *көньяк төркем* (тамиль, малаялам, каннада, телугу, тулу һ.б. телләр)*;*

2) *үзәк төркем* (гонди, куи, парджи телләре)*;*

3) *төньяк-көнчыгыш төркем* (курух һәм малто телләре);

4) *төньяк-көнбатыш төркем* (брахуи теле).

***Урал телләре гаиләсе***нә кергән телләр Россиядә, Эстония, Венгрия, Финляндия һәм Скандинавиянең төньягында таралган. Гаилә эчендә ике тармак аерыла:

1) *фин-угор тармагы*ның үз эчендә 4 төркемчә:

– балтыйк буе-фин төркемчәсе (фин, эстон, карель һ.б. телләрдән тора);

– пермь төркемчәсе (удмурд, коми-зырян, коми-пермяк һ.б. телләреннән гыйбарәт);

– Идел буе төркемчәсе (мари, мордва һ.б. телләрне үз эченә ала);

– угор төркемчәсе (венгр, хантый, мансый һ.б. телләрне берләштерә);

2) *самодий тармагы* (тере телләрдән ненец, энец, нганасан, селькуп һ.б., телләр керә). Кайбер аз санлы халыклар юкка чыгу чигендә тора, дүрт самодий теленең дә өчесе үлеп бара. .

***Алтай телләре гаиләсе*** дөнья халкының якынча 6%-ын берләштерә, Балкан ярымутравыннан алып Япон утрауларына кадәр һәм Төньяк Боз океаныннан Үзәк Азиягә чаклы тоташмаган ареалларны үз эченә ала. 4 төркемгә бүленә: *төрки* (30 лап тере һәм үле тел), *монгол, тунгус-маньчжур* һәм *япон-корея* (соңгысы аерым да карала). Бу төркемнәр үз эчендә түбәндәгечә сурәтләнә.

1. *Төрки* телләр ике тармакка бүленә:

а) *көнбатыш хун* тармагы. Аның эчендә түбәндәге төркемчәләр аерыла:

– болгар төркемчәсе (болгар, чуваш телләре керә),

– кыпчак төркемчәсе (караим, комык, карачай-балкар, татар, башкорт, каракалпак, казах, ногай телләре һ.б.),

– угыз төркемчәсе (төрекмән, әзербайҗан, төрек, кырым татарлары теле һ.б.);

– карлук төркемчәсе (үзбәк, уйгыр телләре);

ә) *көнчыгыш хун* тармагы ике төркемнән тора:

– уйгыр-угыз төркеме (тува, тофалар, якут (долган), сары уйгырлар, хакас, шор һ.б. телләр);

– кыргыз-кыпчак төркеме (кыргыз, алтай һ.б. телләр).

2. *Монгол* телләренә хәзерге монгол (халха) теле, бурят, калмык, ойрат һ.б. телләр керә;

3. *Тунгус-маньчжур* телләренә әкренләп югала бара торган эвенк, эвен, маньчжур телләре карый.

4. *Япон* һәм *корея* телләре, озак вакытлар генеалогик классификациядә урыннарын таба алмый йөргәннән соң, соңгы елларда Алтай телләре гаиләсенә кертеп карала башладылар.

***Чукот-камчатка телләре гаиләсе*** аз санлы гаилә, бу телләр Россиянең ерак төньяк-көнчыгышында (Себердә) таралган. Бу гаиләне шартлы рәвештә ***палеоазиат телләре*** дип тә йөртәләр һәм аңа географик билгеләре ягыннан палеоазиат телләрен дә кертеп карыйлар. Себердә таралган әлеге аз санлы халыклар борынгы Себер халкының калдыклары булырга тиеш дип саныйлар, аларның бер өлеше монгол яулары чорында өлешчә ассимиляцияләнгән, ә бер өлеше Төньяк Америкага кысрыкланган булса кирәк. Палеоазиат телләрен ике төркемгә бүлеп карыйлар:

1) Чукотка һәм Коряк милли округында, Якутиядә таралган *чукот-камчат төркеме* (чукот, коряк, ительмен, алютор, керек телләре);

2) *себер (Енисей) төркеме* (кет, юкогир, нивх телләре), алары күбрәк Красноярск өлкәсендә таралган.

Кайбер хезмәтләрдә эскимос-алеут телләре дә бу гаиләгә кертелә.

***Нигер-кордофан гаиләсе*** халыклары (дөнья халкының якынча 6%-ы) күбрәк Көнбатыш, Үзәк, Көнчыгыш һәм Көньяк Африкада (Синегалдан КАРга кадәр) таралганнар. Әлеге гаиләне макрогаилә дип исәпләп, 10 тел гаиләсеннән тора дип уйлыйлар:

1) *кордофан* телләренә Судандагы 20 ләп кечкенә тел керә;

2) *манде* телләре Көнбатыш Суданның үзәгендә таралган;

3) *атлантик* гаилә үз эченә 7 төркемне ала;

4) *иджоид* телләре (10 лап тел) Нигер елгасы култыгында таралган;

5) *догон* гаиләсе – Нигер елгасының көньяк-көнчыгышында таралган берничә кардәш телдән гыйбарәт;

6) *кру* гаиләсе көнбатыш һәм көнчыгыш тармаклардан тора, 35-40 чамасы тел керә;

7) *сенуфо* теле элек гур гаиләсенә кертеп каралган, соңгы вакытларда аерым тел гаиләсе төзи дип фаразлана;

8) *саванна* телләре гаиләсе гур һәм адамава-убагин төркемнәреннән гыйбарәт, аңа 230 лап тел керә;

9) *ква* гаиләсе Көнбатыш Суданның көньягында таралган 80 ләп телне үз эченә ала;

10) *бенуэ-конголез* – Африкадагы күп санлы телләрдән гыйбарәт булган иң зур тел гаиләсе. Бениннан Сомалига һәм көньяктан КАРга кадәр булган бик зур территориягә таралган, 900 ләп тел керә.

***Нил-сахара телләре гаиләсе*** (дөнья халкының якынча 0,6%-ы) – афразия һәм нигер-конго макрогаиләләренә кергән телләр арасында таралган, әмма аларның берсенә дә кермәгән Африка телләреннән гыйбарәт булган гипотетик макрогаилә. Бу телләр Малидан Эфиопиягә, Мисырдан Танзаниягә кадәр территориядә таралганнар. Нил-сахара телләрендә сөйләшүчеләр катнаш европалы-нигероид расага карый. Нил-сахара гипотезасы буенча бу макрогаилә 9 тел гаиләсе һәм берничә изолят телдән тора:

1) *сонгай телләре* Нигер һәм Малида таралган 10 лап телне үз эченә ала;

2) *сахара телләре* (Чад күле буенда Сахараның бер чите) 10 лап телдән гыйбарәт;

3) м*абан телләре* (Чадның Судан белән чиктәш көньяк-көнчыгыш өлеше) 5-10 телдән тора;

4) *фор телләре*нә Чадның көнчыгышындагы һәм Суданның көнбатышындагы ике генә тел керә;

5) ү*зәк Судан телләре* үз эчендә көнбатыш һәм көнчыгыш өлешләргә бүленгән 8 төркемнән тора, 60 лап тел керә;

6) к*өнчыгыш Судан телләре*нә 80 ләп тел керә;

*7) каду телләре* элек кордофан телләре гаиләсенә кертелгән, Судан республикасы үзәгендәге 7 телне үз эченә ала;

8) к*ульяк телләре* Угадандагы 3 кечкенә телдән гыйбарәт;

9) к*оман телләре*ндә Эфиопиядәге һәм Судан чикләрендәге 5 тел бар.

*Берта* һәм *гумуз* телләре – Эфиопиядәге изолятлар; *кунама* теле – Эритрейдагы изолят.

***Койсан телләре гаиләсе.*** “Койсан” термины 1928 елда этнограф Л.Шульце тарафыннан кертелә (khoi – кеше, san – бушмен), ул аны бу халыкларның гомуми физик-раса тибын билгеләү өчен куллана. 1963 елда Дж.Х. Гринберг бу терминны макрогаилә атамасы белән бәйли. Үз гипотезасын нигезләү өчен ул бу телләрдәге кайбер типологик охшашлыкларны һәм лексик параллельләрне, иң мөһиме аларда шартлаулы (щелкающий) кычкырыклар (клики) булуын күрсәтә. Бу макрогаиләне ул хадза, сандаве һәм көньяк Африка-койсан төркемнәренә бүлә. Хәзерге вакытта мәгълүм булган койсан телләре ике гаиләгә бүленә һәм 3 изолят тел аерыла:

1) *үзәк койсан телләре* ике төркемне үз эченә ала: кхой-кхой телләре (Намибия һәм КАР) һәм чу-кхве (калахари) телләре (Намибия, Боствана, Калахари чүленең төньяк-көнчыгышы);

2) *жу-къви телләре* ике төркемнән тора: Төньяк койсан төркеме (Намибия, Ангола һ.б.) һәм көньяк койсан телләре.

Изолятлар: *квади* теле (XX гасырда үлгән); *сандаве* һәм *хадза* телләре (Танзания).

***Кытай-тибет телләре гаиләсе*** телләре Көнчыгыш, Үзәк, Көньяк-Көнчыгыш Азиядә һәм Көньяк Азиянең төньяк чигендә таралган. Бу гаиләгә кергән телләр сан ягыннан күп булмаса да, аларда сөйләшүче кешеләр саны ягыннан бу гаилә, һинд-европа телләре гаиләсеннән генә калышып, икенче урында тора. Бу гаиләдә күп кенә лингвистлар ике төркем бар дип исәпли (ә кайбер классификацияләрдә төркемнәр саны 13 кә җитә):

1) *кытай* төркеменә кытай һәм кытай теленең бер диалекты дип саналган дунган теле керә. Кытай теленең диалектлары гына да 7 төп төркем барлыкка китерә. Дунган теле Кытайда һәм Урта Азиядә таралган;

2) *тибет-бирма* төркеменә тибет һәм бирма теле карый. Күпчелек классификацияләрдә бу төркем үз эчендә бик катлаулы итеп бүленә.

***Тай телләре гаиләсе***нә берничә дистә тел керә, алар Көньяк Кытайда, Һинд-Кытай ярымутравында һәм Һиндстанның көнчыгышында таралган. Бу гаилә *тай төркеме* (бер төркем диалектлары белән тай, лаос, шан телләре) һәм *кадай төркеме*нә (Кытай провинциясендә яшәүче 750 меңләп кеше сөйләшә торган ли теле һәм диалектлары, лати, лакуа, гэлао телләре) бүленә. Барлык тай телләре дә типологик яктан үзара якын һәм кытай теленә охшаган. Күп кенә тай телләренең язулары бик борынгы.

***Австро-азиат телләре гаиләсе***нә Көньяк-Көнчыгыш һәм Көньяк Азиядә (Вьетнам, Таиланд, Камбоджа, Лаос, Бирма, Малайзия, Кытай, Һиндстанның көнчыгышы), Һинд океанындагы кайбер утрауларда яшәүче халыкларның телләре (150 ләп) керә. Бу телләрнең әлеге гаиләгә кертелүләре ышанычлы рәвештә дәлилләнгән дип санала, шулай да эчке классификациядә ачык булмаган моментлар шактый, чөнки күп кенә тау кабиләләренең телләре әлегәчә өйрәнелеп җитмәгән. Австро-азиат телләрендә сөйләшүчеләрнең саны 1990 еллар уртасында 90 млн.га якынлаша, аларның 70%-ы – вьетнамлылар. Әлеге тел гаиләсендә дүрт төркем аерыла:

1) *мон-кхмер телләре* (вьетнам, кхмер; мон, чонг, самре, пеар һ.б.);

*2) мунда телләре* (сантали, мундари, корку, кхариа һ.б.);

3) *никобар телләре* (кар, чаура, нанкаури, шомпен һ.б.)*;*

4) *нахали телләре* (соңгы елларда бу төркем әлеге гаиләгә ялгыш кертелгән дигән фикерләр дә бар).

***Австронезия телләре гаиләсе***нә 150 дән артык тел керә. Аны кайчак икегә (индонезия һәм океания яисә индонизия һәм полинезия телләренә), ә кайвакыт дүрт төркемгә (индонезия, полинезия, меланезия һәм микронезия телләренә) бүләләр. Бу гаилә телләрендә Көньяк-Көнчыгыш Азия утрауларында һәм ярымутрауларында яшәүче күпсанлы халыклар сөйләшә. Телләр саны ягыннан бу гаилә иң эреләрдән санала, бу телләрдә сөйләшүчеләрнең саны да шактый (300 млн. чамасы). Әлеге тел

гаиләсенә *яван* (1000 елдан артык язу тарихына ия), *бали, малайя, тагаль, малагаси* кебек зур телләр дә керә. Болардан тыш *маори, гавай, самоан* кебек полинезия телләре дә мәгълүм.

Зур географик территорияләргә таралып урнашуларына карамастан, австронезия телләренең кардәшлеге XVIII гасырда ук таныла. Әмма эчке бүленеш кенә хәзергәчә урнаштырылмаган. Моның сәбәбе: көньяк океан диңгезчеләре, Евразия чүлләрендә күчмә халык булып яшәүче төркиләр кебек, даими рәвештә һәм төрле юнәлешләрдә күченеп торганнар һәм шул ук вакытта бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә булганнар, шуңа күрә аларның телләре дә берникадәр буталган.

***Эскимос-алеут телләре гаиләсе***нә кергән аз санлы халыклар Гренландиядә, Төньяк Америка белән чиктәш төньяк районнарда, Россиянең ерак төньяк-көнчыгышында яшиләр. Аңа күп диалектлардан торган эскимос һәм алеут телләре керә. Икесендә дә аффиксация киң кулланыла. Эскимос телләрендә агглютинация таралган, алеут телләрендә флексияләр очрый. Эскимос телендә сөйләшүчеләр Гренландиядә, Канадада, Аляскада һәм Себердә яши. Алеут телендә аралашучылар Прибылов утравында (Россия), Алеут утрауларында (АКШ) яши. Типологик яктан фин-угор телләренә якын. Шуңа күрә Россия тикшеренүчеләре бу телләрне еш кына Урал телләре гаиләсенә кертәләр. Кайбер хезмәтләрдә Америка индеецлары телләре белән охшашлыкларны да күрсәтәләр.

## Телләрнең типологик классификациясе

Телләрне һәм телләрнең үзара мөнәсәбәтен өйрәнүгә юнәлдерелгән типологик караш тел белеменә югары дәрәҗәдә якын. Бу караш, телләрнең кардәш һәм географик рәвештә чиктәш булу-булмавына, бер үк тарихи чорга караган яки карамаган булуларына игътибар итмичә, телләрне бер-берсе белән чагыштыра. Ул бары тик бер тел гаиләсе яки ареалы белән генә чикләнми. Типологик каршы кую, гомуми һәм аермалы структур сыйфатларны табу өчен дөньяның барлык телләре дә кулланылырга мөмкин.

Телләрне типологик яктан тикшергәндә тел белеме кеше теленең тел универсалияләре теорияләрендә төзелгән идеаль,

гипотетик моделенә таяна һәм конкрет телләрнең үз системаларындагы гомуми төзелеш законнарын тормышка ашыру юлларын эзли. Шушы тикшеренүләр нигезендә телләр структур типларга, классларга бүленә. Лингвистик типологиянең төп максаты – телләрнең типологик классификациясен төзү. Анда һәр тел теге яки бу типологик статуска ия була.

Телләр типологиясе белән кызыксыну телгә карата генетик караш формалаша башлаганда ук уяна. XVIII-XIX гасырлар чигендә барлыкка килгән лингвистик компаративизм үз эченә чагыштырма-тарихи һәм типологик карашларны кертә.

Иң беренче төгәл типологик фикерләр Р.Декарт, Г.В. Лейбниц, А.Смит, И.Г. Гердер кебек галимнәрнең хезмәтләрендә күренә. Лингвистик компаративизм юнәлешенең башында абыйлы-энеле Фридрих фон Шлегель һәм Август Вильгельм фон Шлегель тора. Шушы абыйлы-энеле ике галим, беренчеләрдән булып, телнең типологик (морфологик) классификациясенә нигезләнгән тәҗрибә тәкъдим итәләр дә инде. Фр. Шлегель флектив телләр дип исемләнгән төшенчә куллана башлый. Бу төшенчә санскрит, грек, латин телләренә карата кулланыла. Әлеге телләрдә сүз үзгәргән очракта, флексия күренеше, ягъни сүзнең тамырында авазларның грамматикалашкан чиратлашуы башлана. Флектив типтагы телләр эстетик яктан камил дип табыла. Телләр иерархиясендәге иң түбән баскыч кытай теленә бирелә. Ике баскыч арасында Фр. Шлегель аффиксаль телләргә урын бирә. Аның фикеренчә, телләрнең үсешендә борынгы камил формаларны “чарлау” күренә. Шулай ук, синтетизмнан аналитизмга күчү тенденциясе дә ассызыклап үтелә. А.В. фон Шлегель грамматик структурасыз телләрне аерып күрсәтә (алга таба аларны аморф яки изоляцияләнгән телләр дип атыйлар) һәм аларга аффиксаль, флектив телләрне каршы куя. Синтетизм һәм аналитизм төшенчәләре кулланылышка керә, беренче күренешнең икенчесе белән алмашу тенденциясе хакында да әйтелә. Ләкин беренчелек синтетик телләргә бирелә.

Тел формаларында универсаль һәм специфик компонентларның булуын күздә тоткан контенсив типологиягә XIX гасырның бөек галиме Вильгельм фон Гумбольдт нигез

сала. В. фон Гумбольдт өчен барлык тип телләр дә тиң булган. Ул бары тик изоляцияләнгән, агглютинатив һәм флектив телләрне аера. Агглютинатив телләр классында аерым бер подтип – инкопорацияләнгән телләргә басым ясала. “Чиста” типлар булу мөмкинлеге галим тарафыннан кире кагыла. Телләрнең морфологик классификациясендә В. фон Гумбольдтның схемасы хәзерге көндә дә кулланылышта.

Бу схемада барлыгы дүрт класс (тип) бар.

1. Флектив телләр.
2. Агглютинатив телләр.
3. Изоляцияләнгән, яки аморф телләр.
4. Инкорпорацияләнгән, яки полисинтетик телләр.

Телләрнең типологиясен өйрәнүгә XIX гасырның башка вәкилләре дә зур өлеш кертә (аеруча – Август Шлейхер). Аларның классификацион схемалары, гадәттә, бер-берсеннән катгый рәвештә чикләнгән 3-4 типны үз эченә ала. XX гасырның беренче яртысында Эдвард Сепир тарафыннан тәкъдим ителгән концепция алга таба зур адым ясарга булыша. Бу концепция нигезендә, морфологик структураның тасвирламасында тамыр төшенчә (морфема), деривацион, реляцион һәм кушма реляцион төшенчәләр арасындагы мөнәсәбәтләр үзенчәлеге күздә тотылырга тиеш. Моннан тыш, мөнәсәбәтләрне грамматик юл белән белдерү ысулы (изоляция, агглютинация, фузия һәм символизация) һәм синтезлау дәрәҗәсе (аналитик, синтетик, полисинтетик) аерыла. Нәтиҗәдә күп баскычлы, үзгәрүчән телләр классификациясе барлыкка килә.

Дж.Гринберг, күләмле индекслар төшенчәсен кертеп, бу концепциягә яңалык өсти. Мәсәлән, 100 сүздән (W) торган текстта 100 дән 200 гә кадәр морф (M) булган вакытта, ягъни бердән күбрәк һәм икедән азрак булган M/W синтезының индексы куелган очракта аналитик телләр белән эш ителә булып чыга. Тагы да югарырак индекс аффиксаль телләрне, төгәлрәк әйткәндә, синтетик телләрне (2 дән 3 кә кадәрге индекс белән) һәм полисинтетик телләрне (3 тән югары индекс белән) характерлый.

Шулай итеп, уздырылган тестлар нәтиҗәсе буенча, вьетнам теле 1,06 синтез индексы, фарсы теле – 1,52, инглиз теле – 1,68, инглиз-саксон теле – 2,12, якут теле – 2,17, рус теле – 2,33,

суахили – 2,55, санскрит – 2,59, эскимос теле – 3,72 синтез индекслары белән характерлана. Шул ук тәртиптә агглютинация, деривация, сүз төрләнеше, префиксация, суффиксация, изоляция, “чиста” сүз төрләнешенең дә индекслары билгеләнә. Башка тикшеренүчеләр тарафыннан бу методикага караган эшләр бары тик контроль текстларның күләме, аларның стилистик һәм авторлык мәсьәләләрен барлау белән генә чикләнә.

Морфологик классификациядә аффиксларның тамыр морфемалар белән кушылу ысулларына һәм аффикслар ярдәмендә грамматик төшенчәләрне чагылдыру характерына зур игътибар бирелә.

Флектив аффикслар:

– еш кына берьюлы берничә граммеманы чагылдыралар (Ю.С. Маслов буенча синтетосемия күренеше): рус телендәге “*пишу*” сүзендәге флексив аффикс (-у) беренче зат, берлек сан, хәзерге заман, хикәя фигыль граммемаларын белдерә;

– үзара омосемик сыйфатларга ия: мисал өчен, рус телендәге “*трава*” һәм “*бревна*” сүзләре. Беренче очракта /а/ фонемасы исем, берлек сан, хатын-кыз род категориясендәге, баш килештәге -*а* морфемасының экспоненты ролен үти; икенче очракта исә шул ук /а/ фонемасы исем, күплек сан, баш/төшем килеше төшенчәләренең комплексын белдергән башка бер -*а* морфемасының экспоненты булып тора;

– бер үк грамматик төшенчәне белдерүдә бер-берсе белән конкуренциягә керергә мөмкин: мәсәлән, рус телендәге “*студенты*” һәм “*дома*” сүзләрендә -*ы* һәм -*а* морфемалары күплек санны белдерәләр;

– нуль дәрәҗәсендәге экспонент иясе булырга мөмкин: күплек сандагы русча “*страна*” сүзенең сүз формаларын чагыштырыйк: страны – стран-# - странам;

– таркалу яки гадиләшү процесслары нәтиҗәсендә тамыр морфемалары һәм флексия бер-берсе белән бәйләнергә мөмкин; мәсәлән, рус телендәге “*нога*” исеменең юнәлеш килешендә, күплек сандагы формасы *ног-ами* буларак бүленә. Биредә -*а* кушымча составына керә, ләкин башта бу -*а* тематик суффикс ролен үтәгән, ә -*mi* кушымча булып торган; шулай ук рус

телендәге “печь” фигыленең инфинитивы pek-ti формасына барып тоташа.

Моннан тыш грамматик сыйфатлар сегмент морфемалар ярдәмендә генә түгел, ә фонемаларның тамыр эчендәге грамматик чиратлашуы (эчке флексия) нәтиҗәсендә дә барлыкка килергә мөмкин; мәсәлән, инглизчә *man – “кеше”* һәм *men – “кешеләр”, goose – “каз”* һәм *geese – “казлар”, find – “табалар”* һәм *found – “таптылар”*, яки немец телендәге *brechen – “ваталар”* һәм *brachen – “ваттылар”*. Мондый умлаут һәм сыну (приломление) кебек зур чиратлашулар немец телендә регрессив ассимиляция нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Мәсәлән, немец телендәге *sprechen* – “сөйләшергә” фигылендә, хәзерге заманның 2 һәм 3 затларында *e* урынына *i* ның барлыкка килүе (du sprichst, er spricht), кайчандыр аффикс составында *i* сузыгының булуы белән аңлатыла (борынгы немец телендә: sprich-ist, sprich-it). Әлеге сузык юкка чыккан, ләкин чиратлашу калган һәм тере чиратлашудан тарихи чиратлашуга әйләнгән;

– флектив телләрдәге кайбер сүзләрнең тамырлары еш кына аерым кулланыла алмый: мәсәлән, рус телендәге *бежа-ть, пи-ть* фигыльләренең форма ясый торган тамырлары.

Агглютинатив аффикслар исә киресенчә:

– иң күбе бер граммеманы белдерәләр (Ю.С. Маслов буенча гаплосемия күренеше);

– кагыйдә буларак, омосемик тәңгәллеккә ия түгелләр;

– бер үк грамматик күренешне белдерүдә конкурентлары булмау сәбәпле, бу мөнәсәбәттә – стандарт;

– нуль дәрәҗәсендәге экспонентка ия булмыйлар;

– сүзнең тамырыннан һәм бер-берсеннән төгәл рәвештә аерымланалар.

Моннан тыш, агглютинатив телләргә эчке флексия күренеше хас түгел. Ә аффикслар эчендәге фонемаларның чиратлашуы грамматикалашмаган. Бу чиратлашу инерцияле (прогрессив) ассимиляция нәтиҗәсендә барлыкка килә. Мәсәлән, күплек санны белдерә торган төрки *-лар/-ләр* аффиксындагы сузык [а] һәм [ә] авазларының чиратлашуы тамырның сузык авазлар рәте (алгы яки арткы) белән контрольдә тотыла: мәсәлән, төрек телендәге *adamlar* – “кешеләр” яки *evler* – “өйләр” сүзләре.

Агглютатив телләрдәге сүзләрнең тамырлары, нигездә, мөстәкыйльрәк, ягъни, алар җөмләдә аффикслардан башка да кулланылырга мөмкин.

Тел типологиясе бүгенге көндә тел күренешләренең тагын да зуррак өлешен чолгап ала. Грамматик категорияләрнең типологик яктан тикшерелүендә Санкт-Петербург типология мәктәбе вәкилләре – А.А. Холодович, В.С. Храковский, В.П. Недялков, А.П. Володин һ.б. галимнәрнең өлеше зур.

XX гасырда типология вәкилләрен тел системасының башка баскычлары да кызыксындыра башлады. Мәсәлән, ***фонологик классификация*** (Н.С. Трубецкой, Р.О. Якобсон) телләрнең фонемалар системасы төзелешендә, системада һәм текстта сузык һәм тартыкларның күләм мөнәсәбәтендә, иҗек структурасында, суперсегмент (просодик) берәмлекләрдә охшашлык һәм аермалыкларны эзләү белән шөгыльләнә.

Фонологик типология өчен иң әһәмиятле билге – телдәге төп фонетик берәмлекнең характеры. Андый төп берәмлек фонема булган телләрдә “фонема төзелешле” телләр турында фикер йөртелә. Бу – күпчелек телләр, ягъни телләрнең күбесендә төп фонетик берәмлек – фонема. Ә инде төп фонетик берәмлек иҗек (силлабема) булса, “иҗек төзелешле” телләр барлыкка килә (кытай, бирма, вьетнам).

Фонологик типологиядә икенче әһәмиятле билге – сүз һәм иҗекнең просодик характеристикасы. Бу билгегә карап тональ яки политоник телләр (кытай, бирма, вьетнам) монотоник телләргә (калган телләр) каршы куела; ирекле сүз басымына ия телләр басымы даими яки ярымдаими телләргә (һинд-европа, фин-угор) һәм басымсыз (тунгус-манчьжур) телләргә оппозициядә тора.

Фонетик һәм фонологик типология әлегә барлык телләр материалында да, барлык фонетик күренешләрне дә исәпкә алып эшләнеп бетмәгән. Бу өлкәдә тикшеренүләр дәвам итә.

XX гасырда төрле телләрнең синтаксик төзелешен өйрәнү галимнәрнед игътибарын үзенә аеруча җәлеп итә. Беренче чиратта бу субъект-объект мөнәсәбәтләренең белдерү ысулларын чагыштырма рәвештә өйрәнүгә кагыла (И.И. Мещанинов, Г.А. Климов, С.Д. Кацнельсон, Дж.Гринберг,

А.Е. Кибрик һ.б.). Бу юнәлешкә структур типология вәкилләренең Санкт-Петербург төркеме керткән өлеш зур.

***Синтаксик классификация*** өчен сүз тәртибен чагыштыруга нисбәтле тикшеренүләр кызыклы. Мәсәлән, субъектның (S), фигыль-предикатның (V) һәм объектның (O) урнашу тәртибе тәкъдим ителгән 6 формуланың берсе белән күрсәтелергә мөмкин: SVO, SOV, VSO, VOS, OSV, OVS. Рус телендә һәр алты форма да кулланылырга мөмкин, ләкин SVO формасы нейтраль, стилистик яктан тамгаланмаган дип санала.

S һәм O, S һәм V, S һәм O арасындагы мөнәсәбәтләр төрле була ала. Мәсәлән, S һәм V арасында ярашу булганда V, S га хас бер яки берничә граммеманы кабатларга мөмкин. Исем категориясе класслары булган телләрдә исә бу ярашу фигыль төзелешендәге төрле класс күрсәткечләре ярдәмендә билгеләнә. Мисалга авар телендәге күренешләрне китерергә була: в-ачӀана – “әти килде” һәм эбел й-ачӀана – “әни килде” (в-/й- фигыль яраштыручылары). V һәм O ны да шундый ук ярашу күренеше үзара бәйләргә мөмкин. Ярашу бер үк вакытта V ны S белән дә, O белән дә бәйләгән очракта, әлеге күренеш полиперсональ (ике, хәтта өч) төрләнеш исемен ала. Дәлил өчен, абхаз теленнән кайбер мисаллар: ды-з-беит – “аны (кешене)-мин-күрдем”, и-з-беит – “шуны (әйберне)-мин-күрдем”, и-бы-р-тоит – “шуны (әйберне)-сиңа (хатын-кыз, род белән төрләнгән) -алар-бирәләр”.

Синтаксик типологиядә сүз тәртибе һәм бәйлекләр арасында бәйләнеш тә күзәтелә. Бу нисбәттән ике класс аерыла: *уңга тармакланган* телләр (һинд-европа, семит, австронезия телләренең күбесе) һәм *сулга тармакланган* телләр (алтай һәм кавказ телләре).

Җөмлә төзелешендә исем конституентлары синтаксик функцияләренә карап (субъект, туры һәм кыек тәмамлык буларак) һәм семантик рольләрне башкаручы буларак тасвирланырга мөмкин (агенс – ситуациянең җанлы катнашучысы һәм пациенс – ситуацияне башлап җибәрмәгән, контрольдә тотмаган катнашучы).

Килеш төрләнеше хас булган телләрдә, фигыль-предикатның күчемле яки күчемсез, фигыльнең актив яки пассив формада булуына карамастан, S һәрвакыт (яки бик еш) исем килеше

белән белдерелә. Мондый төр телләр – *номинатив телләр* дип атала. Номинатив телләрдә туры тәмамлык гадәттә төшем килеше белән белдерелә (шуңар күрә аларның икенче исеме – аккузатив телләр). Актив конструкциядәге S – агенска, O пациенска кара-каршы куела. Пассив конструкциядә исә агенска – O, ә пациенска S кара-каршы куела. Күчемсез фигыль янәшәсендәге S пациенс буларак кабул ителергә мөмкин. Һинд-вропа телләре җөмләләренең номинатив төзелеше белән характерлана. Моннан тыш, номинатив телләргә абсолют күпчелек керә. Мәсәлән, афразия телләре, төрки телләр, монгол, тунгус-маньчжур телләре, тибет-бирма, Австриядәге телләрнең бер өлеше һ.б.

Әгәр субъектның килеш категориясе фигыльнең күчемле яки күчемсез булуына карап билгеләнә икән, димәк бу очракта *эргатив телләр* турында сүз алып барыла. Эргатив конструкцияләр һинд-иран, кавказ, эскимос-алеут, баск һ.б. телләргә хас. Күчемсез фигыльле җөмләләрдә S күчемле фигыльле объект өчен нормаль булган килеш белән төрләнә. Күчемле фигыльле S исә аерым килеш – эргатив килеш белән төрләнә. Шулай итеп, эргатив агенсны, ә абсолют (ягъни башка һәртөрле килеш) – пациенсны белдерә. Мәсәлән, баск телендәге берничә җөмләгә күз салыйк: *Ni-k gizona ikusi dat,* ягъни, “Мин кешене күрдем”. Биредә *nik* эргатив килештә, ә *gizona* исә абсолют килештә тора; *Gizona etorri da*, ягъни, “Кеше килде” җөмләсендә *gizona* абсолют килештә кулланылган. Эргатив телләргә кавказ телләре (грузин, убых), австронезия телләре (тонга), австралия телләре (дьирбал), папуас, чукот-камчат, эскимос-алеут һәм майя (тцелтал) телләре керә. Эргатив үзенчәлекләр, шулай ук, хинди һәм урду телләрендә дә чагыла.

*Актив төзелешле* телләрдә субъект һәм объект түгел, ә бәлки актив һәм пассив башлангыч бер-берсенә каршы куела. Актив (җанлы) исемнәр, нигездә, хәрәкәт фигыльләре белән, ә инактив исемнәр хәл (торыш) фигыльләр белән яраша. Агенс – агентив ярдәмендә, ә пациенс исә – инактив ярдәмендә белдерелә. Активлык яки инактивлык фигыль ярдәмендә бирелә. Гуарани теленнән бераз мисал: *o-hesa t-roga* – “Ул синең йортыңны күрә” һәм *ti-miri* – “Ул тыйнак”. Көнчыгыш помо теле: *ha ce.xelka* –

“Мин шуам (аңлы рәвештә түгел, ниятсез)”, *wi ce.xelka* – “Мин шуам (аңлы рәвештә, ният белән)”. Актив телләргә кайбер америнд телләре (дакота), лхаса-тибет, гуарани телләре керә. Моңа охшаш ләкин системага әйләнмәгән күренешне рус (*Меня знобит*, ягъни “Калтырата”) һәм немец телләрендә (*Mich friert* – шул ук мәгънәдә килә) күрергә була.

А.Е. Кибрик фикеренчә, җөмләнең номинатив, эргатив яки актив формасы өч функциональ факторның эшчәнлеге белән аңлатыла: бер-берсенә каршы куелган формаль чараларны экономияләү, мәгънә аеру тенденцияләре, дәлилләү факторлары.

Җөмлә кисәкләре типологиясе иянең универсаль булмавы, синтаксик конструкция һәм актантларның семантик рольләре арасында бәйләнеш, яңа яки мәгълүм булган кагыйдәләр хакындагы, коммуникатив-прагматик чагылыш спецификалары турындагы идеяләрне дәлилли.

Тел системаларының морфологик, синтаксик, фонологик дәрәҗәләрдәге типологик чагыштырулар бүгенге көндә бәйсез рәвештә уздырыла. Моның белән беррәттән, тел төзелешендә өстенлек иткән типологик билгеләрне эзләп табарга омтылу һәм бер типологик сыйфатларның икенчеләренә (мәсәлән, морфологик сыйфатларның синтаксик сыйфатларга) буйсынуларын билгеләү процесслары ешайды.

Типологик тикшеренүләр даирәсенә хәзерге көндә Африка, Австралия, Себер, Көньяк-Көнчыгыш Азия, Океания, Америка индеецларының телләре дә кертелә башлады.

Компаративистлар үзләренең игътибарларын кардәш телләрдәге типологик охшашлыкларга юнәлтә. Структур типология белән беррәттән, семантик, лексик һәм иҗтимагый-функциональ типология дә үсеш ала. Телнең коммуникатив һәм когнитив функцияләренең телнең формаль төзелешенә һәм үсеш тенденцияләренә тәэсирен өйрәнү кызыклы юнәлешләрнең берсенә әверелеп бара.

**Телләрнең ареаль классификациясе**

***Ареаль тел белеме***

Ареаль тел белеме бер телнең төрле диалектлары яки бер-берсе белән чиктәш булган телләрнең территориаль бүленешен

өйрәнә. Ареаль тел белеме XIX-XX гасырлар чигендә диалектологиядән аерылып чыга. Бу вакытка инде диалектологиядә сөйләшләр арасында төгәл чикләрнең булмавы һәм һәр тел изоглоссалар тарафыннан теркәлгән таралу үзенчәлекләренә ия дигән фикер хөкем сөрә. Ике чиктәш диалект арсында линия генә түгел, ә бәлки бер бәйләм изоглоссалар урын ала. Диалектларның чигендә күчеш (вибрация) зоналары да бар.

Бераз соңрак чиктәш телләр арасында да төгәл чикләрнең булмавы һәм аларның бер-берсенә үзенчә күчүләре турындагы фикерләр килеп чыга.

Ареаль тел белеме лингвистик география методыннан файдалана. Тоташ яки сайланма тикшеренүләр нәтиҗәсендә, килеп чыккан авазларның, лексик, грамматик күренешләрнең таралуын сурәтләгән изоглоссалар географик карталарга теркәлә. Телчеләр, үз чиратында, төрле карталарны чагыштырып, тел инновацияләренең нәрсә нәтиҗәсендә һәм кайда килеп чыгуын, ничек таралуын билгелиләр. Кайбер очракларда тел күренешләренең чикләрен генә түгел, ә икътисади, сәяси, этнографик, мәдәни чикләрне дә күздә тотарга кирәк була. Шулай итеп, теге яки бу телнең тарихын тулысынча өйрәнү мөмкинлеге туа, ә территориаль яктан чикләнгән телләргә килгәндә, телнең дивергенциясе һәм конвергенциясе белән танышуга юл ачыла.

Ареаль тел белеме синхроник булырга мөмкин, ләкин еш кына ул диахрониягә дә бәйле. Диахрония ярдәмендә гомум һинд-европа теленең диалектларга бүленеше, бу телнең кайбер конкрет тарихи чордагы диалект чикләре хакында, бүгенге аерым бер телнең тарихи диалектик бүленеше турында яңа билгеләр пәйда була. Диахрония ярдәмендә кайбер тел берләшмәләренең (Балкан, Кавказ, Үзәк Азия, Идел-Кама) ареаллары билгеләнә, юкка чыккан субстрат телнең йогынтысы ачыклана.

Телләрнең ***ареаль классификациясе*** ареаль тел белеме кысаларында барлыкка килә. Бу классификация мөстәкыйль булса да, ул генеалогик һәм типологик классификацияләр арасында тора. Ул генеалогик классификация эчендә дә, төрле генетик чыганаклы телләр өчен дә эшләнә ала. Ареаль

классификациядә контактлы күренешләр белән бәйле билгеләр әһәмияткә ия. Бер тел эчендә ареаль классификация телнең диалектларына бәйләп башкарыла. Болар лингвистик география фәненең нигезендә ята.

Ареаль классификация телләрне тышкы, урнашу ягыннан гына төркемли кебек. Мәсәлән, географик критерий нигезендә Кавказ һәм Африка телләре аерыла, төркем һәм төркемчә атамаларында төньяк, көнбатыш һ.б. шундый сүзләр очрый. Зур территорияләрдә һәм чиктәш булмаган урыннарда таралыш алган тел гаиләләре, хәтта аерым телләр була. Шулай ук дөньяда кардәш булмаган телләрдә сөйләшүче халыкларның кечкенә генә территорияләрдә янәшә яшәп ятулары мәгълүм. Мәсәлән, Кавказда һинд-европа, Алтай телләре гаиләләренең төрле төркемнәренә караган телләр таралыш алган. Һиндстанның көньягында, Африканың күпчелек районнарында, Яңа Гвинея утрауларында шул ук хәл күзәтелә.

Әмма ареаль классификациядә болар гына түгел, бәлки лингвистик фактлар да исәпкә алына:

1) янәшә яши торган халыклар һәм аларның телләре күпчелек очракта килеп чыгышлары ягыннан да бәйле була. Мәсәлән, тарихи география һәм тарихи этнология фәннәре мәгълүматлары буенча, Америка җирле халкының (аборигеннарның) телләре кардәш дип фараз ителә;

2) кардәш булмаган телләрдә дә, озак вакытлар бергә аралашып яшәү сәбәпле, охшаш сыйфатлар барлыкка килә. Мәсәлән, күрше телләрнең фонологик системаларында (басым, тартык һәм сузык авазлар, тон), синтаксисларында охшашлыклар табыла. Генетик яктан кардәш булмаган, әмма янәшә яши торган телләрдәге мондый охшашлыкларны *ареаль охшашлыклар* дип йөртәләр. Телләрне шундый тел фактлары охшашлыгына нигезләп төркемләү ареаль классификациянең нигезен тәшкил итә.

Телләрнең ареаль классификациясе дөнья телләре картасын төзүдән, аерым телләрнең яки телләр төркеменең таралыш ареалларын билгеләүдән гыйбарәт. Ареаль классификация *ареал, зона, тел берләшмәләре (союзы)* кебек категорияләр белән эш итә.

Ареаль лингвистикада иң төп төшенчәләрнең берсе – *тел* яки *диалект ареалы*, ягъни аерым тел күренешләренең яки җыелмасының, шулай ук аерым телләр һәм телләр төркеменең таралыш чикләре. Ареалларны тикшерү-өйрәнү нәтиҗәсендә аерым тел күренешләренең генә түгел, бәлки телләрнең, диалектларның һәм ареал гомумилекләренең – тел союзларының таралыш һәм үзара тәэсир итешү өлкәләре ачыклана.

Географик факторлар күп кенә тел күренешләрен аңлатуда мөһим роль уйный. Чикләре күренеп торган географик мохит (су чиге, тау һ.б.) телләр арасында да төгәл чикләр билгели (Океаниядәге австронезия телләре). Аермачык чиге булмаган географик мохит (тигезлек, яр буе), киресенчә, диалектлар чылбыры барлыкка китерә. Анда күршеләр бер-берсенең телен яхшы аңлый.

Географик факторлар телдәге үзгәрешләрнең характерын һәм тизлеген дә аңлатырга мөмкин. Мәсәлән, башка кардәш телләрдән географик изоляцияләнгән телләр консерватив була. Һинд-европа телләре гаиләсенә кергән телләр белән чагыштырганда, литва теленең консерватив булуы аның географик изоляциядә яшәве белән аңлатыла. Телдәге яңалыкларның да сәбәбе географик шартлар булуы ихтимал. Мәсәлән, славян һәм роман телләре чолганышында яшәү нәтиҗәсендә, гагауз телендә *“ия – хәбәр – тәмамлык”* рәвешендәге сүз тәртибе барлыкка килгән (башка төрки телләрдә “ия – тәмамлык – хәбәр”).

Лингвистик география лингвистик типология белән тыгыз бәйләнгән. Бу ике фән чигендә *тел берләшмәсе* (союзы) төшенчәсе барлыкка килә. Терминны Н.С. Трубецкой тәкъдим итә һәм ул чиктәш территорияләрдә таралган һәм кардәш булмаган телләр төзелешендәге охшашлыкларны аңлата. Тел берләшмәсе бер охшашлыкны гына түгел, ә телләр арасындагы күпсанлы һәм сизелерлек охшашлыкларны күздә тота. Шундый тел союзларының классик үрнәге – балкан телләре союзы. Аңа һинд-европа телләре гаиләсенең төрле төркемнәренә караган телләр керә: болгар, македон, яңа грек, албан телләре. Аларның фонетикаларында, грамматикаларында охшаш сыйфатлар бар, постпозитив артикль кулланыла. Бу билгеләр хәтта якын кардәш

телләрдә дә күзәтелмәскә мөмкин. Фәндә Идел-Кама тел союзы (төрки һәм кайбер Урал телләре керә), Һималай телләр союзы (һинд-европа телләре гаиләсенең иран һәм һинд төркемнәре керә), үзбәк-таҗик телләре союзы, Үзәк Азия телләре союзы турында тасвирламалар бар.

Чиктәш телләрнең бер-берсенә якыная баруы турында фикер йөрткәндә еш кына *диффузия* терминын да кулланалар: тел бәйләнешләре вакытында грамматик күренешләрнең бер класстан икенчесенә диффузияләнүе (үзара керешеп китүе) күзәтелә. Диффузия тел союзлары төшенчәсе белән чагыштырганда киңрәк төшенчә. Зур вакыт аралыгы үткәннән соң, төрле ареалларда таралган кардәш телләр белән чагыштырганда, бер ареалдагы кардәш булмаган телләр типологик яктан якынрак була башлый. Бу диффузия нәтиҗәсе буларак аңлатыла. Телләрнең территория нигезендә барлыкка килгән конвергенциясе генетик туганлыкка бәйле түгел дияргә була. Кардәш телләр дә, кардәш булмаганнары да тора-бара якынаерга мөмкин. Әмма шулай да конвергенция процессында кардәшлекнең турыдан-туры йогынтысы да бар: якын кардәш телләрдә лексиканың һәм грамматик сыйфатларның үтеп керүе массакүләм төс алырга мөмкин. Моны украин теленә поляк теленең тәэсире мисалында исбатларга була.

Телләрнең ареаль классификациясендә дөнья телләренең хәзерге һәм тарихи лингвистик картасы сизелерлек аерыла, ягъни классификациянең синхроник һәм диахроник аспектлары бүленеп карала. Тарихи сәбәпләр аркасында бер җирдә барлыкка килгән тел планетаның төрле урыннарында киң таралыш алырга мөмкин. Испан телендә сөйләшүче 300 млн. халыкның бары 30 млн.-ы гына Испаниядә яши, ә калганнары Латин Америкасында көн күрә. Алар да испан телен үз туган телләре саныйлар. Мәсьәләгә диахроник якын килү баба телне билгеләргә мөмкинлек бирә.

Фәндә күптөрле ареаль классификацияләре булуы мәгълүм. Мисал өчен, кайчак бөтен дөньяны өч гиперареалга бүләләр: *Иске дөнья (Старый свет), Яңа дөнья (Новый свет)* һәм *Океания.* Икенче төрле, җентеклерәк бүленешләр дә булырга мөмкин (бер телнең, диалектның таралыш ареаллары һ.б.).

Америка галиме Дж.Николсның хезмәтләрендә *сузынкы* һәм *йомык ареал*лар билгеләнә. Сузылган зоналар гадәттә тигезлекләрдә була һәм анда телләр генетик яктан бертөрле булу күзәтелә. Йомык зоналар исә географик чикләнгән (тау, океан, диңгез һ.б. белән) ареалларда барлыкка килә һәм генетик төрлелек белән аерылып тора. Мәсәлән, Евразия даласы – сузынкы зона, Кавказ – йомык зона.

Дөнья телләренең барысын да кертеп ясалган ареаль классификацияләр әлегә юк дәрәҗәсендә. Бу уңайдан үрнәк итеп А.Кибрик классификациясен[13] китерергә мөмкин. Ул үзенең "Дөнья телләре һәм тел ареаллары" хезмәтендә 10 макроареал аерып чыгара.

1. Африканың Сахарадан көньяктарак булган өлеше (нигер-кордофан, Нил-Сахара, койсан телләре керә).
2. Төньяк Африка һәм Якын Көнчыгыш (афроазиат телләре гаиләсе).
3. Үзәк һәм Көньяк Азия (һинд-европа телләре гаиләсенең һинд һәм иран төркеме, дравид телләре гаиләсе).
4. Кытай һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия (Кытай-Тибет, тай, австроазиат телләре гаиләсе).
5. Океания (австронезия һәм папуасс телләре).
6. Австралия.
7. Европа һәм Кавказ (һинд-европа телләренең калган төркемнәре һәм Кавказ телләре).
8. Төньяк Азия (Урал, Алтай, палеоазиат телләре)
9. Төньяк Америка.
10. Көньяк Америка.

Хәзерге көндә фәндә бу классификациядән дә камилрәк бүленеш күренми, шунлыктан телләрне ареаль яктан төркемләүне шуңа нигезләп күз алдына китерергә була.

**Телләрнең функциональ классификациясе**

Хәзерге фәндә телләрне яңача төркемләү буенча эзләнүләр дәвам итә. Алда санап үтелгән генеалогик, типологик һәм ареаль классификацияләрдән тыш, кайвакыт социолингвистик һәм социомәдәни, мәдәни-тарихи классификацияләрне, телләрнең

---

[13] А.Кибрик. Языки мира и языковые ареалы. 2008 (интернетресурс )

яшәүчәнлегенә карап төркемләүләрне дә күрсәтәләр. Дөрес, аларның үзенчәлекле классификацияләр буларак яшәүләре турында тел белемендә сүз алып бару әлегә кабул ителмәгән. Әмма шулай да мондый классификацияләрнең булу ихтималы, аларда каршы куелырга тиешле билгеләр (язусыз, борынгы язулы, иске язулы телләр; дәүләт телләре / рәсми телләр һәм рәсми булмаган телләр, гомуммилли, җирле һәм кабилә телләре һ.б) ачык күренеп тора.

Хәзерге дөньяның лингвистик картасы аның административ-сәяси картасы белән тыгыз бәйләнгән: дөнья телләре бу телләрдә сөйләшүче халыкларның саны, таралыш ареалы, иҗтимагый функцияләре, үз дәүләтендәге һәм аннан читтә абруе белән дә бер-берсеннән аерылып торалар. Телләрнең ***функциональ*** (иҗтимагый-функциональ, яки социологик) ***классификациясе***, кагыйдә буларак, күп планлы, чөнки анда тел һәм җәмгыятькә мөнәсәбәтле күп кенә даими һәм үзгәрүчән факторларны исәпкә алырга кирәк. Телләрнең тәмамланган функциональ классификациясен эшләргә тырышу, аның күп факторлы булуы аркасында, һәрвакытта да уңышлы нәтиҗәләргә китерми.

Тулы *функциональ классификация* бер төркем критерийларны исәпкә алырга тиеш дип саныйлар. Төп критерийлар итеп түбәндәгеләр билгеләнә: тере телләрдә сөйләшүчеләрнең саны; дөньяда үле һәм тере телләрнең саны; телләрнең этник территорияләрдән читтә таралышы һәм аларның хәзерге вакыттагы әһәмияте, роле; язулы һәм язусыз телләр; табигый һәм ясалма телләр; телләрнең иҗтимагый функцияләре, аларның яшәү формалары. Кайбер билгеләре буенча, хәзерге вакытта телләрнең функциональ классификациясен түбәндәгечә күзалларга мөмкин.

1. Этник гомумилек белән бәйләнешләренә карап, өч тел тибын аерып була: *халык теле, кабилә теле* һәм *милли телләр*. Телнең иҗтимагый тибын халыкның иҗтимагый бергәлеге билгели.

2. Этник территориядән читтә таралуы һәм телнең хәзерге дөньяда тоткан урыны *җирле телләрне*, аерым төбәкләрдә яшәүче халык кына куллана торган *төбәк телләрен, халыкара*

*аралашу телләрен* һәм *дөнья телләрен* (БМО телләре – инглиз, француз, кытай, испан, гарәп, рус) билгеләргә нигез бирә.

3. Җәмгыятьтә үтәгән функцияләре һәм яшәү формалары буенча, *әдәби телләр* һәм *диалектлар, дәүләт телләре, культ* яки *ритуал телләр* һ.б. аерыла.

Теге яки бу тел коллективына хезмәт итә торган иҗтимагый-коммуникатив система компонентлары бер-берсе белән билгеле бер мөнәсәбәтләрдә торалар. Тел коллективы үсешенең һәрбер этабында бу мөнәсәбәтләр күпмедер дәрәҗәдә даими була. Әмма бу алар һич тә үзгәрмиләр икән дигәнне аңлатмый. Илдә сәяси ситуация үзгәрү, икътисади үзгәртеп корулар, иҗтимагый һәм милли сәясәттә яңа ориентирлар пәйда булу һ.б. – барысы да иҗтимагый-коммуникатив системага да тәэсир итә, аның составына һәм функцияләренә йогынты ясый.

Җир шарының төрле төбәкләрендә һәм илләрендә телләр төрле ситуацияләргә куелган, чөнки һәр дәүләттә аерым телләр яшәешенең үз иҗтимагый, тарихи, мәдәни һәм иҗтимагый шартлары бар. Мәсәлән, күпчелек Африка илләрендә дәүләт үзәген тәшкил итәрдәй милләт юк. Шул ук вакытта аларда берничә дистә кабилә һәм халык теле кулланыла. Кагыйдә буларак, бу телләрнең күбесе язусыз, терминология эшкәртелмәгән, шунлыктан күп кенә коммуникатив функцияләрне үти алмыйлар.

Телләрнең функциональ классификациясе дөньяда тел ситуацияләренең үзенчәлекләрен күзалларга ярдәм итә, телнең җәмгыятьтәге функцияләрен характерлый.

Карап үтелгән классификацияләрнең эчтәлегендә аермалар булуы бәхәссез, бу үзенчәлекләр аларның логик төзелешендә дә чагылыш таба. Иң элек аларны *табигый* һәм *ясалма* классификацияләргә бүлеп булыр иде, чөнки аларның кайберләре тикшеренүчеләр уйлап тапкан критерий-билгеләр буенча башкарыла һәм шунлыктан алар күппланлы, күптөрле. Боларны ясалма классификацияләр дип билгеләп була (типологик, функциональ классификацияләр). Икенче төркем классификацияләр күренешләрнең табигый асылын ачыклыйлар, аларны исә күп телләргә ирексезләп тагып булмый, бу билгеләр ярдәмендә “күплек эчендә бердәнбер тел” ачыклана (генеалогик,

ареаль классификацияләр). Шунлыктан генеалогик һәм типологик классификацияләрнең күплеге материалны төрлечә шәрехләүне түгел, ә белемнәрнең җитеп бетмәвен генә күрсәтә.

Икенчедән, генеалогик һәм типологик классификацияләр күпсанлы телләрне тулаем бүлүгә нигезләнә, ә ареаль классификациядә исә телләрнең якынлыгы нигезендә барлыкка килгән аерым охшашлыклар гына билгеләнә. Теләсә кайсы классификациядә “калдык”лар, бәхәсле очраклар була. Ареаль классификациядә дөнья телләренең күпчелеге шундый очракны тәшкил итсә дә, моңа артык борчылырга нигез юк кебек. Ә инде генеалогик классификациядә урнаша алмаган телләр әлеге классификациянең дөреслегенә шик тудырырга мөмкин. Тиешле параметрлар сайлап алынганда, типологик классификациягә “калдыксыз” бүленеш характеры бирергә дә мөмкинлек бар.

Шушы очракларны исәпкә алганда, телләрне төркемләүләр арасында “төп” классификация буларак генеалогик классификация карала. Теләсә кайсы идиоэтник телне тасвирлаганда аның кайсы тел гаиләсенә каравы билгеләнә. Әгәр дә андый мәгълүмат булмаса, бу аның иң мөһим үзенчәлеге буларак күрсәтелә. Менә шуңа күрә генеалогик классификация дөнья телләрен төркемләүдә үзенчәлекле, дәрәҗәле урын били.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Дөньядагы телләрнең санын билгеләү проблемасының асылын аңлатыгыз.

2. Дөньядагы телләрне нинди принциплар буенча төркемлиләр?

3. Генеалогик принцип нидән гыйбарәт?

4. Телләрнең кардәшлеген ничек билгелиләр?

5. Тел гаиләсе, телләр төркеме, кардәш телләр, баба тел төшенчәләрен аңлатыгыз.

6. Иң зур тел гаиләләрен атагыз.

7. Дөнья картасында тел гаиләләрен билгеләргә өйрәнегез.

8. Тел гаиләләренең үз эчендә төркем-төркемчәләргә бүленүен конкрет тел гаиләләре мисалында сөйләгез.

9. Телләрне гаиләләргә нисбәттә төркемләргә өйрәнегез.

10. Лингвистик классификациянең нинди төрләре бар?

11. Морфологик, фонетик, синтаксик классификацияләрнең асылын аңлатыгыз.

12. Ареаль классификациядә телләр ничек төркемләнә?

13. Дөнья картасында телләрнең ареалларын билгеләргә өйрәнегез.

14. Функциональ классификациядә нинди критерийлар исәпкә алына?

## ТЕЛ БЕЛЕМЕНЕҢ МЕТОДОЛОГИЯСЕ ҺӘМ МЕТОДЛАРЫ

Теләсә кайсы фән үз методларын эшкәрткәннән соң гына үзен кешелек белемнәренең үзенчәлекле бер тармагы буларак таныта ала. Теге яки бу чорда тиешле методларның өстенлек итүе күп очракта фән үсешенең гомуми характерын билгели.

Гомуми тел белеменең төп проблемаларыннан берсе лингвистика методларына бәйле.

Хәзерге тел белемендә инде күп еллар дәвамында тел турындагы фәннең барлыкка килүен кайсы еллар белән билгеләргә һәм аны борынгымы, әллә чагыштырмача яшь фән дип билгеләргәме, дигән сораулар тирәсендә бәхәсләр тынмый. Бу нисбәттән, галимнәрнең карашлары икегә бүленә. Беренчеләре тел белеме тарихын борынгыдан, тел шул чор фәненең методлары һәм ысуллары белән фәнни тикшеренүләргә җәлеп ителгән заманнардан башлыйлар. Европада тел турындагы фәннең яралгылары классик борынгы чорга карый, ә башка илләрдә һәм кыйтгаларда, мәсәлән, Һиндстанда тел белеменең чишмә башы тагын да тирәнгәрәк – безнең эрага кадәр берничә гасыр элегрәк вакытлар белән билгеләнә. Икенче караш буенча, тел фәненең барлыкка килүе соңрак чорга, төгәлрәк әйткәндә, XIX гасырның беренче чирегенә карый дип белдерелә. Бу төркем галимнәр моны шушы елларда Ф.Бопп, Р.Раск, А.Х. Востоков һәм Я.Гримм хезмәтләрендә телне тикшерү һәм тасвирлау өчен тел белемендә моңарчы булмаган махсус метод эшкәртелү белән дәлиллиләр, әлегә кадәр телнең башка фәннәр, аеруча фәлсәфә белән комплекста гына тикшерелүен ассызыклыйлар. Башкача әйткәндә, икенче караш буенча фикер йөртүчеләр үз фәннәренең барлыкка килүен махсус метод уйлап табылу белән бәйлиләр.

Тел белеме теоретиклары фикеренчә, нинди дә булса юнәлешнең танылуы өчен төп билге – аның үз методы булу. Нәкъ менә метод тел фактларын тасвирлау аспектларын барлыкка китерә, тикшеренүләрне тәртипкә сала. Мисал өчен, компаративистика чагыштырма-тарихи метод эшкәртелү нәтиҗәсендә барлыкка килә; структурализм дескриптив һәм

трансформацион методлар белән эш итә; функционализм кысаларында барыннан да бигрәк кыр методы кулланыла һ.б.

Әмма теориягә нисбәттә, метод икенчел күренеш. В.А. Звегинцев фикеренчә, “метод үзе генә һәр фәндә әһәмиятле булган объектны танып белү юлы түгел. Метод теория белән билгеләнгән, теориягә “хезмәт иткән” танып белү чарасы булырга мөмкин; ул теориядә кулланылган системаларны һәм гипотезаларны тикшерү, төзәтмәләр кертү өчен эмпирик фактлар бирә”.

Шунысын да билгеләү мөһим: методлар теориясен ахыргача эшкәртелгән дип санап булмый. Әлеге проблеманы анализлаучы галимнәр методта өч төшенчә табалар (төрле концепцияләрдә бу төшенчәләр төрлечә):

1. Танып белү ысулы (фәлсәфә методы, танып белү методы).
2. Фәнни-тикшеренү алымнары җыелмасы (махсус методлар).
3. Анализ кагыйдәләре җыелмасы (анализ алымнары).

Б.А. Серебренников концепциясендә фәлсәфә аспекты метод теориясенә кертеп карала, фәнни-тикшеренү методлары системасы түбәндәгеләрдән тора дип билгеләнә:

1. Метод теориясе (методның лингвистик нигезләре, фәнни-тикшеренү методларын куллану методикасы, гомуми танып белү теориясе нигезләре).
2. Эчтәлекләре методның лингвистик нигезләре ярдәмендә билгеләнгән фәнни-тикшеренү алымнары комплексы.
3. Техник алымнар һәм процедуралар комлексы.

Ю.С. Степанов буенча, зур үсешкә ия метод системасы өч өлештән гыйбарәт:

1. Яңа материалны ачыклау һәм фәнни методикага кертү ысуллары мәсьәләсе (совет тел белемендә “методика”, Америка тел белемендә “предлингвистика”).
2. Әлеге материалны системалаштыру һәм аңлату ысуллары мәсьәләсе (совет тел белемендә “метод”, Америка тел белемендә “микролингвистика”).
3. Системалаштырылган һәм аңлатылган материалның чиктәш фәннәр, барыннан да бигрәк фәлсәфә мәгълүматларына нисбәте һәм нисбәтләү ысуллары турында мәсьәлә (совет тел

белемендә “методология”, Америка тел белемендә “металингвистика”).

Ю.С. Степанов барлык методларны *гомуми* һәм *хосусый* диган төрләргә бүлә. *Гомуми методлар* – телне тикшерү-өйрәнүнең билгеле бер лингвистик теория һәм гомуми методологияләр белән бәйле теоретик нигезләмәләренең, ысуллар һәм методикаларының гомумләштерелгән җыелмалары; *хосусый методлар* – техник ысул, телнең теге яки бу аспекты өчен корал кебек билгеле бер теоретик нигезләмәләргә таянган аерым алымнар, методикалар, операцияләр.

Алда әйтеп үтелгән концепцияләрдәге фикерләрне йомгаклап, методның ике төп компонентын аерырга мөмкин:

1. Тел һәм сөйләм фактларын анализлауга нәкъ менә шулай якын килүнең теоретик нигезе.

2. Шуннан килеп чыккан тикшеренү методикасы.

Хәзерге лингвистик методның беренче компонентына килгәндә, бүгенге көндә тел белемендә лингвистик парадигмаларның алышынуы күзәтелә: тел күренешләрен статик халәттә өйрәнүдән аларны яшәү процессларындагы динамикада өйрәнүгә күчү бара. Бу факт тел белеменең үсеш логикасына бәйле: XIX гасырда теге яки бу тел элементларының барлыкка килүенә игътибар ителә; XX гасыр урталарында бу тел берәмлекләренең барыннан да бигрәк төзелеше анализлана; хәзер исә бу элементларны динамикада, кулланылыш процессында өйрәнү ихтыяҗы барлыкка килде.

Лингвистика фәненең бөтенлеген һәм дәвамчанлыгын тәэмин итеп, методлар үзара тыгыз бәйләнгән һәм башка методларга хас анализ методикалары һәм алымнары хисабына тулыланалар. Мисал өчен, функциональ метод структур тикшеренүләр алымнарыннан ихтималлылык-статик методиканы, чагыштырма-тарихи методны актив файдалана һ.б.ш.

Методның икенче компонентына килгәндә, фактик материалны анализлауның конкрет алымнарын куллану нигезендә методология – тышкы тирәлекне аңлау һәм танып белү юлын билгели торган дөньяга фәлсәфи караш ята.

Теге яки бу методны сайлауда *тышкы* һәм *эчке шартлар* аерып карала. Фактларны тышкы яктан, объектив өйрәнгән

вакытта тикшеренүче стихияле яки аңлы рәвештә түбәндәгеләргә нигезләнә:

1. Материалның беренчел, аңның икенчел булуы.

2. Дөньяны танып белү мөмкинлеге.

3. Фәнни нәтиҗәләрнең дөреслеген практик яктан тикшерү һ.б.

Тишеренү методларын сайлау булган фактик материалның, бу фән буенча тупланган теоретик белемнәрнең, галимнәрнең тикшеренү объекты һәм максаты турында күзаллауларының һ.б. күләме кебек эчке фәнни факторларга да бәйле.

Кешелек белемнәренең бөтенлеге, бердәмлеге бер өлкәдә зур фәнни ачышлар ясарга ярдәм иткән идеяләр һәм методларның еш кына икенче фәнни өлкәләрдә дә уңышлы кулланылуына китерә. Ю.С. Степанов тел анализлау методлары һәм алымнары белән артык мавыгудан кисәтә; фән алдында төрле фәннәр күзлегеннән, төрле методлар ярдәмендә хәл ителергә тиешле проблемалар булуын искәртә.

Күпсанлы анализ алымнарын куллану фәннең актив халәттә булуын күрсәтә, ә бу вакытта алынган нәтиҗәләр теоретик һәм гамәли әһәмияткә ия.

Традицион методлар белән алынган нәтиҗәләрнең дә, заманча методлар куллану биргән мәгълүматларның да гамәли әһәмияте булырга мөмкин. Мәсәлән, тасвирлама грамматикалар, аңлатмалы һәм этимологик сүзлекләр, телләрне укыту методикалары тасвирлама метод ярдәмендә булдырыла. Телне традицион методлар ярдәмендә тасвирлау барышында алынган матераллар укыту-педагогик максатларда иркен файдаланыла, ә телне математик тикшерүләр, трансформацион грамматикалар мәгълүматны табигый һәм ясалма телләрдә эшкәртү өчен кулланылалар. Һәр метод үз алдына хосусый бурычлар куйса да, ахыр чиктә бер үк максатны – белемнәр туплауны күздә тота. Әмма монда төп шарт – бу белемнәр, нинди юл белән табылуга карамастан, бер үк кыйммәткә ия булырга тиеш. Бу нисбәттән моны алтын белән чагыштырырга мөмкин: кемдер аны зур көч белән эзләп таба, ә кемгәдер ул җиңел генә әти-әниләреннән мирас булып күчә – әмма болар алтынның бәясенә тәэсир итми. Белем дә шулай ук.

Традицион лингвистика казанышлары тел турындагы фәнгә барлык иҗтимагый фәннәр арасында иң төгәле дигән лаеклы дан китерде.

Фәндә методлар һәм методикаларны *гомумфәнни* (барлык яисә күпчелек фәннәрдә кулланыла торган) һәм хосусый фәнни (аерым бер тармакта гына кулланылган) дигән төрләргә бүлү яшәп килә. Беренчеләренә индукция, дедукция һ.б. керә, ә икенче төркемгә, мисал өчен, чагыштырма-тарихи метод һ.б. карый.

Фән куллана торган танып белү чаралары һәм алымнары җыелмасы фәнни тикшеренүләрнең *методика*сын барлыкка китерә. Әлеге методика тикшеренү өчен сайлап алынган объектка бәйле рәвештә төрле булырга мөмкин. Әмма аны эшкәртү һәм куллану тикшеренүченең чынбарлыкка мөнәсәбәттә нинди принципиаль позициядә булуыннан тора.

**Тел белемендә гомумфәнни методлар**

*Чагыштыру* барлык фәннәрдә дә кулланыла, чөнки элеккеге һәм яңа мәгълүматларны, тикшеренүләрнең төрле нәтиҗәләрен һ.б. һәрвакыт чагыштырырга кирәк. Тел белемендә чагыштырма-тарихи һәм тиңләштермә (сопоставительный) методларның нигезендә әлеге метод ята.

*Индукция* аерым хосусый күзәтүләр нәтиҗәсен гомумиләштерүдән гыйбарәт. Танып белүнең әлеге юлы тәҗрибә мәгълүматларыннан аларны системалаштыруга таба баруны һәм системалаштырылган мәгълүматлардан эмпирик законнар ачуны күздә тота. Тел белемендә индукция методы ярдәмендә сүзнең төп билгеләре, сүзләрнең семантик-грамматик төркемнәре, җөмләнең сүзгә мөнәсәбәте кебек мәсьәләләр ачыклана.

*Дедукция* я постулат саналган, яисә хосусый күзәтүләрнең нәтиҗәләрен якынча гомумиләштерү юлы белән табылган нигезләмәләргә таяна. Еш кына эмпирик ачышларга кадәр булган фактлар дедукция ярдәмендә алдан күрелә һәм фаразлана (мәсәлән, Д.И. Менделеев галлий, скандий һәм германийны шулай ача). Лингвистикада, мәсәлән, түбәндәге сораулар дедуктив чишелеш таләп итә: Сөйләм чылбырының шушы өлеше сүз буламы? Әлеге сүз нинди семантик-грамматик класска карый? һ.б.

*Анализ* – күңелдән (яки эксперимент юлы белән) кисәкләргә таркату яисә аерым-аерым өйрәнү өчен предметның сыйфатларын аерып чыгару. А.А. Потебня рус телендәге творительный падеж семантикасын шулай анализлаган.

*Синтез* – нәрсәнең дә булса состав өлешләрен яки сыйфатларын кушу һәм бербөтен итеп өйрәнү. Синтез күбрәк җөмлә кисәкләрен, текст төзелешен һ.б. тикшергәндә кулланыла.

*Гипотеза,* аерым өлешләренең һәм сыйфатларының эчке бәйләнешләре буенча, өйрәнелә торган предмет турында синтетик яктан тулы күзаллау бирә. Әлеге бәйләнешләр алдан, тәҗрибәгә кадәр ачыклана; аларның булуын, билгеле бер характерларын белгән хәлдә, реаль фактларны аңлату һәм фаразлау мөмкинлеге тудырыла. Гипотезалар ихтимал булган чишелешләрне генә белдерәләр, алга таба тикшеренүләр барышында аларның дөреслеге я раслана, я кире кагыла. Расланган, ягъни фактлар белән туры килгән гипотеза фәнни теориягә әйләнә.

**Тел белемендә хосусый методлар**

Тел белемендә хосусый методлар XIX гасырда гына барлыкка килә башлый. Болар, иң беренче чиратта, телләрне чагыштырма-тарихи өйрәнү методлары була. XX гасырда структуралистлар бер төркем методлар тәкъдим итә. Бераз соңрак телне өйрәнүдә математик метод күренә, иң соңыннан функциональ методлар пәйда була.

Телне өйрәнүнең хосусый методлары барысы да кешенең сөйләм эшчәнлегенең үзенчәлекле аспектларын танып белүгә йөз тота һәм лингвистик мәсьәләләрнең аерым төркемнәрен чишәргә мөмкинлек бирә.

*Телләрне чагыштырма-тарихи һәм типологик өйрәнү методлары*

Әлеге методлар түбәндәге алымнардан гыйбарәт:

1. Кардәш телләрнең яңгырашы буенча якын сүзләрен, белдергән мәгънәләрен исәпкә алып, чагыштыру.

2. Бер телнең төрле тарихи чорлардан алынган, фонемалар яки семемалар составын үзгәрткән сүзләрен чагыштыру.

3. Үзара тәэсир итешүче телләрне чагыштыру. Бу алынмаларның чыганагын, һәр телнең алган яңа телдәге ролен (субстрат, суперстрат, адстрат) ачыклау өчен эшләнә.

4. Диалект күренешләрен картага төшерү. Бу аларның әлеге телдә сөйләшүчеләр яшәгән территорияләрдә таралышын күрсәтә. Барлыкка килгән карталар тел вәкилләренең таралу юлларын, архаик һәм яңа лексемалар белән сүз формалары нисбәтен, яңа сүзләр һәм күренешләрнең таралу үзәкләрен һәм перифериямләрен ачык күрсәтә. Картага төшерү өчен диалекталь материалны җыю, аларны картада сурәтләү алымнары һәм карталарны уку, шәрехләү кагыйдәләре эшләнгән.

5. Кардәшлекләренә карамыйча, территориаль контактларының булу-булмавына игътибар итмичә, төрле телләрнең системаларын чагыштыру.

Телләрне чагыштырма-тарихи һәм типологик өйрәнүнең барлык методлары телләр арасындагы кардәшлек яки кардәш булмау мөнәсәбәтләрен, территориаль һәм мәдәни багланышларның булу-булмавын, тел системаларының гомумкешелек һәм милли үзенчәлекләрен ачыклауга юнәлдерелгән. Бу методлар барысы да телләрнең тарихи үсеше проблемаларын җәмгыять тарихы белән бәйләнештә карауга хезмәт итә.

*Телләрне өйрәнүдә структур методлар*

Бу методлар XX гасырда кеше аңында яшәгән тел системасын өйрәнү, аның элементларын һәм структурасын танып белү өчен уйлап табыла.

1. Фонемалар системасы элементы буларак фонеманы аерып чыгару һәм, фонемалар системасын төзү өчен, фонемалар арасындагы оппозицияләрне ачыклау методлары.

2. Телнең теге яки бу берәмлегенә үз тирәлегендә, янәшәдәге берәмлекләр белән ярашуында дистрибутив анализ ясау. Үз тирәлекләренә бәйле рәвештә, берәмлекләр, тел системасындагы урыннарын билгеләү өчен, классларга бүленергә мөмкин.

3. Алга таба җөмләне парлы кисәкләргә таркату юлы белән, җөмләне тәшкил иткән кисәкләргә анализ; тел текстларын анализлауны һәм синтезлауны күздә тота.

4. Трансформацион анализ. Аның ярдәмендә бер үк пропозиция яки денотатив ситуацияне белдергән синтаксик төзелмәләр классы ачыклана (сестра читает книгу – книга читается сестрой – чтение книги сестрой).

5. Семемаларны семаларга аера торган компонентлы анализ.

Хәзерге көндә дә телне анализлауда структур методлар уйлап табу дәвам итә.

*Телне өйрәнүдә математик методлар*

Әлеге методлар XX гасыр урталарында үсеш ала һәм моңа ул заманда киң кулланылышка керә башлаган электрон хисаплау машиналары (ЭВМ) ярдәмендә машина тәрҗемәсе перспективалары этәргеч бирә.

Текстларны машинага кертү өчен эшкәрткәндә телнең аерым якларының микъдари бәяләре турында мәгълүмат алына; алар телнең математик моделен төзүдә гамәли куллану өчен генә түгел, бәлки лингвистик теория өчен дә мөһим һәм файдалы була. Математик методлар арасында математик статистика, информация теориясе һәм математик логика методлары лингвистика өчен аеруча күп мәгълүмат бирә.

1. Статистик методлар тел чараларының функциональ стильләрдә таралышын, язучының индивидуаль стиль үзенчәлекләрен һ.б. билгеләгәндә файдаланыла.

2. Информация теориясе методлары техник элемтә чаралары ярдәмендә мәгълүмат тапшыруны яхшырту өчен кулланыла. Бу методлар ярдәмендә, мисал өчен, эшлекле стильнең кирәгеннән артык булуы ачыкланган; иң югары билгесезлек (энтропия) алдан әзерләнмәгән телдән сөйләмдә күзәтелүе билгеләнгән.

3. Математик логика кысаларында символик тел эшкәртелә, аның ярдәмендә фикерләр һәм фикерләр арасындагы логик бәйләнеш, төшенчәләр, төшенчәләр классы һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләр тасвирлана.

Математик методлар, нигездә, телнең микъдари характеристикаларын өйрәнү өчен уңайлы. Телне математик яктан өйрәнү методлары алда санап үтелгәннәр белән генә чикләнми, әмма калган методлар телне машиналар ярдәмендә эшкәртүгә хезмәт итәләр.

*Функциональ методлар*

Функционализмның төп таләбе – телне хәрәкәттәге хәлендә, функцияләрен үтәгән вакытта өйрәнү. Шуңа бәйле рәвештә, функциональ методлар тел элементларының яшәү үзенчәлекләрен һәм аларны куллануга тәэсир итә торган факторларны ачыкларга мөмкинлек бирәләр. Мисал өчен, продуктивлык принцибы буенча төзелгән *кыр методын* куллану яңа барлыкка килгән һәм юкка чыга барган күренешләрне ачыкларга, телдә барган процессларны билгеләргә булыша.

Методларның һәр төркеме үз өлкәсендә кулланыла һәм үз бурычларын хәл итә. Алай гына да түгел, тел эшчәнлегенең төрле якларын өйрәнгәндә бу методлар бер-берсен тулыландыра. Мисал өчен, структур методлар тел системаларының тарихи үзгәреш закончалыкларын тирәнрәк аңларга ярдәм итте. Типологик чагыштырулар телләрнең милли үзенчәлекләрен ачты. Математик методлар телләр төзелешендәге һәм яшәешендәге күп аермалыкларны билгеләде.

Шул рәвешчә, һәр фәндә кулланыла торган методлар фәннең үзенчәлеге; тикшеренүче-галимнәрнең фәннең асылы, килеп чыгышы, үсеше һ.б. турында күзаллаулары; фәннең һәм аңа чиктәш / чиктәш булмаган фәннәрнең үсеш дәрәҗәсе; тикшерүгә дучар ителгән фактик материалның күләме; тикшеренүчеләрнең максат-бурычлары һ.б. шартлар белән билгеләнә.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Тел турындагы фәннең барлыкка килүенә нисбәттә галимнәр нинди фикерләрдә торалар?

2. Методлар теориясен эшкәртүче галимнәр методта нинди төшенчәләр табалар?

3. Б.А. Серебренников концепциясендә фәнни-тикшеренү методлары системасы нәрсәләрдән тора дип билгеләнә?

4. Ю.С. Степанов фикеренчә, метод системасы нинди өлешләрдән гыйбарәт?

5. Методның ике төп компонентын атагыз.

6. Тел белемендә кулланыла торган гомумфәнни методларга нәрсәләр керә?

7. Гомумфәнни методларны аерым-аерым аңлатып бирегез.

8.Тел белеменең хосусый методлары дип нәрсәләргә әйтәләр?

9. Телләрне чагыштырма-тарихи һәм типологик өйрәнү методларын тасвирлагыз.

10. Телләрне өйрәнүдә структур методларга нәрсәләр керә?

11. Телне өйрәнүдә нинди математик методлар кулланыла?

12. Функциональ методларның төп максаты нәрсәдә?

# ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


Алефиренко Н.Ф. Лингвокультурология: Ценностно-смсысловое пространство языка: Учебное пособие. – М.: Флинта, 2010. – 284 с.

Алефиренко Н.Ф. Теория языка. Вводный курс: Учебное пособие для студ. филол. спец. высш. учеб. заведений. – 4-е изд., стер. – М.: Издательский центр «Академия», 2010. – 384 с.

Алифанова О.Г., Исаев Д.В., Рыхлова О.С. Перспективные научные исследования в языкознании [Электронный ресурс]. – М.: ФЛИНТА, 2012. – 200 с. – Режим доступа: http://e.lanbook.com/book/4655.

Ахунзянов Э.М. Общее языкознание. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1981. – 256 с.

Ахунзянов Э.М. Русские заимствования в татарском языке. – Казань: Изд. Казан. ун-та, 1968. – 367 с.

Белая Г.В., Симонов К.И. Введение в языкознание: Учебное пособие. – М.: ТЕЗАУРУС, 2010. – 304 с.

Беликов В.И., Крысин Л.П.. Социолингвистика. – М.: РГГУ, 2001. – 439 с.

Бодуэн де Куртенэ И.А. Общее языкознание. Избранные труды. – М.: Юрайт, 2017. – 343 с.

Боронникова Н.В. История лингвистических учений: Учебное пособие. – М.: Директ-Медиа, 2013. – 524 с.

Будагов Р.А. Введение в науку о языке. – М.: Добросвет-2000, 2002. – 544 с.

Введение в языкознание: Программы и учебно-методические материалы для студентов 1 курса по специальности «05.03.02. – Родной язык и литература» / Сост. И.С.Насипов. – Стерлитамак: СГПА, 2007. – 36 с.

Вежбицкая А. Язык. Культура. Познание. – М.: Рус. словари, 1997. – 412 с.

Верещагин Е.М., Костомаров В.Г. Язык и культура: Лингвострановедение в преподавании русского языка как иностранного. – 4-е изд., перераб. и доп. – М.: Русский язык, 1990. – 246 с.

Виноградов В.В. История русских лингвистических учений. – М.: Высш. шк., 1978.

Воробьев В.В. Лингвокультурология: Монография. – М.: Изд-во РУДН, 1998. – 336 с.

Гируцкий А.А. Введение в языкознание. – Минск: ТетраСистемс, 2005. – 288 с.

Гируцкий А.А.Общее языкознание: Учебник. – Мн.:Вышэйшая школа, 2017. – 238 с.

Гомуми тел гыйлеме. Программа һәм аерым темаларның кыскача методик эшкәртмәсе: Татар филологиясе факультеты студентлары өчен / төз. И.Б. Бәширова. – Казан: КДУ , 2003. – 48 б.

Горбачевский А.А. Теория языка. Вводный курс: Учебное пособие. – М.: Флинта: Наука, 2011. – 280 с.

Городецкая Л.А. Лингвокультура и лингвокультурная компетентность: монография. – М.: КДУ, 2009. – 264 с.

Гречко В.А. Теория языкознания. – М.: Высшая школа, 2003. – 375 с.

Даниленко В.П. Общее языкознание и история языкознания [Электронный ресурс]: Учеб. пособие. М.: ФЛИНТА, 2016. – 272 с. – Режим доступа: https://e.lanbook.com/reader/book/84584/#1.

Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 351 с.

Җамалетдинов Р.Р., Нурмөхәммәтова Р.С. Тел белеме нигезләре. – Казан: Ихлас, 2014. – 240 б.

Зайнуллин М.В., Зайнуллина Л.М. Общие проблемы лингвокультурологии: курс лекций. – Уфа: РИЦ БашГУ, 2008. – 204 с.

Закиев М.З. Татарская грамматика. Том 3. Синтаксис. – Казань, 1995. – 576 с.

Закиев М.З. Татары: Проблемы истории и языка. – Казань, 1995. – 464 с.

Замалетдинов Р.Р. Национально-языковая картина татарского мира: дис. ... докт. филол. наук. – Казань, 2004. – 499 с.

Замалетдинов Р.Р. Теоретические и прикладные аспекты татарской лингвокультурологии. – Казань: Магариф, 2009. – 351 с.

Иванян Е.П. Общее языкознание. Теория языка. Ч. 2: курс лекций. – М.: ФЛИНТА, 2019. — 463 с.

Иванян Е.П. Общее языкознание. Теория языка. Часть 2 [Электронный ресурс]: учеб. пособие. – М.: ФЛИНТА, 2014. – 463 с. – Режим доступа: https://e.lanbook.com/reader/book/47593/#1.

Казанская лингвистическая школа: Книга первая: Казанская тюркская лингвистическая школа / сост.М.З.Закиев. – Казань: Татар.кн.изд-во, 2008. – 424 с.

Кодухов В.И. Общее языкознание. Учебник для студентов филол. специальностей ун-тов и пед. ин-тов. – М.: Высш. шк., 1974. – 303 с.

Колесов В.В. История русского языкознания. В 2 томах. Том 1. [Электронный ресурс]: Учебник для вузов. – М.: Юрайт, 2018. – 332 с. – Режим доступа: https://biblio-online.ru/viewer/2911ADF8-CF9C-4EDFA18A-CF0EAD3F8FD7#page/2.

Колесов В.В. История русского языкознания. В 2 томах. Том 2. [Электронный ресурс]: Учебник для вузов. – М.: Юрайт, 2018. – 350 с. – Режим доступа: https://biblio-online.ru/viewer/9D098EA8-16CF-4F02A603-57180E3599F1#page/1.

Корнилов О.А. Языковые картины мира как производные национальных менталитетов. 2-е изд., испр. и доп. – М.: ЧеРо, 2003. – 349 с.

Красных В.В. Этнопсихолингвистика и лингвокультурология: курс лекций. – М.: ИТДГК ”Гнозис”, 2002. – 284 с.

Краткий словарь когнитивных терминов / Под общ. ред. Е.С.Кубряковой. – М.: Изд-во Моск. ун-та, 1996. – 245 с.

Куликова И.С., Салмина Д.В. Введение в языкознание: учебник для бакалавров. – М.: Юрайт, 2013. – 699 с.

Леонтьев А.А. Путешествие по карте языков мира. – М.: Изд. Дом Мещерякова, 2008. – 344 с.

Лыкова Н.Н. История языкознания в текстах и лицах [Электронный ресурс]: Учеб. пособие. – М.: ФЛИНТА, 2016. – 192 с. – Режим доступа: http://e.lanbook.com/book/84314.

Маслов Ю.С. Введение в языкознание. – М.: ACADEMIA, 2005. – 304 с.

Маслова В.А. Лингвокультурология: Учебное пособие для студентов высш. учеб. Заведений. – М.: Academia, 2001. – 208 с.

Мечковская Н.Б. Общее языкознание. Структурная и социальная типология языков: Учебное пособие для студентов филологических и лингвистических специальностей. – М.: ФЛИНТА, 2016. – 312 с.

Мечковская Н.Б. Общее языкознание: Структурная и социальная типология языков: Учебное пособие. – М.: Флинта; Наука, 2001. – 312 с.

Михалёв А. Б. Общее языкознание. История языкознания: Учебное пособие. – М.: Прогресс-Традиция, 2019. – 238 с.

Немченко В.Н. Введение в языкознание: Учебник для вузов. – 2-е изд., перераб. И доп. – М.: Юрайт, 2013. – 679 с.

Норман Б.Ю. Теория языка: Учебное пособие. – М.: Флинта, 2012. – 296 с.

Нурмөхәммәтова Р.С. Тел белеменә кереш (теоретик материаллар, тел турында кызыклы мәгълүматлар). – Казан: Ихлас, 2010. – 160 б.

Нурмөхәммәтова Р.С. Тел белеменә кереш: югары уку йортлары студентлары өчен уку-укыту ярдәмлеге. – Казань: Казан ун-ты нәшр., 2019. – 120 б.

Общее языкознание. Программа и методическая разработка отдельных тем для студентов факультета татарской филологии / сост. И.Б. Баширова. – Казань, 2003. – 56 с.

Паршина И.Г, Озерова Е.Г. Когнитивно-прагматические векторы современного языкознания. [Электронный ресурс]: сб. науч. тр. – М.: ФЛИНТА, 2014. – 512 с. – Режим доступа:: http://e.lanbook.com/book/51803.

Пятаева Н.В., Насипов И.С. Введение в теорию языка: Учебно-терминологический словарь для ст- тов. – Стерлитамак: СГПИ, 2001. – 170 с.

Пятаева Н.В., Насипов И.С. Введение в теорию языка: Учебное пособие. Рекомендовано УМО МОиН РФ. – Стерлитамак: СГПА, 2007. – 208 с.

Пятаева Н.В., Насипов И.С. К проблеме преподавания вузовского курса теории языка в сопоставительном аспекте на материале тюркских и славянских языков // Проблемы изучения и преподавания тюркской филологии: преемственность поколений: Сб. материалов Междунар. научно-практ.конф., посвящ. 80-летию академика М.З.Закиева и 10–летию кафедры татарской и чувашской филологии, Россия, Республика Башкортостан, г.Стерлитамак, 18-20 сентября 2008 г. / Науч. ред. М.В.Зайнуллин; Отв.ред. И.С.Насипов; Зам. отв. ред. И.С.Мансуров.– Стерлитамак: Стерлитамак. гос. пед. академия им. Зайнаб Биишевой, 2008.– С. 202-204.

Пятаева Н.В., Насипов И.С. О сопоставительном изучении в вузе курса теории языка // Сборник материалов Всероссийской научно-практической конференции. – Елабуга: ЕГПИ, 2002. – С. 24-31.

Реформатский А.А. Введение в языкознание. – М.: Аспект Пресс, 2004. – 536 с.

Рождественский Ю.В. Лекции по общему языкознанию. – М.: Высш. шк., 1990. – 381 с.

Рождественский Ю.В., Блинов А.В. Введение в языкознание. – М.: ACADEMIA, 2005. – 943 с.

Сафиуллина Ф.С. Тел гыйлеменә кереш. – Казан: Хәтер, 2001. – 383 б.

Сафиуллина Ф.С., Сәлимов Х.Х., Сәлимова Д.Ә. Тел гыйлеменә кереш. – Казан: 2000. – 126 б.

Сепир Э. Избранные труды по языкознанию и культурологии. – М.: Прогресс, 1993. – 654 с.

Степанов Ю.С. В трехмерном пространстве: Семитотическике проблемы лингвистики, философии, искусства. М., – 1985. – 335 с.

Степанов Ю.С. Константы: Словарь русской культуры (Опыт исследования). – 1997. – 824 с.

Сусов И. П. Введение в языкознание. – М.: Восток-Запад, 2006. – 382 с.

Теория языка. Материалы к лекционному курсу: Учебно-методическое пособие / сост. С. А. Алексанова. – Славянск-на-Кубани: Филиал Кубанского государственного университета в г. Славянске-на-Кубани, 2018. – 127 с.

Фортунатов Ф.Ф. Сравнительное языковедение. – М.: Юрайт, 2018. – 220 с.

Хайруллина Р.Х. Фразеологическая картина мира: от мировидения к миропониманию. – Уфа: Изд-во Башк. ун-та, 2000. – 285 с.

Хроленко А.Т., Бондалетов В.Д. Теория языка: Учебное пособие. – М.: Флинта, 2012. – 512 с.

Шулежкова С.Г. История лингвистических учений: Учебное пособие [Электронный ресурс]: учеб. пособие. – М.: ФЛИНТА, 2017. – 405 с. – Режим доступа: https://e.lanbook.com/book/91594.

**Периодик басмалар**

Вопросы филологии. – URL: http://dlib.eastview.com/browse/publication/675/udb/4.

Вопросы языкового родства. – URL: http://dlib.eastview.com/browse/publication/39386/udb/4.

Вопросы языкознания. – URL: http://dlib.eastview.com/browse/publication/699/udb/4

Известия РАН. Серия литературы и языка. – URL: http://dlib.eastview.com/browse/publication/642/udb/4.

Известия Южного федерального университета. Филологические науки. – URL: https://elibrary.ru/contents.asp?id=34111235.

Tatarica. – URL: https://kpfu.ru/philology-culture/zhurnal-39tatarica39

Филологические науки. – URL: https://dlib.eastview.com/browse/publication/33866/udb/4.

Филология и культура. Philology and Culture. – URL: http://www.philology-and-culture.kpfu.ru/

**Интернет-ресурслар**

Базы данных компании «Ист Вью» [раздел: Периодические издания (на рус. яз.) включает коллекции журналов России: по общественным и гуманитарным наукам; по вопросам педагогики и образования; по информационным технологиям; по вопросам экономики и финансов; по экономике и предпринимательству; Статистические издания России и стран СНГ]: сайт. – URL: http://dlib.eastview.com.

Единое окно доступа к образовательным ресурсам: федеральная информационная система свободного доступа к интегральному каталогу образовательных интернет-ресурсов и к электронной библиотеке учебнометодических материалов для всех уровней образования: дошкольное, общее, среднее профессиональное, высшее, дополнительное: сайт. – URL: http://window.edu.ru.

КиберЛенинка : научная электронная библиотека [научные журналы в полнотекстовом формате свободного доступа]: сайт. – URL: http://cyberleninka.ru.

Научная электронная библиотека статей и публикаций «eLibrary.ru» [российский информационно-аналитический портал в области науки, технологии, медицины, образования]: сайт. – URL: http://elibrary.ru.

Научная электронная библиотека. Монографии, изданные в издательстве Российской Академии Естествознания [полнотекстовый ресурс свободного доступа]: сайт. – URL: https://www.monographies.ru/.

Федеральный центр информационно-образовательных ресурсов [для общего, среднего профессионального, дополнительного образования; полнотекстовый ресурс свободного доступа] : сайт. – URL: http://fcior.edu.ru.

ЭБС «Znanium.com» [учебные, научные, научно-популярные материалы различных издательств, журналы]: сайт. – URL: http://znanium.com/.

ЭБС «Университетская библиотека ONLINE» [учебные, научные здания, первоисточники, художественные произведения различных издательств; журналы; мультимедийная коллекция: аудиокниги, аудиофайлы, видеокурсы, интерактивные курсы, экспресс-подготовка к экзаменам, презентации, тесты, карты, онлайн-энциклопедии, словари]: сайт. – URL: http://biblioclub.ru/index.php?page=main_ub_red.

ЭБС «Юрайт» [учебники и учебные пособия издательства «Юрайт»]: сайт. – URL: https://www.biblio-online.ru.

ЭБС издательства «Лань» [учебные, научные издания, первоисточники, художественные произведения различных издательств]: сайт. – URL: http://e.lanbook.com.

Электронный каталог изданий Института языка, литературы и искусства им.Г.Ибрагимова АН РТ. – URL: http://www.antat.ru/ru/iyli/publishing/book/index.php

Электронный каталог Кубанского государственного университета и филиалов. – URL: http://212.192.134.46/MegaPro/Web/Home/About.

Электронный каталог научной библиотеки КФУ им. Н.И. Лобачевского. – URL: http://old.kpfu.ru/zgate/cgi/zgate?Init+ksu.xml,simple.xsl+rus

Энциклопедиум [Энциклопедии. Словари. Справочники : полнотекстовый ресурс свободного доступа] // ЭБС «Университетская библиотека ONLINE» : сайт. – URL: http://enc.biblioclub.ru/.

**Сүзлекләр**

Линвистический энциклопедический словарь / Гл. ред. В.Н. Ярцева. – 2-ое изд., дополненное. – М.: Большая Российская энциклопедия, 2002. – 709 с.

Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча тел белем терминнары сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1998. – 128 б.

Сәлимов Х.Х. Тел гыйлеме терминнары сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 143 б.

Татарча-русча-инглизчә тел белеме терминнары сүзлекчәсе / төз.-авт. Ә.Ш. Юсупова, Г.Р. Галиуллина, Р.С. Нурмөхәммәтова, Э.Н. Денмөхәммәтова. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2014. – 160 б.

ЭЧТӘЛЕК

**Сүз башы**........................................................................ 3
**Кереш**............................................................................ 5
Лингвистик фән буларак “Тел теориясе”.............................. 5
“Тел теориясе” курсының максатлары һәм бурычлары......... 6
Тел белеменең төп сораулары................................................. 9
Тел универсалияләре............................................................... 10
Тел белеменең башка фәннәр белән бәйләнеше.................... 11
**Тел белеменең кыскача тарихы**.......................................... 20
Борынгы классик филология................................................... 23
Урта гасырлар тел белеме....................................................... 26
Яңарыш чоры тел белеме......................................................... 31
XVII-XVIII гасыр тел белеме.................................................. 34
XIX гасыр тел белеме............................................................. 44
XX гасыр тел белеме............................................................... 55
XX гасыр ахыры тел белеме.................................................... 58
XXI гасыр тел белеме.............................................................. 61
**Тел белемендә мәктәпләр һәм юнәлешләр**........................ 65
Тел белемендә натурализм...................................................... 65
Психологик юнәлеш................................................................ 69
А.А. Потебняның лингвистик концепцияләре....................... 76
Тел белемендә логик юнәлеш................................................. 83
Тел белемендә яшь грамматикачылык.................................... 87
Мәскәү лингвистика мәктәбе.................................................. 94
“Сүзләр һәм әйберләр” юнәлеше. Лингвистик география..... 101
Неолингвистика....................................................................... 104
Тел белемендә эстетизм........................................................... 106
Ф. де Соссюрның лингвистик концепциясе........................... 110
Тел белемендә иҗтимагый юнәлеш........................................ 116
Тел белемендә структурачылык.............................................. 120
Прага лингвистик мәктәбе....................................................... 122
Глоссематика............................................................................ 125
АКШдагы дескриптив лингвистика........................................ 129
Телнең тамга (знак) теориясе.................................................. 132
Казан лингвистика мәктәбе..................................................... 141
XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы тел белемендә яңа фәнни юнәлешләр..................................................................... 171

Лингвокультурология фәненең барлыкка килүе..................... 173
**Иҗтимагый күренеш буларак тел**............................................... 187
Тел һәм җәмгыять....................................................................... 187
Телнең функцияләре.................................................................. 191
Тел һәм фикерләү....................................................................... 196
Тел һәм сөйләм.......................................................................... 202
**Дөньядагы телләр һәм аларны төркемләү**.......................... 216
Телләрнең генеалогик классификациясе................................. 219
Телләрнең типологик классификациясе.................................. 230
Телләрнең ареаль классификациясе........................................ 238
Телләрнең функциональ классификациясе............................. 243
**Тел белеменең методологиясе һәм методлары**................... 247
Тел белемендә гомумфәнни методлар..................................... 251
Тел белемендә хосусый методлар............................................ 252
**Әдәбият исемлеге**.................................................................... 256

*Уку басмасы*

**Замалетдинов** Радиф Рифкатович
**Нурмухаметова** Раушания Сагдатзяновна

# ТЕЛ ТЕОРИЯСЕ

**Уку-укыту ярдәмлеге**

Басарга кул куелды 24.03.2020.
Офсет кәгазе. Цифрлы басма.
Формат 60x84 1/16. Гарнитура «Times New Roman».
Шартлы басма табагы 15,35. Шартлы нәшр. табагы 12,75.
Тиражы 100 экз. Заказы 163/3.

Әзер оригинал-макеттан Казан университеты нәшрияты
типографиясендә басылды

420008 Казан, Проф. Нужин ур., 1/37
тел. (843) 233-73-59, 233-73-28